ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2010



# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

## 2010 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында



*Р. Зәйдуллин*



*Ф. Садриев*



*В. Федотов*



*А. Миңнуллина*



*И. Ханов*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, шулай ук Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән хезмәтләрнең югары сәнгати дәрәҗәләрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимен кабул итәргә һәм 2010 елда, искәрмә буларак, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге биш Дәүләт бүләген бирергә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Зәйдуллин Ркаил Рафаил улына**—«Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар» шигъри җыентыгы өчен, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел һәм «Ташка ордым башны: Хикәяләр, эсселар» проза әсәрләре җыентыгы өчен, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2008 ел;

2) **Садриев Фоат Миңнәхмәт улына**—«Бәхетсезләр бәхете» трилогиясе өчен, беренче китап—Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2001 ел, икенче китап—Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел, өченче китап—Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2007 ел;

3) **Федотов Владимир Сергеевичка**—төрле еллар (1995-2009 еллар) концерт программалары, шул исәптән «Дустыма», «Чарующие звуки баяна» («Баянның сихерле аһәңе»), төзегән һәм югары сәнгатьчел башкарган өчен;

4) **Миңнуллина Асия Минвәли кызына**—«В.Качаловка һәйкәл» һәм «Хәйриячегә һәйкәл» скульптураларын иҗат иткән өчен, Казан шәһәре;

5) **Ханов Илдар Мәнсәви улына**—Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында скульптура һәм монументаль-декоратив композицияләр сериясе, шул исәптән «Ату» («Расстрел») рельефы (Казан шәһәре), «Ватан-ана» һәйкәле, «Тормыш агачы» («Древо жизни» скульптурасы (Чаллы шәһәре), «Шигърият агачы» («Древо поэзии») скульптурасы (Тукай-Кырлай авылы, Арча районы).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль,*
*2010 ел, 23 апрель, № ПУ-282*

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

**5**
**(1051)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур., 2*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


Бу санда

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ**

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Фатих КӘРИМ. Ант. *Шигырьләр.* ... 5
Хисам КАМАЛОВ. Үлем куа килә. *Фронт истәлекләреннән.* ... 6
Рөстәм МИНГАЛИМ. Юллар... юллар. *Шигырьләр.* ... 44
Мәдинә МАЛИКОВА. Юкә чәчәк аткан чак иде. *Роман.* ... 48
Резеда ВӘЛИЕВА. Татар кызына. *Шигырьләр.* ... 73
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Тау артында кояш бар. *Роман.* ... 78
Рәниф ШӘРИПОВ. Ике шигырь. ... 121
Миңзифа ӘХМӘТШИНА. Язмышлар ярда кавыша... *Шигырьләр.* ... 125


**ТАТАРСТАН АССР ТӨЗЕЛҮГӘ 90 ЕЛ**


Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы турында декрет ... 35


**БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ**


Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре ... 37


**ЮБИЛЕЙЛАР**


Ким МИҢНУЛЛИН. Гыйлем йортыбыз бәйрәме ... 128


**ХӘТЕР**


Афзал Шамов – Гомәр Бәширов: фронт һәм тыл хатлары ... 142


**ФӘН**


Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ... 158
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ... 161


**ТАРИХ**


Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе ... 164


**ПУБЛИЦИСТИКА**


Рәфикъ ЮНЫС. Татар батырмы? ... 172


**СӘНГАТЬ**


Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Кыйммәтле хәзинә остасы ... 166


**АК ҖИЛКӘН**


Алисә ЗАРИПОВА. Бер телефон тарихы. *Хикәя.* ... 176
Туфан МИҢНУЛЛИН. Бәләкәй Туфан ... 178
Ким ШАКИРОВ. Ялгышлык бүләк иткән ачыш ... 183

«Казан утлары» архивыннан ... 76; 186
Безнең календарь ... 170
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Х. КАМАЛОВ. «Нас догоняет смерть» (фронтовые записи), романы М. МАЛИКОВОЙ «И сад был в цвету», Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ «За горою солнце»; стихи Ф. КАРИМА, Р. МИНГАЛИМА, Р. ВАЛЕЕВОЙ, Р. ШАРИПОВА, М. АХМЕТШИНОЙ.
«К 65 летию Великой Победы»: «Татарские писатели—участники войны».
«К 90 летию ТАССР»: Декрет об Автономной Татарской Социалистической Республики.
«Юбилеи»: статья К. МИННУЛЛИНА к юбилею Академии наук РТ.
«Память»: А. ШАМОВ и Г. БАШИРОВ: «Письма между фронтом и тылом».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.)
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения».
«Публицистика»: Р. ЮНУС. «Храбры ли татары?»
«Искусство»: статья Г. БАЙРАМОВОЙ к 80 летию музыковеда, профессора М. Нигматзянова.
«Белый парус»: рассказ А. ЗАРИПОВОЙ «История одного телефона».
Наш календарь.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Памятник меценату». Работа А. МИННУЛЛИНОЙ; народный писатель Хисам КАМАЛОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry: H. KAMALOV. «We are being caught up with death» (Frontline records), novels by M. MALIKOVA «And garden was in bloom», R. GABDULHAKOVA «Over the hill there is sun»; poetry by F. KARIM, R. MINGALIM, R. VALEEVA, R. SHARIPOV, M. AHMETSHINA.
«To 65th anniversary of Great Victory»: «Tatar writers and participants in war».
«To 90th anniversary of TASSR»: Decree of Tatar Autonomous Socialist Republic.
«Jubilee»: article by K. MINNULIN to anniversary of Academy of Sciences of Tatarstan.
«Memory»: A. SHAMOV and G. BASHIROV: «Letter between front and rear»
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages (continuation).
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«History»: A. HALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin.
«Journalism»: R. YUNUS. «Are Tatars brave?»
«Art»: article by G. BAYRAMOVA to 80th anniversary of musicologist, professor M. Nigmatzyanov.
«White Sail»: story by A. ZARIPOVA «Story of a phone».
Our calendar.
From photo archives of Magazine.
Diary of socio-cultural life.
On our covers: «Monument to Maecenas». Work by A. MINNULLINA; people's writer Hisam KAMALOV.

---

★ **Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
★ **Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
★ **Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.**

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 4.05.2010, график буенча 4.05.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–521. Тираж 4834.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

**«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2**

**© «Казан утлары», 2010 ел.**

Фатих
Кәрим

## Ант

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә—балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм!..

Бәлки, соңгы тапкыр күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.

Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!»—ди ул күңеленнән;
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм!

*1942*

Хисам
Камалов

# ҮЛЕМ КУА КИЛӘ

ФРОНТ ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН

Тышта мең тугыз йөз кырык икенче елның җәй урталары иде. Фронтларда канкойгыч каты сугышлар бара. Харьков юнәлешенә таба хәрәкәт итүче частьның бер пехота подразделениесе авылда ялга туктады. Көндез колонна белән бару куркыныч иде. Ә авыл шактый ярлы, шалама күренә. Түбәсе салам белән япкан ихатасыз саман йортлар. Шулай да тыштан акшарланган. Тәрәзә капкачлары яшелгә буялган. Йорт артында озын балак сыман бәрәңге бакчасы. Тыкрык башында кое сиртмәләре калгый... Һәр йортка өчәр-дүртәр кызылармеец урнаштырганнар иде. Солдатны, билгеле, өй ризыгы, сөт-катык кызыксындыра. Әмма өметләр акланмады. Авылда бер сыер малы да юк икән. Кайбер хуҗалыкларда кәҗә-сарык ише вак мал гына. Ул да түгел, кешеләрнең ипи күргәннәре юк ди. Бәрәңге, яшелчә белән җан асрап торалар... Бу хәл бик тиз билгеле булды. Авылның тышыннан ук моны чамаларга мөмкин иде.

Вакытлыча батальон командиры итеп билгеләнгән лейтенант Томилин үз штабы белән колхоз идарәсенә урнашкан иде. Идәнгә сузылып ятып ике-өч сәгать черем итеп алды. Ул уянып чыкканда кояш шактый күтәрелгән, идарә лапаслары өстендә карга-чәүкә өере чыркылдаша. Шунда урамның каршы ягындагы киртә буена күзе төште. Анда балалар тезелеп утырган. Гаҗәп, бер тавыш-тын юк, уйнамыйлар, буталмыйлар. Тын гына күзләрен идарәгә терәгәннәр. Бу ни хәл? Нишләп бирегә килеп тезелгәннәр? Колхоз хисапчысы, чыра кебек озын хатын, аңлатты: болар, диде, әтиләре сугышта үлгән ятимнәр. Күрәсездер, алар ач. Ябыгып, тәмам шәүләгә әйләнеп баралар. Куллары кашык сабы юанлыгы гына. Нигә колхоз тәэмин итми дисезме? Иген уңмый, булганын кырып-себереп хөкүмәт алып бетерә. Сугыш якынлаша башлагач, нәчәлниклар, партиеслар качып киттеләр...

---

Хисам КАМАЛОВ (1926) – *Татарстанның халык язучысы; «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым», «Туләнмәгән куз яше» һ.б. купсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

Болар сугышка чаклы действительный хезмәттә бушка ашап, бушка киенеп, рәсми хәбәрдарлык буенча тормышны ал да гөл дип беләләр иде. Авылның чын хәлен күргәч, гаҗәпкә калдылар. Ачы хакыйкать аларның аннарын үткен кыры белән сыдырып үткән кебек булды. Шулай да гадәттәгечә эчтән тындылар. Әмма детдомда үскән Томилин алай дәшмәү артына поса торган түгел иде. Бу хәлгә чынлап борчылды. Ул урта буйлы, кинчә сөзәк инле подполка итеп алдырган саргылт чәчле башына пилоткасын кырынрак кигән. Көрән томса чыраенда карарчанлык чагыла. Чыбык кисәге белән үзенең кирза кунычына суккалап әрле-бирле йөренә. Ул, баскыч култыксасына таянып, тәмәке көйрәтүче иптәшләренә карады.

—Бу балаларны ашатасы иде бит, ә?—диде пилоткасын мангаена табарак җайлап.—Ничек уйлыйсың, ә?

—Син акылыңдамы, ни чутына?—Түгәрәк тук йөзле юка күкрәкле комиссар Краснов авызын кыегайтып көлеп куйды. Үзен өстен куюын белгәнгә, Томилин аның көлүенә дикъкать итмәде.

—Базада «энзе» бардыр әле, ә?

—«Энзе»гә ягылырга кем рөхсәт итә? Ие!—дип штаб башлыгы какча чырайлы Чернов та кеткелдәп алды. Ул һәрчак төрттереп сөйләүчән иде. Чынлап та, буй җитмәү нәрсәгә үрелү унайсыз хәлгә куя. Шулай да Томилин тынычланмады... Болар өчесе дә күптән түгел генә югары постка билгеләнгән лейтенантлар. Һәрберсенә звание кадерле. Шуның өстенә өчесе дә яшьләр иде. Уставтан аз гына читкә тайпылуны бик тиз сизәләр һәм үрә торалар. Аннары холык-фигыльләрендәге очлы почмаклар кыршылмаган, һәр эштә төртеп чыга иде.

Мондый очракта Томилинның ятып калганчы атып кал дигән тәвәккәллек этәргече бар иде. Шуны исенә төшерде дә, полк штабына барырга булды.

—Йөрмә,—диде Краснов боеручан тавыш белән. Ул Томилинның детдомдагыча үзен иркенрәк тота торган гадәтенә һәрчак каршы төшә иде. Бу аның вазифасыннан да килеп чыга. Ник дисәң, комиссар комбатны бераз йөгәнләп тоту өчен куелган. Часть йөзенә кызыллык китерерсең! Үзен яклаганны көтеп Черновка башын борды. Әмма тегесе эндәшмәде. Кайчак Томилинның кушканга каршы килү балалыгы да үзен сиздерә иде. Ул Красновны тыңламау рәхәтлеге кичерә-кичерә штабка китте. Эре-эре атлавында үҗәтлек беленә иде.

Әллә ни озак вакыт үтмәде, юраганы юш килгәнме, ике тәгәрмәчле, зур казан куелган арбага җигелгән ат идарә каршына килеп туктады. Томилинның хезмәттәшләре әллә күзебезгә күренәме дип шаккатканнар. Ул: «Кичә кич миномет ротасы килеп җитмәгән. Бүген дә юк. Ужинга пешерелгән ботка шул килеш калган. Башка подразделениеләргә тәкъдим иткәннәр, ләкин көне буе эсседә әлсерәп килгән солдатларның тамагыннан берни үтми, бары чәй генә сораганнар ди. Ботка тәмам куерып, каты хәлгә килгән»,—дип аңлатты.

Повар, кәкре борынлы яшь кенә әрмән, казанның өстен ачты. «Айда, налетай!»—диде ул каты акцент белән. Балалар дәррәү кузгалдылар, шыбырдашу, чыр-чу китте. Теге хисапчы хатын килеп тәртип урнаштырды, кайсыларын савыт алып килергә йөгертте.

Гәрәбәдәй сары, итле тары боткасын повар ниндидер фанер соскы белән кисеп-кисеп алып өләшә башлады. Ыгы-зыгы тынды. Карчык-корчык та кофталарына коштабак яшереп килә иде. Кузла астындагы капчыкта җидесигез буханка ипи бар икән. Повар аларны да чыгарды. Хисапчы хатын өлешләргә бүлеп бирә торды. Томилин баскыч култыксасына сөялеп күзәтте. Ботка, ипи кисәге эләктергән балаларның йөзләре нур белән яктыруын күрү күңеленә май булып ята иде.

Идарә эчендә бу тамашаны тәрәзәдән карап торган комиссар, командирлар шыпырт кына сөйләшә. Бигрәк тә төлке чырайлы, бер күзен кысып карап торган рота командиры Тарутин учакка май сала:

—Комбат әкәмәтләр күрсәтә,—диде ул башын Красновка таба кыегайтып. Чөнки комиссар белән комбатның борчаклары пешмәвен яхшы белә иде.—Моны дөрес аңламаулары мөмкин.

—Төймәдән дөя ясарга безгә бир...—Чернов Томилинның бу кыланышын эчтән хупласа да, комиссарга ярарга тырышып шулай әйтте.

—Рапорт язам,—диде Краснов ничектер катгый итеп.

—Йә-йә, бик кызма әле син!—дип Чернов аны дуамалланып китүдән тыярга итте. Аңа комиссар белән комбат арасында буферлык ролен уйнарга туры килмәде.

Ботка, ипи өләшенеп беткәндә генә бер өшәнгән озын буйлы бөкре карт күренде. Томилин повар янына килеп ялынырга тотынды. Әрмән як-ягына каранды һәм каяндыр ярты буханка ипи табып чыгарды. Лейтенант, синең өчен генә, ди,—ди ипине картка сузды. Карт башын ия-ия рәхмәт әйтте.

Кояш горизонт артына төшкәндә подразделениегә походка кузгалырга дигән боерык килде. Бик тиз җыйналып юлга чыктылар. Командирлар колонна алдында атлыйлар.

Төн урталары житәрәк ике кызылармеец хәлләре бетеп юл өстенә егылды. Икесе дә юка гәүдәле, эчкә баткан күкрәкле, маерык кыяфәтлеләр иде. Симулянтлар, диде Краснов һәм алар янына килеп:

—Встать!—дип команда бирде.

Тегеләр торырга тырышып иңнәрендәге скаткалары эченнән башларын суздылар. Әмма тез буыннары тотмый, хәлсезлек үзенекен итә. Хәйләлиләр дияр идең, йончыганлыклары йөзләренә чыккан. Ниндидер авырулары бар, ахры. Көнбатыш Украинадан килгәннәр симулянтлыклары белән теңкәгә тиде. Болар каяндыр комлы-балчыклы яклардан булса кирәк. Анда икмәк унмый, бәрәңге дә кузы чикләвегеннән эрерәк кенә буа... Томилин берсенең мылтыгын үзе күтәрде, икенчесенекен Чернов алды. Хәллерәкләре тегеләрне ике яклап култыкладылар. Ничек тә привалга хәтле өстерәлергә кирәк иде. Кызылармеецлар ухылдый-ухылдый атлыйлар. Йа, Хода, болай ничек немец солдатларына каршы тора алырбыз? Эт үләксәсе кебек авыр мылтык. Аны җилкәдән салып, корып өлгергәнче немец сине әллә ничә тапкыр атып ега. Аның автоматы иңенә асылган, түтәсе кендектән өстәрәк, кул тидерү белән ата башлый. Гранаталары ыргыту өчен җайлы, каскалары башка уңайлы. Үзләре барысы да бертигез эреләр, тазалар. Аларга какао, шоколад бирелә икән...

Алгы сызыкка ял иткән, ныгыган кызылармеецларны гына куярга кирәк. Неужели шул хакта башларына килми? Инде елдан артык сугыш бара. Юкса болай ватандарлык хисе, энтузиазм белән генә дошманга каршы торып буламыни?

Таң атканда алгы сызык якынлашканы сизелә башлады. Бомба, снаряд шартлаулары тонык кына ишетелә иде. Эчкә шом тула, киеренкелек арта, солдатлар эчләренә йомылганнар. Подразделение бер куе урманлыкка кереп яшеренде. Кызылармеецлар хәлдән таеп җиргә аудылар, агач төбенә башларын төртеп күзләрен йомдылар. Томилин теге хәлсезләрне санчастька урнаштырырга тырышып чапты, әмма эше барып чыкмады. Санчасть бик арттa икән, шулай да полкның азык-төлек олауларына төртә алды. Аннары шинелен башына каплап, куе үлән өстенә сузылды, шул минутта ук йоклап та китте.

Күпмедер ятканнан соң, ерактагы шартлау тавышына «дерт» итеп уянды. Шинелен ачып, башын күтәрде. Юлдан берничә бричка яралылар төяп кайтып бара иде. Арттагы икесенең өстен торбоша белән япкан. Димәк,

кайтканда авыр яраларыннан үлгәннәр. Торбоша кырыеннан бер мәетнең яшь кенә зәңгәрсу битле йөзе күренә. Чыраенда бер җыерчык юк, ул газап кичермичә генә үлгән, ничектер барысыннан котылып, иркенләп йоклап киткән төсле иде. Көн туып килә, ә ул дөньядан киткән. Бу көн аның башына туган икән! Хәер, кем башына кайчан көн туасын беркем бер кайчан белә алмый инде.

Марш-бросок белән тагын бер ыргым ясап, төн урталарында тиешле квадратка барып життеләр. Урман белән капланган биек булмаган тау буе икән.Тау итәгеннән аз гына арырак—коры елга чокыры сузылып китә. Позиция тагын да ары булырга тиеш. Томилин елгыр күренгән өч кызылармеецны алны тикшерү өчен җибәрде. Алар моны бик тиз башкардылар. Анда төз кыр икән, баш төртер түмгәк тә юк. Томилин рота командирлары кече лейтенантлар Тарутин һәм Папашин белән тиз генә киңәшеп алды да оборонаны шушы коры елга чокыры буенча урнаштырырга кирәклеген әйтте. Бигрәк тә ерганакның тауга перпендикуляр формада сузылуы бик унай булып тоелды. Тарутин үзенең ротасын алып ерганакның уң тарафына юнәлде, Папашин—икенче ягына. Монда траншея казып чиләнәсе түгел, ерганак ярларына бары окоплар казып кирәсе. Аннары тауның уң ягыннан тирән яр бу ерганакка кадәр сузыла. Элемтә өчен уңай булачак. Чөнки тау башында урманда җәйге ферма корылмалары бар иде. Полк штабы шунда урнашачак диделәр.

Тау буеннан төшкән тирән ярның урман бетеп вак куаклыкка әйләнгән җирендә Краснов белән Чернов батальон штабы өчен блиндаж хәстәрен күрәләр булыр.

Сәгатьтән артык вакыт үттеме-юкмы, кызылармеецлар ярны ишеп-казып һәрберсе үзенә окоп әзерләп өлгергән иде. Мылтыкларын хәрби әзерлеккә, бруствергa җайлап куйганнар. Томилин төн яктырганчы башны җиргә яшерергә өлгермәбез дип бик курыккан иде. Хәзер эченә җылы керә башлады... Ул бурыч кешесе, үзенә эшләргә тиешлене җиренә житкермәсә, тынгылык тапмый... Станоклы пулеметларны җайлырак урнаштыру кирәклеге исенә төшеп, шуларны күздән кичерергә булды. Ерганак буенча Тарутин кызылармеецлары билгән якка атлады. Әйе, бер дә иренми эшләгәннәр. Окоп ячейкалары комырык кына түгел, бөгелми-нитми үз буеңа басып торырлык. Солдат шинеленең якасын күтәргән, кечкенә башы пилоткага сыеп беткән, пулемет гашеткаларын җайлап маташа иде. Комбатны күргәч, якасын төшерде. Дары исе татыган кеше икән.

—Нишләп бик тын, әллә берәр тозакка килеп кердекме?—дип шикләрен белгертәсе итте. Томилин үзе дә тәгаен генә белми иде, шулай да шикне бетерергә кирәк дип уйлады.

—Без ике дивизия арасына туры килдек,—диде ул ышанычлы тавыш белән.

—Юкса кыш көне немец безне үзенең тылында калдырып кырык чакрым алга китеп барган иде,—дип солдат сүзен ялгады. Унбиш тәүлек буе көне-төне хәрәкәт итеп, үзебезнекеләргә чыгып кушылдык.

—Пулемет урынын бераз тирәнәйт!—Томилин боерык тонын кушмыйча әйтте.—Болай бит мишень кебек.

—Так так, иптәш командир, үзем дә төзәтеп маташа идем.—Ул каударланып көрәге белән казый башлады.

—Станкач бер ноктага текәп атарга көйләнмәгән, шуна көпшәнең ничек торуы мөһим. Болай синең пулялар немецларның баш очыннан үтә...

—Так точно, иптәш командир, моны онытып торам икән, теомать!—Ул пулеметы белән хәстәрләнергә тотынды. Томилин икенче ячейка-окопларга күчте.

Ул күккә карады, карангылык сизрәп, яктырып килә шикелле. Әмма бар җирне куе томан сарган. Әллә томан, әллә төтен, кайдадыр урманмы, авылмы янмый микән?

Ерганак—яр буенча йөреп, сугышчыларның корал, хәл-әхвәлләрен барлап чыгарга өлгермәде, аны полк штабына чакырып вестовой килде. «Нәрсә бар икән?»—дип тәшвишләнде Томилин. Әллә яна комбат билгеләделәрме, һаман көтелгән пополнение килгәнме? Әллә берәр гаебем табылганмы? Краснов белән Чернов роталарның ничек урнашуын тикшерергә тау буендагы коры сызадан төшеп киләләр. Томилин тиз-тиз аңлатты: «бик җайлы оборона булдырылды,—диде.—Әмма солдатларны безнең алда үзебезнекеләр булу-булмау, юкмы мәсьәләсе борчый. Шуны берәр ничек ачыклый алмассызмы?»

Полк штабы тау өстендәге кардада ике таш корылмага урнашкан. Тәрәзә пыялалары коелган берничә бүлем. Плащ-палатка пәрдәле бүлемдә полк командиры Чмут Лев Андреевич. Ул уртадан калку буйлы, какча гәүдәле, нык муенлы, җил ашаган карангы авыр чырайлы. Эчен нидер кимереп тора шикелле. Башын сул җилкәсенә авыштырып йөри. Яра галәмәте булса кирәк.

Томилин уставча доложит итә башлаган иде, Чмут кул ымы белән туктатты. Өстәл артыннан чыкты да аның каршына атлады. Калай лампадагы ут теле бер якка сөрлегеп янды. Шунда бүтән подразделение командирлары да килеп бастылар. Томилин, оборона дошман утын кайтару өчен уңайлы итеп төзелде, диде. Чмут солдатларның мораль-матди хәле турында белеште.

—Дүрт көнлек сухой паек тулысынча биреллеме?

—Төгәл үтәлде, иптәш майор!—Томилин җыелган командирлар каршында бераз каушап калды.

—Каскалары бармы?

—Ул як ярый, әмма автоматлар бик аз...

—Көне-сәгате белән пополнение килеп житәргә тиеш,—диде майор, икеләнергә урын калдырмаган тон белән.

—Танкка каршы батареялар кайчан булыр?—Төркемнән бер лейтенантның башы сузылды.

—Башта безгә бүген үк ПТР ротасы килеп кушылырга тиеш. Аларны взвод саен пехота белән аралаштырып урнаштыру ротныйларга йөкләтелә...—Чмут башын турайтты.

—Комплектование булырмы, юкмы?

—Ул хәлне һаман вәгъдә белән сузалар,—диде Чмут эчке бер ачу белән, теше сызлаган кебек уртын чәйнәп торды, янагында бүлтәймәләр селкенгәләде.—Ярым-йорты подразделение бирделәр. Син булдырасың дип аркадан кагып. Һаман шул кыерсыту инде, валлаһи! Сугыш башлангач кына чыгардылар да әйттеләр: Ватан өчен сугышта гаебеңне юып аклан, имеш! Нинди гаеп? Дәшмиләр. Шуның күләгәсе башка төшә. Миңа—ярар, минем кул астындагылар ни өчен интегергә тиеш?! Безгә дигән ике миномет ротасы һаман юк. Без артиллерия батареяларына беркетелергә тиеш—бергә яу алып бару өчен! Ул да вәгъдә генә булып калды. Тапланган биография белән командалык итү гаять кыен. Санга сукмыйлар. Эте дә, бете дә сине кыерсыта. Отпор бирергә хакың юк. Биографияңне күзгә төртәләр...

Аны бер интендант бүлдерде.

—Лев Андреевич, ул хакта зарлану мәгънәсез,—диде ул йомшак кына итеп.

—Әйе, чын, мәгънәсез!—Чмут шунда ук килеште.—Миңа әйттеләр: сиңа «дөреслек жене» кагылган, төп бәлаң шул, имеш!—полк командирының

тугрылыгы кайберәүләрнең ачуын китерде, каш җыерып, иреннәрен кыстылар. Ләкин эндәшмәделәр. Чмут гозерен белдерде:

—Иптәш командирлар, сезне аз беләм, җаваплылыкны аңлавыгызга ышанам. Шушы рубежда дошманны ике-өч тәүлек кенә тоткарларга кирәк. Көчле коралланган берничә дивизия килеп җиткәнче, дошманның борынына сугарга, алга ыргылырга бирмәскә. Бары ике тәүлек. Теләсә нинди чаралар белән!.. Шунда теге интендант аның җиңенә тотынды. Чмут башын борды һәм алар ширма артына шыкайдылар. Анда радист элемтәгә кереп, кычкыра, сүгенә иде. Чмут тагы да караңгы авыр чырай белән чыкты һәм командирларга үз подразделениеләренә ашыгырга боерды.

Өйлә җиткән икән инде, ә көн һаман ачыла алмый. Болытлар агылып тора. Зәңгәрсу-күгелҗем горизонтта ут-ялкын чаткылары яшен кебек сызылып-сызылып китә. Бомба шартлаган тавышлар куе томан эченнән шомлы булып ишетелә. Полк командирының эчендәге серләрен чыгаруы Томилинда икеле-микеле тәэсир калдырды. Нәрсәгә дип ихласлык итәсе килде? Үз кул астындагыларда ышаныч казану өченме? Барча нәрсә аста, яшерен булган җирлектә эчкерсезләнү ахмаклыкка тиң бит?..

Штабтан төшеп килгәндә элемтә кабеле сузучылар очрады. Безне сезнең батальонга билгеләделәр, блиндажыгыз әзерме?—дип төпчеделәр. Ярны ишеп, бер накатлы гына итеп эшләнгән блиндажны хозвзводның өч солдаты өлгертеп ята иде. Уртада ара, як-ягын җир сәке итеп әмәлләгән. Яктылык ишектән генә төшә. Элемтәчеләр яшел тартмалы аппаратларын ишек катына куйдылар, заземление ясадылар.

Бу эшкә канәгать булып, Томилин тау итәгендәге ерганак буенча урнашкан сугышчыларын тагы бер кат күздән кичерергә исәпләп, аска таба бара иде. Кинәт томан эченнән Чернов белән комиссар калкып чыкты. Күз аклары ялтырый, чырайлары кара янган. Ни бар тагын? Алар бик хәвефле хәлне әйттеләр: ротный Тарутин һәм тагын дүрт кызылармеец үз урыннарында юк. Таң алдыннан гына позициядә булмаулары беленгән...

—Юк, булмас!?—дип ышанмады Томилин. Әллә мушкага алалармы дип йөзләренә якын килеп күзәтте.

—Булган, утырган да шуган шул менә!—Чернов папирос кабызды. Алар бер-берсенә туры карарга базмыйча басып торалар. Өч җаваплы кеше. Җаваплылыктан кем тайпылыр, кем үз өстендә тояр? Краснов нииндидер хаклылык белән сүз башлады:

—Томилин, исеңдәме, Көнбатыш Украинадан килгәннәрне алгы траншеяга куярга ярамый дип кисәткәнем, ә?

—Мәгънәсез кисәтү иде, мин аларны кая куйыйм ди. Хозвзводта җыен аксак-туксак,—хезмәттәш иптәшләренең җаваплылыкны үз өсләреннән шудырырга маташуы Томилинның ачуын кузгатты.

Тарутинның эчендә черек барлыгы бер дә сизелмәде, теомать! Чернов тәмәке төпчеге белән җиргә төкерде. Аның шактый шөбһәгә төшкәнлеге күренә. Икесе дә карьералары өчен шүрлиләр булыр. Күптән түгел звание алып, башлык булдылар. Башлык булу ләззәте иптәшлекне аста калдыра шул.

—Краснов, син дә бу хәлгә әзрәк җаваплы түгелмени?—Томилин кызып китте.

—Комиссарны тыңламыйча устав бозганың өчен җавап тота алмыйм, гафу ит!—Ул тагы үзен гаепледән тизрәк аерып куярга ашыкты.

—Кискен моментта хезмәттәшен ташлаган син үзен—Тарутин кебек! Гафу ит, имеш! Сата да, аннан гафу үтенгән була. Түбәнлек бу!—Томилинның тамагына ачу төене утырды. Ул тамагын кыргалады.

—Комбат, эчкә кермә, бик куертма әле.—Чернов икенче папиросын

авызына капты. Ул араны йомшартырга азаплана иде шикелле.

Тарткалаша-бәхәсләшә полк штабына менделәр. Анда ыгы-зыгы. Бер төркем интендантлар балык өере кебек бер бүлемнән икенче бүлемгә күчә. Тышта штаб башлыгы, монда Углов каты-каты боерыклар кычкырып ала. Томилинның эченә җылы керде: Углов каты куллы, тәртип урнаштырачак. Мут холык фигыле белән йомшак күренде. Интеллигентлыгы да сизелә иде. Командир өчен куркыныч сыйфатлар, дип уйлады ул. Әллә пополнение килде микән, биредә халык ишәйгән. Әмма ПТРчылар күренми, һаман килеп җитә алмыйлар микәнни?

Алар алгы бүлемнән үтеп икенче бүлемдәге чатыр алдында тукталдылар. Аның артыннан вестовой башын сузды да эчкә борылды. Ашыгып, кинәт майор Чмут каты атлап болар каршына килде. Майорны алыштырганнармыни, баягы салкынлыгы беткән, ярсулы кыяфәттә иде. Ул барысын да белә икән, кай арада житкергәннәрдер. Начар хәбәр жир астыннан йөри ди, хак, ахрысы.

—Комбат, кече лейтенант һәм дүрт кызылармеец кайда?—Чмутның тавышы коры һәм янаулы иде.

—Төгәл генә белмибез, иптәш майор...—Томилинның каушаудан тамагы карлыкты, ул авызына йодрыгын китереп ютәлләде.

—Сугышчы 3-4 сәгать позициясендә булмаса, ул дезертир санала. Комиссар Краснов моны беләме?—Чмутның тавышы тагы да кырысланды, яңагында «кабырга»лар беленеп-беленеп китә иде.

—Иптәш майор, эш болай,—дип Краснов бар зиһенен туплады.—Комбатны мин башта ук кисәттем, Көнбатыш Украинадан булганнарны алгы сызыкка куярга ярамый, дидем.

—Мәгънәсез кисәтү, иптәш майор...—Томилин бераз үзен кулга алырга өлгерде.—Кисәтү ансат, ә шуны ничек реальләштерергә? Хикмәт шунда, мин аларны кая куйыйм? Хозвзводта нестроевойлар.

—Син аларны якладың,—дип, Краснов чөйгә тукмак белән суга башлады.—Бер нигезсез кешегә шикләнеп карау ярый торган эш түгел, дидең.

—Әйе, алар шат күңелле, эшлекле егетләр иде. Тынлаучаннар, ничек ышанмыйсың ди...—Томилинның бу акланулы Чмут янындагылар чыраенда көлемсерәү тудырды.

—Комбатның политик сукырлыгы бу,—диде вестовой. Чмут аның үз эшенә катнашуын хуплый иде кебек. Шунда ук тәгаен карарга килгәнлеге йөзенә чыкты.

—Лейтенант, сине командирлыктан читләштерергә мәжбүрмен,—дип, ул тагын кемнәргәдер ымлады. Тегеләр Томилинга ташландылар һәм пистолетын каерып алдылар. Майор уң ягына бөтен гәүдәсе белән борылды да, бер таза гына жилкәле хәрбигә төбәлде.

—Лейтенант Корунный, пехота батальоны командиры итеп билгеләнәсез!—диде. Теге каушап, агарынып китте. Аннары майор комиссар Красновка текәлде: —Син үз вазифаңда каласың! Живо, приказны үтәгез!—Шул мәл майорны бер интендант беләгеннән тотып ширма артына алып кереп китте. Краснов кинәт югалып калгандай булды, кулы калтыранды, кесәсеннән нindидер кенәгә табып чыгара алмый маташты. Ниһаять, тапкач, ширма артына шыкыды. Аннан штаб башлыгы белән бергә бу якка атладылар. Краснов аңа нindидер документ сузды. Штаб башлыгы сукыр лампа яктысына иелеп документны карады да, хәерхаһ төстә:

—Эшләп тор, аннан карарбыз,—ди-ди кире ширма артына чигенде. Краснов теге кенәгәне куен кесәсенә көчкә салды, нишләргә белми, битләре бер агарды, бер күгәрде. Кыр сумкасын бер ачты, бер япты.

Пистолет кобурасын учы белән сыпырды. Бер нияткә килә алмыйча иләсмиләс тора иде. Томилин ягына күз дә ташламады, әйтерсең, ул биредә юк. Сизелеп тора, алгы линиягә бармас өчен бер-бер әмәл, жай эзли. Менә аның йодрыклары төйнәлде, хәлиткеч мизгелне ычкындырмас өчен йөзен ертып икенче бүлемгә кереп китте. Анда особый отдел башлыгы капитанны эзләп тапты. Краснов әнчекләнеп, теге кенәгәне аңа төртте. Капитан ут яктысына килеп карады да: «Әһә, әһә», дип торды. Теге яктан бер комсоставны чакырып чыгарды.

—Лейтенант Мизин, беренче батальонга комиссар итеп билгеләнәсең!—дип боерды.

—Иптәш капитан, мин үз частемны көтәм,—диде теге тотлыгып.

—Отставить! —капитанның тавышында тимер катысы иде.—Син Корунныйны яхшы беләсең! Всё!—Ул гәүдәсе белән каерылып берәүгә тагын боерды: —Порученең, комиссарны подразделениегә илтеп куй!

Мизин исә хәлнең кинәт шундый борылыш ясавына әзер булмаган, таяныч эзләгәндәй як-ягына каранды. Алгы линиягә бару һәрчак бик авыр инде, кай кешене шөбһәгә төшерә. Ул һаман кузгала алмый тора. Порученең жиңеннән килеп тоткач, сискәнеп китте кебек. Ул лейтенантны тартып алып чыгып китте. Ә Красновның чырае яктырган. Арка бөкресе турайган. Бая сыгылып төшкән иңнәре күтәрелгән. Ләкин шатлыгын яшерергә тырыша, боеккан булып стенага сөялгән. Комиссарлар особистлар штатында сынала булса кирәк. Тыштан берничә особист елт кына кереп Чмут ширмасы артына чумды. Нәрсә булган? Батальоннан тагын өч кызылармеец качкан икән. Менә сиңа мә! Моны аю гәүдәле особист сержант Томилин янына килеп белдерде. Нииндидер ачыш ясаган шикелле дулкынланган иде. Ул аны жилтерәтеп тотып пәрдә артына алып керде. Анда өстәлдә калай сукыр лампа яна. Чмут картага килеп карандашын кәкре-бөкре кызыл, зәңгәр сызыклар буенча йөртә. Штаб башлыгы Углов исә аның белән килешмичә каршы әйтеп, үзенең дәлилләрен тезә иде. Особист Чмутка доложить итте. Теге башын күтәрде, карандашын ачу белән өстәлгә бәрде.

—Подразделениене таркаттың, сукин сын!—дип жикерде Томилинга карамыйча. Аның муен тамырлары уклау юанлыгы кебек булып кабарды.—Протокол языгыз! И в особый отдел! Всё!—Ул, кулын кискен селтәде дә, картага иелгән штабистлар белән сөйләшә башлады. Особист Томилинны элеккеге бүлемгә алып чыкты, такталардан тиз генә кулдан өстәл сыман нәрсә корыштырганнар. Керәчин салган шешәгә пилтә куйган лампа яна. Әллә каян Краснов килеп керде һәм өстәл янына тезләнде.

—Мина протокол язарга кушылды,—диде ул, кыр сумкасын чырт-чырт ачып-ябып. Үзе Томилиннан карашын яшерә иде кебек. Томилин дәшмичә түзә алмады.

—Краснов, намусыңа кил әле, без икебез дә жаваплы түгелмени?—диде ихлас тавыш белән. Краснов башын күтәрми генә кәгазьләрен кыштырдатып сөйләнде.

—Намусны куй инде, хәзер намус урынына принцип. Неужели сизенмисең? Менә, әйтик, нейтралкада рус һәм немец яраланып яталар ди. Рус жәлли, немецның ярасын бәйләшә. Ә немец исә үлгәндә дә ярдәм итми, чөнки аңарда хис юк, принцип кына. Шуңа күрә ул жиңә. Безгә исә жиңү өчен дошманның үз коралын үзенә юнәлдерергә кирәк. Принцип сакларга, шунсыз дошманны дөмектерә алмаячакбыз. Менә шул. Ә жаваплылыкка килгәндә, ачык булсын, мине комиссар итеп раслап өлгермәгәннәр, икенчедән, сине куркыныч турында кисәтүем рапортта әйтеләчәк. Язма дәлил.

—Үзең бая яңа комбат янына комиссар булып барудан баш тайдырдың,

ә? Нигә куак артына постың? Чөнки алгы сызыкка барудан курыктың, артыңны юешләдең! Син фактта позицияне ташлап качучы чын дезертир! Ләкин бик шома, эз калдырмыйча качтың. Һе!

—Эх, Томилин,—дип Краснов аны кызганган тавыш белән бүлдерде.—Синең сүзләреңнән хәзер берниндәй бәясе юк. Ник зерәгә маташырга? Хәлләр шундый борылыш алган икән, аны кире кайтарып булмый...—Ул югарыдан торып, хәтәр хәл үткәнне тойган иркенлек һәм нахаллык белән сөйләде. Аның йөз ертуын, намуссызлыгын күреп Томилинның йөзе сүнде, өметен өзеп читкә карады.

Өлкән особист Красновка ышанмады, протоколны үзе язды. Краснов кайбер сүзләр кыстыргалады. Язып бетергәч, укып чыкты да кул куярга Томилинга сузды.—Юк,—дип баш чайкады тегесе.—Бу гадел түгел, мин килешмим, рапорт язам!

—Дөрес, брат,—диде особист.—Анда үзләре хәл итәрләр!—Ул кәгазь битләрен тәртипкә китерде дә тизрәк китү ягын чамалады. Аның артыннан шым гына Краснов та кузгалды.

Тышка күз салса, инде караңгылык сизрәп, көн тәмам яктырып беткән икән. Кинәт җир дерт итте, аннары каты шартлау тавышы колакны ярды. Аннан тагы бер-бер артлы шартлаулардан җир чайкалды, аяк асты шуып-шуып киткән кебек була иде. Бүлем эченнән Чмут һәм ияк асты салынган кызыл чырайлы, акай күзле штаб башлыгы атылып чыктылар. Мондагы сержант, кызылармеецларны алачык тирәли траншея казырга, круговая оборонага әзерләнергә приказ биреп куарга тотынды.—Марш! Марш! Көрәкләр, балталар, хозвзводка, тизрәк, тизрәк! Ни шагу назад! Без паники!—дигән боерыклар яңгырады.

Томилин да яр астында куе агачлыкка урнашкан хозчастька китте. Сүз әйтүче булмады. Каушау-куркудан кешеләрнең күзләренә ак-кара күренми, ыгы-зыгы купкан иде. Мондый чакта пистолет белән янаган каты приказ гына толпаны рәткә сала ала.

Сарай тышында кемдер пистолет тотып траншеялар казыта да башлаган. Эш бик тиз үрчи иде. Таза кешеләр эш чыгуга канәгать булган кыяфәттә җирне умырып-умырып алып өскә ыргыталар. Эш куркуны да онyттыра иде.

Алачыктан астарак ике каен уртасына полкның күзәтү пункты төзелгән булган. Аның өске накаты башына стереотруба беркетелгән. Чмут блиндаж күзе белән окулярга ябышкан. Тау итәгендәге алгы сызык—оборонаны күзәтә. «Ой-ой-ой! бетерделәр бит, нишләргә? Ах-ах-ах!.. Самолетлар астан гына очып гранаталар ташлый, пулеметтан сиптерә. Танклар!»—дип Чмут ыңгырашып куйды. Бер танк оборона траншеясының теге башыннан окопларны җимерә-җимерә килә. Окоптагы кызылармеец куркудан акыра-акыра каядыр качмакчы булып ыргылды һәм танк чылбыры астына эләгеп, балчыкка күмелде... Чмут бу мәхшәрне озак күзәтә алмады. Башын ике кулы белән учлаган килеш штабка атлады. Аңа каршы штаб радисты килә иде. Ул яман хәбәр әйтте:—Немецлар күптән Оскол шәһәрен алганнар. Без йөз чакрым дошман тылында калганбыз. Хәзер нишләргә инде?—радист аның белән янәшә атлый. Чмут ярым үле кыяфәттә бер сүз дәшми. Гүя берни ишетми, берни күрми.

Ул ширма артындагы өстәленә килеп капланды. Башын ике учы белән кочып утырды. Радист, штабистлар аңа сүз кушарга куркалар иде. Ә Чмут калын иреннәрен кыйшайтып авыз эченнән нидер мыгырдана:—Йа, хода! Бу ни хикмәт? Бу нинди корткычлык, әшәке хыянәт? Тагы алдадылар!—Аның аркасында калак сөякләре кыймыл-кыймыл килә. Эчтән күз яшен көчкә тыю галәмәте.—Нишләп безне һаман каһәрлиләр? Нигә намуслылар башына

каһәр ява?! Ватанга чын бирелгән фидакарьләрне агач атка атландыру бернинди киртәгә сыймый бит! Сыймый!—Ул кинәт калкынды, янында беркем дә юк иде. Пистолетын алды да чигәсенә китереп тәтесенә басты. Тоңык шартлау тавышы яңгырады. Чмут өстәл кырыена тотынмакчы булды, ләкин кулы ычкынып аска ишелеп төште. Өстәлгә кызыл буяу түгелгәндәй иде. Бүлмәгә интендантлар гөрләп җыелды... Чмутны күтәреп алдылар да өстәлгә сузып салдылар. Штаб башлыгы Угловны алып килделәр. Чмутны күрүгә ул аны тирги, сүгә башлады. Командирның үзен шулай итүе хыянәткә тин, диде. Башын селкеп торды. Ул нишләргә дә белмәде. Ачы тавышлар, яралыларның кычкыруы аны тышка өстерәде. Кинәт яралы кызылармеецлар бик күбәйде. Алар тазалар белән буталды. Кайберләре, яралыны саклаган булып, бу корылмадан чыкмау җаен карыйлар.

Томилин траншея казыган җирдән артык куерган ыгы-зыгыга аптырап эчкә керде. Кулында көрәк иде. Өстәл өстендә яткан полк командирының мәетен күреп телсез калды. Өстәл тирәсендәгеләр, «Күмәргә кирәк, күмәргә»,—дип кычкырыналар, ләкин бу эшкә алынырга берәү дә базмый кебек. Кемнендер боерыгын көтәләр булыр. Бар төштә каушау, паника. Ана кызны, ата улны белми иде. Шул мәл тау итәгендә немецлар көчле динамиктан:—«Русь, сдавайся! Вы окружены! Русь, сдавайся!»—дип кычкыра, ә урман аны хәтәр итеп яңгырата. Дулкын-дулкын кебек итеп башларга китереп бәрә. Мәетне нишләтергә белми басып торганнар кайсы кая пышан-пышан тайдылар. Томилин ялгыз калды. Кинәт теге бүлмәдән мыеклы таза старшина килеп чыкты. «Мин полкның завхозы,—диде—Лейтенант, зинһар, майорны җирләргә булыш...» Томилин, ана таба борылып, әзер икәнен белдерде...—Тәмам башны җуя яздым, теомать!—дип карганды завхоз. Аның каушаудан тавышы карлыккан, күкле-яшелле булып чыга иде. Полк байрагы минем җаваплылыкта бит, теомать! Дошманга эләксә, мина трибунал, теомать! Лев Андреевич әйбәт кеше иде. Ходай ярлыкасын инде, теомать! Мин яр астында кабер әзерләдем...

Старшина булдыклы куллы икән, җәсәдне күтәрергә җайлы итеп плащ-палаткага төрде. Икесе ике баштан тотып чыкканда алачыкта таза берәү дә калмаган. Өермә сыпырып алгандай булган иде. Тик авыр ярылылар гына кычкыра: «Братцы, не оставляйте! Братцы, помогите! Братцы, не для себя, для мамы, пожалейте!! Не оставляйте-е-е!..» Берәү хет килеп карасын иде...

Яр астына алып төшеп мәетне кабергә куйдылар. Баш очына байрак төреп бикләнгән кечкенә сейф та сыйды. Ашыга-ашыга балчык иштеләр. Кабер өстенә чыбык-чабык ташладылар... «Рәхмәт сиңа, лейтенант,—диде старшина, мыек өстеннән учын шудырып.—Иң курыкканым байрак иде, хәзер дошман кулына эләкмәячәк, теомать! Әйдә, минем ике атым бар, берсе сиңа! Ат белән җайлырак булыр.»

Өскә күтәрелделәр дә, бераз баргач, ике блиндаж янына килеп чыктылар. Агачлар арасында атлы арбалар икән. Старшина нидер шәйләп алга таба чаба башлады. «Стой! Стой!»—дип буыла-буыла кычкыра иде. Томилин килеп җиткәндә, ниндидер интендантлар атларны туарганнар да, атланып шылырга маташалар иде. Старшина бер ат башына тотынмакчы булган иде, аны бәрдереп киттеләр. Томилин өзәңгегә аягын тыга алмый маташканының тезгенен эләктерергә өлгерде. Теге атланды да: «Җибәр! Җибәр!»—дип акыра иде.

Томилин тезгенне ычкындырмый, ат алга өстери. Җайдак шәрран яра. Томилин абайламый калды, теге сул кулы белән пистолетын алды да атты. Томилин беләгенә каты итеп сукканын тойды, тезген ычкынды, ул җиргә егылды. Тәнен пешереп кайнар кан акканын сизгәч кенә яраланганын

аңлады. Җайдак күз ачып йомган арада юкка чыкты. «Мародерлар, сволочьлар!—дип сүгенде старшина. Томилинның сул җинен ертып төшерде, терсәк турындарак пуля тишкән ярага калын бинт куеп, өстеннән каты кысып бәйләде... Икенче бинт белән беләкне муенга эләктерде.—Моннан өч-дүрт сәгать элек кенә ышанычлы ватан сакчылары идегез, теомать! Курку адәм баласын ерткычка әйләндерә...»

Алар олаудан өр-яңа киемнәр алып рядовой булып киенделәр. Бу да бер саклану чарасы иде. Аннары вещмешокларга сохаридыр, консервыдыр тутырырга да онытмадылар. «Без бит инде пленда,—дип сөйләнде старшина.—Немец моннан йөз чакрымдагы торак пунктларын алган. Әмма без ул җанварның тырнагына эләкмәскә тиеш! Россия—очсыз-кырыйсыз. Һәр очракка әзер булырга, фамилияләребезне украинча куярга, без Көнбатыш Украинадан дип әйтергә кирәк.»

Төне буе бардылар, ату, шартлау тавышлары һаман озата килә иде. Гаҗәп, Томилин ярасы авыртуын тоймый диярлек. Куркудан, артык киеренкелектәндер инде. Кулының бармакларын кыймылдата ала. Димәк, сөяккә эләкмәгән, шуңа сызлавы да әллә ни түгел.

Старшина бу тарафларны бераз белә икән. «Моннан 30—35 чакрымда Шевардино авылы бар,—диде.—Килгәндә бер хозяйкада ике кич кундык. Ну, хозяйка ут хатын инде, теомать! Менә ул яраңны дарулап бәйләр...»

Әмма юраган юш килмәде. Теге авылга сугыла алмадылар. Урманда утын хәзерләүче бер карт авылда полицайлар күплеген искәртте. Монда аларның штабы урнашып өлгергән.

Менә биш тәүлек инде бер дә юньләп ял итеп тормыйча чигенәләр. Алда ни көткәнен белер хәл юк. Әмма сукыр өмет алга өстери дә өстери. Аларга юлда адашкан берничә кызылармеец килеп кушылды. Өшәнгәннәр, мәлҗерәгәннәр. Шулай да күзләрендә яшәү чаткысы ялтырый.

Яктырып килгәндә бер куе чаукалыкта туктарга мәҗбүр булдылар. Ник дисәң, алда тигез дала, бик еракта, күгелҗем офыкта ниндидер авыл шәйләнә иде. Ачык кырга чыгарга берәүнең дә йөрәге җитмәде. Ат менүле немецлар, полицайларга җим буласылары килми иде. Кайсыдыр бер тиктормас ару-талуны белмәүчесе янәшәдәге кечкенә тау астында чишмә тапты. Котелогы белән салкын су алып менгән. Иң элек Томилинга эчәргә бирде, аны төркемдә башлык итеп таный башлаганнар иде. Әйтмәс борын старшина аның янына килеп тезләнде, яраның бинтларын сүтәргә тотынды. Марля белән кан укмашып каткан иде. Кемдер, ябышкан бинтны кубарырга ярамый, кан китүе мөмкин дип киңәш бирде. Әлбәттә, сакчыллык кирәк иде, старшина марляны бер кырыйдан кубара башлап карады, тик Томилин авыртуга чыдый алмыйча, уртын чәйни-чәйни кулын тартып алды. Старшина шуның өстеннән генә яңа бинт чорнады. Томилин бер төптән үскән нечкә тал чыбыкларын бөкте дә шулар өстенә ятты. Авыртудан кулын өскә күтәреп торды. Авыртуы бераз басылган кебек булды. Аны йокы томаны баса башлады. Төркемдәгеләрнең сөйләшүләре ерактан ишетелер-ишетелмәс кенә колагына керә. Кайсыдыр: нигә мылтык күтәреп чиләнәсең, ташлап калдыр, дип сөйләнде. Җәяүлегә янчык та авыр. Мылтык белән йөрү куркыныч, мылтыклы кешегә аталар... Теге эндәшмәде, патронташын атып бәрде, гильзаларның чыжлап чәчелгәне ишетелде. Йокы баскан кебек булса да, тиз генә черемгә китеп булмый. Ярасы авырта, аяклары гүли. Җанын билгесезлек агач корты кебек кетер-кетер кимерә. Уйлар, ният-өметләр кинәт кенә барысы берьюлы чәлпәрәмә килде дә төште. Нәрсә була инде бу галәмәт? Моңа ничек бәя бирергә, ничек аңларга, шушы буталчыкны :ничек бер кыләпкә салырга? Юк, моның очына чыга торган түгел! Нәрсә генә эшли ала ул? Ташкынга эләккән йомычка кебек, хәлләр ихтыярына

буйсынырга гына кала. Шулай да бер нәрсәне һич аңлап булмый: рота командиры була торып, Тарутин үз сугышчыларын ташлап кача түгелме? Башсызлыкмы, әллә исәп белән эшләнгән эшме бу? Минутлык куркуга бирелеп, йомшап, аның, ихтыярын җуюмы? Алай да булуы ихтимал. Кеше ялгышын соңыннан гына аңлый. Ләкин булганны кире кайтару мөмкин түгел инде... Шул мизгелдә уйлары көчсезләнә барып, ул йокы томанына чумды.

Күпме вакыт узгандыр, аягына нидер тигәнгә күзләрен ачты. Көн кичкә авышып бара икән. Кузгалырга вакыт. Әмма аның алдында битләрен, ияген кызыл төк баскан Краснов басып тора иде. Фамилиясе генә түгел, чәче дә, чырае да кызыл иде.

—Томилин, синдә бер-ике сохари булмасмы?—диде ул, хәл-әхвәл белешеп тормыйча һәм чыбыклар өстенә чүмәште. Томилин бик тиз йокысын ачты, шинель кесәсеннән ике сохари алып аңа сузды. Шунда гына Краснов аның ярасына дикъкать итте. Исе китмәгән төстә, кайда, ничек, дип сораган булды.Томилин, тегенең ни беләндер кәефенә тию, төрттерү нияте белән: «Полк байрагын барыгыз да ташлап качтыгыз бит»,—диде. Байракны сейфка бикләп җиргә күмгәндә немец самолеты өстән сиптереп үтте...

Бу сүзләрдән соң Красновның кашлары, чырае җыерылды, горурлыгына тиде шикелле. Читкәрәк карап, чүп нәрсә турында сүз барган төстә:

—Синнән башка да яшерерләр иде әле,—диде.

—Кем? Барыгыз да җил очырган кебек юкка чыктыгыз. Протокол язганда бик батырланган идең!

—Байрак минем җаваплылыкта түгел.

—Илне дә минем җаваплылыкта түгел дип калдырыргамы?

—Анысы бөтенләй бүтән мәсьәлә,—дип, Краснов, бу сөйләшү мәгънәсез дигәндәй, кулын селтәде.

—Хәер, син алгы сызыкка барудан ничек кирәк алай качтың бит! Минем күз алдында...

—Юк, мин бары приказны үтәдем,—диде Краснов бүртенә башлап. Син тавык башың белән барыш механизмына төшенә алмыйсың!—Ул, тупикка килеп төртелгәнен белеп, шуны инкарь иткән төстә, кулы белән кире тибәрү хәрәкәте ясап китеп барды. Аны иптәшләре чакыра иде. Алар да өч-дүрт кеше бер булып оешып чигенәләр, күрәсең, куаклар арасында эрегән кебек булдылар.

Тагын юл, һаман көнчыгышка, үзебезнекеләргә таба. Сугыш тавышы ишетелми. Тик аны таш җәйгән юлга килеп чыкканда, күрәсең, машина колонналары, танклар, башка техника тимер ташкын булып көнчыгышка агыла. Бу нинди хикмәт, бер дә бу агымны тыярлык көч юк микәнни!? Марш белән алга баралар бит! Бу инде каршы тора торган армия бөтенләй юк дигән сүз! Менә ышанып булмый, бу мөмкин түгел. Әмма фактка күз йомып кына котыла алмыйсың.

Күз бәйләнгәндә бер зур гына авылга юлыгып, бераз азык-төлек юнәтеп булмасмы дип өметләнделәр. Йортларга икешәр кеше керергә сөйләшенде... Томилин белән старшина таза йортлар тезелгән, чокырлар белән аерылып торган тыкрыкка керделәр. Ләкин кинәт авыл уртасында автоматтан ата башладылар, кешеләрнең йөрәк өзгеч кычкырулары ишетелде. «Лап-лоп» кемнәрдер каядыр чаба, аларны «лап-лоп» кемнәрдер куа иде шикелле. Томилин бер коры саз чокырына атылып барып төште, ярады кулы бәрелде, күзенә утлар күренде. Авыртудан башта куркынычны да онытып торды. Ә старшина кайда? Адәм баласында саклану инстинкты хәтәр, хыянәтчел. Ул аңга буйсынмый, аннан алда куркынычны тоя һәм сине бер таш кисәге кебек итеп әллә кайларга илтеп ташлый. Аңга килгәч, шаккатасың.

Томилин башта старшинага тавышын кысып кына эндәште. Үз янына чакырды. Бераздан кычкырыбрак боерды. Юк. Байтак көтеп утырды. Юл уртасында тавышлар тынды. Инде бүтән мөмкин түгел иде. Ул чокырдан чыгып авыл кырыендагы үк личә буйлап чапты да чапты. Бер посадкага килеп керде. Карангылык сизри башлаган. Агачлар арасында күләгәләр ыгы-зыгы килә. «Кемнәр?»—дип кычкырды Томилин. Таныш тавыш ишетте ул. Краснов төркеме икән. Томилин алар янына килде. «Ни бар, ник шаулашасыз?» Краснов аңлатты: төркемдәге бер особист гөмбә ашап агуланган, аңын җуйган. Краснов өч кызылармеецка аны шушы авылга илтеп калдырырга боерган. Ике сәгать вакыт биргән. Инде өч сәгать үткән, тегеләр һаман юк икән... Ташлап калдырсалар, әйләнеп килмәячәкләр, диде кайсыдыр. Краснов бик нык уйга калды. Особист үзен кызылармеецлардан өстен тоткан, мин сезне трибуналга бирәм дип янаган. Алар, сез холуйлар, дип көлә торган булган. Краснов кузгалырга дип, көтеп ятуның мәгънәсез булуын дәлилли-дәлилли урыныннан торды, алга таба атлый башлады. Бүтәннәр дә ана ияреләр инде. Бер сержант иярмәде, авылга китте. Без сезне фәлән урында куып житәрбез, диде. Карта буенча 20 чакрым маршрут чама белән билгеләнгән иде. Ләкин сержантның үз исәбе булырга тиеш. Чөнки зур төркем белән качып йөрү бик унайсыз. Тотылу ихтималы бермә-бер арта. Иң унае ике-өч кешелек төркем. Ашау-эчү мәсьәләсендә дә шулай җайлы. Авылларга сугылып кача-поса җыйган кече телгә дә житми, эчне котырта гына. Кызылармеецлар хәлсезләнеп жиргә егылалар һәм тора алмыйлар. Кичә ял итәргә туктаган жирдә ике кеше хәлсезлектән һәм авырулардан аякларына баса алмады... «Братцы, калдырмагыз! Братцы...»—ди-ди чабуга ябышалар. Күзләреннән яшь ага. Әмма төркем рәхимсез, аларны алып үзе һәлак булырга теләми. Бу эштә Краснов аеруча актив иде. «Төнлә авылга шуышыгыз, шунда рәт чыгар. Шыңшымагыз! Күрәсез ич хәлне!» Төркем башы Краснов ашыктырды да куалады. Өмет бар иде, яшеренгән урман ешкынлыгы авылга якын иде. Хәлләнгәч, шунда барырга бик җайлы... Шулай да бүре өере кебек, бара алмаганнарны ташлап китү күңелгә авыр таш булып ятты. Берни эшләр хәл юк... Һәркайда кырыслык, рәхимсезлек.

Төркемдә шундый тактика гамәлгә керде. Авылга якынрак жирдә яшеренеп яталар да, төнлә рейд ясыйлар. Куркынып төсләре качкан хуҗадан ризык теләнергә туры килә. Ләкин авыл халкы шактый ярлы. Бик аз тамызалар. Кайчак авылга киткән вак-вак төркемнәрдән берничә кызылармеец әйләнеп кайтмый. Карыйсың, көн эчендә әллә каян калкып төркемгә берничә кызылармеец кушыла. Шулай төркем бер кимеп, бер артып, һаман үзебезнекеләргә таба хәрәкәт итә.

Хәл алып урман чытырманлыгында ятканда берәү телдәрләнде.

—Немец кулына эләккән хәлдә безнең бер котылу шансы бар,—дип әйтеп ташлады. Бу нәрсәгә барысының да колагы шәпкәйде. «Ничек? Нинди шанс?»—дип кызыксына башладылар. Теге тагын да үсенеп сөйли.

—Немецлар белорусларга, бигрәк тә көнбатыштагыларына бик хәерхаһ карыйлар. Чөнки алар советка бер ел элек кенә кушылган. Пленга алу белән аларны өйләренә кайтарып җибәрәләр ди. Менә шул, фамилияңне белорусча итеп яздырасың, Көнбатыш Белоруссиядә туганмын, дип бер авыл исемен атыйсың. Һәм син иректә...

—Һе, немец ансат кына ирекка җибәрер, тот капчыгыңны,—дип каршы төште кайсыдыр.

—Юк, немец тырнагына эләгергә ярамый, Ходай сакласын,—диде хәстәрле шәбрәк тавыш.—Пленныйларның гаиләләрен Себергә сөрәләр икән. Менә вәт!

—Плен калганга без гаеплемени, баш командирлар ташлап качтылар бит. Без нишли алабыз. Һаман шул башбаштаклык, яптыр малахай!

—Башлыклар безне дошман авызына ташлаганда безнең гаиләләрнең ни гаебе бар? Юк, башка сыя торган нәрсә түгел бу.

—Үзе теләп немецка хезмәт итүчеләрнең генә гаиләләрен сөрәләр икән...

—Көнбатыш Белоруссиядә немецларны ипи-тоз белән каршы алулар булган ди.

—Юк, булмас, хатын-кыз сүзен сөйләмә!—дип кырт кисте Краснов.

—Ник исегез китте,—диде карлыккан тавыш.—Теге елларда гаепсезгә арестовать ителгәннәрнең якыннары немецка өмет багламаганнар дисеңмени? Андыйлар немецны күтәп алсалар да табигый.

—Юк, табигый түгел, иленне сату ул. Патриотлыкны югалту, бары шул гына.—Краснов кырыс хөкем итә иде.

—Ул патриотлыкны, бер гаепсезләрне төрмәгә тыгып, Совет әвәл үзе бетерде.

—Молчать, антисоветчыл лыгырдыйсың!—Краснов тагы да катгыйланды.

—Менә һәрчак шулай аз гына дөреслекне әйтә башласаң, антисоветчыл дип гаеплиләр. Совет исә факт-хакыйкать белән бер дә санашмады. Шуның нәтиҗәсе менә күз алдында.

Моңа каршы Краснов бер сүз әйтә алмады. Капларга козеры юк. Киресен кабатларга дәлилләре көчсез, ахрысы. Чөнки кайчаннан бирле хуҗасы ташлаган этләр шикелле качып-посып, куылып йөриләр. Үз туган җирендә шулай булып. Ә тиреҗ белән сугарылган бу хәшәрәт дошман мәсхәрә итә. Байлыкны урлап, талап үз иленә озата. Моннан да хурлыклырак хәл булуы мөмкинме?

Бераз черем итеп алгач, солдатлар күлмәкләрен салып кызына башладылар. Теге вак «җанварлар» тынгы бирми иде.

—Безнең ристан булып йөрүгә бүген 21 көн икән. Очко!—дип куйды кайсыдыр.

—Юк, исән-имин үзебезнең якка чыга алсак, очко булыр.

—Алдагысын Алла белә, дигәннәр.

Ул вак «җанварлар» Томилинның да җилкәсен ашый иде, ләкин ул сер бирми. Командир горурлыгын нык тота. Әмма ярасы торган саен ныграк авырта. Яңадан бәйләргә кирәк иде, бинт каян аласың? Көндез урман посадкасында ятканда яра чатнап сызлый башлады. Томилин ах-ух ыңгырашканда берәү килеп әйтте: син аны сидек белән чылатып кара әле, диде. Чарасыз, шулай эшләде. Гаҗәп, сызлау басылды. Әле күпме кайтасы бар икән? Фронт сызыгы һаман ерагая да ерагая. Немец баскыннары ил эченә таба һаман эчкәрерәк керә. Үз башына булгыры!

Үзебезгә чыга алсам да миңа шикләнеп караячаклар дигән уй килде Томилинга. Званиедән мәхрүм итүләре дә мөмкин. Ул шик келәймә кебек миңа гомер буе ябышып торачак. Ә чынын исәпләгәндә, минем ни гаебем бар? Бая теге кызылармеец әйткәнчә, без бит шартлар корбаны гына. Шартларны без тудырмыйбыз, үзгәртә дә алмыйбыз. Димәк, барысына да түзәргә дә түзәргә кирәк! Үз эченә йомылырга.

Ни генә булса да, бүген исән әле. Шулай да бик нык өшәнелгән, арылган. Кузгалганда саннар, буыннар шыгыр-шыгыр килә. Аз гына артынны терәденме, күзне йокы баса.

Колак төбендә генә мотоцикл пырылдаганы ишетелде. Бу нәрсә тагын? Ул керфекләре аша күрде: яктырып килә икән. Бар нәрсә аермачык күренә. Кинәт автомат тавышы колакны ярды, баш очыннан утлы пулялар

сызгырып узды. Вакланган кайры йомычкалары күзгә керде. «Һальт! Һальт! Һальт!» дигән, эт өргәнне хәтерләткән тавышлар яңгырады. Кайтавазлар аны кабатлады. Томилинның йөрәге аяк табанына төшеп киткәндәй булды. Кулы калтырый, яра авыртуы онытылган иде. Агачка тотынып торып басты. Посадка кырыенда автомат тоткан немецлар «Һальт! Һальт!» дип кычкыралар. Барысы да тирән каскалар кигән, чырайлары күренми. Безнекеләр урыннарыннан торып, кулларын күтәргәннәр. Томилинның зиһене җитди, теге пистолетны чыбык арасына ташлады. Тик Краснов кына кырыйда чалбарын төшереп бер аягы белән җиргә тезләнгән. Аның бер бот төбе яраланган икән. Томилин аның янына атылды. «Ни булды, ни булды?»—дип өтәләнде. Теге аңа бинт пакеты сузды. Томилин теше белән тышын шатырдатып умырып атты да, марля тасмасын ярага урый башлады. «Кан бик нык ага, тамырга тигән, ахры,—диде Краснов.—Әнә теге юан баганадан рикошет белән бәрде шикелле...» Аның йөзе агарып, суырылып киткән иде. Краснов бер аягын өстерәп атлый-атлый чыбыкларга тотынып торды. Ярасына чыбык тиеп китте. Ул «а-а-а» дип кычкырып куйды. Шул мәл посадка кырыена бричка җиккән ат килеп туктады. Арбадан немец мундиры, пилотка кигән таза адәм төште һәм саф русча: «Убитых нет ли?»—дип сорады. Немецлар аңа нидер әйттеләр, бу аларга шома гына немецча нәрсәдер аңлатты. Томилин, үз хәлен онытып, тагы гаҗәпкә калды. Кай арада дошман ягына чыккан, аңа каударланып хезмәт итәргә керешкән? Немецны көтеп алучылар да булгандыр инде. Зур гаилә бер гарип-горабасыз булмый ди. Шул факт күзгә ташлана иде. Авылларда коточкыч хәерчелек, ачлык хөкем сөргәнен һәрдаим күрәбез. Шундый шартларда кешеләр ачлыктан котылу ягын гына карыйлар. Теләсә нинди вәгъдәгә ышаналар, буш өметкә ябышалар. Ачлыктан да хәтәр нәрсә юк. Тамак тәмугка кертә дип тикмәгә әйтмәгәннәр. Ачлык бик хыянәтчел, кеше аңа каршы тора алмый. Ач кешедә иман, әхлак булмый. Шуңа теләсә нинди мөмкинлеккә тотына ул. Немецка өмет баглап, аңа ялланулар гаҗәп түгел. Әмма кыйблаларын тиз алыштырулары аптырашта калдыра. Аларны хыянәттә гаепләячәкләр. Ач калдырып, Совет власте үзе хыянәткә этәрүен исәпкә алу булмас. Юк...

Шул мәл Томилин ярасыннан яңа кан типкәнен күреп алды. Иптәшләреннән бинт сораштырды. Тик берәү дә шәфкать күрсәтмәде.

Краснов аягына баса алмады. Немец нидер кычкырды. Олаучы аны бер култыгыннан тотып, бричкага алып килеп утыртты. Аннары нишләргә белмичә чыбыкка тотынып торган Томилинны иненнән җилтерәтеп арба артына төртте.

Немецлар кычкырынып төркемгә кузгалырга һәм посадка буйлап атларга боердылар. Әсирләр хәлсезләнгән, тәмам бетеренгән кыяфәттә, бөкшәеп кенә өстерәләләр иде. Кызылармеецларның чыраенда югалып калганлык, гаҗизлек чагылды. Олау да шулар артыннан кузгалды. Юл бер сырт булып сузылган үргә таба иде. Сыртка җиткәч, күренде: астанрак зур шоссе юлы үтә икән. Анда бихисап машиналар чаба. Барысы да—Көнчыгышка. Шул тикле күп техника! Томилинның аркасына салкын су сипкәндәй булды. Бу тимер ташкынга ничек чыдамак кирәк. Ой-ой-ой! Бераз баргач, зур гына авылның ак йортлары калкып чыкты. Олы юл шуның кырыеннан уза шикелле. Ниһаять, авылга керделәр. Киң генә урам. Берничә җирдән сырттан төшкән ерганаклар кисеп узган. Аларга кечкенә күперләр салып тоташтырганнар.

Менә зур гына сигез почмаклы, челтәр култыксалы ачык верандалы йорт каршына китереп туктаттылар. Анда шактый күп халык җыелып тора иде. Малай-шалай да шунда чабыша. Әсирләрне бер кырыйгарак китереп

бастырдылар. Халык белән аралаштырмас өчен берничә полицай арага куелды. Төркемдә кыймылдау булса, шунда ук күреп алалар һәм карабин түтәсе белән төртәләр. Краснов белән Томилинны арбадан төшереп төркем алдына куйдылар. Томилин тирә-якка күз салды. Карасана, алар алгы сызыкка барганда привалга шушы йортта туктадылар түгелме соң? Йортка тоташ озын лапас. Анда карлыгачлар чырый-чырый килеп, ук кебек кыеклап атылып очалар иде. Әнә хәзер дә кыйгачлап астан гына һаваны сызып үтәләр. Авыл бик ярлы булып чыкты. Алар янында алама киемле, йомык йөзле агайлар һәм ач күзле бала-чага уралды. Бу нәрсә инде?

Кара бу полицайларны, кичәге совет кешеләре бүген немецка бер-берсеннән уздырырга ашкынып булышып йөриләр. Гаҗәп инде, ничек тиз үзгәргәннәр. Немецларны көтеп алучылар инде бу полицайлар. Совет власте, тормыш төрлечә рәнҗеткән кешеләр. Кешеләрне кыерсытуда күп чак властьның гаебе дә булмавы мөмкин бит. Ярлы, ач халык теләсә нинди ихтималга ябыша. Безнең егерме биш еллык гуманистик-патриотик тәрбия бик тиз юкка чыккан түгелме соң? Хәер, барча кешеләр өчен бу кагыйдә була алмый. Мал аласы тышында, адәм аласы эчендә ди. Илен сатмаган меңләгән патриотлар үзләрен күрсәтерләр әле.

Чуар халык төркеме идарә баскычы янындарак мыж килә. Полицайлар, баскыч култыксасына бүксәләрен терәп, халыкка нидер кычкыралар, нәрсәдер көтәргә кушалар. Сизерәгән саргылт кожан, шалама кепкалы ач яңаклы бер карт баскычтан төште дә, халык төркемен аркылы ерып чыгып әсирләр янына килде. Полицайлар тыймадылар. Әсирләр җирдә утыралар. Томилин яралы беләген икенче учы белән сыпыра-сыпыра алгы рәттә утыра иде. Аңардан арырак төркем эчендә бер ботын ике учы белән каплап Краснов чүмәшкән. Карт, башын кыегайтып, кырын-кырын атлап әсирләрне күздән кичерә башлады. Томилин турында кинәт:—Әнә ул, әнә!—дип чигенә-чигенә кычкырып җибәрде. Томилин шылт та итмәде, күзе дә читкә тайчанмады. Карт: Сволочьлар!—дип сүгенә-сүгенә китте. Төркемдәгеләр як-якларына карандылар. Кемгә төртеп каһәр яудырды? Беркем тәгаен искәрә алмады. Бу нинди тилергән адәм дигән тәэсир калды. Әллә Томилинны чамаладымы нәләт төшкән карт? Чынлап таныса, якын ук килгән булыр иде. Әмма Томилин бу кешене таныды. Кухня янына соңарып килгән карт бит бу. Бик ялварып теләнде. Томилин повардан гозерләнеп ипи бирдерткән иде. Башын тилегә салып, немецларга ярашып маташмыймы? Җан саклар өчен ни генә эшләмәссең?

Ул арада идарә баскычында автоматлы колгадай немец, зәңгәр мундир, биек фуражкалы, җиңнәренә ак тасма бәйләгән полицайлар калкынды. Колга немец командалык иткәнен күрсәтү өчен автоматын күккә чытырдатты да, «Ахтунг, ахтунг!» дип тамак ярып кычкырды. Веранда култыксасына бүксәсен терәп, бер сары чәчле, кирпеч йөзле полицай сөйләргә тотынды.

—Жураво районы һәм авылы гражданнары, тыңлагыз,—дип башлады ул. Тавышын көчәйтү өчен йодрыгын авызына китереп бик нык тамак кырып алды.—Данлыклы немец гаскәрләре большевикларны җимереп безгә ирек һәм җир алып килде. Иртәгәдән һәр гражданга җир бирелә. Җиргә хуҗа итеп беркетелә. Барча уңыш үзенә була, бары 1 процент налог түли. Моңарчы ипи чырае күрмәгәннәр житеш тормыш белән яшәячәк!

Шунда әсирләр арасында кемдер шыпырт кына йөрәк тавышы белән кыҗрап: «Алдыйсың, сволочь!» дип пышылдады. Аңа аяк ымы белән әллә ничәү кушылды. Билгеле, полицай моны ишетмәде.

—Шуның өчен мәрхәмәтле немец армиясенә рәхмәт белдерәбез...—Ул кулына тоткан кәгазь битләрен актаргалады һәм дәвам итте:

—Безгә комендант шарфюрер Трипнер әфәнде Жураво участогы управасы оештырырга кушты. Управага унбишләп кеше сайлана. Монда авыл старосталары да кирә. Менә алар...—Ул исемлекне күзенә якын ук терәп укый башлады.

—Жураво авылы старостасы Атаманов,—диде һәм ун ягында басып торучыга ияге белән күрсәтте. Халык эченнән: «Кем ул?»—дигән тавыш яңгырады. Сөйләүче аңлатма бирде: «Атаманов политически гаепләнеп кулга алынган. Немецлар аны Харьков төрмәсеннән коткарганнар. Ә Ключи поселогы старостасы итеп Брынза куела.—Сөйләүче ияге белән Атаманов янындагы озын какча кешегә ымлады.—Ул национализмда гаепләнгән. Немецлар азат иткәннәр...

Полицай авыл старосталарын атап, сәяси положениеләрен әйтеп чыкты. Халык эченнән кемдер:

—Нигә барысы да тюремщиклар?—дип кычкырды.

—Үзләре теләк белдерделәр,—диде сөйләүче.—Комендант әфәнде барысын да тикшерде һәм хуплады.—Ул Шарфюрер янына атлады, немецча нидер әйтте. Трипнер култыксага бер кулы белән таянып, башын әтәч кебек кукрайтып сөйләп китте. Русчасы ипи-тозлык кына, әмма анларга мөмкин. «Большевиклар тар-мар ителде,—диде.—Бүген-иртәгә Мәскәү, Ленинград алыначак. Әгәр авыл кешеләре немецларга тугрылыклы булса, әйбәт хезмәт итсә, житәкчелек моны исәпкә алачак һәм бүләкләячәк. Ат һәм сыер биреләчәк! Әмма алдан кисәтеп куям: кызылармеецларны, пленныйларны, партизаннарны яшерүчеләр булса, шундук атып үтереләчәк! Хайл Гитлер!»—Ул кулын өскә чөйде һәм бер адым артка чигенде. Полицай исә алга иелә төшеп: «җыелыш тәмам»,—дип акырды. Халык бәрелә-сугыла таралды. Лапас астында жигүле атлар тора икән, шуларга төялеп элдерделәр генә, баскычтагылар да өй эченә керде. Әсирләр, ни булыр, дип шул якка текәлгәннәр иде. Фронт тылы ягыннан зур төркем әсирләрне сакчы немецларның этләр белән хау-хаулап куып китергәннәре күренде. Лапастан бричкага жигелгән олау чыкты. Баскыч төбендә туктады. Өйдән алып чыгып, аягы яралы гражданский киемле таза гына кешене арбага салдылар. Кузлада биленә зур авыр пистолет таккан (Томилинның парабеллумны беренче күрүе) киң җилкәле, юка гәүдәле полицай утырган. Дилбегәсен еш-еш тартып ялкау атны куалый. Ул Томилин белән Краснов янына туктап, аларны арбага алды. Немец сакчылары, полицайлар әсирләрне куа башладылар. Авыл эченә керми торган юлдан барырга дип, карабин түтәләре белән аркаларына төрткәлиләр иде. Ә яралыларны полицай икенче якка алып китте. Ниндидер төз кыр уртасындагы межа шикелле аз йөрелгән юлдан баралар. Казылмаларда арба шалтыр-шолтыр селкенә, яралылар ах-ух киләләр, яраларын тоткан итәләр. Теге яралы кузлага якын гына утырган, «Потише!» дип әйткәләп куя. Томилин аның киң җилкәсенә, сынык козереклы киң кепкасы яртылаш каплаган чыраена һәм көрәктәй кулына игътибар итте. Әллә шахтер микән дип уйлады, чөнки бу тарафларда бик шахта поселоклары күп дип ишеткән иде. Ул ана сүз катты, нидер сорамакчы иде, ләкин полицай кузладан ярым борылып, авызын кыйшайтты:

«Молчать!» дип акырырга һәм пистолеты белән янарга тотынды.

—Кая илтәсез, яраларны бәйләргә кирәк?—дип, полицайга сүз катты сынык козерёк. Ул кузла тактасының бу башына сул терсәген куйган, арба селкеткәндә гәүдә авырлыгын шуңа салып, ярасы авыртудан саклана иде. Полицай җавап бирмәгәч, козерек соравын янә кабатлады. Шүрли торганнардан түгел, ахрысы. Тик полицай тагын кыек авызы белән: «Молчать!» дип җикерде. Авызыннан селәгәе агып төште. Кыяфәтендә яралыларга шул тикле ачы нәфрәт ки, хәзер үк аларны үтереп ташлар иде.

Бу совет тарафыннан бик нык рәнжетелгән кеше булса кирәк. Нәфрәте идейныймы әллә? Юк,физический шикелле. Әле кичә генә үз кешеләре булганнарга карата дошманлык кайдан тусын?

Полицай атны тагын да ныграк куа башлады. Анын юан, ишкән аркан кебек кытыршы муенында тамырлары бүртте. Сикәлтәләрдә арба дангыр-донгыр килә, яралылар «ой-ой», «а-а-а» дип ынгырашалар. Козерёк: «Әкрен, үтерәсең бит!»—дип кычкырды. Полицай аның саен атны чыбыклады. Алда күпер бар икән, ат шып туктады, нәрсә бу? Күпергә җәйгән киртәләрнең аралары шыр ачык, аерылып-аерылып тора. Аяклары ярыкка төшүдән куркып ат алга атламый, як-якка тартыла, чәбәләнә, артка чигенә. Полицай атны яра. Ул ике аягын да арба алдына алып яралыларга аркасы белән утырды. Дилбегәне ике куллап тарта торгач, ат нишләргә белми үрә басты. Теге һаман кыйный. Ат гыж-гыж килә иде. Козерёк, бер мәлдә кинәт калкынды да, полицайның якасыннан ачык муен тамырына кизәнеп бик каты сукты. Учында очлы тимер икән. Кан чәчрәде, җине кызылга буялды. Полицай ык-ык-ык итте, куллары бушап һавага тотынды да, арба эченә ишелеп төште. Козерёк тамчы да каушамады. Дилбегәне кулына алып, атны бөтенләй икенче якка борып чаптырып алып китте. Яралыларга күз дә салмады. Томилин белән Красновның күзләре, эзләреннән чыгып, аклары гына йолт-йолт килә, үзләре дер-дер калтырыйлар, тәннәре манма су булды. Йа, Хода, өнме бу, төшме? Төш дияр идең, Козерёк атны бик каты чаптыра, арба аварга җитеп сикерә. Ә Козерёкның аркасы шундый тыныч, гүя ул иптәшләрен утыртып базарга бара. Томилин аның башсыз кыюлыгына бик гаҗәпләнде. Үтә тыныч табигатьле булып күренде ул. Хәер, куркыныч янаганда мәче дә арсланга әйләнә ди. Томилин көчкә исен туплады һәм, полицайның гәүдәсен якасыннан өстерәп, кузладан аякларын ычкындырды да, арба төбенә сузып салды. Ул җан бирә алмыйча тартыша, дерелди иде. Ә Козерёк атны куа гына. Арба селкенүен уйламый да. Боларга кырын күзен дә төшерми иде.—Спокойно!—диде ул артына карамыйча гына. Атны исә чаптыра бирә. Инде эңгер-меңгер белена башлады. Полицай кыймылдап куйды һәм гырр-гырр килде. Бу үлем гырылдавы иде.

Козырёк тезләнеп утырган, ярасы барын да сизми, ахрысы. Сынган козыреклы кепкасы анын күзен каплаган, бары чыгынкы яңагындагы мускуллар тартышуы гына күренә. Бөтен вөҗүден үч комарына юнәлткән. Нинди тәвәккәл кеше бу! Йә баш, йә мал дип тотынгандыр. Дошман бик әшәке шул, йә ул сине, йә син аны.

Озак кына чаптылар. Атның авыр сулаганы ишетелә башлады, утлыкканлыгын эченең еш тирбәнеп торуы да белгертә иде. Ниһаять, кучер атны туктатты. Сыек эңгер-меңгердә нindидер текә яр буе беленде. Козерёк хәле китеп, арба кабыргасына аркасын терәде, башын артка ташлап уш алып торды. Маңгаендагы тирен җине белән сыпырып-сыпырып куйды. «Уф! Уф!»—дип ыңгырашты ул, яралы аягын ике учына тотып.

—Бу сволочь безне больницага түгел,Грузинка шахта поселогындагы гестапога алып бара иде,—диде сулышына буыла-буыла.—Әллә сез комиссарлармы, ә? Шүрләмәгез, мин пособниклар белән көрәшер өчен горком калдырган кеше. Фамилиям Пьявкин Алексей... Өй алды иҙәнендә ятканда ишеттем, «комиссар» дип сөйләнделәр. Каян белгәннәр икән?

Томилин ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Бу кискен хәлләр анын зиһенен алган кебек иде. Пьявкин алдашмый шикелле, менә бит ул аларны үлемнән коткарды. Немецларның комиссарларны урында ук атулары билгеле иде. Томилин әле нормаль халәтенә кайтып житә алмаган. Сөйләве өзек-өзек, ышанычсызрак чыкты. Краснов көчкә-көчкә телен

әйләндереп берничә дәлил өстәде. Аның хәле начар кебек сизелә. Ярасы аза башламады микән?

Пьявкин артык төпченмәде, арба канатына аркасы белән ята төшеп, башын өске үрәчәгә куеп хәл алуын дәвам итте. Бераздан әйтте:—Мин бу төшләрне бераз беләм,—диде, башын аларга таба борып. Утыз тугызда хәрби учениеләр шушы төбәктә булды...

—Безнең комиссарлар икәнне ничек белгәннәр, гаҗәп,—диде Томилин.—Немецлар, крестьянча киендереп, авылларга алдан ук шпионнар җибәрәләр... «Без, берсен тотып, эшен бетердек,—диде Пьявкин.—Ә бу—төрмәдә надзиратель булып зэкләрнең канын эчкән адәм»—диде ул мәеткә ымлап. Аның тавышы карлыккан, үзенеке кебек түгел иде. Бик каты киеренкелек кичергәндә шулай була.

—Ничек?!—дип шаккатты Томилин.—Советка хезмәт иткән һәм немец ягына чыккан?

—Мондыйларга кем яклы булу әһәмиятле түгел, кем кыйбат түли, шул мөһим. Кешене газапламыйча яши алмый алар...

—Бер уйласаң, властьлар шундыйларны саклыйлар?

—Пычрак эшне кемнән булса да эшләтергә кирәк бит!—Ул озак кына тынып торды да:

—Бу үләксәне нишләтәбез, ә?—дип, комиссарга эндәште. Тегесе җавап бирмәде. Томилин баядан бирле үзләрен коткаручыга ничек булышырга белми. Командир була торып, бер эш тә майтара алмыйм микәнни дип оялып утыра иде. Караңгыга күзе ияләшкәч, арбадан тотына-тотына төште дә, як-якка караштырды. Өч-дүрт метрда гына бик текә кызыл яр бар икән. Пособникны шунда мәтәлдерергә һәм вәссәлам! Бу ният Пьявкинга ошады. Ул полицайның коралын алды, документларын үз пиджәгенә күчерде. Искереп беткән күн итеген салдырды. Аннары өчәүләп гәүдәне өске үрәчәгә шудырып менгерделәр дә этеп җибәрделәр. Ул дырк итеп барып төште. Томилин белән Пьявкин, җиргә тезләнеп, гәүдәне яр кырыена өстерәделәр. Бераз тын алгач, аска томырдылар. Кантарларны куптарып, шатыр-шотыр төшкәне ишетелде.

Үрмәләп менеп, арбага урнаштылар да, хәзер нишләргә икән дип тынып калдылар. Әле генә булып алган хәл тәэсиреннән арынып, уйларны рәткә салырга, зиһенне тупларга кирәк иде. Инде кап-караңгы булды. Атның тамагы ачкан, әле болайга, әле тегеләйгә тартылып, озын үләннәрне уртламак итә иде. Ә яр буе куркыныч, ат, үләнгә алданып, эшне харап итә яза. Томилин шуны Пьявкинга әйтте. Теге шунда ук килеште һәм, дилбегәне тотып, атны алга куалады.

Юл түбән таба китте. Тик озак бара алмадылар. Ачыклык бетте, ниндидер чытырманлыкка кереп ат туктады. Томилин, арбадан көчкә-көчкә төшеп, тирә-юньне тикшерде. Карангылык комачауласа да, нечкә чыбыклы куаклар үскән җир булуын чамалады. Аяк астында биек куе үләннәрне аягы белән тойды. Арба үрәчәсенә тотынып, Пьявкинга: «Шушында төн уздырырга туры килә»,—диде. Теге баш каккач, Томилин атның аркалыгын төшерде, авызлыгын алды, тезгенен җибәрде. Ат шунда үләннәрне кертләтергә кереште.

Арбада Краснов «ах-ух» килеп ята. Тәне ут кебек яна иде. Пьявкинның моңа исе китмәде. Чөнки үзе дә сызлана башлады. Бая яра авыртуын онытулар соңыннан икеләтә авырту белән кайтара иде. Ул кузла астындагы печәнгә башын төртеп тынып калды. Томилин исә арба артына җайлашты. Әз, әз генә черем итеп булса, дип күзләрен йомды. Юк, йоклап китә алмады. Башында уйлар, тузгыган күч кебек гөҗ-гөҗ килеп кайный. Пьявкинның тәвәккәл батырлыгын аңлап бетереп булмый иде. Бу

батырлык идейныймы, әллә үз табигатендә булганмы? Хәер, икесе бергә тоташкан, ахрысы.

Урманның исә үз тормышы, якында гына ниндидер кош шырыйлап кычкыра. Ерткыч карчыга берәр кошны ботарлый булса кирәк. Томшыкка томшык бәрелгән шыкырдаулар ишетелеп китә. Төн болытлы, чык төшмәс дип Томилин шинель якасы белән башын томалады. Ләкин аркасы сызлавы астан лезвие кискән зәһәрлек белән башына менә иде. Шулай да черем итеп алды шикелле. Бер мәл кулын нидер бик әче итеп тешләгәнгә күзен ачса, кигәвен канын эчеп маташа икән. Инде яктырып беткән. Ул арбадан тотына-тотына төшеп тирә-якны күзәтә башлады. Колагына су чылтыраган тавыш килде. Бер аягын көчкә өстерәп (аягын итек кырган, хәтәр авырта) бераз атлый биргән иде, чылтырап аккан чишмәгә килеп чыкты. Тизрәк күкрәге белән суга капланды, туймастай булып чөмерде дә чөмерде. Ул арада тезләре белән атлап Пьявкин килде, суны учларына алып эчте дә эчте. Пилотка белән су алмакчы итте Томилин, ләкин бер минутта агып бетә иде. Полицайның сукнодан тегелгән немец пилоткасы белән Красновка су алып килделәр. Атны су ярына тарттырдылар. Ул да тәмам кибеккән булган.

Нишләргә, кая барырга дигән хәл җанны тырный иде. Бөтен эш Пьявкинга бәйләнгән, ул ни әйтсә, шул була. Башта Томилин фронт хәлләре белән кызыксынды. Аларның төркемнәргә бүленеп чигенүенә унбиш көн вакыт узган икән инде. Бары өч-дүрт көн генә сыман тоелган иде. Пьявкин немецларның бик зур прорыв ясап, кырыгар чакрым алга баруларын, бернинди каршылыкка карамыйча Донны аркылы чыгып, Сталинградка ыргылуларын әйтте. «Ләкин паникага бирелергә хакыбыз юк, кискен көрәштә Ватан өчен һәркем үз бурычын үтәргә тиеш,—диде ул ничектер пафоска бирелеп.—Дошман рәхимсез, без аңардан да катырак булырга тиешбез...»

Ул ярасы авыртудан чыраен сытты, яралы аягын ике учына алып, күтәреп торды. Шулай иткәч, авыртуы җиңеләеп тора иде шикелле. Үрәчәгә башын куеп яткан килеш сүзен дәвам итте: «Хәзер Вассер дигән шахта поселогына разведкага титаклап булса да барып карыйм, унике чакрым ул. Берәр олау табып өйләдән соңга таба килеп җитмәсәм (ул полицайның сәгатен Томилинга сузды), төньякка юнәлеп барыгыз. Егерме биш чакрымнарда Князево хуторы булыр. Аннары Кусково, Дурново, Борщевка... Анда безнең ышанычлылар бар. Пьявкинны бик сак телгә алыгыз! Бетте!»

Ул тәртә юанлыгы таяк юнәтте. Шуңа ике куллап тотына да, авырткан аягын өстерәп ала иде.

Көттеләр-көттеләр, Пьявкин күренмәде. Үзләре генә юлга чыгарга ниятләделәр. Ни булса шул. Атның тамагы туйган шикелле иде. Томилин аркалыгын күтәреп бәйләде, тезгенен тартты. Арбага җайлап урнашты да, дилбегәне кулына алды. Әйдә, бахбай!

Юлсыз кырдан, межалардан бардылар. Инде житеп шактый агара башлаган иген басуларын кисеп уздылар. Кич булып килә иде. Бу юл һичшиксез ниндидер торак пунктка илтергә тиеш иде. Нинди булыр ул? Тозакмы, әллә котылумы? Үзләрен язмышка тапшырдылар. Башка чаралары юк иде шул.

Юл авыл урамына түгел, ындыр артына алып керде. Урамга борыла торган тыкрыкта бер ихаталы әйбәт кенә йорт алдына туктадылар. Томилин арбадан төште, титаклый-титаклый җил капка ярыгыннан эчкә керде. Ике күтәртмәле баскычтан үрмәләп өй алды ишеген дөбердәтте. Бик житез генә бер хатын һәм карт чыкты. Томилинның хәлен күреп барысын да аңладылар, боларны өйгә керттеләр. Җир идәнле алгыяк, анда салам түшәлгән иде.

Күп тә үтми, карт бер ачык йөзле таза гына хатынны алып килде. Ветеринария санитары икән. Куыклы лампа яндырып, түмәр өстенә куйдылар. Хатын иң элек Красновның ярасын карап, бинтын сүтә башлады. Тынга каплана торган сасы ис таралды. Краснов аңлы-миңле хәлдә иде. Бинтларны куптарганда кинәт «а-а-а» дип акырды да, аңын җуйгандай, тынып калды.

—Заражение башланган, ой-ой,—дип ухылдады санитар хатын... Марганцовкалы җылы су ясап, ул шуның белән яраны чистарта башлады.— Монда куярлык даруым юк бит, Ходаем, нишләргә инде?—дип сөйләнде үзе.—Бу бит бик куркыныч! Берничә көндә кан бозыла да... Моны яндырмый ярамый. Йодның гына көче җитмәс шул.

Аның сүзләре Томилинны исенә китергәндәй итте. Иптәшенең үлү куркынычы үзенең кул сызлавын онытырды. Нишләргә икән дип зиһенен, хәтерен эшләтә торгач, бер хәл исенә төште.

—Мышьяклы препаратың юкмы?—диде ул.

—Бар,—диде хатын.—Әллә фельдшермы син?

—Тормыш тәҗрибәсе бу,—диде Томилин.—Мышьяклы порошокны ак майга изеп, шуны ярага сөртсәк, ә?

—Юк, юк, бик каты яндырыр бит?—Хатын акыллы күзләрен Томилинга төбәп торды. Башын эшләтүе сизелә иде. Катгый карарга килеп, өйгә кереп китте ул һәм порошокны майга изеп, сулейма даруы ясап чыкты.

—Ярар, тәвәккәллим,—диде хатын һәм Красновның аягы янына тезләнде, аның ак челтәре, матур ботлары күренде. Ул лампаны якын китерде, ярага сулейма сөртә башлады. Һушын җуеп яткан Краснов исенә килеп, «кыһ-кыһ», «уф», «И-и-и» дигән авазлар чыгарды, ләкин күзен ачмады. Хәле юк иде. Хатын яраны бер кат майлады да, яңа яшел бинт белән бәйләде. Кычыткан суында төнәтелгәнгә яшел икән бинт.

Томилин ярасындагы кан белән ябышып каткан бинтны ниндидер май сөртеп йомшартты, үлеклəгәнен белде дә, кубарып алды. Үлекләү—төзәлү билгесе, дип сөйләнде үзе. Яра өчен иң кирәкле дару—ревонолы бар икән. Шуны тампонга сеңдереп, ярага куйды. Тыгыз итеп бәйләде. Томилин шешкән балтырын да күрсәтте.

—Бу—йөрәк таза булмаудан килә,—диде санитар хатын.

—Йөрәктән зарланганым булмады үзе,—дип куйды Томилин, хатынның игелек тулы чыраен күзләре белән сөеп.

—Йөрәк күп вакыт авыртуын белгертми ул. Монда нинди дәва кирәк инде?

Хатын Томилинның юеш маңгаена салкынча учын куеп торды.— Температурагыз да бар. Иртәгә нинди дә булса дару юнәтербез. Малларга да кешеләргә бирелә торган дарулар кулланыла. Тик дозалары гына үзгә...

Аларны өйдәге бер почмак бүлмәсенә күчерделәр. Ашарга-эчәргә китерделәр. Краснов башын күтәрә алмады. Томилин аның авызына сөт салды. Үзе дә сөттән башка нәрсәне авызына ала алмады.

Хуҗа хатын керде. «Атка курмы кирәк, карт төнлә шуңа бармакчы була, рөхсәттер бит?»—дип, Томилинга карады. Томилин: «Бик дөрес!»— дигәч, сукыр лампаны да алып чыгып китте.Томилин сызлаган кулын әле болай, әле тегеләй җайлаган итә, әмма авырту басылмый. Краснов та аңгы-миңге авыр ыңгырашып куя, әллә черем итә, әллә аңын җуйган көе ята.

Икенче көнне өйлә узгач, Томилин күзен ачты. Краснов һаман ут яна, тимер мич шикелле, аңардан кызу бәрә. Каны бозылу дәвам итә микәнни? Сулейма да файда итмәгәч инде. Иң көчле инфекция даруы түгелме соң?

Арткы хәвефле уе чыраена чыккан хуҗа хатын тыз-быз йөргәләнде.

Яралыларның бередә ятуы хуҗалар өчен бик куркыныч иде, билгеле. Ни хәл итмәк кирәк. Хатын хәвефкә төшеп йөри. Шулай да ашарга ипи һәм дуңгыз мае китергән. Томилин такталардан корыштырган ятагына торып утырды. Ашамлыкларны күргәч, авызыннан сулар килде, ярасы сызлавы онытылды. Бу кадәр дә тәмле ризык булыр икән! Ничә көн инде авызга бер бөртек тәгам кергәне булмады! Ул тар гына телем дуңгыз маен Красновның авызына көчләп кертте. Балага чәйнәгән ипиле имезлек каптырган шикелле, һәм гаҗәп, теге челт-челт итеп майны суыра башлады. Моны аңсыз рәвештә эшли иде шикелле. Чөнки организм үзе аннан тыш үлем белән көрәшә булыр...

Томилин тыштан килә торган тавышларга колак салып ятты. Иминлек мәсьәләсе ничек икән? Авылда немецлар даими торамы? Әллә полицайлар гынамы?

Өч-дүрт көннән соң, караңгы төшкәч, теге санитар хатын тагын килде. Яулыгын ике як битен каплап бәйләгән, өстендә иске генә фуфайка, аягында тузган кирза. Ул яулыгын салды, чәчен рәтләде, битен сыпыргалады. Озынча аксыл битле, тулы тәнле матур гына хатын икән. Ул иң әвәл Красновның ярасын карады. «Температурасы кимегән,—диде хатын эшлекле төстә.—Димәк, даруның файдасы бар! Яле, күзеңне ач!» Ул Красновның кызгылт төк баскан чәнечкеле битләрен учы белән йомшак кына чәбәк-чәбәк итеп алды. Теге күзен ачты һәм «Рәхмәт!»—дип пышылдады. «Томилин, мине ташлама. Әнием хакына!»—Ул сүзләрен көчкә-көчкә әйтә иде. Зәңгәр күз кабаклары селкенгәләп торды. Хатын Красновның ярасын эшкәртте дә, сулейма мае сөртеп бәйләп куйды.

—Нигә-әллә сиңа ышанмыймы?—дип, хатын Томилинга башын борды. Томилин җилкәсен кыймылдатты, сүз әйтә алмады. Аннары хатын аның хәлен белеште, балтырын да карады. Йөрәктән бу, диде. Аз гына мышьяк катнашмалы бер дару бар. Шуны кулланып карасагыз? Бик әйбәт препарат. Аны эчкәннән соң муенга, гәүдәгә чуан чыга. Үлек җыя. Соныннан ул тишелеп ага. Йөрәк мускуллары ныгый, чистара. Томилин, билгеле, риза иде. Аның авылдагы хәлләрне бик тә беләсе килә иде. Бередә артык куркыныч сизелми әле, диде хатын. Авыл юл өстендә түгел. Ләкин полицайлар бик еш күренә. Идарәләре күрше поселокта. Авылдан берничә адәм шунда хезмәт итә. Кайсын әйтәләр безнең яклы дип, кайсын немецка сатылган дип. Күбесе утырган адәмнәр, немец аларны төрмәдән коткарган... Томилин гражданский кием хакында сүз катты. «Рәтләрбез,—диде хатын.—Мондагы кеше дип, кәгазь ясап, ерактагы шахта хастаханәсенә керергә мөмкин. Әмма бик четерекле эш...»

—Юк, үзебезнекеләргә таба, тоньякка хәрәкәт итәргә кирәк,—диде Томилин.

Яралылар ун көнләп дәваланып яттылар. Краснов, ниһаять, күзен ачты. Томилин аңа, сый-тәрбия өчен хуҗаларны ни беләндер бәхилләтәсе иде бит, дип әйтте. Краснов исә, исән чакта моннан ычкыну ягын кайгыртыйк, диде. Ул хаклы иде.

Карт бик тере күренә иде. Тик кенә ятмаган. Төнлә колхозның җитеп килә торган солысын кырдан чабып ташыган. Атны да солыда тоткан. Ул элек дуңгыз фермасында фуражёр булып эшләгән. Немецлар биш йөз дуңгызны машиналарга төяп алып киткәннәр. Бар байлыкны ташып бетерәләр икән. Шуны күреп эчтә ут яна, ут дөрли. Уф, уф дип көенде карт. Безнекеләр һаман чигенәләр икән. Немец Сталинградка барып җиткән ди... Картның югалып калганлыгы бөтен кыяфәтенә чыккан иде.

Ягымлы санитар хатын төннәрен килгәләп торды. Гражданский киемнәр юнәтеп китерде. Краснов та тернәкләнә башлады. Сулейма килештеме, әллә

яшь организм үзе җинә бардымы?! Яралылар хатынга коткаручылары итеп карыйлар иде. Рәхмәт йөзеннән, ана ике командир исеменнән, документ язып бирделәр.

—Әллә безнең белән китәсеңме?—дип әйтеп куйды Краснов, күбрәк үзләрен кайгыртып инде, әлбәттә. Хатын моны сизгәндерме, юкмы, башын чайкады. Аннары кайсы тарафтан барып үзебезнекеләргә чыгарга мөмкин икәнен өйрәтте. Житмеш чакрым ары Прохоровка станциясе бар, диде. Анда немец гарнизоны тора. Көнбатыш ягыннан читләтеп үтәргә, һаман төньякка таба барырга. Авылларның исемен белмим. Немецның һөҗүме шул төштә туктатылган дигән хәбәр бар...

—Безне Прохоровка тирәсенә ат белән илт, ат белән кайтып китәрсең.

—Кире кайтып булмас шул...

Ат белән Прохоровкага чаклы илтергә карт та риза булмады. Белмәгән хәвефле юлга чыгу да бик куркыныч шул. Берничә рота полицай якын-тирәләрне айкап йөриләр икән. Тәннәрен теге вак «җанвар» бик нык кычыттыра, борчый иде. Хуҗаның пошаманга төшеп, авырыксынып йөрүенә карамастан, Томилин, йөз ертып, үзләрен юындыруны һәм эчке киемнәрне алыштыруны үтенде. Исән котылсак, бәхилләтми калмабыз дип тә әйтте. Кызыл командирлар сүзе бу, диде. Хуҗалар яралылардан ничек тизрәк арынырга белми иде кебек. Шуңа күрә тиз-тиз лаканга кайнар су салып, аларны юындырдылар. Капчыктан теккән күлмәк-ыштан да табылды...

Олаучы аз сүзле, шулай да сөйләнде: биредә ата улны, ана кызны белми, диде. Мөнәсәбәтләр чуалып, чәбәләнеп, төенләнеп беткән. Ул чәбәләнгән төенне чишү үзебезнекеләр кайткач кына мөмкин булыр. Әнә, Волошок кебек исәрләр немецка чын күңелдән бирелгәннәр. Үзебезнекеләр кайтмас дип ышана микәнни ул? Бер саплам җеп озынлыгы да уйлый алмый, ахрысы...

Көн болытлы, дымык булды. Байтак ара үттеләр. Өйләдән соң ат та әлсерәде, эче-эчкә ябышты. Ял кирәк иде. Моның өчен җайлы урын караштырдылар. Межа буенча юл өлгергән, ап-ак булып җәйрәп утырган арыш басуына килеп чыкты. Ике ягы да җигүле ат күмелерлек арыш. Аз гына җилдән башаклар кыштырдый, ниндидер ямансу аваз тараталар. Ул да түгел, алда кешеләр күренде. Олаучы яралыларны арба төбенә яткырып, өсләренә торбыша япты. Якынайгач, күренде, өч-дүрт хатын арыш чаба, берничәсе көлтә бәйли иде. Әллә бирегә немец килеп җитмәгәнме, дигән уй килә. Боларны күреп хатыннар чалгыларын сабы белән җиргә кадап карап торалар. Әллә ни шүрләмәделәр шикелле. Олаучы арбадан төште, исәнләште. Курыкмагыз, үзебезнекеләр, диде. Һәм торбышаны ачты. Хатыннар гаҗәпләнеп, куркып кына арба янына килделәр. Белешү, аңлашу китте. Биш-алты чакрымда авыл икән. Анда немецлар. Староста үзебезнен яклырак. Балалы хатыннарга немецлардан яшерен генә кышлык икмәк әзерләргә рөхсәт иткән. Барыбер әрәм булып бетәр иде. Колхоз атларын, малларын немецлар станциягә ташып бетергәннәр: Баш немец офицеры яшь кенә укытучы кыз белән яши. Шуңа халыкка йомшаграк. Бик бәйләнми. Кыз читтән килгән. Артта чыш-пыш йөри, имеш, ул кызга райком шулай кушкан.

Хатыннар тамак ялгап алырга утырдылар. Яралыларга бик тозлы кипкән ит белән ипи арттырдылар. Аннан груша чәе гаять тәмле булды. Хатыннар ашыгалар иде, көлтәләрне кечкенә ындыр табагына китереп, башаклы башын авыр таяклар белән сугалар. Көлтә җип-җиңел булып кала. Төшкән арышны һәрберсенә тигез бүлеп, капчыкларына тутыралар. Караңгы төшкәндә биштәр белән җилкәләренә асып кайтып китәләр.

Арадан берсе яралыларга юлны тәфсилләп өйрәтте. Берәү дә зар еламады, немецлар кайчанга кадәр булыр дип тә төпченмәде. Немецның вакытлы бер афәт икәнен яхшы беләләр, шикләре юк. Шул афәттән үзләрен һәм балаларын исән-имин коткару эшенә чумганнар. Бүтән мәсьәләләр аларны кызыксындырмый да шикелле иде. Билгеле инде, тыштан гына шулай бу. Житди, бер ноктага тупланган монсу карашларыннан, зәңгәрсу күз күләгәләреннән эчләрендә ут янганын чамаларга була иде.

Ниндидер коры үзән, чокыр-чакыр, тирән яр кырларына урнашкан авылга күз бәйләнгәч килеп туктадылар. Текә таучык өстендәге урта кул йорт-жирле, ихаталы гаилә аларны кабул итте. Хужа урта яшьләрдәге, жыерчыклар ермачлаган тар битле аксак кеше иде. Чакырылмаган кунаклар килгәнгә ул куанды шикелле, яралыларны өйгә ашыга-ашыга урнаштырды. Бүлмәдә сукыр ут яна иде. Анын жәһәт кылануы аңлашылды, ул салмыш иде. Кунакларга да чирек шешә белән самогон куйды. Кабарга—тозлы кәбестә, катлама итеп пешергән соры түгәрәк нәрсә. Хужа кыстый-кыстый эчерә иде. Стаканга салганны бетерми тынмый. Янында басып тора. Яралылар башта шикләнә калдылар: берәр мәкер белән сыйламыймы? Хатыны да кара коелып орым йөри иде. Бераздан сизделәр: хужа салырга әвәс икән, һәрчак «юеш» икән. Эчәргә сәбәп табылганга өтәләнгән. Тагын шул: ул бер дә сагаймый, кычкырып сөйләшә. Немецларны варварлар дип атый.

Атны яр астына, куаклыклар артына яшерделәр, үзләрен иркен чормага урнаштырдылар. Монда ике лейтенант унбиш көн качып ятты, диде хужа, ничектер ярарга тырышып.

Иртән йорттагы тавышка уяндылар. Ярыктан карасалар, ишек төбендә—автоматлы немец, полицай һәм бер таза гына хатын. Алар янында титаклап хужа бөтерелә. Тынлый торгач, аңладылар, утыз бишенче елда бер байны раскулачить иткәндә, танасын алып бу аксакка биргәннәр. Яна власть килгәч, элекке хужа сыерны кире бирүне таләп итә. Ул хатын хәзер немец конторында жыештыручы икән.

—Без аңа түләдек бит!—Хужа бер полицайга, бер хатынга таба муенын сузып кычкыра. Муены сырлы-сырлы ишкән юан бау сыман.

—Түләден шалкан бәясе!—Хатын бер дә чәүчәләнми, үзен бик тыныч тота. Хаклык үз ягында булуына аркалана кебек.

—Давай, чыгар!

—Юк, мин үзем алмадым, миңа сельсовет бирде. Һе! Асат кына!

—Чыгар сыерны!

Сыер хужасы чәтер хатын кулларын алга суза-суза тәтелдәргә тотынды:

—Син сыерны барыбер сатып эчәчәксең. Сиңа теге елда калай түбәле яхшы йорт бирделәр. Бай Кирилл йортын. Кайда ул? Син аны сатып эчеп бетердең. Башта түбә калаен саттың. Сыерны да бетерәчәксең. Чыгар! Нәселле ул.

—Юк, бетермим,—диде аксак, шактый какшый башлап. Немец, кыбырсып полицайга боерды, ияге белән абзарга ымлады. Полицай шунда ук йөгерә-түртелә сыерны муенчаклап алып чыкты. Аксак кинәт муенчакка атылды, әмма немец автоматын терәде: «Вег! Вег!»—дип акырды. Элеккеге хужа, чәтер хатын мунчакны тотып, карышып торган сыерны юлга тарта иде. Полицай чыбык алып бик каты сыптыргач, сыер бик тиз капкага таба атлап китте. Аксак ачулы үртәлү белән: «Тьфү»—дип акырып калды.

Кичтән юлга чыгарга омтылганнар иде, аксак жибәрмәде. Ана ат кирәк

булган икән. Ерак түгел генә тегермән бар, ди. Каравылчыларын атканнар. Складта бик күп он калган. Төнлә аксак белән олаучы дүрт капчык алып кайттылар. Өчесе хуҗага, берсе олаучыга. Кире кайтканда запас булыр, диде. Адәм баласында нәфсе алдан йөри бит. Кайта аламы-юкмы, әле билгесез, чөнки сират күпере кичеп баралар.

Оны шәп икән. Хуҗа хатын иртән кабартмаларны табага өеп куйган иде. Күптән мондый тәмле ризыкның авызга кергәне юк. Хуҗа төшереп алган, юлчыларны кыстый да кыстый. Аның үз нияте бар икән: атны мина калдырыгыз, ди. Сездән аны барыбер алырлар, дия-дия, яралыларга, олаучыга башын кыегайтып карап катты. Ин элек олаучы телгә килде. Аның үз мәнфәгате көчле. Ул атны үзенә калдыру өчен ничә көннән бирле казгана. Ат минеке, үземә кирәк, диде. Юк, диде хуҗа сары чәчле башын болгап-болгап: ат командирларныкы, хәрби частьныкы... Олаучының күзе акайды, ул кызганыч бер кыяфәткә кереп яралыларга текәлде. Хуҗа минем артта сөйләшеп аларны үз ягына аударганмы, янәсе. Томилин, күпереп торган кабартмага чөгендер повидлосы яга-яга: «юк,—диде,—ат олаучыга була! Башта ук шулай килешенгән иде...» Хуҗа ык-мык итте. Бирегә фронт ерак түгел, ди. Ут эченә ат белән бару мөмкин булырмы? Алгы сызыкта немец солдатлары мыж инде. Миндә яшәгән лейтенантлар алгы линиянең өзек җирен ничектер белделәр. Шуннан үзебезнең якка чыкканнар булса кирәк. Икесе дә яралы, юан таякка ике куллап таянып, аякларын өстерәп алалар иде.

Яралылар да дәшмәде, олаучы да. Шулай да аның эченә пошаман кергәнлеге йөзенә кара коелудан сизелә иде. Караңгы төшкәндә алар юлга кузгалдылар.

Олаучы ачулы иде. Атны башка вакытка караганда ныграк куа. Яктырганда бер урман юлына төштеләр. Туптан аткан тавышлар ачыграк ишетелә. Урман ерактагы тавышларны көчәйтәме, әллә чынлап та алгы сызыкка якынлашып киләләрме? Ә юл шактый йөрелгән, казылмаланган. Ләкин машина кермәгән кебек. Урманда янга борыла торган ташландык юл бар иде, олаучы атны шуннан алып китте. Юл түбәнгә таба, ниндидер елгагамы, чокыргамы төшә. Күп тә үтми акшарлы, текә кыеклы йортлар күренде. Авыл астарак, алар авылның йөрми торган башына килеп чыкканнар. Томилин дилбегәгә тотынды. Олаучы атны куелык артына тартып туктатты. Күзәтеп тора башладылар. Бер дә төтен чыкканы, кешеләр йөргәне күренми. Авылны әллә ташлап киткәннәр, әллә яшеренеп яталар.

Караңгылык иңә башлагач кына түбәнгә текә җирдән төшеп, ин кырыйдагы бөтен ихаталы, тәрәзә капкачлары буяулы йортка туктадылар. Җил капкадан эчкә үтеп, өй ишеген дөбердәттеләр.

Хуҗалар—таза бәдәнле, юан балтырлы хатын һәм юка гәүдәле озын буйлы ир —читенсенмичә каршы алдылар. Атны тугарып, арбаны эчкәре лапас артына яшерделәр. Бирегә немецларның күренгәннәре дә юк икән. Бу якларда калын урманнар, чолганышта калган частьларның кайбер төркемнәре шушында җыелган ди. Кораллы отрядлар булып бирегә күренгән немецларны кырып ташлыйлар икән...

Хуҗабикә, кадерле кунаклар килгән кебек шатлыклы йөз белән, өстәлгә табын әзерли. Ни өчен шулай йөргүе бераздан аңлашылды. Малае юка гәүдәле озын төксе егет—төрмәдән чыккан икән. Немецлар шәһәргә көтмәгәндә танклар белән кергәннәр. Танкларга каршы ата торган корал бездә юк икән... Хуҗа хатын гөбедәй юан балтырларын ялтыратып каядыр чыгып китте. Томилин сагаеп калды.

Итле борчак чумары бик тәмле иде. Чиректе шешә белән куксел төстәге самогон да килде, «первач!»—дип куйды егет шатланып. Егет бер тәлинкәгә

аз гына самогон агызды, шырпы кабызып өстенә китерде. Самогон зәңгәрсуланып яна башлады.

Эчемлек көчле, тамырларга тиз йөгерде. Яралыларны бик тиз җебетте. Егет тә кызды. Башта олаучы белән бәхәскә керде. Ул, ни әйтсән, шуна каршы килеп сөйләшә торган кеше икән. Берәр нәрсәне яхшы дисәң, юк, ул начар дип бәхәсләшә. Начар дисәң, юк, син белмисең, ул яхшы дип дәлилләргә тотына иде. Кыза төшкәч, олаучының чумар кебек җилсенгән күз кабаклары ачылып китте.

—Мин ары бармыйм, борылам,—дип куйды ул, якында гына ишетелгән ату тавышларына ымлап.

—Юк, син безне үзебезнекеләргә чыгарырга тиеш!—диде Краснов тавышын күтәреп. Самогоннан аның күзләре урыныннан купкан иде. Ул үзен тормозда тота алмаган төсле күренде

—Юк, мин бурычымны үтәдем, булды, житте...—Олаучының сары төк баскан битләре мәче сырты сыман кыймыл-кыймыл килде.

—Мин РККА комиссары, аңлыйсыңмы? Карышсаң, беләсеңме нәрсә буласын? Трибунал! Краснов йодрыкларын йомарлап олаучыга ташланмакчы итеп талпынды. Арага озын егет керде. Кулларын кире тибәреп Красновны урынына утыртты.

—Комиссар булдым дигәч тә, син кем ул тикле?—Егет тә кызган, аның озынча кытыршы битләренә алсу таплар типкән.—Звание кешенең ниндилеген билгеләмиии...—Ул, дерелдәвен күрсәтмәс өчен, кулын аска яшерде. Кыяфәтеннән бик нервлы, тиз сүтелә торган зат икәне сизелеп тора иде.

—Ыбыр-чыбырга звание бирмиләр!—Краснов бик каты кычкырып куйды да, йодрыгы белән өстәлгә сукты. Нишләгән ул, бөтенләй үз-үзен белештерми кебек. Томилин аның җилкәсеннән тотты. Җилкә дер-дер килә иде.

—Активистка, әләкчегә бирәләр,—дип кычкырды егет тыела алмыйча,—тизәккә шпал ябыштыралар да, кешегә әйләндерәләр. Шул тизәк командалык итә. Әнә ни өчен һаман чигенәләр? Тизәкләр баш булган өчен!

—Отставить антисоветчинаны!—Краснов шашынулы тавыш белән кычкырды.

—Мине бер гаепсезгә яла ягып утырттылар.—Егетнең тавышы калтыранып өзелде.

—Дөрес утыртканнар!—дип ярсыды Краснов.

—Әһә, дөресме?!—Егет сикереп торды, Томилин аша сузылып Красновның якасыннан чытырдатып алды да, буа башлады. Ачудан тешләре шакыр-шыкыр килә иде. Краснов ике куллап тегенең кулларын бугазыннан алмакчы булып тартыша. Тыны кысылудан «кырк-кырк» итеп сулышын рәтли. Битләре күкселләнде. Томилин арага кереп егетнең бер кулын эләктерде дә самбо ысулы белән артка каера башлады. Егет аңа бик каты типте. Томилин урындыгы белән идәнгә тәгәрәде. Егетне дә үзе белән өстерәде. Олаучы Красновны кочаклап алды.

—Котырган! Үтерә яздың бит!—дип егеткә кычкырды. Егет хәтәр шүрләп, күзләрен акайтты һәм җәһәт кенә торды да, бәладән баш-аяк дигәндәй, шыкаеп өйдән чыгып шылды. Ул тәмам айнып беткән төсле иде. Олаучы, Красновның башын ияк астыннан тотып, авызына самогон койды. Ул күзен ачты. Башын ике учына алды да, нишләдем мин дигән шикелле, уф-уф-уф дип пошкырынды. Олаучы аны иплән кенә тотып идәнгә яткырды. Үзе бу болгавыр моменттан файдаланырга ашыкты.

—Мин киттем!—диде дә, җәһәт кенә ишек артында юк булды. Билгеле, самогон аңа да кыюлык биргән, тизлек өстәгән иде. Аның атны җигеп,

шалтор-шолтыр чыгып барганы ишетелде. Өй тынып калды, хатын өйдә юк иде булса кирәк, үзен белгертмәде...

Алар бик соң уяндылар. Өйдә шылт иткән тавыш юк. Нәрсә бу? Ташлап киткәннәрме? Хәзер кая барырга? Томилин идәндә яткан жиреннән башын күтәрде. Краснов торып утырган, иптәшенә карарга унайсызланып, ярасының бинтларын сүтә. Теге санитар хатын запас дару биргән икән. Кечкенә колбадан бармагы белән алып ярасына сөртә иде. Ләкин балтыры кызарып шешә түгелме? Гангрена башланганга охшый.

—Кичә, тьфү, әйтергә оят, шайтан алгыры!—дип куйды башын якякка чайкап. Бинтын урап бетерде дә, аягын сузарга итте һәм «а-а-а» дип кычкырып куйды. Аягы язылмый башлаган икән.

—Син кулын каермасаң, теге сволочь минем эшне бетерә иде,ә?—дип Томилинга карады.

—Бик ачулы иде,—диде Томилин,—Төрмәгә утыруының бөтен үчен синнән алмакчы булгандыр.

—Моны болай гына калдырырга ярамый...

—Чү, чү, шыпырт бул, зинһар!—Томилинның шөбһәдән күз аклары чыкты.—Ачуга җибәрсәң, безне немецка бирер дә куяр. Нишли аласын?

—То-то шул, теомать!—Краснов мөгрәгән кебек аваз салды.—Уйлама, яхшылыгыңны онытмам...

—Бәладән котылуга онытачаксын,—диде Томилин юри-мырый тонда. Краснов үзен барлаган шикелле уйга калып торды. Төрттерүне сизде.

—Мин принципиаль кеше, юк, онытмам!

—Принцип бит яхшылыкны танымый, принципны гына белә!

Томилин сүзләреннән соң Краснов тагы уйга калып торды. Ләкин сүзне дәвам итмәде.

Кояшта уңган озын кожан киеп теге егет кайтып керде. Ишек тупсасына утырды да: «Әйдәгез, үзебезнең якка озатып куям»,—диде боларга карамыйча гына. Яралылар ни әйтергә белми күзләрен тасрайттылар. Сынап карап торганнан соң, Краснов авызын ачты:

—Син совет кешесеме?—дип сорады кырыс кына. Кичен булган хәл өчен егетнең үзен гаепле тоюын чамалап алган иде ул.

—Белмим,—диде егет теләмичә генә. —Төрмәдә советлыгымны кыйнап бетерделәр, шулай да кеше галәмәте бар әле. Дүрт яралы командирны үзебезнекеләргә чыгардым. Менә язу бирделәр. Ул кесәсенә тыгылды.

Томилин ашыга-ашыга:

—Ах, нинди честный парин икәнсең! Молодец, ышанабыз!—диде, йөзе-кыяфәте яктырып.—Безнең белән бергә чыкмыйсыңмы соң?

—Юк, мине анда тагын утыртачаклар. Менә бу комиссар ишеләр...—Ул рәнжегән төскә кергән, шешенке күз кабаклары салынып төшкән иде.

—Комиссарның бер аягы язылмый, нишләргә?—Томилин егеткә гозерле чырай белән карады. Егет чыгып китте һәм ике сәгатьләп йөреп кайтты. Кулында балта белән генә эшләнгән кәстил һәм кәкре таяк иде.

Бу тирәдә тирән-тирән ярлар, үзәннәр, җәһәннәм чокырлары икән. Барысы да куе урман, куаклыклар белән капланган. Төн кебек караңгы, куркыныч урыннар. Немец бирегә баш тыгарга шүрли, ахрысы. Шунын өстенә безнекеләр дә ерак түгел.

Тар гына урман сукмагыннан бардылар. Краснов бик тиз хәлдән тайды. Ял итәргә вакыт юк иде. Егет Красновны баш ягыннан күтәреп култыгына алды. Томилин аякларыннан күтәреп титаклады. Хәл кергәч, Краснов тагы кәстилләренә тотынды. Текә яр кырына җитеп туктадылар. Бик текә, кәстил белән дә, икәү күтәреп тә атлау мөмкин

түгел иде. Егет практик яктан зиһенле икән, кожанын салып жиргә җәйде дә, Красновны шуңа яткырды һәм аска таба шудыра башлады. Томилин, артына утырып, үкчәләренә таянып алга хәрәкәт итә, тегеләр артыннан өлгерә иде.

Бик озак газапландылар. Яр төбенә төшеп, күпереп торган коры мүкле түмгәккә килеп аудылар. Егет кыр сумкасыннан алып, берәр сынык катламага шырпы кабы кадәр дуңгыз мае куеп аларга бирде. Үзе дә капкалады. Төнне шунда уздырырга туры килде. Аткан тавышлар еракта иде кебек. Ләкин урман кайтаваз ясап аларны якынайта кебек. Ә ракета яктысы төнне зәңгәргә әйләндереп тора да, сүнгәч, тагын дегеттәй куе караңгылык чорный. Сискәндереп мәче башлы ябалак шырыйлап кычкыра, канатка канат бәргәләнгән авазлар килә. Карчыга ниндидер кош белән тамак ялгый булыр.

Төн шактый озын булды. Көз үзен белдерә башлаган икән. Яктырып килгәндә дер-дер килеп уяндылар. Егет кыр сумкасыннан бер кара катлама, бер кисәк дуңгыз мае чыгарды. Шуны өчкә тигез бүлеп капкалап алдылар. Кузгалганчы Томилин егеттән кәгазь, карандаш алып үзләрен коткаручы турында белешмә язды. Красновтан да имза куйдырды.

Сукмак баткаклы иде, кәстил белән бару мөмкин түгел. Красновны икесе ике баштан күтәреп бардылар. Бер инеш янына килеп җиткәндә хәлләре бетте. Суы сай гына, тармак-тармак булып ага. Тагын егеткә авыр баш туры килде. Ул Красновны күтәреп сул җилкәсенә җайлады. Шапор-шопыр суга кереп китте. Су итек кунычына аз гына житми иде. Томилин суны ишә-ишә кәстилгә таянып атлады. Яр сөзәк иде, чирәмгә авып, Томилин итек эченә кергән суны түкте. Ыштырларын сыгып чорнады. Байтак кына бер ягы урман, икенче ягы буш кыр буенча бардылар. Карасалар, биек ярга килеп төртелгәннәр икән.

—Хәзер ерак түгел, үзегез...—дип, егет кәстилләрне алды да саубуллашып та тормыйча, китте дә барды. Котылдым бу имгәкләрдән дигән кебек иде. Күз ачып йомганчы агачлар арасында юкка чыкты. Болар, нишләргә инде дип, башларын күтәреп карасалар, берничә карабинлы кызылармеецның яр башыннан аска таба чабып төшкәнен күрделәр.

Беренче тикшерү-пропуск пунктында аларны аердылар. Бу нәрсә? Томилинның эченә шом төште. Коридорда очрашкач, Краснов сөйләшергә теләмәде. Ул төсе-кыяфәте белән үзгәргән иде. Күзләрендә ниндидер эчке мәкерле яшерен куаныч очкынлана. Яннан гамьсез генә узып китүен ничек аңларга? Яхшылыгыңны гомергә онытмам дигән антлары кая? Сабын куыгы гына булдымыни? Бергә күпме газап чиккән, үлемнән бергә көч-хәл белән ычкынган, зур бәхетсезлектән котылдырган кешене ничек дошман күрергә мөмкин? Юк, аң кабул итми моны.

Әле ул гынамы? Бераз соңрак Красновның әшәке эче тагын да ачылды. Томилинның ярасы төзәлеп беткәндә аның белән трибунал тикшерүчесе кызыксынды. Кайбер хәлләрне ачыклар өчен генә дип сорашты, белеште. Берничә көннән тагын килде. «Томилин, син хәрби җинаять кылучы булып гаепләнәсең,—диде.—Теге вакытта төзелгән протокол һәм комиссар Краснов күрсәтмәләре буенча җинаять эше кузгатыла. Менә арест өчен ордер...»—Ул кулындагы папкасын ачып, бер бит кәгазь алды да Томилинга сузды. Ул арада мылтыклы ике НКВД кешесе аның янына килеп басты.

Томилин Казанның Комлев урамындагы госпиталендә дүрт айдан артык дәваланган иде. Шуннан аны Кремль буендагы төрмәгә илтеп яптылар.

Ә бит мин Красновны калдырып үзем генә чигенә ала идем. Алай эшләсәм, башка ситуациягә эләгә идем. Үткәнемне белүче дә, барлаучы

да булмас иде. Алай итәргә намусым кушмады. Красновны кызганып үземә бәла алып чыкканмын. Юләр, юләр! Янәсе, иптәшлек хакы бар, бергә хезмәт итү хакы!? Ә Краснов боларның барысына төкереп биргән. Карьерасы өчен кешелеклелеген югалткан, иптәшен саткан! Ул һаман әйтә иде: кызгану үзеңә бәла булып төшә, кызгануга бирелмәгез, дип... Кызгану хисе булмаса, адәм баласы вәхшигә әйләнә бит. Әнә немецлар нинди ерткыч җанварлар! Ләкин дошманнарга карата шулай. Үз милләттәшләренә алай аяусыз түгелләр, ди.

Томилинга өч ел бирделәр. Ул штрафбатка җибәрүне сорап гариза язды. Аны фронтка озаттылар. Алгы сызыкта безнең һөҗүм вакыты иде. Томилин Митава шәһәрен штурмлаганда һәлак булды.

Краснов кабат фронтка бармады. Хәрби комиссариатта эшләде. Аннан райком инструкторы булып йөрде. Бераздан райком секретаре итеп куйдылар үзен. Бик әйбәт, өстенлекле, житеш тормышта гомер кичерде. Кискен хәлләрдә үзен коткарган, гомерен саклап калган Томилин турында бервакытта да исенә төшермәде, уйлап та карамады.

---




*Бөек Җиңүгә 65 ел*

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЕЛЪЯЗМАСЫ

ЖУРНАЛЫБЫЗ—БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА

**1941 ел.** «Совет әдәбияты»ның 5 (май) санында Габдрахман Әпсәләмовның «Йөрәк ярасы», Атилла Расихның «Очрашу», Мин Шабайның «Бер төн» хикәяләре, Сибгат Хәкимнең «Гайшә» поэмасыннан өзек һәм Зәки Нури шигырьләре дөнья күргән.

**1942 ел.** «Совет әдәбияты»ның 5 (май) санында Фатих Кәримнең «Гөлсем» поэмасы, Хатип Госманның «Сугыш көндәлеге», Әхмәт Фәйзинең сатирик шигырьләре басылган.

**1943 ел.** «Совет әдәбияты»ның 5 (май) санында Гомәр Бәшировның «Мунча», Хатип Госманның «Мәче баласы», Фатих Хөснинең «Чүлмәк түбәле өйдә» хикәяләре, Фатих Кәримнең «Үлем уены» поэмасы, Әнәс Камалның «Беренче апрель» пьесасы һәм Нури Арсланов, Әхмәт Юныс, Сибгат Хәким шигырьләре чыккан.

**1944 ел.** «Совет әдәбиятының 5 (май) санында Нәкый Исәнбәтнең опера өчен «Түләк батыр» либреттосы, Ибрай Газиның «Алар өчәү иде», Гомәр Бәшировның «Бер төн», Фатих Хөснинең «Хуторда» хикәяләре, Салих Баттал һәм Шәрәф Мөдәрриснең ватанпәрвәр шигырьләре дөнья күргән.

**1945 ел.** «Совет әдәбияты»ның 5 (май) санында Әхмәт Ерикәйнең, Мөхәммәт Садриның һәм Тажи Гыйззәтнең ватанпәрвәр шигырьләре, Дәржия Аппакованың балалар өчен хикәяләре басылган.

## СОВЕТЛАРНЫҢ БӨТЕНРОССИЯ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ДЕКРЕТЫ

# АВТОНОМИЯЛЕ ТАТАРСТАН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ ТУРЫНДА

*1920 елның 27 мае*

**Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карар итәләр:**

I

1. Россия Социалистик Федератив Совет Республикасының бер өлеше буларак Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасын бар итәргә һәм аның составына кертергә:

а) Казан губернасыннан: Казан, Лаеш, Мамадыш, Свияжск, Чистай, Тәтеш һәм Спас өязләрен—Жидяев һәм Йорт-күл волостьларыннан башка. Алабуга өязенең Черкас һәм Салавыч волостьларын, Краснококшай өязенең Күлле Киме һәм Кышлау волостьларын;

б) Уфа губернасыннан: Минзәлә өязен;

в) Самара губернасыннан: Бөгелмә өязеннән Азнакай, Александровка, Әлки, Әлмәт, Баулы, Богоявленский, Варварино, Югары Карамалы, Каратай, Кузайкино, Ивановка, Мәсәгүт, Микулино, Мордовское Афонькино, Мордовская Ивановка, Мордовская Кармалка, Түбән Чыршылы, Яна Писмән, Салих, Спас, Спиридоновка, Стәрлетамак, Сумарохово, Тымытык, Урсалы һәм Чиканас волостьларын;

г) Вятка губернасыннан: Малмыж өязенең Кошкино, Носы, Арбор, Янгул, Сәрдекбаш, Нижне-Четаево һәм Шуда волостьларын;

д) Сембер губернасыннан: Сембер өязенең Сөендек, Олы Тархан һәм Б.Цильна волостьларын, Буа өязенең Старо-Студенец, Янтуган, Шыгырдан, Яңа Кәкерле, Чүпрәле, Мәчәле, Борындык, Рунга, Тимбай, Убей һәм Городище волостьларын.

Искәрмә: Татарстан Социалистик Совет Республикасы составына Уфа губернасының Бәләбәй һәм Бөре өязләрен кертү мәсьәләсен әлеге өязләр хезмәт ияләре үз ихтыяжларын белдергәнгә кадәр ачык калдырырга.

2. Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасының дәүләт власте аппараты, РСФСР Конституциясендә каралганча, жирле депутатлар Советларыннан, Үзәк Башкарма комитетыннан һәм Татарстан Социалистик Совет Республикасының Халык Комиссарлары Советыннан хасил була.

3. Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасының эшләрен идарә итү өчен түбәндәге Халык комиссариатлары булдырыла: 1) Эчке эшләр—почта һәм телеграф идарәсе белән, 2) юстиция, 3) мәгариф, 4) сәламәтлек саклау, 5) социаль тәэминат, 6) игенчелек, 7) азык-төлек, 8) финанс, 9) халык хужалыгы Советы—хезмәт һәм элемтә юллары бүлекләре

белән һәм 10) эшче-крестьян инспекциясе.

Искәрмә: Чит ил эшләре һәм тышкы сәүдә тулаем РСФСРның Үзәк органнары карамагында кала бирә. Хәрби эшләр белән турыдан-туры якындагы Округ хәрби комиссариатына буйсынган Татарстан хәрби комиссариаты шөгыльләнә. Контрреволюция белән көрәш Бөтенроссия Гадәттән тыш Комиссиясе Татарстан Халык Комиссарлары Советы белән килештереп оештырган Бөтенроссия Гадәттән тыш Комиссиясе органнары карамагында кала.

4. РСФСРның финанс һәм хуҗалык сәясәтенең республиканың бөтен территориясендәге бербөтенлеген саклап калу максатында Татарстан Социалистик Совет Республикасының азык-төлек, финанс, халык комиссариатлары, халык хуҗалыгы Советы, хезмәт һәм элемтә юллары эшче-крестьян инспекциясе бүлекләре, эчке эшләр халык комиссариаты каршындагы почта һәм телеграф идарәсе тиешле РСФСР Халык комиссариатларының турыдан-туры буйсынуында калалар, аларның фәрманнарын һәм инструкцияләрен үтәргә тиеш булалар.

5. Татарстан Социалистик Совет Республикасының эчке эшләр (почта һәм телеграф идарәсеннән башка), юстиция, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат һәм игенчелек Халык комиссариатлары үз эшгамәлләрендә мөстәкыйльләр һәм турыдан-туры ТССР Үзәк Башкарма комитеты алдында җаваплы.

6. Казан Советы Рәисе Татарстан Халык Комиссарлары Советы составына хәлиткеч тавыш хокукы белән керә.

7. Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы бөтен кирәкле финанслар һәм техник чаралар белән РСФСРдан тәэмин ителә.

8. Татарстан Социалистик Совет Республикасының 1нче съезды чакырылганга кадәр Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасында хәзерге положениедә күрсәтелгән чикләрдә хакимият бөтен тулылыгында Татарстан Социалистик Совет Республикасының Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан бар ителгән Вакытлы революцион комитеты кулында була. Әлеге комитетның иң әүвәлге бурычы Татарстан Социалистик Совет Республикасының 1нче Советлар съездын чакыру һәм революцион комитетның Татарстан Социалистик Совет Республикасының бу положениенең 3нче пунктында күрсәтелгән бүлекләренә тәңгәл килгән бүлекләрен оештырудан гыйбарәт.

9. Эчке эшләр Халык Комиссариатына һәм Милләтләр эшләре Халык Комиссариатына Татарстан Социалистик Совет Республикасының чикләрен җентекләп билгеләгәндә туарга мөмкин мәсьәләләрне хәл итү өчен катнаш комиссия оештыру йөкләнә.

*Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты рәисе* **М. Калинин.**
*Халык Комиссариатлары Советы рәисе* **В. Ульянов (Ленин)**
*Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты секретаре* **А. Енукидзе**

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

**Риза Ишморат** *(1903–1995)*



1903 елның 1 ноябрендә хәзерге Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында туа.

Егерменче елларда беренче сатирик комедияләрен яза.

Сугыш башлангач, ул фронтка китә. Беренче Украина фронтында татар телендә чыккан «Ватан намусы өчен» исемле газетаның башта—хәрби мөхбире, соңыннан җаваплы мөхәррире сыйфатында Воронеждан Берлинга кадәр авыр сугыш юлы уза, Берлиндагы урам сугышлары вакытында каты яралана.

Сугыштан соң Риза Ишморат тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә, танылган драматургка әверелә.

**Хәмит Кави** *(1906–1944)*



1906 елны хәзерге Чуашстанның Козлов районы Әлмән авылында туа.

Утызынчы елларда ул фәнни-популяр характердагы очерклар, мажаралы хикәя-повестьлар яза, бер-бер артлы унлап китап бастырып чыгара.

1941 елның сентябрендә Хәмит Кави фронтка китә һәм Совет Армиясе командиры сыйфатында Идел буеннан илнең көнбатыш чикләренә кадәр сугышчан юл уза. 1944 елның 15 июлендә Украинаның Волынск өлкәсендәге Друженополь авылы тирәсендә барган сугышларның берсендә ул батырларча һәлак була.

**Сәет Кальметов** *(1918–1992)*



1918 елның 20 апрелендә хәзерге Башкортстанның Яңавыл эшчеләр бистәсендә туа.

1943 елның җәендә үзе теләп фронтка китә һәм Беренче Украина фронты гаскәрләре составында Берлинга кадәр сугышчан юл уза.

Сугыштан соң Сәет Кальметов драматург буларак киң танылу ала.

### Әгъзам Камал *(1918–1943)*



1918 елның 21 гыйнварында Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында туа.

Утызынчы елларда ул «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли, бер-бер артлы шигырь китапларын бастырып чыгара.

Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Әгъзам Камал алгы сызыкта сугыша. Канлы бәрелешләрнең берсендә авыр яраланып, шактый вакыт госпитальдә дәвалана, аннары Саратов шәһәрендәге хәрби училищены офицер дәрәҗәсе алып тәмамлаганнан соң, ул кабат үз гаскәри берәмлегенә—Сталинград фронтына кайта һәм, андагы хәлиткеч сугыш операцияләрендә күп мәртәбәләр катнашып, 1943 елның 16 маенда дошман пулясыннан һәлак була.

### Хисам Камал



1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылында туа.

1943 елның ноябрендә унсигез яше дә тулмаган үсмер егетне гаскәри хезмәткә алып, 1944 елның апреленә кадәр мәгълүм Суслонгер хәрби лагерьларында әзерлек курслары үткәннән соң, май башында фронтка озатыла. Ул икенче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында бик күп канлы бәрелешләрдә катнаша, 1944 елның җәендә яраланып, өч ай чамасы госпитальдә ятып чыга, аннары янадан фронтның алгы сызыгына җибәрелә, артиллерия полкының кыр элемтәчесе сыйфатында Латвия җирләре аша Польша чикләренә кадәр сугышчан юл уза. 1945 елның 26 февралендә Хисам Камал кабат яралана һәм янәдән госпитальгә озатыла. Бу юлы җәрәхәт бик житди булып, аңа ел ярым төрле госпитальләрдә дәваланырга туры килә, ахырда бер аягын төптән кистереп, 1946 елны өенә кайта.

Сугыштан соң Хисам Камал шагыйрь һәм прозаик буларак танылды, роман-повестьлар язып күренекле әдипкә әверелде.

### Әнәс Кари *(1920–1954)*



1920 елда Татарстанның Азнакай районы Уразай авылында туа.

1942 елның көзендә Әнәс Кари фронтка китә, Орлов тирәсендә барган канлы сугышларда катнаша һәм, каты яраланып, ахырда армия хезмәтеннән бөтенләй азат ителә.

Әнәс Кари үзенең кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлый, алар өчен язган шигырь, поэмалары белән танылa.

### Фатих Кәрим *(1909–1945)*



1909 елның 9 гыйнварында хәзерге Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында туа. 1925-1929 елларда ул Казан жир төзелеше техникумында укый. Әдәби иҗат эше белән житди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына карый. 1929 елдан хәвефле 1937 елга кадәр аның ун китабы басылып чыга (икесе—проза, сигезе—шигъри җыентыклар). Шагыйрьне 1938 елның 3 гыйнварында кинәт кулга алалар. Ф. Кәримне ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә, шуңа өстәп, тагын биш елга гражданлык хокукларыннан чикләргә дигән хөкем карарын чыгаралар һәм сәяси

тоткыннар лагерена (совет концлагерена) озаталар. 1941 елнын 1 декабрендә, канлы сугышлар барган көннәрдә, Ф. Кәримне иреккә чыгаралар. Ләкин бер шарт белән: ул «үз теләге белән» фронтка китәргә тиеш була.

1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр, ягъни өч ел буена, Фатих Кәрим фронтның алгы сызыгында була, солдат һәм кече офицер, взвод командиры сыйфатында Мәскәү яныннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугышчан юл уза, Украинаны, Белоруссияне, Карпат илләрен азат итүдә катнаша, ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Ә сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була. Күмелгән урыны шундагы Туганнар каберлегендә.

1941-1945 еллар арасында ул тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык исемдә шигырь иҗат итә.

## Әбрар Кәримуллин *(1925–2000)*



1925 елның 29 маенда Татарстанның Саба районы Чәбия-Чурчи авылында туа.

1943 елдан Ә. Кәримуллин солдат-автоматчы, разведчик һәм сиксән ике миллиметрлы миномет наводчигы сыйфатында Ватан сугышы фронтлары буйлап сугышчан юл уза, Украина, Румыния, Венгрия, Чехословакияне азат итүдә, Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, өч тапкыр яралана, контузия ала, шәхси батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Әбрар Кәримуллин күренекле әдәбият галименә әверелә.

## Гадел Кутуй *(1903–1945)*



1903 елның 28 ноябрендә хәзерге Пенза өлкәсендәге Татар Кынадысы авылында туа.

1920 елда унҗиде яшьлек Г. Кутуй белем алуын дәвам иттерү, татар әдәбиятына якынрак булу өчен Казанга килә. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге дә активлашып китә. 1923 елгы «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының дүртенче, бишенче саннарында «Яшь футурист шагыйрь» дигән баш белән Г. Кутуйның бер бәйләм шигырьләре басылып чыга. 1924 елда исә «Көннәр йөгергәндә» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә, тора-бара пьесалары сәхнәгә чыга.

1935 елда исә «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының тугызуникенче саннарында атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повесте басылып чыккач, әдип бөтен илгә танылa.

1942 елның июнендә Гадел Кутуй фронтка китә, әүвәл Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә. Аннары шул ук бригада составында Волхов, Курск, Брянск, Великие Луки һәм башка бик күп шәһәрләрне азат итү сугышларында катнаша. 1944 елның көзендә Беренче Белоруссия фронтындагы татар телендә чыга торган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә, иҗат эшен дә дәвам иттерә: фронт газеталарында хәбәрләр, мәкаләләр бастыра, әдәби монтажлар төзи, 1944 елда Казанга вакытлыча иҗади ялга кайткач, балалар өчен «Рөстәм мажаралары» исемле хыялый романын яза. Шул ук чорда аның «Без—сталинградчылар» (1944) һәм «Сагыну» (1945) исемле солдат хисләрен сәнгатьчә югарылыкта сурәтләгән атаклы нәсерләре иҗат ителә.

Сугыш бетәр алдыннан, 1945 елның язында, Г.Кутуй, сәламәтлеге начараеп, хәрби госпитальгә эләгә һәм 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеж шәһәрендә вафат була. Кабере Згеж шәһәре зиратында.

## Кави Латыйп *(1927–2008)*



1927 елның 1 маенда хәзерге Чуашстан Республикасының Батыр районы Кызыл Чишмә авылында дөньяга килә. 1941 елны туган авылы мәктәбендә жиде сыйныф тәмамлагач, ул район үзәге Батыр авылында урнашкан педагогия училищесының татар бүлегенә укырга керә. 1944 елның көзендә аны армиягә алалар, фронтка озаталар. Ул махсус гаскәри берәмлек сафларында хезмәт итә, фронтның алгы сызыгындагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

Сугыштан соң Кави Латыйп шагыйрь һәм прозаик буларак таныла.

## Мөнир Мазунов *(1918–1987)*



1918 елның 1 апрелендә хәзерге Пенза өлкәсенең Лопатин районы Иске Карлыган авылында туа. Авылда жидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1935-1938 елларда Әстерхан педагогия техникумында белем ала, аннан бер ел Ижевск шәһәрендәге урта мәктәпләрнең берсендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1939 елда Совет Армиясенә алынып, Ватан сугышы елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. 1945 елның жәендә, «Тревога» исемле фронт газетасының алгы сызыктагы корреспонденты буларак, япон гаскәрләренә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

Сугыштан соң Мөнир Мазунов балалар шагыйре һәм халык яратып кабул иткән жырлар авторы буларак таныла.

## Мәхмүд Максуд *(1900–1962)*



1900 елның 15 гыйнварында хәзерге Татарстанның Теләче районы Югары Кибәхужа авылында туа. 1909-1914 елларда Кышкар мәдрәсәсендә укый, аннары Арчадагы ике сыйныфлы рус-татар мәктәбендә һәм 1916-1918 елларда Малмыж шәһәрендәге Югарыбашлангыч училище дип йөртелгән уку йортында гомуми урта белем ала. Мәктәптә уку елларында татар һәм рус язучыларының әсәрләре белән якыннан таныша, үзе дә каләм тибрәтә. 1918 елның жәендә ул Мәскәүгә китә һәм Үзәк Мөселман комиссариаты тарафыннан чыгарыла торган «Чулпан» газетасында тәржемәче булып эшли башлый. Шунда анын «Бәйрәм житә» исемле беренче хикәясе басылып чыга.

1941 елның жәендә М. Максуд, гаскәри хезмәткә алынып, батальон комиссары, сәяси бүлек агитаторы, татар телендә чыккан «Совет сугышчысы» исемле фронт газетасының баш мөхәррир урынбасары сыйфатында сугыш беткәнчегә кадәр алгы сызыкта була. 1944 елны Казанда әдипнең «Үч һәм нәләт жыры» исеме белән фронт шартларында ижат иткән лирик-публицистик шигырьләре тупланган жыентыгы басылып чыга.

Сугыштан соң Мәхмүд Максуд, нигездә, публицистика, әдәби тәнкыйть, очерк һәм тәржемә жанрларында актив эшли.

## Әдип Маликов *(1921–2009)*



1921 елның 16 августында Башкортстанның Янавыл районы Югары Чат авылында туа. Пермь шәһәрендәге Татар педагогия училищесында укыган чорда Татарстан һәм Башкортстан татар көндәлек матбугатында беренче шигырьләре басылып чыга.

Ватан сугышында Әдип Маликов Сахалин утравының көньяк өлешен японнардан азат итүдә катнаша. Бу операциядә үзенә йөкләнгән хәрби бурычны жиренә житкереп үтәгәне өчен аны

«Батырлык өчен» медале белән бүләклиләр. Сугыштан соң Әдип Маликов күпсанлы поэмалары һәм шигырьләре белән таныла.

## Мөхәммәтша Мамин *(1905—1943)*



1905 елда хәзерге Мордва Республикасы Зубов Аланы районы Горинка авылында туа. 1930 елда ул Казанга килә һәм Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. Студент елларында көндәлек матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре белән катнаша башлый. 1936 елда Казан педагогия институтының аспирантурасын тәмамлаганнан соң, шунда әдәбият укыта.

Мөхәммәтша Мамин татар әдәбияты тарихында, нигездә, үзенең «Һади Такташ поэзиясе» исемле хезмәте белән билгеле. Бу хезмәт 1941 елда аерым китап булып басылып чыга һәм, Һади Такташ иҗатын тулаем алып тикшергән беренче җитди монография буларак, әдәби җәмәгатьчелектә югары бәя ала. Ватан сугышы башлану белән ул фронтка китә һәм ике ел буе алгы сызыкта фашистларга каршы сугыша. 1943 елның августында Воронеж шәһәре тирәсендә барган сугышларның берсендә өлкән лейтенант Мөхәммәтша Мамин каты яралана һәм, шул ярадан савыга алмыйча, госпитальдә вафат була. Ул Воронеж өлкәсендәге район үзәге Воробьевка авылы зиратына күмелә.

## Шәйхи Маннур *(1905—1980)*



1905 елның 15 гыйнварында Татарстанның Мамадыш районы Тулбай авылында туа.

Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә һәм күрше Шәмәк авылы мәдрәсәсендә ала.

1928 елда аның Казанда «Тайга төбеннән» исемле беренче шигъри җыентыгы басылып чыга.

1941 елда фашизмга каршы сугыш башлану белән, Шәйхи Маннур үзе теләп фронтка китә һәм сугышның ахырына чаклы «Сугышчан чакыру» (61 нче армия, 1942), «Алга, дошман өстенә» (Калинин фронты, 1942-1943), «Ватан бәхете өчен» (3 нче Белоруссия фронты, 1944-1945) исемле татарча фронт газеталарының алгы сызыктагы хәрби корреспонденты булып хезмәт итә. Фронт газетасы өчен язылган күпсанлы хәрби язмаларыннан тыш, ул шушы кыен шартларда да патриотик шигырьләр иҗат итә һәм 1943 елда «Гайҗан бабай» поэмасының икенче кисәген язып тәмамлый.

Шагыйрь буларак бик яхшы танылу алган Шәйхи Маннур сугыштан соң аеруча актив иҗат итә башлый һәм күренекле әдипкә әверелә.

## Зыя Мансур *(1916—1965)*



1916 елның 17 декабрендә хәзерге Башкортстанның Дүртөйле районы Житембәк авылында туа. 1937 елда урта мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын башлый: Дүртөйле район газетасында башта—корректор, соңга таба әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елда гаскәри хезмәткә алына һәм, Ватан сугышының беренче көннәрендә үк хәрби-пехота мәктәбенә җибәрелеп, 1941 елның ахырында аны тәмамлап чыга, аннары 1942 елның башыннан сугыш беткәнчегә кадәр хәрәкәттәге армиядә хезмәт итә, авыр сугышларда катнаша, яралана.

Сугыштан соң Зыя Мансур лирик шагыйрь буларак танылу ала.

## Габдрахман Минский *(1906–1983)*



1906 елның 29 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә туа. Әстерханның Тияк бистәсендәге мәдрәсәдә башлангыч белем ала, 1927 елдан «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» журналы битләрендә «Г.Минский» имзасы белән хикәяләре басыла башлый. 1928 елда берьюлы кечкенә-кечкенә өч китабы—«Заманасы шундый», «Миңсылу» исемле көлке хикәяләр җыентыклары һәм «Яна яшьләр» дигән комедиясе дөнья күрә.

1941 елның көзендә Г.Минский фронтка җибәрелә, Керчь ярымутравында барган тарихи сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, контузия ала. Госпитальдә дәваланып чыккач, 1946 елның маена кадәр совет чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә.

Сугыштан соң Габдрахман Минский прозаик һәм драматург буларак кин танылу ала.

## Вәдүт Мифтахов *(1915–1942)*



1915 елның 20 ноябрендә Татарстанның Сарман районы Яхшы Каран авылында туа. Сарманда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1931—1934 елларда—Лубъян урманчылык техникумында, аннан Казан дәүләт педагогия институтында укый. 1939 елда институтта белем алып чыккач, Ватан сугышына хәтле Татарстанның Питрәч районы Шәле авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1939 елда «Шигырьләр» исеме белән беренче җыентыгы басылып чыга, аннан соң балалар өчен язган күләмле поэмасы—«Ятим малай турында әкият»е (1940) дөнья күрә.

Ватан сугышы башлануга, Вәдүт фронтка китә, Мәскәү тирәсендәге канкойгыч сугышларда катнаша. Тула өлкәсендәге каты сугышлар вакытында, 1942 елның 30 мартында, ул батырларча һәлак була. Сугышчан иптәшләре В.Мифтаховның гәүдәсен Тула өлкәсенең Рыдань авылындагы туганнар каберлегенә җирлиләр.

## Мөсәгыйт Мостафин *(1909–1941)*



1909 елның 25 сентябрендә хәзерге Татарстанның Баулы районы Бәйрәкә авылында туа. 1927 елда Бәйрәкә җидееллык мәктәбен тәмамлап, Казанга килә һәм рабфакка укырга керә. Шушы елларда ул әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, очерклар, хикәяләр яза һәм аларны Ютазы район газетасында бастыра. 1931 елда яшь әдипнең Казанда биш хикәясен үз эченә алган «Очрашу» исемле китабы һәм үсмер балалар өчен «Үсү» исемле озын хикәясе басылып чыга.

Мөсәгыйт Мостафин 1941 елның август аенда үзе теләп фронтка китә һәм шул ук елның 6 декабрендә сугыш кырында батырларча һәлак була.

## Шәрәф Мөдәррис *(1919–1963)*



1919 елның 1 ноябрендә хәзерге Татарстанның Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында туа. 1933 елдан ук аның шигырьләре матбугатта күренә башлый, 1937 елда унсигез яшьлек студент егетнең «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Яшь шагыйрьнең әдәби тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дә шушы чорда башлана. 1941 елда аның тәрҗемәсендә чуаш әдәбияты классигы К. Ивановның атаклы «Нарспи» поэмасы дөнья күрә.

1941 елның язында Шәрәф Мөдәррис гаскәри хезмәткә алына

һәм Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк алгы сызыкта була, әүвәл минометчы, ахырга таба татарча фронт газеталарының хәрби мөхбире сыйфатында сугыш юлын уза, яралана, контузияләр ала.

Сугыштан соң Шәрәф Мөдәррис күренекле шагыйрь һәм тәржемәчегә әверелә.

### Хәйретдин Мөҗәй *(1901–1944)*



1901 елның 26 мартында хәзерге Башкортстанның Туймазы районы Төрекмән (1946 елдан Октябрьский шәһәре составына керә) авылында туа.

Унсигез яшендә аны Кызыл Армиягә алалар, һәм шул вакыттан соң аның бөтен гомере хәрби хезмәткә бәйле рәвештә уза.

1932 елда Казанда «Мылтыклылар» исеме белән шигырь, хикәя һәм очерклары тупланган аерым җыентыгы дөнья күрә.

Хәйретдин Мөҗәй Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, гвардияче полк командиры буларак, үзенә йөкләнгән сугышчан бурычларны үтәүдә, гитлерчыларның сугыш башында өстенлек иткән гаскәри көчләренә каршы оборона һәм һөҗүм операцияләрен башкаруда күп тапкырлар кыюлык һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә. Ләкин 1942 елның җәендә, Харьков юнәлешендә һөҗүм хәрәкәтләре барышында ул командалык иткән полк дошман чолганышында кала һәм айдан артык сузылган авыр бәрелешләрдән соң, полктан исән калган авыр яралылар, шул җөмләдән полковник Хәйретдин Мөҗәй, фашистлар кулына әсир төшә. Аны башка әсирләр белән бергә Германиягә озаталар. Ул хәрби әсирләр лагеренда интернациональ антифашистик яшерен оешма төзүдә катнаша.

Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, газаплаулардан соң, үлем җәзасына хөкем итеп, 1944 елның 4 сентябрендә үлем карарын гамәлгә ашыра. Алар арасында полковник Хәйретдин Мөҗәй дә була.

Аның Ватан сугышы чоры әдәби мирасыннан «Сугыш көндәлеге» исемле язмалары сакланып кала.

### Сөләйман Мөлекев *(1920–1941)*



1920 елның 5 гыйнварында Татарстанның Балтач районы Пыжмара авылында туа. Җидееллык мәктәпне һәм Алабуга китапханә техникумындагы курсларны тәмамлаганнан соң, 1940 елга кадәр Татарстан авылларында китапханәче һәм укытучы булып эшли. 1940 елның февралендә гаскәри хезмәткә алына һәм Ватан сугышын Көнбатыш Украинада чик сакчысы булып каршылый. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк ул алгы сызыкта була һәм 1941 елның сентябрендә Киев өчен барган сугышларның берсендә батырларча һәлак була.

Сөләйман Мифтах улы Мөлекев—сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, газета-журнал битләрендә, кумәк җыентыкларда әдәби әсәрләре белән күренә башлаган, әмма сугыш фаҗигасе аркасында үз тавышларын ныклап ишеттерә алмыйча, гомерләре бик иртә киселгән яшь каләм тибрәтүчеләрнең берсе.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ҺАМАН ЮЛДА

*Шагыйрь Рөстәм Мингалим шигъри иҗат юлына яшьли чыкты. Узган гасырның алтмышынчы еллар башында без бу изге юлдан бергә-бергә атлый башладык. Менә 45 ел буе инде без татар шигърияте дигән магистраль юлдан янәшә барабыз.*

*Рөстәмнең бу шигырьләре дә нигездә юлларга—гомер һәм язмыш юллары, еш кына катлаулы биографик, тормыш юлларына багышлана. Чынында бу шигырьләр—юлларга багышланган лирик шәлкем, бер теманы берләштереп торган әсәрләр бәйләме. Шуңа күрә мин бу циклны бербөтен әсәр кебегрәк итеп карадым һәм аны журналга «Юллар... юллар» дигән исем астында гади шигырь бәйләме генә түгел, ә бербөтен шигъри әсәр итеп нәшер итү яхшы булачак дип санап шигырьләрне тематик яктан бер сюжет сымаграк итеп төзедем. Болай иткәндә, минемчә, ул поэмага якынрак бербөтен әсәргә әверелә кебек. Укучылар да шулай кабул итәр дип өметләнәм.*

**Гәрәй РӘХИМ**



Рөстәм
Мингалим

---

## ЮЛЛАР... ЮЛЛАР

### Юлдаш эзләп бару

**Җирдә яшәү—хәтәр юлда
Юлдаш эзләп бару ул.
Чиксез юллар челтәрендә
Юлдаш табу авыр ул.**

---

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937)—*шагыйрь, драматург; «Әйт, Кояшым», «Күз карасы», «Дәрт чүлмәге» һ. б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Бик еракта гөрләп калды
Балачак тавышлары.
Их, гомер агышлары:
Шатлыклар, сагышлары—
Безне соңгы юлга хәтле
Озата барышлары.
И, гомер агышлары.
Шөкер әле, без табыштык.
Бик күпләр табышмады.
Кай арада кая җиттек,
И, гомер агышлары!
Җанга куәт биреп тора
Шатлыгы, сагышлары.

## Юллар алып китәләр

Безнең авылны әйләнеп
Стансага юл үтә.
41 дә ул әткәмне
Мәңгегә алып киткән.
—«Юллар алып китәләр.
Башны харап итәләр»,—дип,
Әйткән минем ишеләр.
Әйе, алып китәләр.
Башны харап итәләр.
Юллар түгел, кешеләр.

## Юлдаш

Юллар тигез, дөнья тигез
И, рәхәт бу җиһанда—
Ышанып баш тапшырырлык
Юлдашың булса янда:
Миңа Алла шундый юлдаш
һәм бик озын юл биргән.
Узган һәр елым тиң тора
Кадерле бер гомергә.

## Адашмадым әрәмәдә

Адашмадым әрәмәдә,
Адашмадым урманда.
Булды минем адашканым
Кереп авыр уйларга.
Андый чакта тәвәккәлләп
Чыга идем юлларга:
Юллар кайгыны тарата,
Юллар җанны юата.
Адашмадым әрәмәдә,
Адашмадым урманда.
Адаштырмас мине хәзер
Хәтта авыр уйлар да.
Чыгып барам юлларга,
Кереп барам юлларга.

## Әлмисактан кыяматкәчә

*(«Тормыш бармый!»—дип зарланучыларга.)*

Шулай булган, шулай булачак:
Зарланучылар зарлана тора.
—«Тормыш бармый!»—дип,
Төкеренә, сүгенә тора.
Ә тормыш бара тора.
Тормышның үз кануннары.
Аның барысы да үзенчә,
Юлы туры—
Әлмисактан кыяматкәчә.
Картлар ишек алларындагы утыргычларда
Урамнардагы бүрәнә өемнәрендә хәл җыеп утыра.
Арганнар елга буйларында,

Тау буйларында,
Юл буйларында ял итеп утыра,
Ә тормыш бара тора.
Шулай булган, шулай булачак:
Кемнәрдер кемнәрнеңдер өйләрен яндыра,
Илләрен туздыра.
Кешеләрне каберләргә тутыра-тутыра,
Тормыш үз юлы белән бара тора.

## Үзең безгә ярдәмче бул, Ходай

Аерылды юллар,
Аерылды куллар.
Уйлар гына охшаш—
Берсыман:
Үзең безгә ярдәмче бул, Ходай?
Без адашып барабыз сыман.
Ул булмагач, миңа,
Мин булмагач, аңа
Алдагы юл тайгак боз сыман.

## Камышларга җил киселә

Казаныма салкын көзләр килеп,
Көннәрем һәм гөлләр өшесә,
Авылым янындагы түгәрәк күл
Хәтеремә килә дә төшә:
Түгәрәк күл генә—
Үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,
Кулларыңа—кул гынам.

Хәл алырга ярга чал көз ята,
Күл өстенә зәңгәр боз ята.
Тал яфрагы корып карала,
Саргая күл камышы.
Камышларга җил киселә,
Җанга үтә тавышы.
Түгәрәк күл генә
Үрдәк өчен юл гына
Юлың булса янәшәмдә,
Кулларыңда—кул гынам.

## Без белгән көн

Көзләр җитте инде, көзләр җитте,
Без йөргән юл карга капланыр.
Тик икебез белгән көн җылысы
Карлар астында да сакланыр.

## Хаталарым күп булды

Мин юлымда күп матурлар күрдем,
Шуңа хаталарым күп булды.
Аннан йөрдем гафу үтенергә,
Кабат күрешү җае юк булды.

## Син класста иң матур кыз

Өйләребез бер өй аша,
Бер үк иде юлыбыз.
Күрше авыл мәктәбендә
Укып йөргән елыбыз.

Син класста иң матур кыз
Булып санала идең.
Юлыбызда урман иде,
Урманда алан иде.

Шул аланда бер көн юри
Йөгереп киткән булдың.
Мин чынлап куган булдым
Һәм куып җиткән булдым.

Ак чәчәкләр арасына
Юри егылган булдың.
—«Шуннан соң»мы?
Шуннан соң шул,
Әйе, бик тә, соңыннан,
Гел сагындык без—ул чакның
Юриен дә, чынын да.

## Фәрештәдәй күреп язганым

Мин бит сине юлда очраттым да
Фәрештәдәй күреп яраттым.
Син дә мине «шундый яраттым,
Сине югалтмам» дип юаттың.
Мин бит сине юлда очраттым да,
Фәрештәдәй күреп яраттым.
Фәрештәдәй күреп яратсам да—
Мин бит сине юлда югалттым...

## «Юлкоголик»лыкка сабыштым

Балачактан мине юллар дәште,
Юллар мине алга өндәде.
Мин юлларда бару гына белдем,
Мин юлларда ару белмәдем.
Юллар миңа яхшы юлдаш бирде,
Дусларымны юллар табышты.
Юллар яратуым өчен генә
«Юлкоголиклык»ка сабыштым.
Юллар миңа яшәү көче бирде,
Алар азык бирде язарга.
Юллар миңа табыш китерделәр
Шушы тормыш дигән базарда.
Хәзер мине тик бер нәрсә борчый—
Соңгы юлга ничек барырмын.
Соңгы юлым бик тә кыска булыр,
Мин юл йөреп туймый калырмын.

## Иң матур юл

Ярый әле бу дөньяда төннәр булган,
Рәхмәт инде төннәремә, төшләремә.
Бу дөньяда төрле-төрле юллар күрдем.
Иң матур юл һаман минем төшкә керә.

Адәм башы җирдә бик күп юллар күрә
Һәммәсен дә хәтерләрдә саклап булмый.
Тик кайчандыр сөйгән ярга илткән юлның
Иң матур юл булганлыгы онытылмый.

Мәдинә
Маликова

# ЮКӘ ЧӘЧӘК АТКАН ЧАК ИДЕ

## (НУРЗИФА)

РОМАН

### Ләйсән

Атна үтмәде, мәдәният сарае янындагы игъланнар тактасында Ләйсән Вәлидинең исеме янә күзгә чалынды. Камал театрында өлкәннәр көненә багышлап шәһәркүләм кичә үткәрелә, анда ул да җырлаячак икән. Керәм дигән җиренә керми калганы юк, икеләнеп тормады Рашат: «Бәхетле» кибетенең гөлләр-чәчкәләр бүлегенә кереп, биш ак роза төрдереп алды да театр ишек төбендә билет тикшерүче апакай каршына барып басты. Бер—егетнең йөзенә карады апа, икенче—аның кулындагы чәчәк бәйләменә. Андыйны тоткарлап буламыни? Ә инде эчкә кергәнгә урын табылмый калмый.

Бу юлы Ләйсән сәхнәгә Ансар Гыймадиев белән бергә чыкты—алар «Травиата» операсыннан дуэт башкардылар..

Шул ук ак күлмәктән булса да, бүген ул бөтенләй яңача, бүтәнчә күренде: чөнки бөтен рәвеше, торышы икенче иде. Элекке концертта сагыштан-моңнан үзәге өзелгән, әмма күңелендә якты өмет балкыган кыз бала булса, бусында ул җан сөйгәне белән кавышу шатлыгыннан очына, бәхетеннән нурланып балкый иде....

Җыр тәмамланып, кул чабулар башлануга, Рашат атылып сәхнәгә менде, чәчәген кызның кочагына салды. Иелде дә, аның тетрәнеп торган, сыгылмалы, нечкә бармакларын учына алып, кайнар иреннәренә тидерде.

Ул, кичә тәмамланмас борын ук залдан чыгып, гардеробтан курткасын алды да, ашыгып ишеккә юнәлде. Машинасын артистлар йөри торган арткы ишек янындарак калдырган иде, кереп утырды да көтә башлады. Кызның озатучысы бармы? Булса—кем? Әгәр булмаса, Рашат андый мөмкинлекне ычкындырмаячак иде.

---

*Дәвамы. Башы 3 санда.*

Озак көттермәде, әнә, чыгып та килә кызыкай. Кичке энгер-меңгердә тулган ай кебек: башында ак берет, өстендә аксыл пальто, кулында зур сумка. Янына елышкан кеше-кара күренми. Рашат ялт итеп машинасыннан чыкты да, ана таба юнәлде.

...Кыз Карл Маркс урамындагы борынгы, затлы йортларның берсендә яши икән. Консерваториягә дә, театрларга да, концерт залларына да якын гына. Гомумән, гомер юлын якты урамнар буйлап, шома юллардан тек-тек басып узар өчен, сәхнә түрендә балкып, алкышларга, чәчкәләргә күмелеп яшәр өчен яратылган зат иде бу. Аның бөтен тормышы уч төбендәге көзге кебек ялтырап ята, яшәеш мәйданы гүяки көмеш җепләрдән үрелгән киртә белән уратып алынган иде. Бу киртәгә әлегә кадәр капка уелмаган иде...

Ләйсән зыялы гаиләдә туып-үскән, әтисе—композитор, халык арасында таралган шактый җырларның авторы, әнисе—музыка белгече икән. Алар бердәнбер кызларын биш яшеннән музыка мәктәбенә биргәннәр. Андый балаларның иңенә сабый чактан икеләтә йөк төшә: гомуми белем дә аласы бар бит әле.

Дәресләрдән кайткач, һәркөнне берничә сәгать фортепиано артында утырырга, тавышны да чарларга кирәк... Тышкы кыяфәтне дә кайгыртмыйча булмый—Ләйсән бассейнга йөрергә дә өлгерә икән.

Бер яктан караганда, үзен белә-белгәннән бирле иҗтиһад итәргә күнеккән, нык ихтыярлы шәхес; икенче яктан караганда, урамга чыгып, халык арасында болганып йөрмәгәнлектән, тормышның күп якларын күрмәгәнгә, яшәеш турында мәгълүматны китаплардан гына алганга күрә, яше егермедән узса да, күңеле белән үсмерлектә калган кыз бала иде бу. Рашатка моңарчы очраган хатыннарның аркасына беренче карашка күзгә күренмәс сер биштәре асылынган булса, бу кыз аның ишедән азат булып, аның җаны да, тәне дә керсез икәнлеге күз карашыннан, һәр хәрәкәтеннән сизелеп тора иде.

Аңа карата мөгамәлә дә бөтенләй башкача, саф-чиста һәм бик сак булырга тиеш иде. Мөнәсәбәтләрне тиз арада якынайту мөмкин булмады, чөнки очрашулар кыска—җаен табып, консерваториядән яки берәр концерттан соң өенә озатып куйсаң гына.

Монда иң үтемлесе—татлы-баллы сүзләр дә, зиннәтле бүләкләр дә түгел, концерт саен сәхнәгә менеп чәчәк бирү иде...

Кыз йөрәге таш түгел, йомшармый булдыра алмады. Башта кулын үпкәнгә каршы килмәде, берәр атнадан бит очыннан пәп иткәч этеп җибәрмәде. Ә бер кичтә иреннәре бер-берсенә орынып киткәч тә ачуланмады.

Ярата идеме Рашат аны?

Сафлыкны, матурлыкны кем яратмый? Шуның өстенә кыз әле талантлы да булса... Нечкә күңелле, әдәп-инсафлы булса...

Дөрес, Рашат кебек егетнең, дөресрәге яшь ирнең, тәкатьсез омтылышларын аңлап, хәленә керә торганнардан түгел. Алай да аның да эчендә җаны бар, шулай булмаса җырлары үзәкләрне өзә, бәгырьләрне телә алмас иде. Ләкин тирән хисләр фәкать җырлаганда ялкын теле булып бәреп чыгып, тыңлаучыларның күңеленә үрли, гадәти тормышта исә сизелми кебек иде. Чакма таш сыман иде ул, эчендәге утны тиз генә тергезеп булмаячагын Рашат бик яхшы аңлый иде. Шунлыктан сабыр булырга тырышты...

Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләр, атналар-айлар үткән саен, хәлләр дә алга таба барды. Кызның әти-әнисе дә сәхнә артында, ишек төбендә болганган Рашатны күреп алган, читтән генә аның ниндирәк кеше, нинди гаиләдән икәнлеген ачыклаганнар һәм бик ошатканнар иде.

Яз башында Рашат әти-әнисен опера театрындагы зур концертка махсус

чакырып китерде. Соңыннан аларны сәхнә артына алып кереп, Ләйсән белән, аның әти-әнисе белән таныштырды. Чәчәк бәйләмнәре артыннан ак мангае, кара күзләре генә елтырап күренгән кыз фәрештәгә тин, аның тирәсендә укмашкан төркем сокланудан, куанычтан нишләргә белми иде.

Мондый күнелле вакыйгалардан соң төп мәсьәләне кабыргасы белән куярга да мөмкинлек ачылды. Рашат, бөтен шартын туры китереп, Ләйсәнгә тәкъдим ясады. Кыз мин риза дип кочакка сеңмәде сеңүен, әмма бик дулкынланган иде. «Әтиләр укуыңны бетергәнче сабыр ит, диләр»,—диде ярым пышылдап.

Алдагы ял көнендә егет әти-әнисен куандырырга кайтып китте. Бер атнадан Тимерҗан белән Суфия махсус әзерләнеп, Казанга кыз сорарга килделәр. Аларга инде аяк терәп каршы тору мөкин түгел иде.

Туйны, бөтен шартларын туры китереп, зурлап, июль башында ясарга дип килештеләр. Башта кыз ягында, аннары кияү йортында. Кемнең ялы, кемнең каникулы туры килә, туган-тумачаны җыярга бик җайлы вакыт иде бу.

...Ләкин аңа кадәр яшисе бар иде әле.

Нәкъ шул айда Рашатның фатиры өлгерде. Тик Тимерҗан бу хакта Ләйсәнгә дә, булачак кода белән кодагыйга да белгертмәскә кушты.

—Алдан ук әйтеп куйгач, кадере бетә аның,—диде.—Алар сезне үзләрендә яшәтмәкчеме? Әйдә, шулай дип уйлый торсыннар. Ә безнең малай йортка кермәячәк. Башка чыгарабыз без аны! Туй бүләге итеп фатир бирәбез! Кода-кодагыйның күзе тоз булсын!

Ярәшкән кияү-кәләш булгач, очрашулар ешайды, әлбәттә. Берничә тапкыр ял көннәрендә парлашып Тимерҗан белән Суфия янына да кайтып килделәр. Ашыкмыйча, төптән уйлап, туй хәстәрләрен күрә башладылар: еракгагы туганнарның кайсыларына алдан ук хәбәр итәргә, күпме кеше чакырырга, кайсы ресторан белән сөйләшеп куярга... Аның тамадасын да алдан билгеләү яхшы! Кияү белән кәләшкә күлмәк-костюм тектерү, балдаклар алу, ике якка бирешәсе бүләкләрне юнәтү—күнелле мәшәкатьләрнең очы-кырые юк сыман иде.

Алай да гел мәшәкать артыннан гына чабып булмый, ял да кирәк. Бер көнне алар, күңелләренә тынгы эзләп, сәнгать музеена керделәр.

Менә шунда беренче тапкыр күрде дә инде Рашат «Казан гүзәле» дигән портретны. Ник тукталып калды ул аның каршында? Әйе, күз салып кына үтә алмады, чөнки портреттагы кыз күз карашы белән туктатты аны, керфекләреннән сирпелгән тылсым белән аякларын идән паркетына беркетеп куйгандай иде. Җанның төбенә үтеп керә торган сизгерлек бар иде бу караштa. Якын итү, соклану, шул ук вакытта, хәлгә керү дә бар иде анда. Һәм кызгану, гафу итәргә әзерлек тә. Иң талантлы рәссамнар тарафыннан язылган картиналардан Мәрьям ана шулай карый. Рашат күзен аннан ала алмыйча, бер адым читкә атлады—Казан кызы карашын аның күз төпкеленнән алмады. Икенче якка авышкач та шулай... Гүяки ул егетне үз яныннан җибәрергә теләми иде...

—Ә бусын мин рәхәтләнеп үземнең бүлмәм түренә элеп куяр идем,—диде колак төбендә таныш тавыш.

Ләйсән янәшәдәге картинага төбәлеп баскан—анда аклы-кызыллы-шәмәхәле гладиолус чәчәкләре тасвирланган иде. «Ярый әле, «Казан кызы»на илтифат бирмәде,—дип уйлады Рашат.—Ярый, минем хәлне сизмәде...»

...Июнь башында Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бер айга Голландиягә гастрольгә китте. Театр анда ел саен барып тора. Бу юлы,

яналык булсын дип тәдер, бәлки, «Травиата» операсында Ансар белән бергә жырларга Ләйсән Вәлидине алып барырга карар кылдылар. Яшь жырчы өчен монын нинди зур бәхет икәнлеген сөйләп тә торасы юк, билгеле...

Ул очып китте, ә Рашат, аэропорт мәйданын уратып алган рәшәткәнең кызган тимеренә ике кулы белән ябышып, ак болыт мендәрчекләре арасына юл алган көмеш очкычка моңаеп карап калды.

## Сабан туе гына гаепле

Алай да бу вакытлы аерылуның бер ягы яхшы булды: хәзер инде кәләштән һәм аның ата-анасыннан яшерен фатирны иркенләп рәтләргә мөмкинлек туды. Шул мәшәкать артыннан чапканда тап булды да инде Рашат «Казан кызы»ның адәми рәвешлесенә—Нурзифага...

Әлбәттә инде, Нурзифа белән ниндидер якын мөнәсәбәтләр булдыру уе егетнең башына да кермәде. Фәкать күңеле тартканга, аның янында җанга ял алганга гына ул аны озаткалап йөрде.

Ә бит янда гына иске яр—Виолетта да уралып йөри иде әле. Нихәл итәсең, дөнья шулай корылган инде ул: бер килмәсә гел килми, бер килсә килә дә тора, килә дә тора.

Ярый әле, Виолетта—нык холыклы, горур хатын булып чыкты. Өстәвенә үткен дә иде үзе: егетнең кем тарафына авышканын тиз аңлады. Әмма җай чыккан саен килеп бәйләнмәде, ни булды дип сорашып тенкәгә тимәде, эчендәгесен тышка чыгармады, йотты. Рашат исә үзен аның каршында һич тә гаепле санамый, киресенчә, кеше хатынын тартып алмыйча дөрес эшләдем, дип исәпли иде.

Ләйсәнне озатуга, мәдәният йортында чын-чынлап урак өсте башланды: пыр тузып сабан туена әзерләнергә керештеләр.

Ел башында гына биредә директор булып утызлар тирәсендәге ыспай гәүдәле, ак чырайлы, гадәттә тигез тешләрен җемелдәтеп, елмаеп сөйләшүче Рәдиф Сәрвәров эшли башлаган иде. Бик ошатты инде ул Виолеттаны, һәр эштә гел ана таянды. Сабан туена әзерләнгәндә, Виолетта төп эшеннән ял алып, көне-төне дигәндәй мәдәният сараенда болганды. Мәктәп балаларыннан да, яшьләрдән дә чыгышлар әзерләде: һинд биюен, гарәп биюен, спорт биюләрен...

Менә кайда раслады кызый үзен, менә кайчан нык ихтыярын, уңганлыгын, хәтта талантын күрсәтте! Киң мәйданда ат уйнатты, дияргә була. Сәхнәдә бөтерелүче-боргаланучыларны гына түгел, башка һәммә хезмәткәрләрне дә—тегүчеләрне, электрикны, костюмерны, җыештыручыны—биетте генә! Хәтта Рашатны да! Әйе, аны да, чөнки һәр биюгә, чыгышка музыка сайларга кирәк иде бит. Ә моны фәкать Рашат белән генә эшләп була.

Аларга сәгатьләр буе икәүдән-икәү генә калып музыкаль үзәк аша төрле-төрле көйләр тыңларга туры килде. Бик мавыгып киткән чакларда куллар кулга тиеп, иңнәр ингә орынып алгалый. Башыннан кичкәннәр чамалый торгандыр: шактый четерекле хәл бу. Рашат өчен... Ә менә Виолетта үзен бик иркен тота, ник бер ым, ник бер күз карашы белән элекке якынлыкны онытмаганын сиздерсен. Әйтерсең лә, алар арасында берни булмаган, әйтерсең, алар бер-берсенә бөтенләй чит-ят! Кайчакта гасабиланып, маңка малайны ачулангандай кычкырынгалап та ала хәтта.

Вакыт-вакыт аның бу кыланмышлары егетнең мин-минлегенә тими калмады, әлбәттә. «Кара син аны, кирәк чакта файдаланды да, кирәгем беткәч, тузган күлмәкне чыгарып аткандай итте бу мине»,—дигән уйлар

килде аның башына.

Сабан туенда Рашат музыка аппаратурасын болын уртасында корылган сәхнәләрнең иң аргысына, Казансуга якынына илтеп көйләде дә, ахырга кадәр шуннан китә алмады. Автобусны да шунда куйдылар, чыгыш ясаучыларга киемнәрен алыштыру өчен шулай җайлы иде.

Виолетта житәкләгән түгәрәкнең кызлары килгән халыкны бизәкле капка төбендә, чәкчәкләр тотып, иртәнге тугыздан ук каршы алып тордылар. Сәгать унда зур мәйданда, сабан туен ачып җибәрү тантанасында алар иң алгы рәттә биеде. Аннары биш сәхнәнең бишесендә чыгыш ясадылар.

Көн аяз, җилсез, артык эссе дә түгел, күкләргә алдан заказ биреп куйганнар диярсең. Халыкның бер өлеше зур мәйданда ярышларны күзәтсә, күбесе болында айкала, бәгъзеләре чирәмлектә табын корып, туган-тумача, дус-иш белән кәеф-сафа кора. Болын кырыенда тезелеп киткән палаткалардагы өстәлләр дә буш тормый...

И-и, ул Яңа Савин районының сабан туйлары! Тагын кайда бар икән андый гүзәллек, иркенлек, хозурлык! Ул Казансу буендагы тубыктан яшел чирәм белән капланган киң болын, яр буендагы бөдрә таллы, көмеш яллы әрәмәлекләр... Төп мәйданның елгага караган ягы ачык калдырылган. Ә анда, су өстендә көймәләр узыша, фонтаннар ата, зур-зур аккошлар йөзә, очкычлар оча. Бу киң, күнелле манзара да, мәйдан уртасындагы уен-узыш, көрәш тә, багана башындагы әләмнәр дә, колга очындагы әтәч тә—һәммәсе үрне киртләп тезелгән эскәмияләрдәге халыкның күз алдында.

Шунысы да кызык тагын: заманында завод эшчеләре өчен дип төзелгән, Квартал дип атала торган бу районда күпчелек халыкны урыс тәшкил итсә дә, сабан туйлары саф татарча уза. Монда якын-тирә авыллардан гына түгел, ерак-ерак районнардан да гаярь егетләр, чая кызлар килеп, ярыш-көрәшләрдә катнашып, зур-зур бүләкләр алып китәләр. Мәйданда ярыш-көрәшләрне атаклы журналист Атлас Гафиятов яисә мәшһүр әдип Рабит Батулла алып бара. Россиядә беренчелекне алган, осталыгын Европа илләрендә генә түгел, Африкада, Япониядә күрсәтеп кайткан, исеме бөтен илгә танылган, Россиянең халык артисткасы Лима Кустабаева җитәкчелегендәге җыр һәм бию ансамбле мәйданны да, сәхнәләрне дә гөрләтә.

Биш сәхнәдә бишәр сәгать буена өзлексез концерт бара. Танылган артистлар, җырчылар арасында һәвәскәрләргә дә вакыт күп бирелә. Өлгер генә! Һәм болында истирәхәт кылып йөргән халыкны, тукталып калып, аерыла алмыйча карап торырлык итеп җырлый-бии бел!

Татарстан иленең гүзәл урыннары санап бетергесез. Казансу болынының чирәмен таптап, комлы ярында су коенып, шундук кыздырыдган шашлык белән сыйланыр өчен генә әллә кайлардан килеп тормаслар иде. Милләтнең сокланып туймаслык асыл балаларын, әгәр үз күнелләре тартмаса, тәкә яисә суыткыч белән кызыктырып та китерә алмассың. Бәйрәме матур аның, тамашасы кызык, шуңа киләләр.

Табигый инде, мондый бәйрәм һәрвакыт җитми кала. Тамашачыга гына түгел, күп кенә артистларга да җитми кала әле ул. Артист сәхнәдән туя димени! Бигрәк тә һәвәскәр артист. Инде сәгать өч җитте, дүртенче китте. Зур мәйданда сабан туе батыры тана хәтле тәкәне җилкәсенә салып, сыгылмаска тырышып, халык алдыннан узды. Бәйрәм тәмамланды кебек. Әмма чирәмлектә тамагын туйдырган һәм бераз кызган кешеләр яңадан кызык эзли башлады, яшьләрнең дә дәрте кайный иде әле.

Менә шунда Виолетта тагын бер тапкыр үзен күрсәтте. Аппаратурасын җыя башлаган Рашатка: «Ашыкма әле!»—диде дә, аэробика түгәрәге кызларын сәхнәгә чыгарып бастырды. Ул арада үзе автобуска кереп китте.

Бу сәхнә мәйданда бердәнбер тамаша булып калганлыктан, халык күп

жыелган иде. Менә ана озын кара шарф белән битен күзләренә кадәр каплаган кыз күтәрелде. Билендә тоташ елтыравык тәңкәләр зен-зен итә, ачык кендеге өстендә асылташ җемелди. Рашат янгыратып шәрык көен уйнатып җибәрде—кыз шарфына уралып, тәнен уйнаклата башлады. Шәрык кызлары мондый биюләрне кайчандыр еланнардан отып алдылар микән әллә? Ул җан иярәренең дә ачык таплар белән бизәлгәннәре, күз алмаслык матурлары бар бит. Хәер, юк, елан да бу рәвешле кылана алмас. Мондый кайнарлык бөркелми аннан, ир затының башын бу рәвешле әйләндерә алмый ул. Виолеттаның биюен әллә ничә мәртәбәләр күргән Рашатның да мангае тирләп чыкты. Аның назларын онытам дип ант эчкән иде бит инде, бүтән искә алмам, дип үз-үзенә сүз биргән иде, ә менә хәзер кочакта ничек боргаланганын зиһене түгел, тәне хәтерләде шикелле...

Төркемдәге ирләрнең аяклары ихтыярсыздан сәхнәгә якынрак атлады, күзләре тасрайды, иреннәре юешләнеп, авызлары ерылды. Бу биюләрне мондый җирдә күрсәтергә ярамый, алар өчен бөтенләй башка, аулак урын кирәктер, мөгаен. Чөнки бу кыланмышларның кеше-кара күзеннән читтә, икәүдән-икәү генә башкарыла торган дәвамы булырга тиеш. Хатын-кыз тәненең боргаланулары, тетрәнүләре ир затын шуңа әзерли...

Әйе, халыкны, бигрәк тә ир-ат затын әвәрә итәргә бик тә оста иде Виолетта...

Бу зур бәйрәмдә алкышларның беренчесе дә, соңгысы да аңа багышланды. Морадына иреште, һәммәсен уздырды ул бу көнне. Казанга өмет баглавы юкка булмаган икән.

...Соныннан аппаратураны җыештырып, автобуска төягәнче шактый вакыт узды. Ул арада балалар, яшьләр китеп барган иде инде. Рашат «Лада»сын капканың теге ягында калдырган иде, шунда китте.

Машинасын кузгатып, кайтыр юлга борылгач, ул автобус тукталышында Виолеттаны күреп алды. Гадәтенчә, сыланып торган кыска чалбарын, билдән югары кофтасын киеп, кендегендәге алкасы елтыратып торса да, халык арасында артык күзгә ташланмый, чөнки арган-талчыкканлыгы бөтен кыяфәтенә чыккан, башы салынган иде. Бу юлы инде берәүнең дә машинасын туктатып аннан: «Күпме?»—дип сорарга башына килмәс иде.

Рашатка да, аның тарафына керфек тә сирпемичә, выжт итеп үтеп кенә китәргә кирәк иде. Шулай итсә, илла да яхшы булыр иде лә! Эчендә җаны юк бәндә шулай итәр иде дә. Ә менә Рашат җансыз да, сансыз да егет түгел иде шул.

Инде узып киттем дигәч, ул тукталды, машинасын артка бирде. Ачык тәрәзәдән башын сузмады, ишеген ачмады. Виолетта үзе килде, үзе ишекне ачты һәм ничектер иелгәнен, бөгелгәнен сиздермичә генә, талгын искән җил кебек, кинәт бөркелгән нур кебек машинаның алгы утыргычына инде. Бик тә таныш, бик тә татлы ислемай исе борынны, битне иркәләде. Кузгалып киттеләр. Юл буе бер сүз дәшмәделәр, бер-берсенең йөзенә борылып карамадылар. Восстание урамындагы «сталинка» дип аталган таныш йортның ишеге төбенә килеп туктадылар. Виолетта машина ишеген ачты, еландай сыгылмалы, матур хәрәкәт белән тротуарга чыгып басты. Аның йөзе каядыр югары, күренми иде, тавышы гына ишетелде:

—Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

Рашат ишекне ябарга кулын сузасы урында, башын сузып аңа карады:

—Бәйрәм үтте бит инде...

—Ул бит башкалар өчен бәйрәм иде. Ә син эшләдең.

—Синең кебек инде...—Рашат киселеп калды.—Сиңа житеп булмый, әлбәттә. Син молодец! Булдырдың! Котлыйм!

Виолетта кулындагы чәчәкле-чуклы сумкасының озын бавын иненең

өстенәрәк шудырды да, йомры ияген чөя төшеп, тураебрак басты:

—Чын күнелдән котларга теләгән кеше юньләбрәк котлый ул!

Рашат машинаның уң ишеген шалт итеп япты да, сул ягын ачып, асфальтка чыгып басты.

Шуннан соң тиз генә кире кереп утыра алмады инде. Ни дисәң дә Виолетта ул сина урамда очраган әшнән түгел, кулын кысып кына котыла алмыйсың. Кочаклап үбим дисәң, урыны ул түгел. Машина дигән тимер тартма кысасыннан чыгып , кыз белән янәшә баскач, көн бик эссе тоелды. Суларга һава җитми башлады, ми түнеп китте. Ә аяклар, батарейка куйган сәгать кебек, үз эшен эшләде: Виолетта артыннан ишеккә таба атлады. Баскычтан менде, фатир ишегеннән керде.... Хәер, бусага аша ничек атлаганы Рашатның хәтерендә калмаган да. Ничек чишенелгән, бик тә таныш, бик тә үз ятакка ничек барып ирешелгән... Ятагы да, кайнар еландай бөтерелгән хатын да бик сагынылган икән... Ничә айлар буе ураза тотарга мәҗбүр ителгән сәламәт, дәртле, кайнар канлы егет тәне андый чакта акылны тынлап торамыни? Бигрәк тә шундый биюләрне карап торганнан соң! Ачның авызыннан ипи кыерчыгын тартып алып кара син!

Әйе, җан тартмаса да тән тарта икән шул.

Төн уртасында фатирына кайтканда, Рашатның тән зәвыгы басылган, әмма үзен гаепле итеп тоюдан күнеле бик тә сызлана иде. «Таза сәламәт ир бит мин, гарип-гораба түгел, әти әйткәндәй,—дип юатырга тырышты ул үзен.—Ләйсән белән өйләнешмәгән әле... Туйга хәтле барыбер мине якын җибәрмәяәк. Аңарчы мин ничек чыдарга тиеш икән соң?»

Гаепне йомып, үкенечләрне эчкә яшереп була, тик менә Виолеттаның кендегендәге асылташ кыйпылчыгы корсакны артык каты сыдырып җибәргән иде. Элегрәк иң четерекле минутларда алып куя торган иде дә бит, бу юлы аның кайгысы булмады. «Туйга хәтле вакыт җитәрлек, төзәлер әле»,—дип юатты үзен Рашат, өенә кайтып, җәрәхәтенә йод сөрткәндә.

...Ялгышмаган, хаталанмаган, бер гөнаһ та кылмаган кешеләр Рашатны хөкем итсен дә таш бәрсен. Хәер, бу заманда андыйлар күп микән?

## Без капчыкта ятмый

Сабан туеннан соң мәдәният сараенда каравылчы, электрик, җыештыручылардан башкаларга бер атналык ял бирелде. Моны ишеткәч, Рашат җиңел сулап куйды, аның өчен ял итүдән дә бигрәк Виолеттаның күзеннән югалып тору әйбәт булды. Билгеле инде, ул аның янына бармаячак, шылтыратмаячак та. Бәхеткә, теге дә үзен искә төшерергә омтылыш ясамады. Тузгыган күнелне тынычландырырга кирәк—театрның гастрольдән кайтыр чагы җитеп килә иде.

...Ерак юлдан Ләйсән тагын да затлырак кыяфәткә кереп кайтты. Борынгы дворян кызларының портретларында гына була торган зыялылык, үз дәрәҗәсен югары тоту сизелә иде аның һәр хәрәкәтендә, күз карашында. Әйтерсең лә, чит илдә бу асылташны тагын да шомартып, ялтыратканнар, шуның белән бәясен дә нык арттырганнар. Хатын-кыз затының мондыйлары поезд вагоныннан чыгуга егет муенына килеп асылынмый. Сәламгә керфекләрен сирпеп, елмаеп кына җавап бирә. Урысларның:«Посмотрит—рублем одарит»,—дигән мәкале Ләйсән турында кебек. Әйе, ул үзенә таба кулларын сузган Рашатка алтын тәнкә биргәндәй итеп елмайды да, нечкә бармагы белән ишарәләп, артыннан чыгып килгән Ансар Гыймадиев кулындагы зур-зур ике сумканы алырга кушты.

Рашат Ләйсәндәге үзгәрешне бер күз сирпүгә тотып алды, кыз исә аның йөзенә, күзләренә текәлеп карамады да шикелле. Аны анларга да була! Шундый илләрне гизеп, шундый җирләрдә булып, шундый унышларга ирешеп кайт әле син! «Монсеррат Кабальены да алай каршы алмаслар иде»,—дип сөйләде перронда Ансар көлеп. Имеш, Ләйсән тамашачылар күнеленә бөтен дөньяга даны таралган испан җырчысыннан да ныграк үтеп кергән. Шулай булмый мөмкин дә түгел: чүмәләдәй Монсеррат тал чыбыгыдай сылу Ләйсән белән чагыша аламыни? Театрга җыелган халыкның колагы гына түгел, күзе дә бар лабаса!

Әйе, Ләйсәннен тормышында бик зур вакыйга иде бу. Ә менә һаман үз Казанында гына пешеп-изелеп яткан Рашат белән бер ай эчендә берни дә булырга тиеш түгел иде. Кыз шулай уйлады.

Алар икесе өчен дә гомердә бер була торган күнелле, зур вакыйгага—туйга әзерләнүләрен дәвам иттеләр. Оста итекчеләр табып, икесенә дә туфлиләр тегәргә заказ бирделәр. Шәһәрдә «Азалия» исемле иң яхшы саналган ательега барып, аның кара чәчле, горур кыяфәтле хуҗасы белән бергәләп кибеттән туй күлмәгенә тукыма алдылар, фасон сайладылар.

Икесенең дә вакыты җитәрлек иде—Рашатның ак «Лада»сы шәһәрне күп тапкырлар урады.

Инде күлмәкне киеп карарга кирәк иде. Ләйсәннең консерваториядә йомышы бар икән, алар шунда, ишек төбендә очрашырга тиешләр иде. Әмма билгеләнгән минутта ул күренмәде. Бераз көтеп утырганнан соң, Рашат эчкә керде. Ишек төбендәге кысан куышта утыручы вахтер марҗадан:

—Гафу итегез, сез күрмәдегезме, Ләйсән Вәлиди чыгып китмәде микән?—дип сорады.

—Бүген күренмәде ул,—дип җавап бирде түтәй.

—Ничек күренмәде, иртән килгәндер бит?

—Килмәде шул.

—Сез, бәлки, күрми калгансыздыр?

—Инде Ләйсән Вәлидине күрмәскә тагын! Күзем чыкмаган ла минем!—диде апакай.

Рашат кире чыгып, телефонын кулына алды. Әмма трубкадан башта сузынкы чинаулар, аннары өзек-өзекләре генә ишетелде. Төймәләргә яңадан төрткәләгәч, ят ир тавышы: «Абонент белән тоташып булмый. Соңрак шалтыратып карагыз»,—дип җавап бирде. Ничек соңрак? Кайчан соңрак?... Ни булган бу Ләйсәнгә?! Ник җавап бирми? Кем шылтыратканны белә бит!

Рашат машинасын Карл Маркс урамына таба борды.

Кыңгырау төймәсенә кат-кат басарга туры килде: ишекне шактый вакыт ачмый тордылар. Ниһаять, ул әкрен генә ачылды, ярыкта Ләйсәннең әнисе Ләйләнең борчулы чырае күренде. Тотканы кулыннан ычкындырмыйча гына:

—Исәнме, энем... Ләйсәннең кәефе юк әле,—диде ул.

—Ни булды? Авырыймы әллә?..

—Бар инде бераз...

—Хәлен белеп чыгарга мөмкиндер бит?

—Син аны борчып йөрмә инде...

—Нишләп?!

—Нишләп икәнен үзе әйтер... Соңрак...

—Нишләп соңрак? Хәзер түгел?

—Анысын аннан сорарсың,—диде сүзен бик серле йомгаклап Ләйлә ханым һәм ишекне егет кулыннан аерыр өчен көч белән тартып, йозагын чыртлатып бикләп куйды.

Рашат тәмам аптырашта иде. Ни булган Ләйсәнгә? Ничек кенә булса да, сырхау сәбәп түгел иде монда.

Ике көн буе ул аңа сәгать саен шылтыратып торды. Ахыр чиктә, «Лада»сын тротуар кырыена куеп, Ләйсәннәрнең ишек төбенә каравылга басты. Һәм менә ни бәхет: кыз чыгып килә! Нечкә сынын кысып торган, тездән югары итәкле киң кофта, балак очлары сәйлән белән чигелгән джинсы чалбар кигән. Чәчен шома итеп тарап, баш артына җыеп куйган. Һәрвакыттагыча гөл кебек! Туфлиләренең биек, нечкә үкчәләре белән йөрәк очына баскандай тып-тып итеп атлап килә.

—Ләйсән!

Ә ул җавап бирмәде, егет тарафына керфеген дә сирпемичә, Ирек мәйданына таба атлап китте. Рашат машинасыннан төшеп, аның артыннан йөгерде, узып китеп, каршысына басты:

—Бу ни дигән сүз, Ләйсән?

—Отстань от меня!—диде Ләйсән урысчалатып. Һәм Рашатны әйләнеп үтмәкче булып, читкә атлады. Рашат аның юлына аркылы торуында булды:

—Аңлатып бир, зинһар, ни булды сиңа?

—Миңа түгел, сиңа!

—Минем хәлем җырларда җырланганча: җаным җәл түгел сиңа, Ләйсән!

—Бу җырны син башкаларга да җырлыйсыңмы? Каян килгән сандугач!

—Ни сөйлисең син, Ләйсән? Кемне әйтәсең?

—Ә... Виолеттага нинди җырлар җырлыйсың?

Рашатның башына чүкеч белән китереп ордылармыни: күз аллары караңгыланып китте. Әмма сер бирергә ярамый иде.

—Кем әйтте?—дияргә мәҗбүр итте ул үзен.

—Үзе! Үзе сөйләде.

—Сез танышмыни?

—Ә телефон нәрсәгә?

—Ә... телефонын каян таптың?

—Синнән алдым!

—Миннән?! Кайчан? Кайда?..

—Мобильнигыңда бар ич!..

—Мобильникта?

Рашат ихтыярсыздан күкрәк кесәсен капшап куйды. Телефонын Ләйсәнгә биргәнен хәтерләми иде ул. Аның аптырап калганын күреп, кыз аңлатуны кирәк тапты. Сүзнең дөресен, турысын гына сөйләргә өйрәнгән, беркайчан да, бер нәрсәне дә эченә яшереп яткырырга ярамый, дип чын күңелдән ышанган сабый күңелле зат иде шул ул.

—Ике көн элек, хәтерлисеңме, ДПС туктаткан иде?

Әйе шул, чыннан да, алар Карл Маркс урамыннан үтеп барганда, күзне ерта торган яшькелт-сары курткасына эре итеп «ДПС» дип язылган кеше аклы-каралы таягын сузган иде. Ни булган, дисәң, кемдер «Девятка»сын тиешсез җиргә куеп калдырган икән. Шуны эвакуатор белән алып китәргә ниятләгәннәр, моның өчен исә акт төзергә, ә актка шаһитләрдан кул куйдырырга кирәк икән. Милиция сүзен тыңламый булмый, Рашатка берничә минут алар машинасы тирәсендә болганып, кәгазьләргә имзасын салырга туры килде. Шунда аның мобильнигы шылтыраган. Телефонны куртка кесәсеннән Ләйсән алган. Шылтыратучы хатын-кыз, ят тавыш ишеткәч, сөйләшеп тормаган. Шиккә калган Ләйсән телефон номерын үз мобильнигына күчереп алган. Кич белән өенә кайткач, иркенләп

Виолеттага шылтыраткан... Икесе дә ихлас, ялганлый белмиләр, ачыктан-ачык сөйләшкәннәр, күрәсен...

—Ышанмагыз егетләрнең яратам дигәненә, дип кенә җырларга калды мина хәзер,—диде Ләйсән, яшь аралаш елмаерга тырышып.

—Ул бит сиңа хәтле... Мин сине белми идем әле...

—Ялганлама! Узган атнада да очрашкансыз!

—Тукта әле, Ләйсән,—диде Рәшат кинәт карлыгып киткән тавыш белән.—Зинһар, гафу ит... Минем аңа өйләнергә уйлаганым юк. Әтиләр белән дә таныштырмадым... Аның ише була инде ул...

—Ә аннары, өйләнешкәч, аның ишеләр булмас, дип кем әйтә?

—Мин әйтәм, Ләйсән, мин! Өйләнешкәч бетте инде... Син мине кем дип белдең?

—Кем дипме? Өстерәлчек, дип беләм мин сине! Хыянәтче, дип! Өйләнешмәс борын хыянәт итә башлагач, кая китә ул... Күрәсем дә килми!.. Ненавижу!

Шул сүзләре белән егетнең битенә түкергәндәй итте дә китеп барды ул.

Иртәгесен дә, аннан ары да Рәшат Ләйсәннең ишеген сәгатьләр буе сагалады. Кыз аны тәрәзәдән күргәндер, мөгаен, чыкмады. Филармониянең концерт залында татар халык җырлары кичәсе буласын, анда Ләйсән Вәлидинең дә чыгыш ясаячагын белгәч, бәйләме белән генә түгел, кәрзине белән чәчәк сатып алды. Әмма бу юлы кыз кулын үптермәде, кәрзинне күтәреп алды да, ул җырлаганда уйнап торган кыллы оркестрның дирижеры Анатолий Шутиковның аяк очына илтеп куйды, шуның белән кара костюмлы, түгәрәк гәүдәле абзыкайны чиксез куандырды.

Әмма Рәшат һаман бирешергә теләми иде. Ул урам якта көтеп торды да, Ләйсән чыгуга каршысына барып басты, беләгеннән тотып, мәҗбүри диярлек, бина янындагы агачлыкка таба тартты.

—Кичер мине, Ләйсән...

—Хыянәтне кичерәләрмени?

—Монда мин генә дә түгел бит! Әтиләр туйга әзерләнә! Нишләргә инде миңа? Синекеләр дә әзерләнә иде бит!

—Мин үземнекеләргә әйттем инде Ә сездә минем эшем юк. Җибәр!

—Ләйсән, кызган мине! Теләсә нишләт, тик ташлама гына!

Рәшат аның каршында тезләнде. Ләйсән китү ягына борылды, аның:

—Кем белән яшәсәң, шуның каршында тезлән! Туеңны да аның белән уздыр!—дигәне генә колакка чалынып калды.

Тротуарда берничә узгынчы тукталып, гаҗәпләнеп Рәшатка текәлгәннәр иде. Ул ак чалбар балакларын каккалап, машинасына таба юнәлде. Эчкә кереп утыргач, кыйнап ташлангандай хәлсезләнеп, шактый вакыт зиһенен туплый алмый утырды. Моңарчы кызлар тарафыннан бу хәтле кимсетелгәне юк иде әле аның. Ничек кенә үпкәләсәләр, тиргәсәләр дә, ике арада гына кала, әти-әнигә барып җитми иде. Инде нишләргә? Әти кешегә ни әйтергә, аларның күзенә ничек күренергә?

Рәшат әтисенең кара бөдрә сакал-мыегы арасында беленмәслек булып кысылган иреннәрен, куе кашлары астыннан хәтәр елтыраган карашын күз алдына китерде дә, хәле китеп, машина утыргычының аркасына сөенде. Бу минутта ул үзен бик кечкенә, мескен дип хис итә иде. Ничек шушындый хәлгә төште соң әле ул?.. Һәммәсенә Виолетта гына гаепле, фәкать ул гына. Кара елан икән... Хәер, елан телефон аша чага алмый бит! Явызлыкта хатын-кыз белән чагыша алырлык тагын берәр җанвар бар микән бу дөньяда? Кем уйлаган аның эчендә шулкадәр агу ята дип... Бер генә чакты, Рәшатның күпме көч куеп, вакыт сарыф итеп, йөрәк хисләрен салып төзегән бәхет

сараен иште дә төшерде. Менә хәзер, гүзәл кәләш белән житәкләшеп якты киләчәккә барасы урында, хәрабәләр арасында, күз яшьләренне янгыр урынына коеп утыр инде!..

Рашат кабаланып кесә телефонын алып, төймәләренә төртте.

—Исәнме, Рашат. Ничек мине искә аласы иттен әле?

Тавышы шундый тыныч, шундый гамьсез, жиде туганы белән сөйләшәмени!

—Ә син... Син ни сөйләп йөрисең анда?

Эшнең нидә икәнен Виолетта шундук аңлап алды.

—Мин берни дә сөйләп йөрмим, сораганга җавап кына бирәм. Фәкать шул гына.

—Җавапны да төрлечә биреп була!

—Нәрсә, ялганларга тиеш идеммени? Алайса, ялганла, дип алдан кисәтеп куярга иде. Минем телефонны аңа биргәнче, дим.

—Мин бирмәдем аңа синең телефонны!

—Шулаймыни? Ә ул әйтә, синнән алдым, ди.

—Миннән түгел, кесә телефоныннан!..

—Ах, шулаймы-ыни! Рөхсәтсез алган дисең инде алайса...—диде Виолетта гажәпләнгәндәй итенеп. —Ул синең арттан шымчылык итәмени? Моннан ары кесәләренне саклабрак йөри торган бул...

Моны әйткәндә, хатынның тавышында кинәнү чагылып узгандай булды. Сүзнең мондый борылышы Рашатны телсез калдыргандай итте.

Шактый тынып торгач, телефон янә телгә килде.

—Алло, ишетәсеңме?

—Әйе...

—Башкаларда эшем юк, үзем турында әйтим әле,—диде Виолетта ничектер сызланулы тавыш белән.—Син минем бердәнберем бит, шуны беләсенме? Бердәнберем!

—Ә ирең?!

—Мине ташлаган бердәнбер син. Андый бүтән булмады, булмас та. Хуш!

...Менә шул рәвешле хатын-кызлар төп башына утыртты егетне.

## Инде нишләргә?

Рашат үз борчуларына баткан, үзенең генә хәле хәл дип күз алдына китерде. Хәлбуки, аның аркасында тагын өчәү хәйран-вәйран булып, шуларның берсе Нурзифа иде. Таныш булмаган ниндидер хатын-кыз телефоннан: «Рашат янында син беренче дә, икенче дә түгел, өченче!»— дип әйткәч, күз аллары томаланып зиһене таралып китте аның. Бераздан аңын жыйса, куллары өстәлдәге кәгазьләрне актара икән. Менә Рашатның шкафларына накладнойлар, менә Самаркин йортының сызымнары... Нидер эшләргә кирәк... Холкы шундый аның: борчылганда, эче пошканда оеп утыра белми, нидер эшләргә, кая да булса барырга омтыла. Тән хәрәкәте жанга хәл кертә, башны да эшләргә мәжбүр итә «Хәнәфинең тәкъдименә жавап бирмәдем бит әле мин,—дип уйлады ул.—Булдыра алмыйм, эшем күп, дип шылтыратырга кирәк». Мозаффар турында да бирәр нәрсә белеп булмасмы. Хәнәфигә тагын шылтыратмады микән? Сөйләшкәләп торалардыр, бәлки?

Бу уй тәвәккәллек бирде, Нурзифа телефонын алды.

—Тынлыйм, Зифуш! Исәнме! Хәлләрең ничек?—Хәнәфинең тавышы бик көр иде. Мондый янгырлы-жилле көнне дә күңеле күтәренке кешеләр булыр икән.

—Исәнмесез... Мин теге... планнарны кире кайтармакчы идем.

—Әйтер сүзең дә бардыр бит? Заказ турында. Узганында бинаны карарга да өлгермәдек. Давай, кил әле син монда. Хәзер машина җибәрәм.

—Юк, бераздан. Төшке аш вакытында.

—Ярый, сәгать бердә күксел «Нексия» ишек төбендә булыр.

...Руль артында утырган караңгы шадра чырайлы, ала-кола киемле адәмне күргәч, Нурзифа бер мәлгә икеләнеп калган иде. Әмма теге ничектер көчәнеп, ясалма елмайды да, уңга авышып, ишекне ачты:

—Исәнмесез! Рәхим итегез!

Нурзифа, трамвай белән барса, яңгыр астында ничек итеп үргә менәсен күз алдына китерде дә, тәвәккәлләп утырды.

Хәнәфи аны бу юлы да тышкы ишек бусагасына чыгып каршы алды. Шул ук бүлмәгә алып керде. Өстәлдә шундый ук табын әзерләнгән иде.

Һәммәсе элеккечә. Хәтта көннең болытлы булуы, тышта яңгыр сибәләп торганы да сизелми: бормалы баскыч янындагы ясалма тәрәзәдән һәрвакыттагыча кояш елмая, алмагач чәчкәгә төрелгән ботагын сузган.

Фәкать бер үзгәрешне сизеп алды Нурзифа: жалюзи белән капланган тәрәзә каршындагы диварда өстенә киндер ябылган рам эленеп тора иде. Узган килүендә ул юк иде. Күңелдә нидер зеңләп куйды, чөнки киндере таныш тоелды.

—Бу... сезнең языла торган картинагызмы әллә?

—Әйе, яңа. Минем өчен өр-яңа!

Нурзифа идәннең ялтырап торган, бер тапсыз бизәкле имән паркетына күз салды, як-ягына каранды: рәссам эшли торган җирдә, мольберт, буяулар куя торган берәр урын булырга тиеш иде. Биредә исә андый нәрсә күренмәде.

—Монда шартлар юк бит. Ник остаханәдә генә эшләмисез?

Хәнәфи серле елмайды.

—Хикмәте бар аның, Зифуш. Сере бар.

—Карарга ярыймы?

—Вакыты җиткәч, Зифуш, вакыты җиткәч. Ярты-йорты эшне күрсәтәсем килми. Мин аны сиңа җиренә җиткергәч кенә күрсәтермен... Әйдә, утыр әле син! Төш вакыты бит. Теге «Бейлис» әле дә сине көтеп тора.

Һәм Нурзифаны беләгеннән тотып, элеккеге урындыкка утыртты да, ябыштырып куярга теләгәндәй, ике учы белән йомшак кына иңнәренә каккалап алды.

Үзе аның янәшәсенә утырып, өстәлдәге сөтле кофе төсендәге йомры шешәне кулына алды.

—Ә бәлки, башта эш турында сөйләшеп алырбыз? Бинаны карарга, дигән идек...

—Эш качмас ул, Зифуш! Карын ачты әле монда.

—Мин шуны сорамакчы идем: Мозаффар абый шылтыратмадымы?

Хәнәфинең йөзе тартышып куйгандай булды.

—Нәрсә син, Зифуш, Мозаффар да Мозаффар дисең? Ул гел сине генә уйлап утыра микән әле? Кирәксенсә, үзе хәбәр бирер иде!

—Узган юлы... Монда шылтыратканда, бик борчылган кебек иде.

—Холкы шундый ла аның! Буявы кипсә дә ярсый, пумаласы тузса да... Әйдә, нервыларны талкымыйк әле. Кабып куйыйк та, тамак ялгап алыйк.

Хәнәфи бокалга яртылаш итеп коньяк салды да, Нурзифаның кечкенә рюмкасына чың итеп бәреп алгач, төбенәчә эчеп җибәрде.

—Аның ни кыланасын белеп буламыни!—диде ул киви телемен суырып.— Әгәр дә ул бу минутларда бездән качып, берәр натурщицаны чишендереп,

этюд ясап ятса, мин бер дә гаҗәпләнмәс идем. Сина хәбәр бирмәве дә шундыйрак уйларга сала. Талантлы художник натурщицасын сөяркә итми калмый бит ул! Үзең дә беләсеңдер инде.

Анын бу сүзләре Нурзифанын бит очларын ялкын теле белән өтеп алгандай итте, күзләрдән яшь чыгарды. Ярый әле, үзе төбәлеп карамады, урыныннан кузгалып, шкаф янына таба итте. Анда ябык киштәләрнен берсендә микродулкынлы мич тора икән. Борылып карамый гына:

—Антрекотларны кайнарлыйммы? —дип сорады.

Һәм җавап көтеп тормыйча, ит калҗалары тезелгән фарфор җамаякны мичкә куйды.

Аннары борылды да, якынрак килеп, мичнен гүләү тавышына кушылып, сүзен дәвам итте.

—Тормышны да, кешеләрне дә белергә вакыт инде сина, Зифуш. Әниләр әйтмешли, күптән балигъ булгансын. Бу яшьтә кеше шактый тормыш тәҗрибәсе туплап өлгерә. Шуны анла: Мозаффар өчен син фәкать натурщица гына. Эшләгәнең өчен акча түлиме сон ул сина? Син инде үзенне арзанга чутламыйсындыр, бәяңне төшермисеңдер, шәт?

Шулай дип, ул, якын ук килеп, иелә төшеп, урындык аркасына авышкан Нурзифанын күзләренә текәлде. Ник болай күзләрен майландырып карый, нәрсәгә ишарәли?

Нурзифанын дымлы күзләрендәге аптырауны, гаҗизлекне күрү ана канәгатьлек бирә иде кебек—иркенәеп елмайды.

—Хәер, натурщица ялларлык чамасы бар микән?—диде сынын турайтып. Һәм, үз-үзен үстереп җибәрергә теләгәндәй, лак катырып тырпайтылган кыска көлсу чәчен ике чигәсеннән өскә таба сыпырып куйды.—Остаханә өчен дә ничә ел түли алганы юк...

—Мин аннан акчаны бирсә дә алмыйм!

—Һәм бер дә дөрес эшләмисең, Зифуш... Бушлай булганга гына һаман сине ясавы түгел микән?

Мич гүләүдән туктады, Хәнәфи җамаякны алып, өстәл янына килде дә, пар чыгып торган зур-зур ит калҗаларын пычак белән ике тәлинкәгә шудырды.

—Әйдә, кайнар чакта ашыйк әле. Ит астына тагын берне кабып куйыйк та. Мин бер тост тәкъдим итәм: рәхәт, мул яшәү өчен күтәрик әле берне! Фәкыйрьлек кешене бик кимсетә бит ул. Гомерен буе кимсенеп яшәргә теләмисеңдер, шәт?

—Юк, билгеле...

—Сон алайса күтәрик берне!

Эчеп куйгач, тәмләп ит чәйнәгәндә, янә сүзен дәвам итте ул:

—Кемгәдер бушка хезмәт итү—булдыксызлар эше ул. Безнең Рәсәйдә кешене бушка эшләтү закон буенча тыела, син шуны беләсеңме? Аяк терәп каршы торсаң да бирелергә тиеш ул сиңа. Сәгатеннән санап. Училищедагы натурщицалар ставкасыннан гына булса да... Син инде Мозаффарны бөек рәссам булып танылыр, дип өметләнәсеңдер. Гойя кебек. Анын музасы буларак, мин дә тарихка кереп калырмын, дип өмет итәсеңдер. Ә бәлки, үзеңне Гойянын мәгъшукасы герцогиня Альба урынына да куеп карыйсындыр әле?

Нурзифанын йөрәге тибүдән туктап калгандай булды. Әллә сон теге картинаны күргәнме бу? Мозаффар, беркемгә дә күрсәтмим, дигән иде дә бит... Анын юкка чыгуыннан файдаланып, картинаны Хәнәфи алган булса?!. Нурзифа ихтыярсыздан борылып, дивардагы каплаулы рамга карап алды. Аннары Хәнәфигә борылды. Ә ул исә чәнечкесе белән тәлинкәсен тырнаштыргалап, сүзен дәвам итте:

—Әйе, башта Гойя ул хатынны күз чагылырлык гүзәл итеп күрсәткән: «Киенгән Маха», «Чишенгән Маха»... Ә соңыннан «Капричос» дигән карикатураларында нинди итеп ясаган ул аны? Анысын беләсенме соң?

—Мин романны укыдым,—диярга мәҗбүр итте үзен Нурзифа.

—Димәк, мөнәсәбәтләренең ни белән тәмамланганын беләсең!

Хәнәфи салмак хәрәкәт белән урыныннан торып, якынрак килеп басты. Нурзифаның күзләренә өстән текәлеп карап:

—Син бәхетле булырга хаклы, Зифа,—диде.—Иркен, ямьле йортта яшәргә! Дөнья гизәргә! Ин гүзәл дингез буйларында ял итәргә хаклы син! Ә Мозаффарның сиңа андый шартлар тудырырга мөмкинлеге юк. Һәм булмаячак та! Бик теләсә дә! Азалия аны беркайчан да ычкындырмаячак, белеп тор! Ә гомер үтә! Син шул өч тиенлек кухня шкафлары сатып йөреп, мантырмын, дип уйлыйсыңмы әллә?

Аннары иелә төшеп, йөзен йөзгә якын ук китереп, эченнән саркытып, пышылдап диярлек:

—Ә минем белән булсаң, күп теләкләреңә ирешә алыр идең,—дип дәвам итте.—Ничек уйлыйсың, әгәр син үзеннән сәнгать салонынны ачып җибәрсәң, ә? Шәһәрдә иң яхшыны... Синең зәвык белән әллә ниләр эшләп була! Ә мин матди ягын тәэмин итәр идем. Күз алдыңа китер: бөтен рәссамнар безнең каршыга килеп басар иде... Мозаффарны да яллап эшләтә алыр идек...

—Ул яллана торганнардан түгел!

Нурзифаның тавышында Мозаффар белән горурлану, үзен дә әңгәмәдәшеннән өстен кую чагылды. Моны тоеп алган Хәнәфинең күзләре хәтәр ялтырап алды. Ул тураеп басты да башын югары чөеп:

—Ялланмый торган адәм дөньяда юк,—диде.—Эш кешесе кемгәдер ялланмый булдыра алмый, чөнки ул хезмәт җимешен сатарга тиеш. Яллана, димәк сатыла, дигән сүз. Сәнгать мәктәбендә укыдың—тарихны бераз беләсеңдер. Дөньяның иң бөек рәссамнары ялланып иҗат иткәннәр! Корольләрнең, императорларның портретларын, аларның затлы сарайларын сурәтләп тамак туйдырганнар, шуның белән күпләре дан казанган. Ә үзебезгә карасак, ни күрәбез? Син үзең дә ялланып эшлисең түгелме?.. Тик кемгә ялландың?.. Сөрсегән фатирларда шкаф куяр урыннарны үлчәп йөрү өчен, ә буш вакытларыңда бер тиенсезгә башка берәүнең ирен каршында ялангач ятып тору өчен яратылмаган син, Зифуш!.. Безгә берләшергә кирәк. Бергә булсак, без бу шәһәрне кулга алачакбыз.

Нурзифа башын иеп, дәшми-тынмый утыруында иде.

—Һәр картинаның сумнар, долларлар белән санала торган хакы бар. Матурлык сатыла, Зифуш! Акча сәнгатьтән өстен!

—Шулаймыни? —Нурзифа башын күтәреп, аның күзләренә текәлде.— Акча өстенмени?

—Байлык булса бар да була. Ә хәерчегә нинди матурлык ди ул! Ач карынга сәнгать артыннан куа алмыйсың.

Нурзифа салмак хәрәкәт белән урыныннан торып басты. Алар Хәнәфи белән буйга бер чамадыр, әмма биек үкчәле туфли кигәнгә, Нурзифа калкурак тоела, өстәнрәк карый иде.

—Ә ант?!

—Нинди ант?

—Хәтерлисезме... Моннан нәкъ ун ел элек сез матурлыкка хезмәт итәргә, сары шайтан артыннан чапмаска дип ант биргән идегез. Минем исемдә!

—Ә-ә, син аны әйтәсеңмени! Һаман шул бер сүз... Гел исегездән чыгармыйсыз, ә?

—Ә мин аны үз антым дип санадым. Әгәр дә язмыш миңа олы талант бирсә...

—Картиналарыңны сатмас идең, бушка өләшеп йөрер идеңме?

—Монда картинаны сату турында түгел, тормышыңда нәрсәне өстен кую турында сүз бара. Байлык дип тырышасыңмы, матурлык дипме. Аңламамышка салышмагыз!.. Ул чакта сез ун ел узгач, очрашып нәтиҗә ясарга дип килешкән идегез.

—Очрашырбыз, билгеле. Җыела алсак!—Соңгысын әйткәндә Хәнәфинең күзләре сәер генә ялтырап куйды.

Нурзифа керфекләрен кыса төшеп, ана текәлде:

—Талантын акчага саткан кеше үлсен, дигән идегез әле!

—Анысы бөтенләй ахмак сүз инде. Яшәү-үлү ул бит язмыш кулында. Картинасын саткан бер рәссам үлә торган булса, кая китә ул! Үзең дә беләсең бит: гомернең бакыена матурлыкны байлар, акчалылар булдырган. Алар сатып алмаса, нинди рәссам гүзәл әсәрләр булдыра алыр иде икән? Ашарына ипиен әйтеп тә тормыйм инде, аның киндере, кылкаләме, буяулары да булмас иде! Ләкин мин сиңа турыдан-туры акча артыннан чабарга кушмыйм лабаса! Матурлыкка уралып та, акчага тиенеп тә яшәргә була бит!

Хәнәфи якын ук килеп аның иңенә кулын куйды. Нурзифа артка тайпылды, йөзе агарынып китте, күзләрендә чиркану чагылды. Хәнәфи иренен тешләп, бер адым чигенде:

—Син миннән куркасыңмы әллә, Зифа? Мин шулай куркынычмыни?

Нурзифа җавап бирмәде, сүз көрәштерүнең мәгънәсез икәнлеге ап-ачык иде. Ни генә әйтсәң дә, Хәнәфинең үз туксаны туксан булып калачак. Китәргә кирәк моннан... Ул сырлап-бизәп ясалган авыр, биек имән ишеккә борылып карады. Бикле түгел микән?.. Монысы йозаксыз булса да, тышкысы бикле дә бикле инде... Аның артында теге шадра чырайлы адәм торадыр. Йөгереп кенә чыгып китә торган түгел. Аннан соң тимер капка, аның янында этләр... Ник килде ул монда? Тимер капка аша ник керде, бу ишекләрнең бусагасын ник атлады? Узган юлы да күңеле нидер сизенгән иде бит! Әгәр Хәнәфи аны болай гына чыгарып җибәрергә теләмәсә? Ачуга китсә, ул аны теләсә нишләтә ала!

Хәнәфи аның уйларын укыгандай текәлеп басып тора иде. Аның чырае тимгелләнеп китте, иреннәре кысылды.

—Курыкма, мин сине ашыктырмыйм,—диде.—Минем тәкъдимем көчендә кала, фәкать шул гына. Ә син уйла. Вакыт узар, кемнең кемлеген белерсең. Тормыш үзенекен итә ул...

—Мине эштә көтәләр...

—Мин сине бер нәрсәгә дә мәҗбүр итмим. Һәммәсе син теләгәнчә булыр, ышан миңа, Зифуш! Мин синең аяк астыңда туфрак булырга риза! Белмисең генә! Күрергә теләмисең генә!

Шулай дип ул, һич көтмәгәндә тезләнде дә, дымлы кулы белән Нурзифаның бармакларын тотып, үбәргә кереште.

—Ач күзеңне, Зифуш! Кем сукырайтты сине? Миңа таян син, миңа! Мин сине күтәрә алам! Зур кешеләр арасына кертә алам!

Нурзифа көч белән кулын тартып алды.

—Әгәр минем сүзем сүз икән, саубуллашыйк!—диде каты итеп.

Хәнәфи аягына тураеп басты, паркетта бөртек тузан да булмауга карамастан, күксел чалбарының тез турларын каккалады.

—Хәзер әйтәм, илтеп куярлар.

Аннары, карашын аска төбәгән килеш ишеккә юнәлде. Аны киң ачып:

—Рәхим ит!—диде.—Тиздән тагын очрашырбыз, дип ышанам.

—Хушыгыз!

Ишегалдына чыгып, машинага утыргач та, Нурзифаның күнелендәге курку басылмаган иде әле. Ул болдырдан бераз читтәрәк кызгылтка буялган зур тимер ишек күреп алды—анысы, мөгаен, идән астына илтә иде. Анда ниләр бар икән? Узганында Хәнәфи аны күрсәтергә теләмәде, бу юлы ул хакта сүз чыкмады. Кухняны җиһазлау сылтау гына, аның гамендә бөтенләй башка, билгеле. Нурзифа чыгу ягына карады: капкасы бигрәк кин, бигрәк биек—завод капкасымыни! Аның янындагы будканы күр тагын—андыйларны элегрәк хәрби сер саклый торган урыннарда гына куя торганнар иде. Керәм дигән кеше рөхсәтсез үтә алмый да алмый инде, чыгам дигәнен дә тоткарлаулары бик ихтимал... Ярый, бу юлы рөхсәт булды, күрәсең, капка әкрен генә кырыйга таба шуыша башлады. Нурзифа җиңел сулап куйды.

## Байның йорты катлы-катлы

Будка эчендә утырган Кармак, өстәлендәге тимер тотканы кулы белән боргалап капканы ачканда, очлы күзе белән күксел машинага текәлде. «Бик тиз озатты әле безнең шеф бу чибәркәйне,—дип уйлады ул. Һәм үзалдына мәгънәле көлемсерәп:—Эше барып чыкмаган, ахрысы,—дип нәтиҗә ясап куйды.—Әгәр мин булсам, берничә сәгать талкымыйча җибәрер идемме соң!»

Моны күз алдына китерү ялгызлыктан, шөгыльсезлектән, пыскып яуган яңгырдан шактый эче пошкан Кармакның кәефен бераз күтәреп җибәргәндәй итте. Әгәр ана, ул кыз—дизайнер, эш белән килгән, дисәләр көлеп: «Андыйларның «дизайнер» дип аталганын монарчы ишеткән юк иде әле!»—дияр иде.

Ул өстәлдә әкрен генә сөйләп торган радиоалгычның тавышын көчәйтеп җибәрде. Аннан сүзләре аңлаешсыз, көе исә хода бәндәсенең нәкъ менә аерым бер тамырларын кузгата торган җыр колакка бәрде.

Кырысның машинасы тиз әйләнеп кайтты. Кармак аны шундук будкага менәр дип көткән иде, әмма ул олы йортка кереп китте—шеф чакырды булса кирәк.

...Хәнәфи Кырысны үтә дә караңгы чырай белән каршы алды.

—Йә, теге нишли анда?—дип аяк астына ымлады ул.

—Әле бер киндерне пычрата, әле икенчесен...

—Берсен дә эшләп бетерәм дип тырышмыймы һаман?

—Юк әлегә. Ара-тирә кәгазьгә хәшәрәтләр ясап куйгалый.

—Бер чара таба алмыйсың инде шуңа! —дип, ияген чөеп, каршында биегәеп торган Кырысның шадра чыраена текәлде Хәнәфи.—Син аңлыйсынмы, без аны хәзер чыгарып җибәрә алмыйбыз. Эт куштымы сиңа аны урларга! Кем шапырынды, сындырам, аяк астында үрмәләтәм, дип, ә?

—Үзең кәнфитләнергә кушасың бит. Югыйсә без аны әллә кайчан бөгә идек инде... Элементарно!

—Сезнең шул булыр инде, дубасить да мочить! Җәзаларга. Тәнен!.. Ә син җанны җәзалау юлын тап!

Кырысның яшел күзләре зураеп, бәбәкләре тагын да каралып киткәндәй булды. Хәнәфинең эченә шом йөгерде. Бу адәмнең мин-минлегенә тию хәерлегә булмаячак иде.

—Ничек тә булса бер чарасын табарга иде бит... Аны монда мәңге тотып булмас! —диде ул карашын читкә алып.

—Уйларбыз,—диде Кырыс һәм ишеккә борылды.

Будкага менгәндә, аның чырае яңгыр болыты кебек караңгы иде.

—Шефка ни ярамаган тагын?—дип сорады Кармак.

—Белмәссең аны!—Кырыс сирәк, сары тешләре арасыннан ямьсез итеп сүгенеп куйды.—Үзе сындырырга куша теге пачкунны, үзе кагылма, ди. Кыз да булсын аңа, буаз да булсын.

—Нәрсәгә аңа карап торырга! Тотарга да кирәгенчә эшкәртергә! Соңыннан үзе үк рәхмәт әйтәчәк!

Тоткынны ничек итеп «эшкәртергә» икәнен күз алдына китергәндә, Кармакның гадәттә күгәренке чырае алланып чыга, кечкенә соры күзләре яктыра иде. Ул икенче бөтендөнья сугышында гестапо кулланган алымнарны, СССРда шәхес культының котырган чорында КГБ кулланылышында булган ысулларны тасвирлаган китапларны укырга ярата. Аны бәхетенә, соңгы елларда кибет киштәләрендә тезелеп торган «детектив» дигән әсәрләрдә адәм баласын газаплауның бик күп төрләре язылган, телевизордан да яңадан-яңаларын күрсәтеп торалар. Әлбәттә, кинәнеп тукмасаң, тырнакларын келәшчә белән йолкысаң яки түшенә кызган үтүк бассаң, эш тизрәк барыр иде. Рөхсәт кенә юк.

—Прожекторлар куярга кирәк,—диде Кармак «яктылык белән җәзалау» ысулын исенә төшереп.

—Яктылык нормаль булырга тиеш, ди бит теге. Сурәт ясарга комачауламасын, ди.

—Ә тавыш? Тешкә тия торган музыка уйнатып торсаң? Аның мине бораулый торганнары бар, диләр.

—Аңа да бирешеп тормас инде...

—Музыканың кешене үтерә торганнары да була икән. Әле укыдым!

—Нинди үтерү! Иҗатына комачауламаска куша, дип әйттем бит инде!

Кармакның сирәк керфекле кысык күзләре түгәрәкләнеп киткәндәй булды:

—Алайса нишли алабыз соң без?

—Хәзерме? Хәзер без тамак ялгап кайта алабыз. Кәримнең лагманы суына торгандыр анда.

Алар төшкелекне гадәттә Язучылар ишегалдындагы «Сарман» кафесында ашыйлар, чөнки анда пешекче булып Кармакның әшнәсе Кәрим эшли, ул лагман белән пылауны теләнне йотарлык итеп әзерли иде.

Будкадан төшкәч, Кырыс ишегалды түрендәге бәләкәй йорт бусагасында басып торган зәңгәр комбинезонлы ир-атка кычкырды.

—Эй, Абрек! Кил әле монда!

Теге якынлашкач:

—Бар әле, будкага менеп, безнең арттан капканы ябып кал,—диде.—Без әйләнеп килгәнче шунда утырып торырсың. Барыбер эшең юк, бу яңгыр астында чүп утап булмый. Селектордан сораучы булса, бер сәгатьтән кайталар, диярсең.

Аннары Кармакка борылды:

—Ә син утыр рульгә!

—Нәрсә, миңа бер кружка сыра эчәргә дә ярамыймы әллә?

—Монда кайткач эчәрсең.

Юлда барганда, кафеда бер-ике рюмка җибәреп сыйланасын күз алдына китереп булса кирәк, Кырысның чырае ачыла төшкән иде.

—Ә теге пачкун ятсын шунда,—диде ул.—Бик кире адәм кебек күренә, тиз генә бирешмәс. Ә шеф аны болай гына чыгарып җибәрә алмый. Бер-бер чарасын күрергә туры киләчәк, барыбер безнең кулга керәчәк ул!

...Бу вакытта Мозаффар үзенең чарасызлыгын бөтен аяусызлыгы белән аңлый башлаган иде инде.

Ул вакытны сузарга теләгәннән генә Хәнәфинең тәкъдименә риза булгандай кыланган иде. Альбомнан сайлап Айвазовскийның диңгездәге давылны тасвирлаган бер картинасын ясый башлаган иде инде. Бу рәссамның диңгез күренешләре йөзләп санала, арада югалганнары да шактый. Исеме һәркемгә таныш, картиналарын белмәгән кеше юк. Эшлә дә куй! Ләкин ул чакта бу—Хәнәфи өчен баш июгә тиң, кешелегенне җимерү, антыңны бозу дигән сүз булачак иде.

Аһ, әгәр дә без биргән антлар кайдадыр югарыда теркәлеп бара торган булса, күкләрдә ниндидер илаһи зат аларның үтәлешен күзәтеп торса һәм хыянәтчеләрне хөкем итсә икән лә... Шушы арада ант биргәннәренә ун ел тула. Нәкъ ун елдан соң очрашырга сүз бирешкәннәр иде... Ә бәлки шуна да ярсып тотынгандыр бу гамәленә Хәнәфи?

Теге көнне Нурзифа белән телефоннан сөйләшкәндә турыдан-туры: «Мине Хәнәфи ябып тота»,—диясе калган... Нурзифаның Самаркин йортында Хәнәфи янында утыруы йөрәккә артык каты бәрде шул. Зиһенне томалады, акылны чуалтты... Инде хәзер нишләргә?

Ул сикереп торып селекторның төймәсенә басты:

—Хәнәфине бирегез!

—Бер сәгатьтән шылтырат,—диде ят тавыш.

—Миңа хәзер кирәк! Хәзер үк!

—Бер сәгатьтән дидем бит! Кеше юк монда!

Мозаффар бүлмә буйлап әрле-бирле йөренергә кереште.

Болайга киткәч, аны бөтенләй юк итүләре дә ихтимал бит... Телевизордан көн саен күпме кешенең юкка чыгуы турында хәбәр итеп торалар. Аларның бер өлеше генә табыла, һәммәсе дә түгел. Калганнары кая китә? Һәркайсы үзенчә юкка чыга торгандыр. Әмма шунысы бәхәссез: табылмаганнарның күпчелеге исән түгел...

Ә урлап китеп, кол ясап эшләтүләр турында телевизорданниләр генә күрсәтмиләр тагын! Андый хәлләр хәтта полиция бик шәп эшли торган илләрдә дә була икән!

Бездә исә андыйны хәзер томана авыл агайлары да эшли, диләр. Әнә, бер бәндә дуңгыз абзары астында чокыр казып, тегү машиналары куйган да, берничә хатын-кызны урлап, шунда төшереп бикләгән, сатар өчен мендәр-юрган тышлары тектергән, теләге булганда, берәм-берәм тотып көчләгән. Мозаффар ул тоткыннарга гаҗәпләнеп караган иде. Шуннан котылуның бер-бер чарасын тапмаска! Акыллары чамалыдыр бу бичараларның!

Хәер, хак тәгаләнең зәгыйфь акыллы, көчсез бәндәләре дә бар бит: алар, дүңгәләк кебек, тамырсызлар. Көчлерәк җил чыкса, аларны куптарып теләсә кая тәгәрәтеп алып китә. Андыйлар күздән югалды дип беркемнең дә күңелендә бер кыл да зеңгелдәми. Мозаффар исә үз җирлегенә мең тамыр белән береккән, аны бу тормышта мең кеше белән аерылгысыз бәйләгән җепләр бар. Берәве генә өзелсә дә кыңгыраулар зыңлый.

Шулай дип уйлаган иде ул теге тапшыруны караганда. Әгәр дә берәрсе, үзең шундый хәлгә төшәрсең, дисә, саташтыңмы әллә дияр иде...

Бу нинди урын? Кая китереп тыктылар аны? Эзлиләр микән? Азалия милициягә гариза язды микән? Урамда юкка чыккан кешене ничек тапмак кирәк? Әйтик, телевизордан сурәтен күрсәтеп, шушы кеше югалды, күрүчеләр булса, фәлән телефонга шылтыратыгыз, дисәләр...

Мозаффар үзен ничек алып киткәннәрен аермачык исенә төшерергә тырышты. Караңгы урам буш иде, аның йөзен күреп калучы булмагандыр. Ник шунда еллар буе телевизордан күрсәтеп тормыйлар.

Милиция исә җинаятьне тикшерүне нидән башлый? «Кем файдасына

бу?»—дигән сорауга җавап эзләүдән башлый ул үзенен эшен. Берәрсенә шиге төшсә, якасыннан эләктерә дә сорау алырга керешә: «Яле, гражданин, сөйләп бир әле: мәрхүмгә ни үчен бар иде? Өченче көнне фәлән сәгатьтә кайда иден? Шаһитларын бармы?» Тик менә Юлдашевнын юкка чыгуы Рәҗәпов файдасына, дигән уй, ай-һай ла, берәрсенен башына килер микән.

Таш диварлардан да бигрәк шушындый уйлар Мозаффарнын сулышын кыса иде.

## Яшел учак янында

Язучылар йорты тирәсендә болытлар җинелрәк, иркәрәк, көн яктырак сыман тоела. Үзенә бер гамьсезлек, күтәренке рух хөкем сөрә монда.

Күнелне күтәрә торган җылылык ишегалды уртасында, ике бик биек юкә ышыгына сыенган кечерәк кенә бинадан тарала булса кирәк. Тирән идән аслы бу бинанын ишеге өстенә кызыл хәрефләр белән «Сарман» дип язылган. Юкәләр алтын челтәргә төренгәндәй шау чәчәктә, тирә-юнь бал исенә туенган.

Кафены Татарстаннын ерак көнчыгышыннан килгән атаклы эшкуар Илсур Хәйрушев ачып җибәргән, исемен җырдан алып кушкан, диләр. Казаннын төрле тарафларында анын тагын өч ресторанны бар, һәммәсе шәпләр, зурлар. Мондагы кечкенә кафе белән вакланмаса да булыр иде. Әмма кесә калынлыгын кайгыртып кына яшәп булмый, җанга да азык кирәк. Илсурнын исә күнеле нечкә, үзе дә шигырьләр, җыр текстлары язгалый, композиторлар белән сөйләшеп, аларны көйгә салдыра, аннары ин шәп җырчылардан җырлата. Иҗат әһелләре белән исә нәкъ менә шушындый җирдә очрашу кулай.

Урыны җайлы булгангамы, әллә ашы тәмлегәме, бер иш халык «Сарман»га бик яратып йөри. Көн уртасында ишегалдында төрле төстәге машиналар тезелеп тора.

Менә шар ачык бизәкле чуен капкадан күксел «Нексия» килеп керде дә, юкәләр артына узып, зәнгәр «Газель белән янәшә туктады. Аннан Кырыс белән Кармак төштеләр. Кафе бусагасын атлаганда, эчтән чыгып килгән ике кеше белән бәрелешә яздылар: болары шагыйрь Назиров белән җырчы Гыймадиев иде.

Бүген иртәнге якта алар телевидение тапшыруына язылдылар. Шул зур эштән сон тамакларын ялгап та, майлап та чыгып килешләре иде. Кафенын ишеге төбенә завхоз Хәлим бик иркен агач эскәмия дә ясап куйган, өстән явып тормаса, ашап чыккач, шунда утырып бераз гәп сатарга булыр иде. Килгән-киткән агай-эне белән сөйләшү өчен менә дигән урын. Әмма бүген эскәмия юеш иде. Шагыйрь белән җырчы ашыкмый гына олы бинанын капкага карап торган ягына—«парадный» дип аталган борынгы, авыр имән ишегенә юнәлделәр.

Бу йортны Казаннын бер бае егерменче гасырнын башында төзеткән булган. Ике катлы, көзгеле ишекләр иркен, бик биек вестибюльгә алып керә. Андагы кин мәрмәр баскыч икенче катка алып менә. Монда бию залы, биллиард бүлмәсе, туйлар үткәрерлек аш бүлмәсе, ял бүлмәләре, кабинетлар, будуарлар булган. Һәммәсе унтугызынчы гасырдагыча, Мәскәү, Петербург зыялыларынын затлы сарайлары үрнәгендә эшләнгән. Баскыч култыксалары сырланган, түшәмнәргә үрмәле гөлләр, чәчәк бәйләмнәре ясалган. Хәзерге вакытта мондыйны музейларда гына күреп була. Һәм менә Язучылар йортында.

Хуҗа үзе бу затлы бинанын рәхәтен озак күрә алмаган, Октябрь

инкыйлабыннан соң аны тартып алганнар, билгеле. Озак еллар анда балалар хастаханәсе булган, гасыр ахырында гына ул язучыларга тәтегән.

Зөфәр белән Ансар килеп кергәндә, завхоз Хәлим мәрмәр баскычның култыксасына куелган буе бер метр чамасы бронза кыз сынына электр чыбыгы сузып азаплана иде.

—Исәнме, Хәлим! Һаман эштә син, ә! Төшке ялың юкмы әллә?

Җыйнак, ыспай гәүдәле, спортчыларга хас төгәл хәрәкәтле Хәлимнең түгәрәк, мөлаем йөзе елмаюдан балкыды. Ул, гомумән, язучы-артист халкын ярата, алар белән аралашудан үзенә бер тәм таба иде.

—Үзебезнең элита өчен тырышам. Сезнең өчен. Булгач-булгач булсын, дим. Менә монда лампочка куям әле.

Ул сынның баш очына күтәрелгән кулына ымлады.

—Мондый борынгы сынга лампочка тоттыралармыни? —диде Ансар.— Бөтен ямен качырасың. Шәмдәл куярга кирәк.

—Аңа шәмдәлне каян табасың инде...—диде Хәлим гаепле кеше сыман.

—Җиренә житкереп, карап тота белмисез бинаны,—дип ризасызлыгын белдереп куйды Ансар. Мондый биналарны опера театры үрнәгендә бизәү тиеш, дип саный иде ул.

Шагыйрь белән җырчы баскычка түгел, ун яктагы ишеккә—«каминлы бүлмә»гә юнәлделәр. Анда ак һәм яшел плитка белән тышланган бик затлы борынгы камин—учак бар иде. Үзе матур булу бер хәл, киштәсенә төрле яклардан килгән язучыларның бүләкләре: атка атланган Салават Юлаев, бөркет, ак торна сыннары тезелгән иде аның.

Атаклы учак иде бу. Урыс телендә язучы татар малае Әхәт Мушинский телевидениедән «Яшел учак янында» дигән тапшырулар ясый, танылган язучыларны, артистларны, рәссамнарны чакырып, сәнгать турында бик хисле, эчтәлекле сөйләшүләр оештыра иде. Бүген дә Зөфәр белән Ансарны нәкъ шушында утыртып әңгәмә корды.

Каминга каршы яктагы диварга зур рам—Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Нәби Дәүли, Нури Арслановның кумәк портреты эленгән. Рәссам Мозаффар Юлдашев аларны бакчада, өстәл янында тасвирлаган.

Зөфәр картина каршына басып, авыр итеп көрсенеп куйды.

—Их, бар иде егетләр, юк инде егетләр! Әле кайчан гына шушы йортны балкытып килеп керерләр, иде. Һәрберсе үзенә аерым бер дөнья! Кабатланмас материк! Аларсыз яшәүне күз алдына да китереп булмый иде. Хәзер менә очрашкан чакларны сагынып сөйләргә генә калды. Бер мизгел кебек кенә тоела...

Ул башын иеп, гадәтенчә шигырьгә күчте:

—Мәңгелек ул мизгелләрдән тора,
Гомер—иң татлысы шуларның...
Сыя аңа һәммә бизәкләре,
Хикмәтләре якты дөньяның.

—Сыяр... сыйдыра алсаң,—диде Ансар уйчан тавыш белән.

—Ә бит сыйдырасы килә. Бөекләребездән үрнәк алып, канатны киң җәеп яшисе иде...

Алар дивар буена тезеп куелган йомшак кәнәфиләрнең икесен учак янынарак шудырдылар да, иркенәеп утырдылар. Нәкъ менә Мушинскийның тапшыруындагы кебек. Телевидение камерасы каршында баягы сөйләшү ярыйсы гына чыкты кебек үзе, әмма күңелдәниндидер канәгатьсезлек хисе дә калган иде. Мәсьәләнең асылына төшеп житеп булмады, кеше

тормышында матурлыкның, сәнгатьнең урыны турындагы иң кирәк фикерләр әйтелми калды кебек.

—Әхәткә әйтермен әле, бүгенге белән генә чикләнмәсен,—диде Зөфәр уйланып.—Сөйләшүне һичшиксез дәвам итәргә кирәк. Тирәннәнрәк актарырга... Әйтик, дүртебезне чакырып, бер бик эчтәлекле тапшыру оештырырга була.

—Кемнәрне ул дүртегезне?

—Моннан ун ел элек ант иткән идек бит...

—Барыбыз бергә жыела алырбыз, дисенме?

—Ә ник жыелмаска, исән-сау бит барыбыз да.

—Хәнәфи килмәячәк,—диде Ансар.—Ни сөйләсен ул?

—Без анда мактанышырга жыелмаячакбыз бит,—диде Зөфәр уйланып.—Бик житди бер мәсьәләне уртага салып, фикер алышачакбыз. Мин мондый тема тәкъдим иттем: бу дөнья нидән яралган?

Ансар сызгырып жибәрде:

—Тапкансың икән! Безнең эшме ул? Әнә фәйләсуф дигән адәмнәр бар, ул хакта шулар гәп сатсын. Яки әнә муллалар.

—Ялгышасың, туган. Сәнгать кешеләренең сүзе бик мөһим монда. Талмудта әйтелгән: иң элек сүз булган, диелгән. Ә мин, мәсәлән, моның белән килешмим.

—Нишләп алай? Үзеңнең ижади коралың сүз бит!

—Әйе, төп коралым—сүз. Әмма сүз дигән коралга тотынганчы, минем күз алдымда образ туа. Аңлыйсыңмы, Образ! Сурәт! Ап-ачык булып! Әгәр ул томанлы булса, аны сүз белән тасвирлап булмый. Минемчә, дөнья яратылыр алдыннан иң элек сурәт булган. Үзең уйлап кара: әгәр дә бу жиһанниндидер Бөек Кодрәт Иясе, Илаһи Зат тарафыннан яратылган икән, башта ул аның ничек буласын уйлагандыр. Шунсыз мөмкин түгел.

—Планын төзегәндер, димәкчеме инде син?—диде көлемсерәп Ансар.

—Язып-сызып куймаса да, ап-ачык итеп сурәтен күз алдына китергәндер. Һәрнәрсәне һәм һәр жан иясен.—Зөфәр кулларын күтәреп, карашын ике учына төбәде.—Менә шушы кулларны гына да бер плансыз ясап булмый бит. Адәм атабызны, Хәва анабызны башта күз алдына китермичә ничек ясамак кирәк...—Ул биек тәрәзә артында чәчәккә күмелеп утырган агачка карады.—Яки менә бу юкәне... Аның яфрак ярганын, чәчәк атканын, көзен алтын яфрак койганын... Һәммәсе башта сурәттә булган! Илаһи затның күз алдындагы сурәттә! Ул сурәтләр төсле, гүзәл булганнар!

—Алайга китсә, моң, музыка да булгандыр,—диде Ансар аның фикеренә кушылып.—Һәрнәрсә дә даими үзгәрештә, хәрәкәттә бит. Ә хәрәкәт гармониясез, музыкасыз булмый. Дөнья яралганда илаһи көй яңгырап torгандыр. Ә беләсеңме, жиһанның илаһи гармониясен үзенә сыйдырган музыкаль әсәрләр бар. Аларны тыңлагач, үзең дә өр-яңадан тугандай буласың, тирә-юнеңдәге һәрнәрсәне дә бөтенләй башкача күрә башлыйсың.

—Дөрес әйттең!—диде Зөфәр.—Дөнья камил өлгеләр буенча, гүзәл көй яңгырап торганда яратылган. Бу караш дингә дә каршы килми. Инде материалистларны алсак... Алар әйтә, адәм баласын хезмәт кеше иткән, ди. Мин алар белән килешмим. Адәм баласын кеше иткән нәрсә—ул сәнгать. Безнең бик ерак бабаларыбыз миллион еллар элек хайван дәрәҗәсендә булганнар. Алар табигать биргән белән тамак туйдыруны һәм үрчүне генә белгәннәр. Кыр кәжәсе яисә бүре кебек. Менә берзаман кайсыдыр бер мизгелдә шундый бер жан иясенең кинәт кенә күңел күзе ачылып киткәндәй булган. Ул—матурлыкны күргән! Әйтик, менә шушы юкә чәчәкләренең матурлыгын. Юк, мөгаен, болан баласының далада уйнаклап йөргәнен күргәндер ул.

—Ә нишләп болан баласын?

—Чөнки тау мәгарәләрендәге бик борынгыдан калган сурәтләрдә болан баласы еш тасвирлана.

—Үзең барып күрденме әллә?—дип шаяртып алды Ансар.

—Тарихчыларның, археологларның китапларын укыдым. Алардагы рәсемнәрне күрдем. Ул борынгы бабабыз, башка ырудашлары кебек үк, анарчы боланны тере ит итеп, тотып ашарга ярый торган нәрсә дип кенә уйлагандыр. Килгән бер мизгел, ул аның матурлыгын күргән. Күргән дә тетрәнгән. Күнел күзе ачылган моның! Жанварның талпынып очынган кыяфәтен хәтеренә сендереп калдырган ул. Һәм, мәгарәсенә кергәч, учак яктысында, аны күз алдына китергән. Шул матурлыкны башка кардәшләренә күрсәтәсе килгән аның. Бу теләге тыелгысыз омтылышка әверелгән...

—Илһам килгән, димәк...

—Әйе, илһам килгән ана. Һәм ул жирдән каты таш табып алган да, шуның белән диварга сурәт чокырга керешкән. Менә шуннан башланган аның адәм затына әверелүе! Иманым камил: кешелек матурлыкны тоя белүдән, тасвирлаудан башланган! Кайбер галимнәр, маймылны кеше иткән нәрсә—эш коралы ул, диләр. Имештер ки, маймыл кулына таяк алып, жирдән татлы тамыр чокый башлаган да, шуннан кеше булган. Хәзерге маймылларның да кайберләре таяк белән эш итә, ләкин бер дә үзгәрми, маймыл булып кала бирә. Әгәр ул шул таягы белән болан сурәте ясый алса, ул чакта, мөгаен, безгә охшый башлар иде... Адәм баласын кеше иткән нәрсә—матурлыкны күрү, аңлау, аны тасвирлау! Матурлыкка күнел күзе сукыр калган бәндәләр—чын кеше түгел, кире хайванлыкка кайткан жан ияләре алар.

—Синенчә, адәми затны Кеше иткән нәрсәләр—рәсем сәнгате, моң. Шулай килеп чыга. Ә сүз соң, сүз! Син аны бөтенләй чуттан төшереп калдырасыңмы әллә?

Зөфәр серле көлемсерәде:

—Сүзнең атасы—сурәт, тасвирлау, анасы—моң, музыка.—Шагыйрьнең йөзе балкыды, бөдрәләре алтын тажны хәтерләткәндәй булды. «Пәйгамбәр менә шушындый буладыр»,—дип уйлап куйды Ансар.

Шагыйрь кулларын күтәреп, карашын биек, бизәкле түшәмгә төбәде дә, шигырь укый башлады:

Булган шундый илаһи бер мизгел:
Биекләргә, зәңгәр күкләргә,
Күтәрелгән жирдән Тасвир, Аһән,
Жир тетрәгән һәм күк күкрәгән.
Зур туй булган йолдыз арасында—
Тасвир белән Аһәң кушылган,
Могжизаи кодрәтле Сүз туган
Гүзәл Тасвир, моңлы Аһәңнән.

—Син бу хакта поэма язарга тиеш,—диде Ансар.

—Күптән язам инде... Тик бик авыр бирелә.

—Чын сәнгать әсәре жинел генә тумый шул ул.

—Әйе, һәр сүздә ап-якты, ап-ачык сурәт һәм кабатланмас моң, музыка булырга тиеш. Аны ишеткән яисә укыган кешенең күз алдында өр-яңа манзара барлыкка килсен һәм күнелендә дәртле яисә сагышлы көй чыңласын. Сүзләр шундый кодрәтле итеп яратылган бит. Ләкин менә хайванлыктан чыкмаган бәндәләр аларның күбесен имгәткән, зәгыйфьләндергән. Тасвирын бетергән, көен-моңын бозган. Шундый гарип сүзләр арасыннан

балкып, яңгырап торганнарын эзләп табу җинел түгел.

Ул башын иеп, бераз тынып торды.

—Кешенең гомере кыска,—диде ул уйланып.—Ул бакый дөньяга күчә дә онытыла. Ә менә җирдә ул калдырган матурлык кала, яши. Уйлап карасаң, исең китәрлек: бөек Мисыр дәүләтенен юкка чыкканына әллә ничә мең ел, ә без шул чорда ясалган Нефертити сынына сокланабыз. Леонардо да Винчи өч гасыр элек яшәгән, ә анын «Джоконда»сына хәзер дә миллионнарча кешеләр мөкиббән. Сөембикә манарасы каршында дүрт гасырдан соң да баш иябез....—Шагыйрь карашын яшел учакка төбәде.—Менә моны да кемдер ясаган. Үзе, мөгаен, күптән юктыр инде, эшләгән матурлыгы хәзер дә күз алдында. Әйдә ягып карыйк әле шуны!—диде ул кинәт кенә.

—Ярый микән соң?

—Нишләп ярамасын! Мич бит ул! Ягар өчен ясалган!

—Мушинский якмый бит.

—Иренә торгандыр. Хәзер, кәгазь-мәгазь булса да ягып җибәрәбез аңа!—диде Зөфәр рухланып.

Һәм урыныннан сикереп торды да коридорга чыгып китте. Аннан бер кочак кәгазь, иске гәзитләр күтәреп кире керде. Иелеп учакнын чуен рәшәткәсе артына гәзитләр бөгәрләп тыкты, чалбар кесәсеннән зажигалка чыгарып, ут төртте. Мич эчендә бик матур булып кызгылт-сары ялкын телләре биешә башлады. Бер мәлгә чыннан да күнелле генә булып китте. Ләкин озакка түгел: мич авызыннан куксел төтен бөркелә башлады.

—Суырмый әле,—диде Зөфәр учакка кәгазь өстәп.—Бераз җылынгач, үкереп суыра башлаячак. Каминнын торбасы түбәдән турыга чыга бит анын.

Ләкин кәгазь өстәгән саен, бүлмәгә төтен ныграк чыга башлады. Ансар ишекне ачты, коридорда хатын-кызлар чырылдашты, чиләк күтәреп Хәлим йөгереп керде дә, каминга су тондырды. Төтен парга уралды, идәнгә корымлы су җәелде.

—Ягарга кирәкмәс иде,—диде Хәлим.—Сорамадыгыз да ичмасам.

—Ниен сорап торасын анын?—диде ачыткан күзләрен сөрткәләп Зөфәр.—Мич ягарга да начальствонын рөхсәте кирәкме әллә?

—Торбасы томаланган бит анын,—диде Хәлим аклангандай.

—Ник томаладын син аны?

—Кыш көне түбәдән кар көрәгәндә калае тишкәләнгән. Язын яңгыр ява башлагач ямарга туры килде. Прсидәтел әйтте, тоташтан каплагыз да куегыз, диде.

—Күрденме,—диде Ансар Зөфәргә.—Матурлык менә шушылай юкка чыга инде ул. Кадерен белмәгәннән, карамаганнан. Монда мич торбасын томалаганнар, анда,—ул вестибюльгә борылды,—борынгы сынга хәзерге заман лампочкасын тоттыралар...

Сын янында ала-кола ярым-хәрби киемнән ике ир заты басып тора иде. Берсе ябык, озан муенлы, икенчесе базык гәүдәле, шадра чырайлы.

—Кемнәр бу?—дип пышылдап сорады аларнын кыяфәтеннән сәерсенгән Ансар.

—Яшь авторлардыр, күрәсен,—диде Зөфәр.

—Нинди яшь булсын алар?

—Автор буларак яшьтер. Син белмисенмени, бик күпләр пенсиягә чыккач кулына каләм ала. Аннары язганнарын күтәреп монда киләләр. Китап чыгарасылары, язучылар берлегенә керәселәре килә.

—Бар икән әле укыйсылар...—дип көрсенде Ансар. Зөфәр исә һаман әле мич белән мавыккан иде.

—Ач син аның торбасын,—диде ул Хәлимгә.—Югыйсә, билләһи, идарәгә язып бирәм!

—Идарә төзәтми ич аны!—диде тегесе көлеп.—Барыбер мина кала! Шушы әйткәнегез бик житкән. Эшләрбез, борчылмагыз!

Озын муенлы адәм аларга якынрак килеп:

—Исәнмесез,—диде.

—Саумысез. Ни йомыш?—диде Хәлим.

—Бер танышыбызны эзли идек.

—Нинди танышыгызны?

—Кәримне.

—Поварныңмы? Кәрим монда керми ул. Кафедан сорагыз әнә.

—Бакырдан ясалганмы әллә бу?—дип кыз сынына ымлады озын муен.

—Бакырдан булса ни? Сиңа барыбер түгелмени?

Хәлбуки, Кармак өчен—озын муенлы бу адәм нәкъ менә ул иде—аның өчен сынның бакыр булуы бик мөһим иде. Алар, Кырыс белән икесе, әллә янгын чыкканмы дип, кызыксынып кергәннәр иде. Кире ишегалдына чыккач, ул теш арасыннан сызгырып:

—Нихәтле мал әрәм ята-а,—дип куйды.

—Кайсы мал?

—Теге сын соң! Күпме бакыр бит анда! Поттан артыктыр!

—Ташла! Күрмәдеңмени, почмакка: «Ведомстводан тыш каравыл саклый», дигән язу кагып куйганнар.

—Син ул каравылны күрдеңме соң? Ишекнең эчке ягында куышы бар, шунда бикләнеп утыра бит ул. Тәрәзәсе ишегалдына чыга. Ә арткы якта ни барын күрми дә, ишетми дә. Әйдә, кереп карыйк әле,—дип шар ачык кече капкага таба тартты ул Кырысны. Алар бакчага кереп, бинаның арткы ягына чыктылар. Монда чыннан да бик аулак иде. Бакчаның теге ягында нииндидер офис бар-барын, әмма төнлә ул буш каладыр, ишеге янында, эчтә бер каравылчы гына утырадыр. Иркен бакчаны биек юкә, тупыллар ышыклый, ә арырак исә куак баскан.

—Шәп урын!—диде Кармак бик канәгать кыяфәт белән. Аннары борылып бинаның өске тәрәзәләренә карады.—Эче тулы компьютердыр инде боларның. Иренмичә, иркенләп бер карап чыгарга кирәк әле.

—Нәрсә, таламакчы буласыңмы әллә?

—Кеше талау түгел лә бу! Общественный милек. Димәк, минеке дә дигән сүз. Әйдәле!

Ул юлдашын тагын да эчкәрәк әйдәкләде.

—Бик шәп куыш бар монда...

Зур бина артында заманында бик шәпләп янкорма салып куйган булганнар. Соңгы вакытта аны язучыларның Тукай исемендәге клубына әйләндергәннәр иде. Клуб булгач, кино күрсәтергә дә кирәк дип, янына кызыл кирпечтән нык итеп кинобудка ясаганнар. Узган гасыр ахырында кино күрсәтүләр бетте, будканың кирәге калмады. Хәер, яхшы малга хужа табыла—бирегә йортсыз-жирсез сукбайлар ияләнде. Кереп кунгалыйлар, юл уңаеннан ихатада күзләренә чалынган әйбер-караны да чәлдереп чыгып китәләр иде. Ахыр чиктә Хәлим куышның ишеген кирпеч белән томалап куярга мәжбүр булды. Кармакның моңа кәефе кырылды.

—Кереп булмый икән шул монда,—диде ул өр-яңа кирпечләрне капшаштырып.

—Нәрсәгә соң ул сиңа?—дип сорады Кырыс.

—Әйбер куеп торырга жайлы иде. Син анда теге зәңгәр «Газель»не күрдеңме? Әллә кайчаннан бирле тик тора. Өр-яңа. Карданын гына сүтеп алсаң да мал бит ул.

—Син тагын безнең ихатадан ташый күрмә!

—Кеше әйберенә тияргә кем дип белдең мине!

—Ә «Газель» үз малыңмы әллә?

—Кешенеке түгел инде. Күрмәдеңмени, номеры хөкүмәтнеке бит, госномер. Уртак мал, дигән сүз.

—Эләктерергә генә торасың үзең.

...Алар машинага утырып, капкадан чыкканда, урамның каршы ягына кара »Джип-Чероки« белән Хәнәфи килеп туктады.

—Нишләп йөрисез сез монда?—дип сорады ул машина тәрәзәсеннән башын сузып.

—Ашарга килгән идек.

—Хәзер үк кайтыгыз.

Шунда Хәнәфи капкадан чыгып килгән Зөфәр белән Ансарны күреп алды да, машинасыннан төште.

—Сәлам!—дип кул изәде.—Кая барасыз? Утырыгыз, илтеп куям.

Машинада хәл-әхвәл сорашу китте, Хәнәфи егетләрне кунакка чакыра башлады.

—Вакыт табып очрашыйк әле бер!—диде.—Әйдәгез, шушы арада утырып алабыз.

—Кайда?—дип сорады Ансар.

—Мин сезне Самаркин йортында сыйлый алам.

—Аның безне чакырганы юк бит әле.

—Чакырыр иде дә, өйдә юк шул ул. Мине хуҗа итеп калдырды. Иркен, аулак, тыныч. Һавасы саф. Менә дигән!

—Күреп кайтсаң начар булмас иде,—диде Зөфәр бармак белән бөдрәләрен аралап.—Хәзерге байлар ничек яши икән.

—Нәрсәсе бар инде аның!—диде Ансар. Зөфәрдән аермалы буларак, аны күп байлар үзләренең туйларына, юбилей бәйрәмнәренә чакыргалап торалар иде.

—Мин сине җырларга чакырмыйм бит, сыйларга чакырам,—диде Хәнәфи.—Олы кунак итеп!

—Шулай дисәң генә инде.

—Сезне кая илтергә соң?—дип сорады Хәнәфи Горький урамына чыккач.

—Мин эшкә кайтам, гәзит-журнал нәшриятына,—диде Зөфәр. Ул «Чаян» журналында эшли иде.

—Ә мин опера театры янында төшеп калырмын.

—Телефоннарыгызны искә төшерегез әле,—диде Хәнәфи.—Иртәгә мин сезгә шалтыратырмын да, кичкә таба килеп алырмын. Килештекме?

Ул шулкадәр ихластан чакыра иде ки, егетләрнең риза булудан башка чарасы калмады.

*Ахыры киләсе санда*



Резеда
Вәлиева

# ТАТАР КЫЗЫНА

## Син—минем язларым

Зур авыл урынында
Кабер дә көл кала.
Күтәреп баланы
Кешеләр кузгала.

Кешеләр кузгала
Киләчәк каршына,
Карамый янгынга,
Үлемгә—барсына,

Кешеләр яшәүне
Коткарып калалар,
Авыллар урынына
Шәһәрләр салалар...

Капмасын янгыннар
Киләчәк таңына,
Аналар, басыгыз
Тынычлык сагына!

Балалар беркайчан
Күрмәсен сугышны,
Белмәсен сугышның
Кайгысын, сагышын.

Булмасын сугышлар!

## Япь-яшь кызлар китте ут эченә...

Оныта алмам, мәңге оныта алмам
Йөрәгемнең әрнеп сызлавын
Озатканда утлы яу кырына
Назлы гөлдәй татар кызларын.

Кызлар китте җырлар җырлый-җырлый,
Ак каеннар сыгылып тыңлады.
Япь-яшь кызлар китте ут эченә,
Йөрәкләрдә калды моңнары.

Гөлләр кебек гүзәл апам китте
Гүләп торган сугыш кырына.
Каерылган пар канатлар кебек
Толымнары калды кулымда.

Киткән икән, бәгърем, мәңгелеккә,
Ут эчендә гомерен җуярга.
Язган икән салкын толымнарын
Кайнар яшьләр белән юарга...

Еллар үтә, сагыш китә, диләр,
Ник әрнетә һаман ул моңнар?
Күз алдымнан китми, пар канаттай,
Сыгылып төшкән шушы толымнар...

## Кырларыңа мәхәббәтем җырлап киләм...

Туган җирем, чыксам иркен кырларыңа,
Хәйран калам тургайларың моңнарына.
Гашыйк булып зәңгәр күзле гөлләреңә,
Йөзем куям талгын-йомшак җилләреңә.

Аяк астым—хәтфә кебек яшел чирәм,
Һаваларың татлы синең, хуш ис кенә.
Бәхетемнән сайрар коштай канатланып,
Кырларыңа мәхәббәтем җырлап киләм.

Җырлап киләм мәхәббәтем-җырларымны,
Күңелемә сарган шатлык-моңнарымны.
Бүләк булсын сиңа сулмас йөрәк җырым,
Әй кадерле, әй сөекле Туган җирем!

## Туган телем

Сандугачым, былбыл-гөлем,
Нигә моңлы синең телең?
Нигә болай сайрауларың
Үзәгемне өзә минем?

Тавышыңда туган якның
Чишмәләре чыңлап китә,
Иң якын көй-моңнарымның
Аһәңнәре чагылып үтә.

Моңнарыңның тәмен беләм,
Бигрәк инде якын күрәм.
Тугандаштыр синең телең
Минем туган телем белән!

## Үпкәлисез миңа, якташларым...

Үпкәлисез миңа, якташларым,
Кайтмыйсың, дип, туган якларга,
Мәхәббәтең бер дә юкмыни, дип,
Бергә үткәргән сабый чакларга?..

Туган ягым минем, туганнарым,
Мин сагынып сезне, җан атам,
Урал тавын, ямьле Әй буйларын
Әүвәлгечә үк өзелеп яратам.

Искә төшкән саен күк Уралым,
Хыялларым дөрләп кабына.
Алтын дәрья кебек кырларының
Нурларыннан күзем чагыла...

Бер тыңласам Үзән буйларында
Язын сандугачлар сайравын,

Моңнарының кыя ташларында
Кайтавазлар булып яңравын,

Бер күрә алсам зәңгәр таңнарының
Атуларын матур сызылып,
Балачагым кире кайтыр кебек,
Алсу йөзле чая кыз булып...

## Туган җирем минем—Татарстан

Туган җирем минем—Татарстан,
Нигезендә алтын яткан җир,
Иңнәреннән горур Идел аккан,
Мусаларны сөеп баккан җир.

Туган җирем минем—Татарстан,
Әкиятләрем чынга ашкан җир.
Газиз халкым, үз иреген яклап,
Көрәш мәйданына баскан җир.

Туган җирем минем—Татарстан,
Болгарларым нигез салган җир.
Егетләре, батыр исемен аклап,
Дан-шөһрәтен саклап калган җир.

## Ялгыз караб

Яр буенда басып торам,
Агым суларга карап.
Тормыш гүя шул агым су,
Ә мин—ялгыз бер кораб.

Әле уңнан, әле сулдан
Дулкыннар кага гына.
Тик тормыш-су тормый туктап,
Ага да ага гына.

Ага да ага, ә күңел
Һаман да бәхет көтә.
Бәхетләр озак көттерә,
Гомеркәйләр тиз үтә...

Бәргәләнә ялгыз кораб
Ике яр арасында.
Белсәң иде, бәхетеңә
Озакмы барасылар...

Тик сүнми, сүрелми күңел,
Гел бәхеткә ашкына.
Аккошлар булып оча ул
Ак өметләр каршына.

Ага да ага тормыш-су,
Ә күңел бәхет көтә.
Тик талмас күңелләр генә
Зур бәхетләргә илтә.

***Редакциядән:*** *Май аенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган шагыйрә, балалар өчен шигырьләр, әкият, поэмалар, күпсанлы популяр җырлар (текстлар) авторы Резеда Вәлиевага 80 яшь тула. Шагыйрәне журналыбыз укучылары исеменнән ихлас котлыйбыз, аңа исәнлек, күңел тынычлыгы, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Казанда Сәйфи Кудаш белән очрашу. Беренче рәттә (сулдан уңга)—Мөхәммәт Гайнуллин, Сибгат Хәким, Нәкый Исәнбәт, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан h. б. 1978 ел.*



*Һади Атласи (1876-1938)— күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарихчы.*



*Сәнгать кешеләре һәрчак юлда, халык арасында булды. Сулдан уңга—композитор Марс Макаров, җырчы Нәҗия Теркулова, җырчы Эмиль Җәләлетдинов, скрипкачы-музыкант Заһид Хәбибуллин. Үткән гасырның 70 нче еллары.*




*Элекке «Болгар» номерлары. Тарихи бинаның соңгы айлары. 2008 ел .*



*Башкортстанда яшәп иҗат иткән халык шагыйре Әнгам Атнабаев (1928-1999).*



*Замандашлар. Сулдан уңга— шагыйрь Рөстәм Мингалим, композитор Фасил Әхмәтов, рәссам Рәшит Имашев, язучы Рабит Батулла. Үткән гасырның 80нче еллары.*

Рәмзия
Габделхакова

# ТАУ АРТЫНДА КОЯШ БАР

РОМАН

### 3

Кышкы каникулда мин әтине өйләндереп килдем...

Бу хәл шулай тиз булыр дип һич уйламаган идем, әлбәттә. Ике атна элек кенә күз яшьләренә буылып, хәсрәттән сыгылып төшкән әтине шул арада әйтерсең алмаштырып куйганнар, кияү егетемени! Кифаясе юаткандыр инде, йөзе тулган айдай балкый, күзләре елтырый, каймак ашаган мәчедәй борын астыннан: «Уфа-Чиләбе, пешә кура жиләге,»—дип мыраулап йөри. Шат иде әти, көләч иде, аны бу кыяфәттә күргәч, ачу-үртәлүдән шартлар дәрәҗәгә җиттем. Әби дә кайгылы кешегә охшамаган, яшь киленнәр сыман жил-жил йөгереп йөри. Мине күргәч, әле кичә генә аерылышкандай коры гына:

—Чәй кайнаган, аш плитәдә, үзең кара инде,—диде дә, каядыр чыгып та югалды.

Тик миндә ашау кайгысы түгел, тамагымнан ризык үтми. Боек карашым белән әнисез йортның почмакларын айкап, монсу уйларга чумып, өстәл янында ялгызым утырдым-утырдым да, аптыраганнан мунча ягарга киттем.

Әнидән башка бу өйдә миңа бер ямь юк иде...

Кичен исә әтидән шундый сүзләр ишеттем:

—Кызым, күпме елап утырсаң да, әниеңне кайтарып булмый. Күреп торасың, әбиең картайды. Син бала-чага түгел, тагы бер елдан укытучы буласы кеше, мине аңларсың. Кыскасы шул, кызым: мин өйләнмәкче булам. Ни диярсең?

Миннән ни «ә», ни «бә» ишетмәгәч, кайтарып сорады:

—Син каршы түгелдер бит?

Шул сүзе миңа житә калды, күңелдә кайнаган нәфрәт ташкынына юл ачылды, сулышыма буылып кычкырып җибәрүемне үзем дә сизми калдым:

—Мин каршы! Каршы!!! Әле әниең кабере дә суынырга өлгермәгән, син инде үзеңнең... Син... син үзеңнең себеркеңне монда алып кайтмакчы буласың! Сезнең аркада әни үлде! Син үтердең әнине! Син үтердең!

Гомердә дә мине мондый халәт-кыяфәттә күрмәгән, авызымнан бер кәлимә каршы сүз ишетмәгән әти югалып калды:

---

*Дәвамы. Башы 4 санда.*

—Чү, кызым, сүзенне үлчәп сөйлә, артыгын кыланма алай...

Кай арада ишеткән, кече яктан әби җилтерәп килеп керде:

—Атана каршы сөйләргә ни хакың бар, манка! Аның тәкерәге генә бит син! Мидхәт, ни пычагыма теленне әрәм итеп, кинәшеп утырасың бу җүләр белән?! Үзен—баш, үзен—хуҗа, ничек телисен, шулай эшлә!

Йөрәккә пычак кададылармыни, хәлем-сабырлыгым бетте, илереп-илереп еларга тотындым. Үзем елыйм, үзем ярсый-ярсый такмаклыйм:

—Сез үтердегез әнине! Икәүләп таладыгыз! Бер көн рәхәт күрмәде мескенкәем. Әзергә бәзер булып, шул ыштансыз Кифая монда килмәкче буламы?!

—Нинди Кифая булсын ди ул сиңа? Анаң кебек кешегә шулай дәшәләр димени, тәрбиясез бала?! Апа дип сөйләш!—диде әти.

—Әйтми генә торыйм әле!—дидем мин киреләнеп. Әрнү-үртәлү хисләре күз-акылны томалаган чак иде.—Әнә, Зәкия әтисенә дә Шакир дип кенә дәшә әле.

Зәкиянең әтисе—мәңге айнымас бер сәрхүш абзый, исерек килеш әниләрен кыйнап бик нык имгәткәч, Зәкия ана башка бер тапкыр да «әти» дип дәшмәскә ант иткән, имеш. Һәм сүзендә тора да. Тәки әтисенә «Шакир» дип йөри. Үземнең дә ишеткән бар, бер чак кибеттә сатучы Сөммия апага: «Безнең Шакир керсә, бурычка бирә күрмә!»—дип сөйләнеп торган иде.

Әнине газап утларында яндырып, вакытсыз гүргә керткән шул кыланчык Кифаяга зурлап-олылап «апа» дип тел әрәм итәмме соң?! Хәзер, тот капчыгыңны! Әнинең кабере суынмас борын монда йөгереп килмәкче була, оятсыз! Килми генә торсын әле! Барыбер көн күрсәтмим мин аңа! Ник килгәненә үкенер, мин әни кебек булмам, җебеп тормам!

Әтигә дә шулай дидем. Ул аптырап баш чайкаудан уза алмады. Миннән ким ярсымаган әби исә бирешергә уйламый, бөеренә таянып, бугаз киереп, һөҗүмен дәвам итә:

—А-а, карагыз әле берәүне! Батырайган, кеше булган икән! Атана акыл өйрәтергә иртә әле сиңа. Нишләргә кирәклеген үзе беләдер. Өйләнәм дигәч, өйләнер. Синнән кем сорап тора?!

Миннән рөхсәт сорап торучы чынлап та булмады... Әти үз сүзеннән чигенә торган кеше түгел. Ул ничек хәл итә—шулай булачак.

Әтидән бары шуны үтендем, ул да булса, бу йортка чит хатын кергәнче, әнинең кырыгын үткәрү иде. Әбиләрдән ишеткәнем бар, үлгәч тә, кешенең җаны кырык көн үз йортында яши, барысын күреп, ишетеп тора икән. Шуңа күрә өйне ташлап йөрергә ярамый, диләр. Имеш, җан ямансулап елый ди. Үз өендә Кифаяның хуҗа булып йөрүен күргәч, әнинең җаны бик рәнҗер. Исән вакытта да күпме рәнҗеткәннәр, инде үлгәч тә рухына хөрмәт юк.

Ләкин бу үтенечем дә аяк астында калды. Әтинең кирелеге, үҗәтлеге, минем сүз-теләгем белән тамчы да исәпләшмичә, әби белән Кифая кубызына биюе аңа булган нәфрәтемне тагы да дөрләтеп җибәрде. Шул көннән соң безнең арада бернинди якынлык калмады, әти минем өчен җиде ят кешегә әйләнде.

Кифая безнең бусаганы атлап кергән көнне, каникулым да тәмамланмаган килеш, мин Казанга китеп бардым. Әнисез ятим генә түгел, туган йортыннан мәхрүм калган сукбай да идем мин...

Борын күтәреп чыгып киткән белән түгел, кикрик тиз шиңде. Стипендиянең яртысын фатирга түләгәч, башым учлап уйга калдым. Болай да санап карадым кулымдагы «Ленин башларын», тегеләй дә санап карадым. Ләкин өстенә карап күпме санасаң да, үкереп еласаң да, җавап бер: бу тәңкә-тиеннәр—ипилек-тозлык кына. Дөрес, минем әле итем-бәрәңгем бар. Әлегә... Алар бетсә, коры суда утырачакмын. Нидер эшләргә кирәк.

Әйе, эшләргә кирәк!

Уйлый торгач, тулай торакка барып карарга булдым. Безнең янда гына кооперация техникумы бар, анда укучыларга хөррият: ике адымда гына общагалары. Аны бик мактыйлар. Тәртип икән анда, бөтен җирләре ялт итеп тора икән. Дәресләр башланганчы, иртүк шунда юнәлдем. Бәхетемә, комендант урынында иде. Бер бәйләм ачкычларын шылтыратып, каршыма үзе килеп чыкты. Тик аның җавабы мине юатмады:

—Бездә үз студентларыбыз эшли.

Һаман нидер өметләнеп, китәргә теләмичә таптанып торуымны күрепме, кызганды бугай:

—Менә урам себерүче егетебез укып бетерә быел, киләсенме соң? Аена җитмеш сум түлибез,—диде.

Минем исәп җыештыручы булып керү иде. Ләкин сайланып маташыр чак түгел, ярар, дидем. Комендант апа миннән тегесен-бусын сорашты да, күршедә генә укып йөрүемне белгәч, син дә үзебезнеке икән, дип, беренче марттан эшкә чыгарга кушты.

Аның яныннан харап горур кыяфәттә кайттым. Күнелемнән генә әти белән бәхәсләшеп тә алдым әле: авызым тулы кан булса да, сезгә ялынмам, беркайчан берни сорамам! Үз тормышымны үзем көйләрмен, күзегезгә дә күренмәм!

Әти мине онытты, ташлады дип әйтә алмыйм. Ул берничә тапкыр телефоннан сөйләшүгә чакырып карады, тик мин—ләм-мим. Шулай итеп, сер бирмәс, тәкәббер кызый тарафыннан «протест акция»се башланды. Хатына каршы да җавап язмадым. Үпкәләгәнемне белеп торсын!

Эш белән укуны бергә алып бару җиңел түгел. Урамны иртүк, халык кузгалганчы себерергә кирәк. Ә җылы урыннан кузгаласы, йокының тәмле кочагыннан һич аерыласы килми. Сәгать дүрттән үк күзне ертып торып басам. Минем исәп, бераз эш күрсәткәч, тулай торактан урын сорау иде. Тамара Васильевна бик яхшы күңелле кеше булып чыкты, үзем сүз кузгатканчы ук: «Торыр урының бармы?»—дип сорады. Дербышки бистәсеннән үк килеп йөрүемне белгәч, алып кил әйберләреңне, бер караватт кына табарбыз әле, дип шатландырды. Шулай итеп, эшләр җайланды, борын күтәреп йөрергә тулы хакым бар иде.

Үземә ярдәмче дә таптым әле. Баш иеп, кеше күрми эшләп йөргән белән түгел, миңа күз салучылар булган икән. Ә мин сизмәдем дә. Бу арада күргән михнәтләр, авыр уй-кичерешләр арытты-талкытты гына түгел, күңелемне дә картайтты бугай. Олы хәсрәт вак-төяк борчуларны, шул исәптән мәхәббәт газапларын да күмеп киткән иде. Үземнең яшь кыз икәнемне, дөньяда егетләр барлыгын онытып та җибәргәнмен.

Бер иртәдә сукмакларны җепшек кардан чистартып маташа идем, янымa таныш түгел егет килеп туктады:

—Ял ит бераз,—диде дә, кулымнан көрәгемне алып, эшкә дә керешге.

Ярдәмнән кем баш тартсын, бу хәлгә бик тә шат-разый булып басып торам.

—Безнең беренче дәрес юк, иркенләп эшләргә була,—диде егет.

—Сезнең урында булсам рәхәтләнеп, туйганчы йоклар идем әле...

—Кызлар эшләгәндә ничек оялмыйча йоклап ятасың ди?!

—Рәхмәт инде сезгә...

—Әйдә, син дип кенә сөйләшик әле, дускай. Академиклар түгел бит. Исемең ничек синең?

—Наргизә.

—Нар-ги-зә... Һе... Илгизәне ишеткән бар, Наргизәне—юк. Ни аңлата инде бу исем?

—Нар—ут-ялкын дигән сүз. Шулай булгач ут-ялкын гизүче буламдыр инде...

—Алайса, кызый, бар икән әле күрәселәрең! Ходай ярдәм бирсен!

—Күргән кадәресе дә бик житкән...—дим эчке әрнү белән.

—Ярь-яшь башың белән зарланып тормасаң! Картайгач та өлгерерсен әле,—ди егет. Эшеннән туктап миңа төбәлә дә елмаеп такмаклый башлый:

—Бир кулыңны, бергә китик әле,
Бер бәхетне ике итик әле!

—Синекен бүлсәк кенә, миндә бүлешердәй бәхет юк...

—Бүләрбез, кайгырма! Без саран халык түгел. Таныш булыйк: Булат булабыз.

—Рәхмәт сиңа, Булат. Мин чынлап та арыган идем. Жепшек кар авыр, кулларым калмады чисти.

—Беләм, беренче курста үзем дә дворник булып эшләгән идем. Хәзер башка жай таптык. Дуслар белән базага товар бушатырга йөрибез.

—Анысы да жиңел түгел инде.

—Исәнлек булганда эшлибез аны.

—Булат, комендант күрсә ачуланыр, бир көрәкне үземә...

—Ачуланмый, курыкма! Тамара Васильевна әйбәт кеше ул, студентларны рәнжетми.

Булат сукмакны кардан чистартып бетерде дә, көрәкне миңа сузды:

—Калганы синә, дускай.

Матур, ягымлы егет иде Булат. Зәңгәр күзләре елмаеп-көлеп тора. Карашы шундый ягымлы, жылы томанга, йомшак мамыкка төреп ала сыман. Буй-сыннары да бик килешле. Шулай танышып киттек. Тик Булат минем өчен бары дус кына була алды. Бик яхшы, ышанычлы дус. Ул соңгы курста укый, диплом эше язып йөри иде. Эшкә үзебезгә, Наратка кайтам, әйдә минем белән, диде. Тик минем күңелдә бушлык, шундый эчпошыргыч салкын бушлык, гүя тере мәет... Нигә шулай, үзем дә белмим. Күңелемне күрер өчен Булат мине төрлечә көйләп карады. Бергәләп кино, концертларга йөрдек, хәтта берничә тапкыр ресторанга да алып кереп сыйлады. Аны яратырга, үз итәргә бик теләдем, бик тырыштым, ләкин... Күреп, аңлап торам югыйсә: Булат ышанычлы, әйбәт егет, аның көчле иңнәренә таянып, кулларыннан тотып, гомер юллары буйлап һич курыкмый-икеләнми атлап булыр иде. Сайлаган һөнәре дә тормыш итү өчен кулай, сәүдәгәрләр югала торган халык түгел. Тик нишлим, күңел эреми, хисләр сүнгән. Йөрәгемдә котып салкыны булгач, сөю уты кабынып-дөрләп китә алмый. Булат мине кияүгә чыгарга үгетләп ялварып йөрде-йөрде дә, өметен өзеп, кул селтәп, туган ягына китеп барды...

Ләкин Наратка барыбер кайттым мин. Жәен без практика үтәргә, балалар ял итә торган лагерьларда эшләргә тиеш идек. Төрлебезне төрле төбәккә билгеләделәр. Курсташым Әлфирә белән миңа Нарат районы эләкте. Мин авылга кайтып тормыйча, хәтта үземнең кайда икәнемне хәбәр дә итми, туп-туры Наратка китеп бардым. Әтиемә рәнжү-үпкәләрем кара болыт булып бар күңелне биләп алган, жылы хисләргә урын калмаган иде ул чакта...

...Июнь аеның яңгыр сибәләп торган елак бер көнендә, без, бер төркем яшьләр, ябулы машинага төялеп, район үзәгеннән утыз-кырык чакрым ераклыкта урнашкан «Дуслык» лагерына юнәлдек. Бездән калганнар жирле халык, бер-берсен яхшы белә, мәш килеп сөйләшеп-көлешеп, жырлашып баралар. Арада кызлар күп, егетләр өч бөртек кенә. Жәебезнең ике ае шул кешеләр белән үтәргә тиеш. Сиздерми генә күзәтеп, сөйләшкәннәрен тыңлап барам. Чәчен кыска итеп кыркыган мул йөзле егет бик шаянга охшаган,

мәзәк арты мәзәк яудыра. Ә сары чәчен муен-иннәрен кытыкларлык итеп үстергәне җырга һәвәс, тавышы бик тигез, моңлы чыга. Озын нечкә буйлы, очлы борынлы, күмер күзле егет сүзгә артык катнашмый, үз уйларына батып, тыныч кына утыра. Ахрысы, бик хыялыйдыр. Бәлки күнеленнән генә шигырь язып барадыр. Кызлар шук, телләре һич тик тормый, егетләр алдында чытлыкланып та алалар. Ә без, болар арасына яна килеп кушылган ике кыргый, бер-беребезгә сыенып утырдык та, пышылдашып кына сөйләшәбез. Чит кешеләр алдында ачылып китеп булмый, ятсындыра. Тегеләр көлә: «Әй, кызлар, колак исе чыгармагыз!»

Атна да үтмәде, лагерь туган йортка, ә юлдашлар якын дуска әйләнде. Әйтерсең, биргә иң шәп, иң күркәм кешеләрне җыеп китергәннәр. Мәктәптә практика үткән бар иде, балаларга әлләни якыная, уртак тел таба алмадым. Миннән укытучы чыкмый, юкка гына вакыт уздырып йөрим дигән фикергә дә килгән идем. Ялгышканмын, теләгең булса, бала күңеленә юл табып була икән. Лагерь ике-өч сәгатенне ашык-пошык үткәреп кайта торган мәктәп түгел. Иртән дә, кичен дә гел бергә әвәрә килгәч, төрле тарафтан, төрле гаиләдән җыелган җиде-ят кешеләр дә үз туганнарың кебек якын тоела башлый икән. Ышанычларын яулый алсаң, нәни халык үзе сиңа тартыла, хәтта күңел серләрен ачып сала. Ә без исә шул балаларның бөртеген дә югалтмый, чирләтми-имгәтми, күз карасыдай саклап, ата-аналары кулына тапшырырга тиеш идек. Ул тиктормас халыкка мизгел саен күз-колак кирәк, көндезләрен генә түгел, төнге йокыларына хәтле саклыйсы.

Мин оста тәрбияче дә, балалар күңеле буенча белгеч тә түгел, ләкин шуны яхшы аңлыйм: аларны үзеңнән түбән, ким куярга ярамый. Тавыш күтәреп, янап-җикеренеп кенә буйсындырам, тынлатам димә. Монда мөнәсәбәтләр үтә дә ихлас булырга тиеш. Бик сизгер зат бит алар. Синең алда—кечкенә булса да, кеше, шәхес, аны хөрмәт итәргә, сүзе-фикере белән санлашырга кирәк. Бала-чага гаделсезлекне, кимсетүне бик авыр кичерә.

Безнең отрядта шундый хәл булды.

Беркөнне Дима исемле малай миңа зар белән килгән. Әләкләшү дисәң дә була инде. Моның әнисе азык-төлек кибетендә эшли, малаен тәмле ризыктан өзми, күрәсең. Лагерьга да, улым ачлыктан үлмәсен диптер инде, бер пакет кәнфит-прәнник тутырып җибәргән. Дима иптәшләреннән кача-поса шул тәм-том белән сыйланып йөри икән. Башкаларга күрсәтсән—бүлешергә кирәк, ә бүлешә башласаң—тиз бетә... Ләкин бер очлы күз моңардагы байлыкны сизеп-күреп алган да, шыпырт кына чәлдерә башлаган. Дима үзенчә эзләнү-тикшерү үткәргәннән соң, конфет кәгазьләрен бүлмәдәше Ринатның мендәр астыннан табып ала. Димәк, бездә ЧП, урлашу бар. Мин нишләргә тиеш?

Ринатны үз яныма чакырам.

—Диманың конфетларын син алдыңмы?

—Юк.

—Ә нишләп кәгазьләре синең мендәр астында ята?

—Белмим, Наргизә Мидхәтовна. Мин тимәдем.

Ринат гөнаһсыз карашы белән күзләремә туп-туры карап тора. Әлегә хәтле тәртипле генә йөрде бу малай, начар гадәтләре күренмәде. Кулыннан тотмаган килеш ничек гаеплим ди аны?

Малай беразуйланып тора да:

—Әгәр мин алган булсам, фантикларны үземнең мендәр астына яшермәс идем,—ди.

Мин аның белән килешәм:

—Әйе шул, мин дә алай итмәс идем, ераграк ташлар идем.

Ринатнын йөзе яктырып китә:

—Сез мина ышансызмы?

—Ышанам.

Шул чакта анын шатланганын күрсәгез!

Уку бер нәрсә, ә практика, тормыш бөтенләй башка шул. Безнен отрядта бер малай бар. Шулкадәр кыюсыз, куркак инде бичаракай, гел башкалардан читтә боегып йөри. Көндезге йокы вакытында тәртип тикшерергә дип бүлмәләренә кергән идем, мышык-мышык елап ята бу.

—Ни булды, Алик? Кем рәнжетте?—дим. Чөнки шәһәр малайлары шук, көчсезрәкләрне җәберләргә генә торалар.

—Әниемне сагындым...

Ямансулаган малайның күңелен күтәрергә теләп:

—Борчылма, озакламый әти-әниләр көне, күрешерсез,—дим.—Әниен сина тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып килер...

—Юк, шул... Килмәс шул.... Без беркайчан да күрешә алмыйбыз...—Алик тагы да ныграк сулкылдый башлый.

Шунда иптәшләренен берсе әйтеп куйды:

—Анын әнисе юк бит, үлде...

Йөрәгем жу-у итеп китте. Юатыр сүз тапмый, бәгыремә төелгән бар кызгану хисләрен учларыма салып, башыннан сыйпамакчы идем, Алик кисәк кенә урынынннан кузгалып урамга атылды. Әллә инде әрнүен, күз яшьләрен читләргә күрсәтергә гарьләндеме, ни дисән дә егет кеше бит.

Ә минем күз алдыма энекәшем килеп баса. Үги ана, кырыс әби янында ничек яши икән ул? «Тор, улым» дип чәченнән иркәләп уятырга, кадерләп-яратып торырга әниебез юк хәзер. Ә мин, анын ин якын кешесе, бердәнбер апасы, энемнен язмышы турында бөтенләй уйламыйча, кул селтәдем дә китеп бардым. Бәлки ул да, кеше күзеннән кача-кача, шулай өзгәләнеп елыйдыр...

Кешеләр—бер-берсенә укытучы, диләр. Менә шул кечкенә генә ятим малай күземне ачты, ашкынып авылга кайтасым, энемне күрәсем, күкрәгемә кысып юатасым килде.

Лагерыбыз урман эченә урнашкан. Шул кадәр ямьле монда, табигатьнен туй иткән, чәчәккә-гөлгә күмелгән чагы бит. Җәйнен барча хуш исләрен үзенә сендергән урман һавасын сулап туймалы түгел, шундый куе, баллы. Тан атканда бар дөнья кошлар тавышына күмелә, иртәнге тәмле йокынны да кызганмый, шуларны тынлап хозурланасын. Ә айлы төннәрнен сихри матурлыгын сөйләп-анлатып бетермәле түгел. Айның көмеш нурлары күнел түренә сузылып үрти-ымсындыра, гүя җир белән күк арасына якты сукмак салып үзенә тарта-чакыра, җан тәнгә генә сыймыйча әллә кайларга ашкына башлый. Бу гүзәллеккә бакалар да чыдамый хәтта, кич җиттеме үзләренен «симфоник концертларын» башлыйлар. Елга кул сузымында гына. Тик ул күнелне алдап, ымсындырып кына тора. Чөнки суы тирән, шуна күрә коенырга рөхсәт итмиләр. Су өстенә тилмереп карап, кипкән иренеңне ялап, үртәлеп йөрисен инде.

Ин кызык тормыш кичен, лагерь тынып калгач башлана. Ләкин балаларны ташлап китеп булмый. Ул хәйләкәр халык, кереп күз салганда мышный-мышный йоклаган булып кылана да, артыннан ишек ябылырга өлгерми, йон туздырып мендәрләр оча башлый. Шуна күрә «биләм»гә чиратлап кына чыгабыз. Әлфирә дигәннән, ул монда бик кыюланып китте әле, сары чәчле Василий белән мәхәббәт куертып маташа. Йөзенә нур кунды, күзләренә йолдыз тулды, авызын җыеп алалмый, балкып-елмаеп бик шат йөри. Минем генә күнел беркемгә ятмый. Хәер, егетләр алтын бәясе монда, барысынын да хуҗасы бар. Васька да, әнә, елтыр күз, өлгер

егет, Әлфирәгә генә түгел, Маринага да күз кысарга өлгерә.

Беркөнне машинага төялеп авыл егетләре килде. Быелтыр җәй биредә эшләп киткән кызларның танышлары икән. Лагерь биләмәсенә чит кешеләрне кертергә ярамый, шуңа күрә су буенда учак ягып, шунда сөйләшеп-җырлашып утырдык. Бервакыт, кай арада аңлашып-парлашып беттеләр, кайсы кая китеп югалды. Таган эленгән карт имән төбендә мин дә Әхсән исемле егет кенә калдык.

—Әйдә без дә су буйларын әйләнеп йөреп килик,—ди бу.

—Миңа монда да яхшы.

Урынымнан кузгалып таганга утырам:

—Буш вакытта атыныйм әле рәхәтләнеп!

—Бала-чага түгелсендер лә.

—Бала-чага шул. Ник, әллә начармы?

—Гомер буе таганда атына алмассың.

—Шуңа күрә җай булганда атынып калырга кирәк.

Гомереңдә бер тапкыр күргән егет белән, әгәр ул сине тамчы да дулкынландырмый, кызыксындырмый икән, ни генә сөйләшәсең? Аңа сөйләр серем юк. Ни дип минем янда калды инде ул? Аның аркасында, шундый җылы матур кичне әрәм итеп, йокларга кереп китиммени?

—Синең исемең ничек соң?—дип сорый Әхсән.

Әй, бер кызык итим, алдыйм әле мин моны. Янадан очрашасыбыз бармы?! Егеткәйнең күзләренә туп-туры карап:

—Гөлнара,—дим.

—Вожатый булып эшлисеңме?

—Юк, вожатый булып эшләмим. Повар мин, балаларга ботка пешерәм.

Егетнең йөзе яктырып китә:

—Чынлапмы? И-и, алайса үзебезнең кеше икәнсең! Укытучылар эре була алар.

—Мин эре түгел, вак.

Әхсән сүзне гел аш-су тирәсендә йөртә:

—Ботка гына пешермисеңдер инде... Коймак пешерә беләсеңме соң?

—Беләм.

—Мин коймак яратам. Әчесен бигрәк тә. Әни миңа гел әче коймак пешерә. Ә бәлеш пешерә беләсеңме?

—Беләм. Өчпочмак та пешерәм әле.

—И-и, алайса бигрәк яхшы. Безнең колхозга поварлар кирәк. Безгә килсәң, эш була сиңа.

—Ә син кем булып эшлисең?

—Маллар карыйм инде. Укыйсым килмәде. Ниемә соң? Болай да яшәп була. Маллар карыйм мин,—дип кабатлады Әхсән.—Ә син сыер сава беләсеңме?

—Беләм.

—Чынлапмы? Әллә син дә авыл кызымы?

—Әллә шул...

Әхсән шат, ул бөтен йөзе белән балкып елмая. Балаларча эчкерсез, рәхәт елмаю. Дөньяның иң бәхетле кешесе шул икән диярсең. Ул минем каршымда чирәмдә утыра. Өстендә үтүкләнмәгән, кыска җиңле шакмаклы күлмәк, чалбарын да юып-сыккан килеш кенә киеп куйган бугай. Яратып йөргән кызы булса, көзгегә ешрак карар иде. Йөзгә матур, ягымлы үзе. Эшләп үскәне күренеп тора, җилкәләре киң, гәүдәгә нык-таза. Тик бигрәк кыюсыз инде.

Әхсән миңа туры карамый, башын аска иеп, чирәм йолка-йолка сөйләшә. Каушый-ояла бугай. Әллә бер тәртипсезләнеп, шукланып алырга инде?

Кагылсам, ут-ялкын эчендә калачак бит бу, зиһенен югалтачак... Бер үпкәннән ни зыян, сагынып искә алсын әле!

—Әхсән, кил яныма утыр, бергә атынабыз.

—Юу-ук, таган чыдамас...

—Алайса, мине атындыр.

Әхсән торып баса. Әкрен генә чайкалып торган таган өскә ыргыла. Бер күккә атылам, бер җиргә. Эчемә салкын җил тула.

—А-а, егылам, егылам, Әхсән, тот мине!—дип кычкырам мин һәм юри аның кочагына килеп төшәм. Егылудан саклап калырга теләп, ул мине кочып ала. Шул арада үрелеп иреннәннән үбәргә өлгерәм. Аннары җәһәт кенә куенынннан ычкынып, көлә-көлә корпусларга таба йөгерәм. Егет ни уйлап калгандыр тагы. Һәрхәлдә, бигрәк тыйнак, инсафлы кыз икән бу димәгәндер...

Икенче көнне кичке якта лагерьда ыгы-зыгы купты. Яныма өлкән пионервожатый Светлана Максимовна килде дә:

—Наргизә, кем ул Гөлнара, белмисенме?—дип сорады.

Аны-моны уйлап тормыйча, юк, дидем. Бераздан Әлфирә дә шул ук сорауны бирде. Мин аптырадым:

—Нигә кирәк соң ул, ни булган?

—Әй, аны бер егет ду китереп эзләтә икән.

Аннары кичә су буенда бергә утырган Алсу сулышына кабып килеп керде:

—Наргизә! Бар тизрәк озат егетенне! Серафима үтерә барыбызны да! Кайсыгызның эше, бүген үк выговор белән куам, ди.

Минем һаман аптыраашта торуымны күргәч, сөйләп бирде.

Иптәшен ияртеп Әхсән килгән, ашханәдә эшләүче Гөлнараны чакырырга кушкан. Ә анда бернинди Гөлнара юк, өч марҗа гына эшләп ята. Берсе Галя исемле. Мич калынлыгы апа. Галяны Гөлнара белән бутыйлармы әллә дип, моны чакырып чыгаралар. Аны күргәч, кунаклар котырыр дәрәҗәгә җитә:

—Безгә Гөлнара кирәк! Аны күрмичә беркая китмибез!

Шулай итеп, бөтен лагерьны айкап, Гөлнараны эзли башлыйлар. Хәбәр директорга барып ирешә. Сәгать буе капка төбендә буталган чит кешеләр белән анлашырга Серафима Тимофеевна инде үзе чыга. Комачаулап йөрмәүләрен, китүләрен үтенә. Тик тегеләр нык тора:

—Үзегездә кемнәр эшләгәнен дә белмәгәч, нинди җитәкче сез?! Табыгыз, чакырыгыз Гөлнараны!

Аларга нәрсә, Серафима белән бала чукындырасылары юк. Ә мина яхшы характеристика кирәк...

Эләктем! Яндым! Менә сиңа кызык—бер табак сызык...

Гаепле башымны иеп капкага таба киттем. Лагерь коймасына чытырдап ябышып, Әхсән баскан. Бер гаепсезгә читлеккә ябылган бичара тоткынмыни, күзләре сагыш-газап белән мөлдерәмә тулы.

Исәнләштек. Ни дияргә белмим, әйтер сүз дә юк кебек. Әхсән үзе дә каушап-югалып калды. Усал малайлар рәнҗеткәннән соң өлкәннәрдән ярдәм-яклау көткән баладай гаҗизләнеп артына борылып карады. Урман юлында, бездән биш-алты адымда гына УАЗ машинасы тора иде, аннан бер ир-ат төшеп, бирегә таба килә башлады. Әхсәнгә охшаган каратут йөзле, озын буйлы таза кеше.

—Гөлнара сеңелкәш, персидәтелдән машина сорап, сине алырга килдек без,—димәсенме.

—Кая?!

—Ничек инде кая?! Кияүгә! Кичә сөйләшкәнсез, килешкәнсез түгелме

соң ? Менә энекәш кайтып әйтте дә, оештырдык барсын да.

—Юу-ук...

—Ничек юк?! Кичә «да!», бүген юкмы? Алай булмый! Бездә алай итмиләр.

Мин гаҗәпләнеп Әхсәнгә текәләм. Тик ул дәшми, гүя телен йоткан, сихерләнгән кебек миңа караган да каткан.

—Әхсән—менә дигән егет ул. Кулыннан килмәгән эше юк. Әйдә, әйдә, озак уйлама, болай да ике сәгать көттек. Ялындырсаң, урлап та китәрбез үзеңне.

Мин куркып капкага ябышам, ашыга-ашыга акланам:

—Юк! Өйләнешү турында бернинди сүз булмады! Мин бернинди вәгъдә бирмәдем! Кияүгә чыгарга исәбемдә дә юк!

Әхсән күзләремә ялварып-йотылып карый:

—Әни жәл бит... Картайды ул, исәнлеге дә юк. Авылда эш күп, әнигә авыр. Булышырга кеше кирәк. Әни әйтә, өйлән инде, улым, ди. Авыр бит әнигә... Гөлнара, әйдә безгә кайтыйк. Чык инде миңа...

Әнисен шул кадәр өзелеп яраткан, аны кызганудан беренче очраган кызны өенә алып кайтып утыртырга риза булган бичара егетне кимсетәсем, рәнҗетәсем килми:

—Ачуланма, Әхсән... Минем әле укыйсы бар. Дөньяда кызлар бетмәгәндер, үз дигәнең табылыр.

Шулай дия-дия артка чигенәм:

—Башка монда килмәгез, зинһар, башка килмәгез...

Әхсән, мине ишетмәгән-аңламагандай, һаман өметләнеп карап тора. Аннары нидер исенә төшергәндәй кызу-кызу кабатлый:

—Мин сиңа хат язармын, Гөлнара! Мин синең укып бетергәнеңне көтәрмен. Адресыңны бир, Гөлнара!

Бу керсез күңелле беркатлы егетне кызганып, алдавыма, нигезсез өмет бирүемә үкенеп:

—Мин Гөлнара түгел...—дим.

Әхсәннең карашында аптырау, гаҗизлек, рәнҗү... Ышанырга да ышанмаска да белми бугай. Ул фәрештә дип санаган, кояш янына ук менгереп куйган изге зат гап-гади алдакчы икән. Аның күзләренә сагыш тула.

Миңа оят, миңа уңайсыз:

—Гафу ит, Әхсән. Мин бит шаярттым гына...

Тик ул җавап бирми, кисәк борылып, эре-эре адымнар белән машинага таба юнәлә. Аны кодаларга килгән абыйсы нәфрәт тулы карашын миңа төби:

—Их, сеңел, кеше күңеле белән шулай уйныйлармыни?!

Шул мизгелдә үк мине кылыч белән урталай ярырга теләгәндәй, ачу белән кулын селти дә, Әхсән артыннан иярә.

Нинди яхшы кешеләрне үпкәләттем... Нигә шундый соң мин, нигә шундый?! Нигә бу дөньяда үз урынымны, үз кешемне таба алмый өзгәләнәм соң?! Ни Сәлимгә, ни Булатка, ни бу егеткә күңелем ятмады. Бар сәбәп Женяда микәнни? Их, Женя, Женя... Әйтерсең лә, кояш нурларын каплап, бөтен тормыш юлыма күләгә булып яттың син, җәфа таягы...

...Ул җәй шулай балалар белән әвәрә килеп урманда үтте. Ялы да, эше дә бергә булды, дисәм, ялгышырмын, бу лагерь дигәннәрендә ни безгә, ни балаларга туйганчы йоклау эләкмәде. Каникул вакытында да күзеңне ертып, иртәнге алтыда торып бас инде. Миннән генә торса, тугызга-унга кадәр рәхәтләнеп йоклатыр идем үзләрен. Шул яшьтән үк солдат режимы белән яшәмәсәләр соң!

Смена тәмамлангач, уч тутырып акча түләделәр. Башкаларныкы белән чагыштырганда әлләни күп тә булмагандыр инде ул, тик берьюлы шул кадәр акча килеп кергәч, күнел үсеп китте. Кием-салымны янартасы иде бит. Шундый ният белән район үзәгендәге ике катлы универмагка юнәлдек. Иркен, зур кибет, хет эчендә биеп йөр. Чөнки бушлык монда, сайлап алу түгел, кулга тотып карарлык та әйбер юк. Кием-салым бүлегенә керсәк, әби-чәбиләр күзе төшәрлек кенә капчык кебек турыга тегелгән, зур-зур кесәле котсыз күлмәкләр, карга куркытыр өчен бакча карачкысына кигезеп куярлык эленке-салынкы кофталар, буй-буй сызыклы киң чалбарлар... Тегеләй дә әйләндереп карадык, болай да—күнелгә ошарлык кулъяулык та табалмыйча, акчабызны учлап, универмагтан чыгып киттек. Әлфирә белән зарланышып баскычтан төшеп бара идек, ни күрим, каршыма Булат килә! Көтелмәгән очрашудан мин сүзсез калдым. Ә ул елмая, авызы колагына житкән. Шул арада бер олау сорауга күмеп ташлады: син кайдан, ничек монда килеп чыктың, ни эшләр бетереп йөрисең?

Үзем турында кыскача гына сөйләп биргәч, аның хәлләрен сораштым. Булат эре генә күкрәк кагып:

—Абзагыз менә шул кибетнен директоры була инде,—димәсенме!

Мин ышанмадым. Әле бит диплом алуына күпме генә, инде директор да булып куйган.

—Булмас ла... Алдыйсыңдыр ла...

—Валлаһи! Менә шундый бәхет ишелеп төште миңа. Торговляда ир-ат дефицит, шуңа күрә бик кадерле затлар без. Таныш булыгыз: сезнең алдыгызда—Нарат үзәк универмагының директоры Булат Азатович Усманов үзе булыр! Шәп яңгырыймы?

Булатның һаваланып сөйләшүе миңа ошамады, аны жиргә төшерергә теләп, киная белән төрттереп куйдым:

—Яңгырый! Буш кибеттә бигрәк тә шәп яңгырый! Иптәш директор, товарыгыз кайда соң? Сезнең патшалыкта тотып алырдай әйбер таба алмадык.

—Әй, заманнан артта калган бичара олан! Кибеттә була димени яхшы әйбер?! Затлы товар затлы хужаларын көтеп складта ята ул!—дип жавап бирде Булат.

—Алайса, әйдә, алып бар складына!

Мондый әрсезлекне көтмәгәндер, күрәсең, егетебез аптырап калды, бераз баш кашып торганнан соң гына:

—Нәрсә кирәк соң сезгә?—дип сорады.

—Без—байлар, безгә күп кирәк!

—Кием-салыммы?

—Әйе инде, матур киенәсе килә бит.

—Әйдәгез, алайса, минем белән.

Булатны очратуым яхшы булды, сәүдә базасының чүпрәк-чапрак складына кереп, рәхәтләнеп сайландык. Монда шактый карангы һәм салкынча иде. Шулай булса да, үзебезгә кирәкле әйберләрне таптык, кызлар борыны сизгер бит. Склад мөдире, карсак буйлы, мул күкрәкле бер апай, болай иркенләп йөрүебезгә эче пошып:

—Булат энем, синең хакка гына инде,—диде.—Тизрәк булыгыз түлке, хужа күрсә, кирәкне бирә,—дип гел ишек ягын күзәтеп, тынгысызланып торды.

Авылга кайтасымны исәпләп, үземә генә түгел, энемә дә бик матур спорт костюмы алдым. Складтан баеп, шат-канәгать чыктык. Ярдәме өчен рәхмәтләр укый башлаган идек, Булатыбыз каш жыерып:

—Ай-һай, ансат котылмакчы буласыз! Рәхмәт—коры сүз генә ул,—диде.

—Ничек юешләтик-бәхилләтик соң? Бушка алмадык, акчасын түләдек. Тагын ни бирик?—дип елмайдым мин.

Булат көлде:

—Үзен кирәк, үзең! Кал монда гына, Наргизә! Менә дигән егет ич мин. Үзенне үзең мактамасаң тагын кем мактый?

Мин артистларча кыланып, кулымны йөрәк турысына куйдым:

—Булат, изгелегенне мәнге онытмам! Син мәнге минем йөрәк түрендә яшәрсең!

—Их, Наргизә...—дип авыр сулап куйды Булат.—Син бүген үк китмисендер бит?

—Юк. Менә Әлфирә белән бәйрәм оештырмакчы булабыз әле. Җәй буе урман эчендә ятып чисти кыргыйланып беттек, шәһәр күрергә исәп.

—Кичен очрашыйк, алайса. Сагындым бит үзенне,—диде Булат.

Яхшылык эшләгән кешегә ничек карангы чырай күрсәтәсен? Ярый, кил, очрашыйк, дидем.

Без ул көнне Әлфирәнең туганнарында кунарга ниятләгән идек. Кичен Василий белән Булат килеп, безне дискотекега алып киттеләр. Яшьләр арасында ул чакта бик популяр булган «Мираж» төркеменең дәртле җырлары астында хәлләр беткәнче биедек. Кайтканда төркемебез аерылды, Әлфирә белән Василий бер якка, Булат белән без икенче якка китеп бардык.

—Уникедән дә калма, җингидән яхшы түгел,—дип кинәнде Әлфирә.

Аягымда яна алып кигән үкчәле туфли иде, бии-бии, йөри-йөри, табанымны кырып бетерде. Шуның әрнүенә түзә алмыйча, Булатны ишегалдына сөйрәдем, уфылдап шундагы эскәмиягә килеп утырдык. Туфлиләрне тизрәк салып аттым да, табан ышкырга керештем:

—Ай Алла, бетте аягым, ничек кайтып җитәм инде хәзер? Вәт дивана, искесен чүплеккә ташладым бит. Яланаяк йөрергә калам бугай.

—Кая булышыйм,—диде Булат һәм... мине кочагына җыеп, үбәргә үрелде. Башымны чак читкә борып өлгердем. Анын хәтере калды:

—Өзелеп яраткан кешең бармы соң, Наргизә? Нигә шулай карышасың? Әллә мине кешегә дә санамыйсың инде?

—Саныйм... Яхшы кеше син. Ә мин начар... Чынлап әйтәм, пар түгел мин сиңа. Күнелем котып кебек салкын, буш... Бер гөл үсми анда...

—Үсмәсә, су сибәрбез, колагыннан тартырбыз! Менә шулай...—Булат шаярып минем колакка үрелә.

—Көлмә! Кызык дип беләсеңме әллә? Бәлки минем дә кемне дә булса өзелеп яратасым киләдер...

—Вакыты җиткәч яратырсың. Алай кырт кисмәле син, Наргизә. Мин бит ашыктырмыйм. Уйла, бәлки кушылырбыз. Мәхәббәт дип... Яши-яши күнәсендер инде бер-береңә. Беркем дә алай чупылдашып үбешеп тә, кочаклашып тормыйдыр.

—Ияләшү мәхәббәт түгел ул. Әнә, эт-мәче дә кешегә ияләшә.

—Таптың сүз! Шулай да... Өмет бирәсенме миңа?

—Юктыр... Ышандыра алмыйм. Авылда йөргән егетем бар. Ул да көтә, өметләнә... Аңламыйм мин үземне, Булат. Буталдым, адаштым бугай бу дөньяда... Кыска гына гомер эчендә дә күпме ялгыштым инде. Ичмасам, киңәшергә әнием дә юк! Онытсин мине, Булат, үз дигәнең табылыр әле.

Булат башын югары чөеп, карашын август күгенең якты йолдызларына төби:

—Оныт, имеш...

Анын тавышы артык боек, төшенке. Булатны юатыр, күнелен күтәрер өчен бер сүзем җитәр иде. Тик мин ул сүзне әйтә алмыйм. Татлы ялганга караганда ачы булса да дөреслек хәерлерәктер.

—Оныт, имеш...—дип кабатлый Булат.—Алай ансат кына булса икән ул! Шулай да югалтышмыйк, Наргизә.

Мин Булатка карап уйга калам. Тин яр, үзенә насыйп яр нинди була икән ул? Дөньяда яхшы егетләр күп, ләкин барысын да яр итә алмыйсын бит. Үзенә дигәнне бер күрүдә, бер караштa танып-сизеп аласындыр, мөгаен. Жанын-тәнен белән ана тартыласындыр. Ләкин күнел күзен сукыр булып, күрми үтүен дә бар. Булат яхшы мөнәсәбәте, матур сүзләре белән тәки үзенә ияләштерә бугай. Аны кире кагып ялгышмыйммы мин? Мәхәббәт йә бар, йә юк... Икеләнергә ярамый, вакытында китә белергә кирәк.

Хушлашканда кистереп әйтәм:

—Мин сине яратмыйм, Булат, өметенне өз. Әйбәт егет син, әйдә, дуслар гына булып калыйк.

## 4

...Авылга якынлашкан саен йөрәгем ныграк тибә, күнел тынгысызлана. Китүемә ярты елдан артык узды, өйдәгеләр турында берни белмим. Кайтасы килә дә, юк та. Авылны бик сагындым. Сөекле энемне, күнелләге рәнжүүпкә хисләре басылмаса да, әтиемне дә күрәсем, хәлләрен беләсем килә. Якты дөньяга күземне ачканнан бирле гел янәшәмдә булган усал әбиемне дә юксынырга өлгердем. Зәһәр сүзләренә, кырыс холкына күнгән—өйрәнгән инде, нинди булса да жиде ят кеше түгел, үз әбием.

Ләкин өйдә ике ят кеше бар... Берсе—Кифая, икенчесе анын кызы—энем белән яшьтәш булган Дилбәр. Кифая апа кызын әнисендә калдырып килергә тиеш иде, ләкин аерым тору икесенә дә кыен булгандыр, күрәсен, ул да хәзер бездә яши икән. Бер хатында әтием шулай язган иде. Кыскасы, бездә бер көтү халык хәзер. Мине ничек кабул итәрләр дә, үзем ничекләр түзеп бетәрмен—хәтта күз алдыма да китерә алмыйм. Үги ана янына кайтунын бер кызыгы-шатлыгы юк икән...

Ә ул, үч иткәндәй, ин беренче булып очрады. Капканы ачуым булды, буш чиләкләрен күтәреп каршыма килеп тә чыкты. Әллә ничек куырылып, өшеп киттем. Ул да аптырап калды кебек. Соры күзләрен зур ачып мина төбәлеп карап торды-торды да:

—Кайттынмы?—диде.

Бу искиткеч акыллы сорау иде! Соравына күрә жавабы да булды:

—Юк, кайтмадым. Үтеп барышлый гына сугылдым.

Ул минем кинаяне анлады, тик сер бирмәде, тыныч кына:

—Кер, әбиен өйдә. Әтиен эштә әле,—диде.

Тик мин өйгә керергә ашыкмадым. Кифая чыгып киткән арада ишегалларын, бакчаларны карап-тикшереп чыктым. Ниләр майтарып ята икән бу монда? Әнием бакча тутырып чәчәкләр үстерә иде, жәй буе аллыгөлле чәчәкләр арасында хушланып йөри идек.

Кифая чәчәкләр үстерми икән. Бакчада шактый үзгәреш сизелә. Чия, кура жиләк, карлыган куаклары шактый тапалган, сирәгәйгән. Анын каравы түтәл-түтәл кишер, кыяр, помидор үсә. Эре-эре помидорлар сабагында килеш кызарып-пешеп утыра. Безнен үги анабыз харап унган апай икән... Ярар, шулай булсын, һәркем үзенчә тырыша, кем чәчәк, кем кыяр үстерә. Кышын авыз тутырып яшелчә ашарлар. Ләкин әтинен кишер-кәбестәгә бик исе китми шул. Әни табынга салат ише нәрсә куйса, йөзен чытып, силос белән тамак туймый, ашынны чыгар, дия иде. Ана өй токмачы да, ит ризыгы булсын. Хәер, әнигә кырыс булган белән түгел, сөекле Кифаясы кулыннан шалкан ашарга да ризадыр, бәлки.

Баскычтан күтәрелгәндә йөрәгемне әрнеткән бер нәрсә булды. Ишек төбенә аяк сөртергә дип әнинен ин яратып кия торган чәчәкле халатын жәеп

куйганнар. Мин аны шундук җыештырып алдым. Өйгә кереп тә тормый мунчага барып, чайкап, элеп куйдым. Карарлыгы калмаган иде, керләнеп, теткәләнеп беткән. Әйткәннәр иде бит, әниегезнең киемнәрен идән юарга тотмагыз, ярамый, дигәннәр иде. Ә бу оятсыз хатын юри шулай мыскыл итәдер инде. Әти күрмәгәнме, сизмәгәнме? Барысы да шуның өстенә басып, аяк сөртеп йөргән. Нык үртәлдем, бик әрнедем бу хәлгә.

Әкрен генә өйгә керәм. Әби миңа арты белән басып, өстәл янында кайнаша. Кулында күпереп пешкән ипи, күкрәгенә терәп шуны кисә: «Бисмиллаһи рахманирахим». Аның чандыр аркасына, шул арканы тулаем каплап торган, кыр-кырыйларына кызыл чәчәкләр сибелгән сары яулыгына, үзе тегеп кигән озын җиңле, бала итәкле чуар күлмәгенә яратып карап торам. Әбиемне сагынганмын икән мин, барыбер дә сагынганмын. Кочаклап аласым килә үзен. Тик әбием андый төчелекне яратмый. Егерме биш яшендә ике бала белән тол калып, гомере буе ялгызы тормыш тарта торгач, күңеле каткан инде аның, ирләр кебек тупасланган. Сугыш вакытында колхозда бригадир булып та эшләгән бит әле ул. Кырыс булмый хәле юк. Йомшак агачны корт баса, йомшак кешене чурт баса, дип кабатлавы да юкка гына түгелдер...

Тын да алмый басып торсам да, әби артында кемдер барлыгын аркасы белән тойды булса кирәк, кисәк борылды. Карашында аптырау иде.

—И-и, син кайттыңмыни? Мәгънәсез! Шул гомер хәбәрсез йөриләр димени?! Әтиеңне утка салдың бит, юньсез!

Сүзләре каты булса да, тавышы йомшак иде әбинең. Түзмәдем, кочаклап алдым үзен.

—Чү-чү, егасың бит. Ипләп кенә...—Әби бу гамәлемне килештермәгәндәй мине читкә этте.

Ачыла башлаган чәчәк кире йомылды... Иренемне кысып, күз яшемне йотып:

—Илнар кайда?—дип сорадым.

—Алар Дилбәр белән су керергә киткән иде.

Бусы яхшы хәбәр, димәк, Кифаяның кызы белән уртак тел тапканнар.

Мин өс-башны алмаштырган арада Кифая үзе дә кайтты. Табын янына утырдык. Әмма сүз ялганмый, Кифая ачылып китә алмый. Мин дә аның белән сөйләшергә атлыгып тормыйм. Ике арада күпер булып әби утыра, тик ул да бу мәсьәләдә дипломат түгел, сүзе гел ашау-эчү тирәсендә генә әйләнә: «Юлда ачыккансыңдыр, ныгытып аша. Хәзер әтиең дә кайтыр, районнан кеше килде дигән иде. Аш тагын өстимме? Катык та сал. Әле кичә генә оеттым. Кисеп алырлык булды. Җәй көне иң тансык ризык шул инде.» Әбинең минем белән гомердә дә болай төчеләнеп сөйләшкәне юк иде. Табын артындагы киеренкелекне йомшартыр өчен шулай юк-барны сөйләнеп утыруыдыр инде.

—Аша, Наргизә, уңайсызланма,—дип өстәп куя Кифая.

Әйтерсең, уңайсызланган кеше бер.

Ниһаять, капка ачылган тавыш ишетелә. Бу әти. Аның гадәте шул: пружиналы кече капканы киереп ача да, кисәк кенә җибәрә. Тегесе бар көчкә шапылдап ябыла, тавышыннан колаклар яңгырап китә. Әти хуҗаларча дөп-дөп басып керә. Минем йөрәк тә дөп-дөп сикерә. Кулымдагы чәйне эчәргә онытып, катып калам. Кифая миңа сынаулы караш ташлый. Әби дә мәгънәле генә тамак кырып куя.

Менә әти керде. Мине күрде. Бер сүз дәшми. Әмма карашы җиргә сендерерлек. Мин әкрен генә урынымнан кузгалам, әтигә кулымны сузам:

—Исәнме, әти...

—Исән, шөкер. Үлмәдек.—Әтинең тавышы шактый кырыс.

Мин дә ялынып, куштанланып маташмыйм, кабат өстәл янына үтеп, чәй эчүемне дәвам итәм. Эчәм, тик тәмен тоймыйм.

Әти кулын юып, үз урынына—түр башына утыра.

Өстәл янында үле тынлык...

Кем беренче сүз башларга тиеш? Ялгышмасам, һич тә гаепләнүче түгел. Башта сүзне судья ала. Шулай булгач, теленне тешлә дә, чәй эчүеңне бел, качкын кызый.

Ләкин бернинди сөйләшү булмады! Төшен дә, кичен дә булмады. Мине тавышсыз-тынсыз гына «ыру»га кабул иттеләр. Ошаса ошый, ошамый икән, бигайбә, башны ташка бәрергә жыенмыйбыз.

Ике як та горур иде.

Мин түземсезләнеп Илнарны көттем. Аның елый-елый Кифаядан зарлануын, үги анабызны хурлавын көттем. Бар күңелем шуны тели иде.

Кифая безнең әнидән ким булырга тиеш. Ул бары тик хурлауга лаек. Утырмасын монда бер гөнаһсыз фәрештә кебек авызын бөреп. Мин аңа «әни» диярге жыенмыйм. «Әни» түгел, хәтта «апа» диярге дә теләгем юк әле. Мин аның күзенә чүп булып керәчәкмен, йөрәгенә үтмәс пычак булып кадалачакмын... Тыштан тыныч кына йөрсәм дә, эчемдә мәкерле, кара уйлар кайный. Энем белән бер сүздә булсак, явыз хатынга күрмәгәнен күрсәтәбез әле! Дөньяга ник килгәненә, безнең бусаганы атлап кергәненә үкенер. Минем куенда ике атна вакыт бар, аның бер көнен дә әрәм итмичә, уртак дошманга каршы кискен көрәш башларга кирәк.

Тик өметләрем акланмады... Су буеннан ачыгып кайткан энем мине тыңлап та тормыйча, тизрәк өстәл янына ябырылып ашаргаябышты. Бүләк итеп алып кайткан костюмга да исе китмәде, әй, барыбер пычрана, аны саклап йөрисем юк, диде. Шулай инде ул бала-чага, урам көчеге кебек жирдә аунамаса күңеле булмый. Тик барыбер кәеф төште. Апасының хәтерен саклап булса да бер киеп караса соң! Энемне шатландырасы килгән иде, ә аның исе дә китмәде, тамагын ялгады да тагын урамга чыгып чапты.

Кояш баеганда каберлеккә керергә ярамый икән. Әни каберенә барып килэм, дигәч, әби каршы төште. Башта мунча кер, иртәнге якта менәрсең, диде.

Төштән соң әти дә, Кифая да эшкә китеп бардылар, мунчаны үземә ягарга калды. Ул кичне клубка чыгарлык рәт булмады, юынып кайттым да, урынга тәгәрәдем. Йокысыз төннән, юлдан соң, кичерешләрнең күплегеннән шул хәтле арыткан иде.

Иртән Илнар белән каберлеккә менеп киттек. Ул теләмичә генә иярде. Чөнки тәмләп йоклап яткан жиреннән кузгаттым.

—Мин нигә анда, нәрсәсен карыйсың соң аның?—дип киреләнгән иде, әби:

—Бар, бар, апаңа иптәш булырсың,—дигәч кенә урыныннан кузгалып киенә башлады.

Энем миннән читләшкән, шул гомер күрешмәгәч соң.

Каберлекнең күгәреп беткән тимер капкасы ыңгырашып кына ачылды. Башка дөньяга киткәннәрнең сагышлы, тын йортына килеп кердек.

—Без Дилбәр белән әнә теге каен башына менгән идек,—диде энем, Идрис бабай кабере өстендә үскән карт каенга күрсәтеп.

—Дилбәр дә мендеме?

—Әйе, ул маймыл кебек, выжт итеп менә дә китә.

—Маймыл күргәнең бармыни?

—Бар. Әти безне Әлмәткә алып барды. Анда зоопарк килгән иде.

Тиз оныткан Илнар... Әнине бер дә сагынмыймы икән? Ә бәлки шулай

булуы яхшырактыр да. Шул яшьтән кайгырып, уйга батып йөрсә, ни була ул аннары. Энемнең дөнья шатлыкларын онытып, гел елап яшәвен үзем дә теләмим ич.

—Монда быел җиләк күп булды. Һәр көн саен менеп җыйдык. Рәхәтләнеп ашадык.

—Кабер таптап йөргәнсездер инде.

—Юу-ук, кабер таптамадык без.

Энемнең күңеле җәйге көн кебек аяз. Кышкы хәсрәтләр язгы сулар белән агып киткән.

Әни кабере янына килдек. Ул тимер чардуган эчендә калган, уртада аның исеме, туган, үлгән елы чокып язылган мәрмәр таш тора. Кабер өстендә беләк буе чыршы үсә. Күренеп тора, карап-чистартып торалар. Чардуган да пөхтә итеп буялган.

—Әни белән икәү буядык,—диде энем.

Илнар авызыннан беренче тапкыр «әни» сүзен ишеттем. Кифаяга «Әни» ди! Үртәлеп, хәтта ачу белән:

—Нинди әни булсын ул сиңа? Менә безнен әниебез!—дим.

Илнар гаепле кешедәй башын ия:

—Әни дип әйтергә куштылар бит...

—Ә син әйтмә!

—Нәрсә диим соң?

—Кифая апа диң.

—Алай әйтсәм, әти ачулана. Әби дә.

—Ә әни? Әни нәрсә дияр?

—Безнең әни үлде бит инде, апа...

—Сине Кифая тудырмаган1 Тудырмаган да, имезмәгән дә! Әнине онытма! Бер генә безнең әниебез! Бер генә!!! Ике әни була алмый.

—Ачуланма инде, апа... Шулай ияләштем бит. Кифая апа яхшы ул. Дилбәр дә яхшы.

—Яхшы булса, бар алар янына! Синең әниең анда, минеке монда. Бар үз әниең янына!

Илнар карышып тормады, авызын турсайтып китеп тә барды. Мин әйткән сүзләрем өчен үкенеп, аның үпкәләп җыерылган ябык иңнәренә кызганып карап калдым. Йә, җиде яшьлек бала ни аңлый инде? Ана исән, тере әни кирәк. Кабердә яткан әни аңа ни бирсен, ни җылыта, ни юата алмый. Ана назын күрми дә калды бит балакай. Кем якты чырай күрсәтә, шуңа сыена инде хәзер.

Телевизордан бер кызыклы тапшыру караган идем. Инкубатор чебиләре белән үткәргән тәҗрибә турында сөйләделәр. Йомыркадан баш төртү белән болар янына гап-гади туп куялар. Чебиләр гел шуңа елышкан, тупка карап чыелдашкан. Байтак вакыт үткәч, тупны тәгәрәтеп җибәрәләр. Чебиләр пипелдәшеп аның артыннан йөгерә, туктагач, сөенешеп кабат тупка сыеналар икән. Менә шулай... Дөньяга килү белән һәр җан иясе үзенә әни эзли, күрәсең. Тик ул җансыз тупта нинди җылы тапты икән наныкайлар?!

Энемне дә, үземне дә кызганып күзгә яшь тулды. Кабер кырына тезләнеп утырдым да әни белән сөйләшә башладым. Ни әби, ни әти, ни Кифая минем хәлемне сорамадылар, тормышым белән тамчы да кызыксынмадылар. Әни булса, энәсеннән-җебенә хәтле төпченер иде. Әни хәзер сөйләшә алмый, бәлки рухы ишетәдер, тыңлыйдыр, күрәдер мине? Һәрхәлдә моның шулай булуына ышанасым килде, шуңа күрә яшьләремә буылып сөйләдем дә, сөйләдем. И әнием, газизкәем... Ятим Тукаебыз язганча: «Барча күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы...»

... Көне буе күңелемә урын тапмый, бер эшкә кулым бармый аптырап йөрдем. Туган йортымда гүя кунак, чит кеше идем. Әнинең юклыгы һәрнәрсәдә, хәтта өйнең һавасыннан ук сизелә кебек. Шундый бушлык, бу бушлыкны беркайчан да, беркем дә тутыра алмаячак. Ул бушлык гомерлек, бәхет алмасының бер өлешен үлем тешләп алган... Әнисен югалткан кешене бернинди сүзләр дә юата алмый, йөрәкнең түренә үк кереп урнашкан бу әрнү мәңгелек, ул соңгы сулышка кадәр озата барачак. Вакыт дәвалый диләр. Юк, дәваламый, бары тик авыр хәсрәт белән яшәргә өйрәтә, кеше үз кайгысына ияләшә, күнә, шул гына...

Әби быел эшкә йөрми, намаз укый башлаган. Бәлки шуңа холкы бераз йомшара төшкәндер. Кифая белән дә бик иплән сөйләшә. Яшь чагы түгел, аның кулына каласы барын уйлыйдыр. Сәер, баласын ияртеп килгән, кешедән калган бу хатын әниемә караганда кадерлерәк булып чыкты әле. Әбием аны рәнҗетсә-кыерсытса, рәхмәт кенә әйтер идем югыйсә. Кифаяның рәхәт яшәвенә ачуым килә. Күз яшьләре, рәнҗү төшә, диләр тагы.... Төшә, пычагым!

Кичен киенеп-ясанып клубка чыгып киттем. Берьялгызым. Римма Түбән Камага эшкә урнашырга китеп барган. Быел безнекеләр урта мәктәпне тәмамлады бит. Сәлим нинди исәпләр белән йөридер. Аның белән күптән хәбәрләшкән юк. Бүген очрашкач, сөйләшербез инде. Тик аны тамчы да сагынмадым. Болай кызык түгел. Шул кадәр салкын, хиссез кешемени мин хәзер?! Бар күңел жылымны, сөю хисләремне Женяга сарыф итеп бетердемме әллә? Гомер буе янарга тиешле учакны, чыбыклар өстәп яшәтәсе, саклыйсы урында, бензин сибеп, бер мизгелдә дөрләтеп, ашыгып сүндергән кебек...

Үзебезнекеләрдән Рәшит белән Лилияне генә очраттым. Лилия мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган, Казанга университетка керәм, ди. Аңардан сыйныфташлар турында сораштым. Барысы да калага китү ягын карый, кем укырга, кем эшләргә. Бездән генә калмаган, мәктәпне тәмамлау белән яшьләр шәһәргә илтүче олы юлга чыгып баса... Ярты авыл Әлмәт белән Чаллыга күчеп бетте бугай инде. Ә Сәлим авылда калмакчы була икән.

—Тиле инде, монда ни бар соң? Жыен карт-коры арасында мүкләнеп бетәрсең,—ди Лилия.

Сәлим үзе клубта күренмәде. Лилия карашым белән аны эзләвемне сизде, ахры:

—Кырда ул, әтисе белән, уборкада.

Никтер күңелсез булып китте. Бүген мине кем озата кайтыр? Булмаганда ярап куя иде әле, ни дисәң дә иптәш.

—Наргизә, мин әйтмәсәм, башкалар әйтер, Сәлим Югары авыл кызы белән очраша. Син бит аны барыбер яратмыйсың, үртәп кенә йөрдең. Ә Зәйнәп Сәлимнең күзенә генә карап тора.

Йөрәккә утлы күмер төште... Барыбер түгел икән шул... Кулыңдагы алманы үзең ашамасаң да, кешегә бирәсе килми. Шулай да эчтәге ялкынны тышка чыгармадым, Лилиянең хәбәренә исем китмәгәндәй:

—Әйе шул, без Сәлим белән дуслар гына,—дигән булдым. Аннары көлә-көлә:

—Әле чак кияүгә чыкмый калдым, кызый,—дип, лагерьда булган хәлләрне сөйләргә тотындым.

Лилия, ышанырга моңа—юкмы дигән сыманрак, күзләрен кыса төшеп, үтә дә житди кыяфәт белән тыңлады. Тик мина кушылып көлмәде:

—Мескен егет, бигрәк мыскыл иткәнсең. Миннисa әбидән калышмыйсың, усал инде үзең,—диде.

Ул кичне клубтан ялгызым кайттым.

Ни авылда, ни өйдә торасым килмичә, җаныма урын тапмый, икенче көнне үк җыендым да, Казанга китеп бардым...

Ул елны минем кадәр тырышып урам себерүче тагы берәр дворник булдымы икән Казанда?!

## 5

Әлмәттә Женя яши. Әлмәттә тагы әтинең бертуган абыйсы яши. Миндар абыйларда мин бары бер генә тапкыр кунак булдым. Шунысы да җитте, башка барасы килмәде.

Ул елны мин бишенчене тәмамлаган идем. Җәй башында әтине Әлмәткә укырга җибәрделәр. Шәһәр күреп кайтырсын дип, әти мине дә үзе белән ияртте. Без Миндар абыйларда яшәдек. Әти көне буе укуда, абый эштә, Венера рәхәтләнеп лагерьда ял итә, ә мин Хәмидә апа карамагында идем. Мин аның өчен, һич арттырмыйм, күктән төшкән бәхет булдым. Әзер ялчы булдым мин аңа. Иң башта бакчасын аркылыга-буйга утап чыктым. Хәмидә апа, (ни могҗиза!) чүп үләннәрен һич тә яратмый икән: «Женем сөйми шуларны!»—дип, минем янда уралып йөрде. Сөймәгәч, тот та ута. Ләкин кызарткан очлы тырнаклар кызганыч, педикюр әрәм була, чүп үләннәре кулны да тупаслата икән. Ә Хәмидә апаның эшендә халык «культурный», анда «авыл хәерчесе» кебек йөреп булмый.

Бакчада эш беткәч, подвалга төшеп киттек. Урман булып үреп утырган былтыргы бәрәңгеләр дә мин килгәнне «тилмереп көткән» икән, шуларны чыгарып түгәргә кирәк булды. Кунакка дип җыенып чыгып киткәндә, Хәмидә апаның подвалын җыештыру безнең планга кермәгән иде. Шуңа күрә әнием өр-яңа күлмәкләремне кидереп-тоттырып җибәрде. Подвалдагы эш фронтын күргәч, мин курка калдым: матур күлмәгем пычраначак ич монда. Ләкин Хәмидә апа «юатты»:

—Җылы су краннан шаулап агып тора, юарсың.

Ялым шәһәр күреп түгел, Хәмидә апага хезмәт итеп үтсә дә, яхшы сүз ишетергә барыбер насыйп булмады. Күрше апасына:

—Кеше көйләп туйдым инде, кайчан китәрләр. Таптылар яхшы урын, миндә гостиницамыни,—дип сукранып утыруын үз колагым белән ишеттем...

Бездә дә кунак йорты түгел, әмма атна саен диярлек көтүләре белән кайталар, мунча кереп, рәхәтләнеп ял итеп китәләр. Булышыйк әле диюче юк. Алар—кунак. Әнием мич тутырып ипи пешерә, аяк табаннары янганчы боларны көйләп чаба. Мин үрмәләп бәрәңге утап йөргәндә, кызлары Венера: «Айда уж, кончай быстрее, я купаться хочу... « дип янымда кыбырсып тора иде. Булышса, «быстрее» булыр иде дә бит, шәһәр кызының иеләсе, җирдә пычранасы килми.

Авыл кешесенә кимсетеп карасалар да, кучтәнәчләрдән баш тартмый үзләре, сөт-каймагын да, ит-бәрәңгесен дә төяп алып китәләр...

Озын сүзнең кыскасы шул: Әлмәттә туганнарым бар дип өметләнеп барып керә торган түгел.

Ләкин мин барыбер эшкә Әлмәткә кайтып урнашырга булдым.

Беренчедән, җиде ят җир түгел, азмы-күпме белгән таныш шәһәр. Икенчедән, анда Женяны очрату өмете бар.

Аны очратасым килү һич тә үлеп сагынудан түгел. Үз-үземне, күңелемне аңлыйсым килә. Нигә шундый хиссез, битараф кешегә әйләндем икән мин? Дөнья ямен күрми, аягурә йоклап йөрим. Женяны очратып югалтканчы янып-балкып торган, шат күңелле кыз идем ич, таулар актарырлык көч-куәтем, дәртем бар иде.

Беренче мәхәббәтем белән очрашу, бәлки, үземне аңларга ярдәм итәр?

Аның белән араны мәңгегә өзсәм, бар халәтемне биләп алган буш хыяллар томаны таралыр да, өр-яңадан гашыйк була алырмын? Ә бәлки, киресенчә... Женяны күргәч, ана булган назлы хисләр дөрләп кабыныр, бозланып туңган жаным, ниһаять, уяныр һәм мин кабат дәртләнеп-рухланып яши башлармын?!

Шулай итеп, кулыма диплом алу белән туп-туры Әлмәт ягына юл тоттым. Шәһәр мәгариф бүлегендә билгеләнеп чыккач, мине балалар бакчасына тәрбияче итеп жибәрделәр. Кайда яшәрмен дип баш ваткан идем, бу мәсьәлә дә жиңел генә хәл ителеп куйды: эшчеләр тулай торагыннан урын бирделәр. Ике кешелек жыйнак кына бүлмә. Мин урнашканда бүлмәдәшем эштә иде. Ул кичен генә кайтты. Ана ялгыз яшәү рәхәтрәк булгандыр, әлбәттә, мин килгәнгә әлләни сөенмәде. Иң беренче соравы:

—Йөргән егетең бармы?—булды.

Мин «юк» дигәч, бик разый-канәгать булып елмайды:

—Алайса, яхшы. Югыйсә Валя егетләр алып килеп үзәгемә үтте. Бу свидание урыны түгел, шуны белеп тор. Кызлар килгәнгә бер сүзем дә юк, ну ир-ат затын женем сөйми.

Мәдинә миннән олы, егерме жиде-утыз яшьләр тирәсендәге, төскә-биткә матур, тик хатыннар сыман юанрак, эре сөякле, тупас гәүдәле кыз иде. Аның фикер агышы миңа бик яхшы аңлашылды. Күңеле булсын өчен:

—Икебез дә бер уйда икән. Мин дә аларны кешегә санамыйм,—дидем.

Мәдинә миңа үз итеп, хуплап карап куйды.

Бүлмәдәшләр белән дус яшәргә кирәк. Бигрәк тә карт кызлар белән.

Мин сүземдә тордым, бусагабызны сыңар егет тә атлап кермәде. Шуңа күрәмедер, Мәдинә белән арабыз якынаеп, жылынып китте. Моңа үзем дә шат идем, чөнки ул Әлмәт районында гына яши. Авыллары шәһәрдән ерак түгел, шуңа күрә атна саен кайтып йөри. Мине дә үзе белән ияртә. Аларда рәхәт. Әнисе ачык йөзле, ягымлы апа. Мине үз кызы кебек якын итте, кайткан саен шатланып каршы ала, киткәндә:

—Өебез иркен, унайсызланма. Рәхәтләнеп кайт,—дип озатып кала.

Мәдинә әнисе белән генә үскән. Ул кечкенә чакта ук әтисе аларны ташлап киткән, бәлки шуңа күрә дә ир-ат халкына нәфрәтледер ул. Бу хакта белгәч, алар миңа үз туганнарым кебек якын тоела башлады. Охшаш язмышлы кешеләр икән без. Гәрчә әтием булса да, мине ташламаса да, гамәлдә ул юк бит. Теге юлы минем белән хәтта ике сүз дә сөйләшмәде. Аның каравы, Кифаясе каршында сандугач булып сайрый.

Мәдинәгә серләремне түкмәсәм дә, бер кайтуда, аулакта калып (Мәдинә йомыш белән иптәш кызы янына киткән иде), Саимә апа белән икәүдән-икәү сөйләшеп утырдык. Әллә үз итеп жылы каравына, әллә бүлдермичә тыңлый алуына, бөтен күңелемне ачтым да салдым аңа. Хәлемә керүче табылганга күңелем булып бераз яшь тә түгеп алдым әле.

—И балакай... Тормыш дигәнең артык катлаулы шул, яшь чакта түгел, чәчең агаргач та аңлап бетерә торган түгел. Иң мөһиме, эчеңдә ачу саклама, үскәнем. Дошманыңны да аңларга, гафу итәргә тырыш. Кешене аңларга теләсәң, үзеңне аның урынына куеп карарга кирәк,—диде Саимә апа.—Эчтәге ачу кешене корт кебек кимерә ул, бөтен чир шуннан килеп чыга. Әтиеңә дә жиңел түгелдер. Болай бер хәбәрсез, үз-үзеңне ашап йөргәнче, кайтып күрен син, үскәнем. Аңлашып яшәргә кирәк, үкенечкә калмасын.

—Саимә апа, ә сез ирегезне гафу иттегезме соң?

—Кичердем мин аны. Мәдинә генә гафу итә алмый. Шул нәфрәте аркасында егетләрне янына якын жибәрми дә инде. Лутчы ялгыз яшим,

ди. Алай ярамый, һәр кошның үз пары булырга тиеш. Югыйсә тормышның ни яме бар?

—Әти аркасында мин әнисез калдым...

—Алай димә, үскәнем. Кеше гаепләргә ашыкма. Барыбызны да язмыш йөртә. Кайчан үләсебез тәкъдирдә язып куелган инде, вакыты житсә, нишләсәң дә юк. Калганы сәбәп кенә аның. Аллаһы Тәгаләнең әмереннән башка яфрак та селкенмәс, ди.

Аның сүзләре белән килешмим мин. Язмыш диләр, тәкъдир диләр... Жир шарында миллионлаган кеше яши, кем алар өчен тормыш планы төзеп утырсын?! Киләчәкне түгел, иртәгә, алдагы мизгелдә үзен ни көткәнен дә белми яши бит кеше. Ходай ничек күреп-күзәтеп, ярдәм итеп бетерсен ди?! Юктыр ла, кеше үз язмышын үзе билгелидер. Әгәр кемдер безнең өчен төзеп-корып куйган юл-сукмактан гына барсак, зиһен-акыл дигәннәре ниемә кирәк соң ул чагында? Өстәгеләр күрсәткән әзер юлдан атла рәхәтләнеп, тәкъдирдә язылганны үтәп тыныч кына яши бир. Уйлап баш ватасы да юк. Явыз гамәлләрең өчен ояласы, үкенәсе дә юк. Мин тәкъдирдә язганча эшләдем, дисең дә, шуның белән бигайбә, вәссәлам...

Олы кешегә каршы сөйләп, үземне тәрбиясез итеп күрсәтәсем килмәде, бу уйлар дөньяга чыкмый, күңелдә генә калды.

Саимә апа сүзен дәвам итте:

—Әтиеңне гаепләргә хакың юк, үскәнем. Ата хакы, ана хакы изге нәрсә ул. Мәдинәгә дә күпме сөйлим, юк, тыңламый, әтисен якын да китерми.

—Ул киләмени?

—Кызын ташламады Илһам, гел ярдәм итеп торды. Шуңа күрә аңа бер үпкәм юк.

Саимә апаның сүзе миңа бик сәер тоелды, үзеңне газап утларына салган сатлыкҗан ирне гафу ит, имеш!

—Ә мин хыянәтне мәңге кичермәс идем!—дидем.

—Кичермәгәннән ни файда? Үзеңә генә авыр була ич. Ачу саклап йөрмә, үскәнем, кайт, аңлаш әтиең белән,—диде Саимә апа.

Тик ул күпме үгетләсә дә, мин үземнекен иттем, кайтмадым...

Әлмәт Казан түгел, тик Шатлык та түгел. Эзләгән, күрергә теләгән кешеңне һәр көнне очрата алмыйсың.

Бирегә килүемә өч айлап вакыт үтте инде, ә Женяны күрергә насыйп булганы юк әле. Аның каравы, базардан чыгып барганда, Хәмидә апа белән маңгайга-маңгай сөзештек. Танымаганга салышып, тиз генә үтеп китмәкче идем, ул үзе күреп өлгерде:

—Бәрәч, Нәргыйзә!

Хәмидә апа минем исемне гел шулай бозып әйтә, үземә калса бик тә матур, бик тә назлы кадерле исемем аның авызыннан чүпрә салгандай күпереп-бүртеп, тупас яңгырашлы Нәръхыйзәгә әйләнеп чыга.

—Син нишләп йөрисең монда?

—Базарга килгән идем.

—Әтиең беләнме?

—Юк, үзем генә.

—Син кайда соң хәзер? Укып бетергәнсеңдер бит?

—Бетердем, райүзәктә, мәктәптә эшлим.

—Зарплатаң күпме?

—Житәрлек.

—Кияүгә чыкмадыңмы әле?

—Юк, чыксам, белми калмас идегез.

—Хәзерге яшьләргә ышаныч юк.

—Миндә ышаныч бар!

Шулай дигәч, Хәмидә апа, әйтер сүзен онытып, авызын ачып калды. Ничек әле болай, бер мокыт авыл кызы бик масаеп «Миндә ышаныч бар!» дип тора? Нинди хикмәте бар?

Хәмидә апа «э-э-э» дип торган арада мин хушлашып китеп бардым.

Үзләре яшәгән урамда сөйләшеп торсак та, чәй эчәргә дә чакырмады «туганкай».

Әлмәттә авылдашлар күп, әллә ничә танышны күрдем инде. Минем биредә эшләвем-яшәвем хакында сүз безнекеләргә барып ирешми калмагандыр. Тик ул тарафтан бернинди хәбәр юк. Әтием: «Кызым, хәлләрең ничек?»— дип, килеп хәлем белсә, күңелем эрер, бар үпкәм онытылыр иде дә бит. Өметен өзеп, мина бөтенләй кул селтәмәгәндер ич?!

Ә беркөнне авылдашлар үзәк өзгеч, коточкыч хәбәр китереп тапшырдылар: Кифая авырлы! Кифая минем әтиемнән бала көтә!

Эчемә суык кереп тулды. Бар өметләр өзелде. Әтигә мин кирәк түгел. Мин—кисеп ташланган тырнак. Уртак балалары тугач, энемә дә көн калмаячак...

—Ни булды, кызый?—Елаудан кызарынып-шешенеп беткән күзләремне күреп Мәдинә курка калды.—Берәрсе үлмәгәндер бит?

—Үлмәде... туарга тора...

—Елан! Кара, ничек үзенә бәйләмәкче була,—диде Мәдинә, мине тыңлап бетергәч.—Бала тапканда үлсә ярар иде.

—Яхшы булыр иде,—дидем мин дә.

Гомеремдә беренче тапкыр кешегә үлем теләдем. Күңелемнең бик тирән бер почмагында рәхимсезлек дигән яман сыйфат яшеренеп яткан икән. Әбиемнең, шайтан барыбызда да бар, ирек бирсән, баш күтәрергә генә тора, диюе хак икән...

...Бар күңелем белән әтине көтсәм дә, теләгем кабул булмады. Минем янга әти түгел, Кифая апа килде. (Апа инде, апа... яшьтәш түгел лә!)

Балаларның көндезге йокы вакыты иде, кызлар белән чәй эчеп утырабыз. Ишек ачылган тавышка борылып карасам, бусагада Кифая апа басып тора! Корсагы иягенә житкән, йөзен кара тап баскан, яңаклары суырылып төшкән. Шул хатынны яратамы әти, булмас, кит моннан. Әни моның янында чәчәк иде!

Аны күргәч тә урынымнан кузгалмагач, үзе дәште:

—Наргизә, кил әле, сиңа сүзем бар иде.

Икәү киенү-чишенү бүлмәсенә чыктык.

—Исәнме...

—Исән!

Минем жавап шактый дорфа яңгырады.

Кифая апа берни сизмәгәндәй тыныч кына сүз башлады:

—Больницага УЗИга күренергә килгән идем. Соңга калганмын, прием беткән икән. Иртәгә иртүк барасы була инде. Бер килгән сине дә күреп, хәлләреңне белеп чыгыйм дидем...

—...

—Ник бер дә кайтып күренмисең? Әтиең дә, әбиең дә көтә. Алай ярамый бит инде...

Бу сүзенә дә коры гына җавап бирдем. Үзен күрәсем килеп тормаганны аңласын:

—Алдама, беркем көтми мине! Беркемгә кирәгем юк.

Кифая апа:

—Син белмисең бит...—дип нидер әйтә башлаган иде, ачу белән аны бүлдердем:

—Беләм, бик яхшы беләм! Исеңездә дә юк! Шул гомер минем белән

кызыксынган кеше булдымы?!

—Нишләп булмасын? Уйлама, бездә дә йөрәк бар, әтиең гел хәлеңне сорашып-белешеп тора.

—Әтине күргән дә, ишеткән дә юк.

—Ышанмасаң, Роза Мәхмүтовнадан сора.

Роза Мәхмүтовна—безнең бакча мөдире. Чынлап та, аңа шалтыратып, сөйләшеп торды микәнни әти? Кифая олы башын кече итеп алдашмас бит. Алайса, ник Роза апа миңа берни сиздермәгән? Әти әйтмәскә кушкандыр, мөгаен.

Бу бик тә, бик тә күңелле хәбәр иде. Эчкә бераз җылы керде. Тик Кифая апага берни сиздермәдем. Бу оятсыз хатынны мәңге якын итәсем юк. Корсагындагы баласы да энем белән икебезгә көндәш булачак җан гына. Бәхетле җан, безгә тиешле наз-мәхәббәт, кадер-хөрмәт хәзер тулаем аңа эләгәчәк. Төпчек бала, җитмәсә соңарып та туса, бик кадерле була ди ул. Әти аны кулыннан да төшермәс инде.

—Ярар, сорармын.

—Наргизә, әниең үлгәннән соң әтиең миңа өйләнмәсә, сина ни җинеллек булыр иде соң? Синең үз тормышың ләбаса. Ир-ат барыбер ялгыз яши алмый, мин булмасам, башкасы табылыр иде. Нигә шулай дошман күрәсең мине?

—Син булмасаң, эти белән чапмасаң, әни үлмәс иде!

—Мин түгел, Гөлзадә үзе безнең арага керде. Мидхәт—минем яшьлек ярым, бар гаебем—аны яратуым.

—Яраткач, нигә башкага кияүгә чыктың, ник ирең үлгәч кенә әтине искә төшердең? Хәзер нишләсәң дә юк инде, әнине кайтарып булмый.

—Беребез дә мәңгелек түгел.

—Әнигә кырык та тулмаган иде.

—Язмышы шулдыр.

Тагын шул язмыш! Бу да үз гөнаһын язмышка сылтамакчы. Дәртеңне тыя алмыйча, кеше иренә асылынсаң, язмыш була инде ул. Беркемнең дә үзен гаепле итеп калдырасы килми шул. Тукта, нәрсә дип минем алда шулай акланып маташа соң әле бу? Шул гомер дәшми йөрде-йөрде дә, хәзер исенә төшкән, ике арага күпер салмакчы була.

—Әниенең рәнҗүе барыбер төшәчәк, барыбер рәхәт күрмәячәксең!

—Каргама, Наргизә. Авырлы хатынны каргасаң, үз башыңа төшә диләр. Сабыйның бер гөнаһы юк.

Кифая апаның күзләренә яшь тулды. Ә-ә, имәндә икән чикләвек, менә нәрсәдән курка икән бу! Туасы баласы хакына каршымда ак җәймә булып җәелеп маташа, шуңа башын иеп, бәхиллек сорап килгән. Андый-мондый хәл булса, Наргизә гаепле аннары, шул гына каргаган иде, дияр, әти каршында мине начарга чыгарыр.

—Курыкма, мин сине каргамыйм,—дидем.

—Әгәр рәнҗеткән булсам, гафу ит.

Кифая апа күземә мөлдерәп карап тора. Мин сүзне икенчегә бордым:

—Кайда кунасың?

—Гостиницага барырмын, мөгаен.

—Ә ник Миндар абыйларга кермисең?

Кифая апа башын иеп дәшми торды. Аннары гаепле елмаеп:

—Хәмидә апа да... мине бик өнәп, яратып бетерми бугай...—диде.

—Кемне ярата соң ул?! Гостиницада йөрмә инде, бездә кунарсың.

Аңа адресны әйтеп, ничек барасын аңлатып, ачкычны тоттырып җибәрдем. Кифая апа каршы килмәде, шатланып, рәхмәт әйтә-әйтә, китеп барды.

Минем дә авырлы хатынның рәнҗешен аласым килми шул...

Бергә, бер бүлмәдә кунсак та, кич буе чөкердәшеп-сөйләшеп утырдык дип әйтә алмыйм. Кифая апа чәй эчте дә, сузылып яту ягын карады.

—Арыдым, гаепләмәгез, аякларым шешенә,—диде.

Иртүк чыгып та китте.

—Астыртын хатын бу, песи кебек утырган булса да, эче тулы корт түлке.

Мәдинә әтинең хатыны артыннан шундый сүзләр әйтеп калды.

—Әй, кем белгән инде аны...—дидем мин. Сүзне тирәнәйтәсем килмәде. Аңлашырга омтылып, ачыктан-ачык сөйләшүе, чакыруымны кире какмыйча минем янда куна калуы үги анама булган нәфрәтемне киметкән иде. Матур кәгазьгә төрми генә, турыдан әйткән сүзләре дә ихлас тоелды. Саимә апа кушканча, үземне аның урынына куеп карадым. Каенана, ир көйләп, үги балалар тәрбияләп яшәү ана да җиңел түгелдер. Исәннәргә яшәргә кирәк, һәркем үзенчә бәхетле булырга азаплана.

Киткәндә Кифая апа тагы бер кат әйтте:

—Без сиңа чит кешеләр түгел, Наргизә. Болай йөрмә, кайтып күрен. Илнар да сине сагына.

Белә минем йомшак җирне.

—Онытып та торам, сиңа хат язып җибәргән иде ул.

Хатка бик сөендем. «Апа, кайчан кайтасың? Мин сине бик сагындым»,—дип язган энем. Шул сүзләрне укыгач, күңелем тулып чак елап җибәрмәдем. Кифая апа белән очрашу эзсез узмады. Җанымны сыпып алган салкын бәсләрдән, үпкә-ачу юшкыннарыннан арынып, йомшара башладым бугай...

## 6

Эшли башлавыма унбер ай дигәндә ялга чыгарып җибәрделәр. Ике ай буе ниләр эшләп бетим дә, кай тарафларга китеп олагыйм икән? Әлмәтнең тулай торагын саклап ятып булмас, авылга—туган йортка кайтырга кирәк! Иң якын кешеләрем: әбием, әтием, Илнар янына. Анда тагы бер кан кардәш—бәләкәй энем дә бар... Әтинең улы булса да, белмим, якын итеп булырмы инде аны. Алдан ук баш ватудан файда юк, кайткач, күз күрер.

Мәдинә: «Әйдә, кыргыйлар булып диңгез буйларын айкап кайтабыз», дигән иде дә, тик ялларыбыз туры килмәде. Ул төзелештә буяучы булып эшли, җәй—алар өчен урып-җыю вакыты. Чернобыль авариясеннән соң ул якларга бару куркыныч та диләр әле. Һавасы да, суы да зыянлы, имеш. Безнең эштәге бер хатынның ирен Чернобыльгә җибәргән булганнар, кайтып ярты ел да яши алмаган мескен... Диңгез буена башка вакытта барырбыз инде. Бу юлы авылга кайтырга кирәк

Туган авыл, туган йорт бер генә була. Кайтырга кирәк!

Кулыма акча алу белән юлга җыена башладым. Акча дигәннән, мин аны бик туздырмаска тырышам, ашау-эчүдән калганын саклык кенәгәсенә җыеп барам. Үзем эшли торып, өйдәгеләрдән ярдәм сорап булмас. Кем белә, бәлки туйлар килеп чыгар. Егетем әлегә юк-югын. Сәлимне былтыр яз армиягә алганнар иде, аны озатырга кайтып булмады. Очрашып йөрмәсәк тә, күршем, классташым, балачак дустым ләбаса. Зәйнәбе озаткандыр әле, көтәм дип вәгъдәләр биреп калгандыр. Женяны очратуга да өметне өздем, бәлки ул Әлмәттән китеп үк баргандыр. Халык бит хәзер акча эшләр өчен Себер якларына барып урнаша, анда көрәп алалар, имеш. «Рәхәт яшисең килсә, Себер кияүен эләктерергә тырыш»,—диләр миңа эштәгеләр. Байлыкка исем китми лә анысы. Кешесе яхшы булсын. Тик кем икән соң ул миңа насыйп буласы яр, бармы икән ул дөньяда? Бәлки мин гомер

буе ялгыз каңгырап яшәргә тиешле бер бичара җандыр... Йөрәктә һаман бушлык. Битарафлык дингезендә шундый тыныч, тик нигәдер бик ямансу һәм куркыныч...

Шулай булыр инде, гомергә бер тапкыр юлга чыктым, анда да билет юк. Кире кайтып китәсе килмәде, берәр машина очрар әле дип юлга чыгып бастым. Көн җылы, аяз. Салкын тидерәм дип куркасы юк, рәхәтләнеп көтәргә була. Юл кырында гына наратлык, берьюлы саф һава да сулыйсын..

Янымнан эре-тере генә җинел машиналар җилдереп уза. Андыйларга ялыну файдасыз, чит кешене аласылары килми. Үзем дә утырырга атлыгып тормыйм, юньсез бәндәгә эләгүең бар. Шуңа күрә автобусларга гына кул болгыйм. Ләкин алары да туктарга ашыкмый, үтәләр дә китәләр, үтәләр дә китәләр... Җиде юл чатын саклап ике сәгатьләп вакыт узды. Шулчак яныма соры «Жигули» килеп туктамасынмы! Кул күтәрми торып та туктагач шикләнә калдым, күрмәгәнгә сабышып аркамны куеп бастым.

—Эй, красавица! Куда едем?

Тавыш үтә дә таныш. Йөрәгемә сеңгән, үткәннәрнең кайтавазы булып яңгырый торган кадерле, күңелгә бик якын тавыш. Ошаса да ошар икән! Кем ул Женяның тавышы белән сөйләшә? Кызыксынып машина иясенә карыйм һәм тетрәнеп китәм. Каршымда... Әнекәем, чынмы бу, саташмыйммы?! Каршымда бит Женя үзе басып тора! Миңгерәү карашымны аңа төбәп, сихерләнгән кебек катып калам.

Ул мине танымый бугай.

—Так едем или нет?—дип сорый.

—Женя...

—Да, Женя, а что? Мы знакомы что ли?!

Ничек инде... Ничек ул мине танымый?! Күз алдымнан кинәт югалуыннан куркып, йотылып-йотылып аңа карыйм. Бер дә үзгәрмәгән Женя, һаман шундый яшь, чибәр. Өс-башы ялт итеп тора. Бәйрәмгә барган кебек киенгән: ап-ак күлмәк, яхшы итеп үтүкләнгән соры чалбар. Йөзе шоп-шома итеп кырылган. Шул килеш фотога төшереп «Экран» журналына җибәрерлек!

Язмыш бар, күрәсең. Менә бит очраштырды. Бу мизгелне ычкындырырга ярамый. Женя белән сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Шатлыгымны, дулкынлануымны йөзгә чыгармаска тырышып, ипләп кенә арткы утыргычка урнашам. Танырмы икән? Ни дияр, оныткан мы мине, юкмы? Хисләре сүнмәгәнме? Күңел тулы сорау.

—Вам куда?

Мин әйткәч, «Ә-ә, беләм, ул якларда булганым бар»,—диде.

Кузгалып киттек, көзгедә Женяның сөйкемле йөзе чагыла. Киң маңгай, тигез кашлар, ягымлы зәңгәр күзләр... Чибәр дә инде үзе. Юк, онытмаганмын икән аны. Мин уйлаганча булды, шикләнүем рас килде: Женяны күрүгә күңел түрендә йокымсырап, пыскып яткан бөтен хисләрем өр-яңадан дөрләп кабынды. Кифая апаны аңларга була...

—Без танышмы?—дип кабатлап сорый Женя, көзгесеннән мине күзәтә-күзәтә.

Шул хәтле үзгәрдем микәнни?

—Таныш идек.

—Беләсезме, эшем шундый, күп кешеләр белән очрашырга туры килә. Хәтерләп бетерә алмыйм.

И тавышы! Шул кадәр тансык, сагынылган. Күзем күргәнгә күңелем ышанмый: миннән кул сузымында гына дөньяда бер кадерле кешем Женя утыра! Юл озын, көзгедәге чагылышын туйганчы кара, баллы тавышын рәхәтләнеп тыңла. Наргизә, сиңа бүген җәйге кояш булып Бәхет әфәнде үзе елмая!

Әңгәмәне өзәсем килми:

—Сез ул чакта төзелештә эшли идегез...

—Ташладым мин ул рабский трудны, нафиг! Эше авыр, акчасы юк. Капитализмны каршыларга әзерләнәбез. Частник мин хәзер, үземә үзем хуҗа.

—Нинди эш белән шөгыльләнәсез?

—Шәп, күңелле эш. Чит ил кассеталары сатабыз. Нинди генә фильмнар юк! Обалденно! Секс-мекс, короче. Халык егылып ала. Күрерсең, бер-ике елдан бездә сексуальная революция башланачак. Короче, безне алда бик күңелле тормыш көтә, чибәркәй!

Женя авызыннан мондый сүзләр ишетү күңелле түгел. Кызлар белән шулай сөйләшәләр димени?!

—Телисенме, сина да берне бүләк итәм, өйрәнә торырсың. Кияүдәме син?

—Юк.

—Татып караганың бармы соң?

Бу сорау миңа ошамый, шуңа күрә ишетмәмешкә салышып, дәшмим. Женя көзгегә үрелеп карый-карый, авызын ерып, миннән җавап көтә.

—Неужели целька?

Абау, нинди ямьсез сөйләшү... Болай булса, юл артык озын тоелыр. Миңа бик күңелсез булып китә, әле бая гына бөтен барлыгымны биләп алган шатлык дулкыннары басылып-тынып кала. Үзгәргән Женя, үзгәргән... Ә бәлки үзгәрмәгәндер, гел шундый булгандыр. Күпме генә беләм соң мин аны?! Бригадирлары ни дигән иде, истә бит: «Сак бул, Наргизә, ачылма бу кешегә!». И, Аллам, танымаса гына ярар иде. Мин бер йомгакка җыерылып, куырылып утырам.

Бераз сөйләшми баргач, Женя машинаны кинәт туктата.

—А ведь я вспомнил! Ты—Настя!

Мин дәшмим. Женя миңа туп-туры төбәлеп сынап карый, карашы белән баштанаяк тикшереп чыга:

—Точно, Настя! Теге идиот парторг кызы. Синең белән расчет ясалмый калды бит, лапочка. Бурычыңны кайтарасың бар.

Ялгышам, ул мине танымады, башка Настя белән бутый. Минем Женяга бернинди бурычым юк.

—Болай булгач, җиләккә кереп чыкмый булмас...

Мин әле Женяның тел төбен аңламыйм:

—Бу вакытта нинди җиләк булсын?

—Җиләге булмаса, шомырты булыр. Изелеп пешкән! Амм... Авызда эри, кабасың да йотасың.—Женя миңа борылып, иреннәрен чупылдатып куйды, майлы, мәгънәле карашы һич тә яхшылык вәгъдә итми иде.

Мин аның кинаяле сүзләрен аңламаганга сабышып, бик җитди итеп:

—Шомыртка кызлар белән барырбыз,—дим.

—Кызлар белән?! Ха-ха-ха... —Женя табигый булмаганча көчәнеп, ямьсез итеп көлеп җибәрә. Үзе көлә, ә карашыннан нәфрәт очкыннары сибелә.—Урманда егетләр белән йөрергә кирәк, лапочка! Шунда гына җиләге дә, шомырты да тәмле була!

Женяның тупаслыгыннан күңелем рәнҗи. Әллә төшеп калыргамы? Ләкин мин аны-моны уйлап өлгергәнче машина кинәт кузгалып китә, олы юлдан читкә борылып наратлыкка таба юнәләбез.

—Так, Настенька. Менә шунда алыш-биреш ясарбыз инде без синең белән...

—Кая барабыз? Ник борылдык? Туктат машинаны! Мин төшәм.

—Цыц, лапочка, тик кенә утыр.

Мин ишеккә ябышам:

—Туктамасаң, сикерәм!

—Гарип каласың киләме? Пожалуста, сикер.

Урман эченә килеп кердек. Бөтен барлыгымны курку хисе биләп алды. Женяны күрү шатлыгы машина тәгәрмәче астында тапталып-изелеп җиргә сеңде...

Туктадык. Женя ишекне киереп ачты:

—Төш!

Мин кузгалмадым.

—Төш диләр сиңа!—Женя көчле куллары белән мине машинадан тартып чыгарды.—Иди ко мне, лапочка...

—Җибәр!

—Юк инде, татарочка моя, теге вакытта синең аркада эт итеп кыйнап ташладылар. Күпме эшләп, тиешле акчабызны алалмадык. Парторг папашаң тырышты. Хәзер барысы өчен дә түләрсең!

Минем каршымда бөтенләй башка Женя, аның күзләре котырган үгезнеке кебек акайган, карашында—кабер суыклары. Ул беләкләремне умырып кыскан. Аның кулларыннан ычкынмакчы булып тыпырчынам, ләкин ул да булмый, Женя тиз астыма китереп тибә дә, мине җиргә егып сала, авыр гәүдәсе белән өстемә каплана. Колагыма ерткыч мышнавы ягыла, йөземне селәгәйле иреннәр ялый, әрсез, тупас куллар күлмәк изүемә кереп, күкрәгемне капшый... Йә, Аллам, ничә еллар буе шул кабахәт җан өчен ут йоттыммы, шул иблисне сагынып, яшь түктемме?! Җанымны нәфрәт, җирәнү хисләре биләп ала, бар көчемне җыеп, өстемдәге кешене этеп җибәрәм. Торып йөгермәкче булам, тик ул мине кабат эләктереп ала.

—Карышып маташа тагы, сучка!—дип бар көченә чигәмә китереп суга.

Шуннан ни булганын мин хәтерләмим...

Аңыма килгәндә җир тетри, баш өстемдә күк чайкала иде. Кояш әле бер, әле икенче якка авыша. Кайдандыр «тыр-тыр» иткән эчпошыргыч тавыш ишетелә. Мин үзем дә никтер чайкалам. Ни булды? Кайда мин? Бөтен тәнемдә коточкыч авырту, хәлсезлек. Бигрәк тә башым ярылып-ярылып сызлый. Шул авыртуны сыпырып төшермәкче булып, кулымны башка куям, бармакларым никтер юешләнә. Мин су эчендә ятаммы әллә? Бәлки шуңа чайкаламдыр. Су турында уйлау белән үтереп эчәсе килә башлый, иреннәрем сусаудан ярылып беткән кебек. «Су, су, су...»—дип пышылдыйм, тик мине беркем ишетми. Баягы эчпошыргыч тавыш кына колагымны ярып керә: «Тыр-тыр-тыр...» Дымлы бармакларны иренемә тидерәм, ниндидер төче тәм сизәм. Ни соң бу? Кан түгелме соң? Кан бит бу! Мин яралымыни?!

Әле берни аңламыйм, берни хәтерләмим. Башымда буталчык уйлар өермәсе генә. Шулчак мине нидер өскә чөя, башымда коточкыч авырту тоеп, кабат билгесезлеккә, караңгылыкка китеп югалам...

Күземне ачканда каршымда зәңгәр киемле кеше басып тора иде. Ул гүя зәңгәр томан эченнән килеп чыкты. Томан тарала барды, кешенең кавын кебек озынча башы пәйда булды, аның чәчләре дә, каш-керфекләре дә, сипкел баскан йөзе дә сары, бары тик күзләре генә сары башаклар арасына кереп буталган күкчәчәктәй зәңгәр иде. Мин аңа төбәлеп-төбәлеп карыйм, тик таный алмыйм. Милиционерлар арасында танышларым юк. Нигә килгән ул минем янга, ни кирәк аңа?

—Тә-әк... Кем булабыз инде без?

—Мин кайда?

Миңа милиционер түгел, ниндидер хатын-кыз җавап бирде:

—Борчылма, больницада син.

Шундый ягымлы тавыш иясен күрергә теләп, башымны борган идем, авыртудан күзләремә яшь атылып чыкты.

—Кузгалма, апаем, тыныч кына ят.

Бу юлы тавыш баш очымда гына ишетелде, каршымда ак халатлы апа басып тора иде.

—Чурт вазми, моның сөйләшерлек рәте дә юк бит,—ди милиционер.—Кайдадыр себерелеп йөриләр дә, безгә шуларның пычрагын җыярга кала.

—Алай димәгез инде,—ди ак халатлы апа.—Бигрәк каты кыйнаганнар бичараны.

—Бирмәгәндер. Бирәсе булмагач, ничего урманда йөрергә!

Мин аларның сүзләренә төшенеп бетә алмыйм әле. Кем турында сөйләшүләрен дә аңламыйм.

—Әй, кызый, сөйләшерлек рәтең бармы? Исемең ничек, хәтерлисенме?

—Наргизә.

—Кычкырыбрак әйт, ишетмим.

Кычкырып әйттем түгелме соң инде? Үз тавышымнан хәтта башым чынлап китте.

—Бәлки иртәгә килерсез? Күреп торасыз, хәле юк бит.

—Көн саен свиданиегә килеп йөрергә вакыт юк минем. Безнең эштә оперативность кирәк. Кайнар эздән йөрмәсәң, шиш, тотарсың көчләүчене. Йә, ялындырма, сөйлә, ни булды анда сезнең?

Кайда? Кайчан? Мин белмим, берни хәтерләмим. Бернинди уйсыз буш карашымны милиционерга төбим.

—Да-а... Пожалуй, берни барып чыкмас, тәки иртәгә килергә калыр.

Милиционер күз алдымнан югала, аның дөп-дөп баскан аяк тавышлары ерагая.

Янымда ак халатлы апа гына кала.

—Кайгырма, сеңлем. Хәтерең кайтыр, син әле шок хәлендә. Үзең белән ни булганын исеңә төшерергә тырыш. Сине җәберләгән бәндә тиешле җәзасын алырга тиеш. Табарлар, утыртырлар.

Бу апаның тавышы бигрәк йомшак, шундый назлы. Әнинекенә охшаган. Тизрәк әни килсен иде, аны күрәсем килә.

Күзем йомыла, төшемдә наратлар күрәм, бик күп наратлар. Шундый төзләр, шундый биекләр. Алар гүя вальс бииләр, әйләнәләр дә әйләнәләр...

Мин төнлә уяндым. Ап-айнык булып. Акылым җәйге күктәй аяз иде. Уянуга барысын да искә төшердем. Авылга кайтырга җыенып, юлга чыгып басуымны, Женяны очратуымны, аның сүзләрен, кизәнүләрен искә төшердем. Тик ничек больницага килеп эләгүемне күпме тырышсам да исемә төшерә алмадым. Сорау алырга килгән милиционер да, аның сүзләре дә хәтеремдә яңарды. Уйлап ята торгач аңладым, Женя мине кыйнаган гына түгел, аңсыз хәлемдә көчләгән дә... Кара эшен башкаргач, ташлап китеп барган. Кемдер мине табып алган, больницага китергән. Мөгаен, шулай булгандыр...

Хәлләр шәптән түгел...

Иртәгә кабат көнбагыш башлы милиционер килер, үзенең мәгънәсез, оятсыз сорауларын яудырыр. Мин ана барысын да сөйләп бирергә тиеш. Аннары суд булачак. Аннары инде миңа төртеп күрсәтәчәкләр, менә бу бичара кызны мәсхәрә иткәннәр, аны хәзер кем кияүгә ала инде, и мескен, диячәкләр. Хәбәр авылга да кайтачак: «Мидхәт кызы оятка калган, җәй буе чапкан урысы көчләгән икән. Парторг кызлары да фәрештә түгел, үз баласы шундый булгач, башкаларны өйрәтеп йөрисе дә юк. Авыл егетләрен

санламый кәпрәеп йөрсәң, менә шулай була ул...» Һәм башкалар, һәм башкалар...

Безнең авыл апаларына гайбәт өчен жим генә бир. Ач кош балаларыдай авызларын ачып, йотарга гына торалар. Кеше кайгысы кем өчендер күнел юанычы... Әбиемә хәтле: «Теләгәненне алдынмы, мәсхәрәгә калдынмы?!»—дип мыскыл итәр әле. Кифаясы да тыштан кайгырган булып кыланса да, эчтән генә сөенер, менә, бик борын күтәреп йөргән иден дә, акылга утырттыларммы, дияр...

Гайбәте бер хәл, минем язмышым жимерелде әле монда. Киләчәгемнең кояшын урладылар. Үтәр сукмакларыма гөл түгел, көлләр сибелгән. Бәхеткә илтер күперләр янган...

Бернинди суд булмаска тиеш! Качарга, каядыр китеп югалырга кирәк! Минем кем икәнне белмиләр, янымда бернинди документым юк иде. Саклык кассасында азмы-күпме жыйган акчам бар, шуларны алырга да, даның дөньяга таралганчы бу шәһәрдән чыгып таярга кирәк. Еракка, еракка китәргә!

Минем бер генә барыр жирем бар: ул Майлысу. Анда әниемнен туганы Фатыйма апа яши, ул мине куып чыгармас, үз янына сыйдырыр. Минем кайдалыгымны беркем белмәс. Югалган икән, югалган. Югалган кешеләр дөнья тулы, мин беренчесе дә, соңгысы да түгел...

## 7

—Горбачев илне таратып бетерә, әйтте диярсез. Россиягә Иван Грозный, Сталин кебек каты куллар кирәк. Безнең халык каешка өйрәнгән ул, ялкау урысны башкача тыңлатып булмый. Ә бу интеллигент илне таратачак. Башы-аягы белән Америка алдына китереп салачак. Факт, шулай булачак! Безгәме соң инде демократия?! Әкият! Урыска эчәргә булсын. Ә Горбачев аның көн-төн суыра торган тәмле сускиен тартып алды, анти-алко-голь-ная кам-па-ния, имеш! Тфу, адәм көлкесе! Урыс эчмиме сон инде?! Шунсыз яши алмый бит ул. Юк, бу демагогтан тучны рәт чыкмый. Всё коту под хвост. Демократия дигән нәрсәне безнең халык мәнге дә аңламаячак. Иллә бардак башлана, мин әйтте, диярсез. Факт, шулай булачак! Брежнев та бозау булды, халык урлашырга өйрәнде. Ә хәзер гупчим бардак булачак. Сталин кирәк, Сталин!

Аскы ятакта зур корсагын кочаклап, бертуктамый мангай тирен сөртеп утыручы абзый баядан бирде лыгырдый да лыгырдый. Бер колагымда аның тавышы чыңлый, икенчесендә поезд тәгәрмәчләре тукылдый: «тыкы-тыкы, тыкы-тыкы...» Абзый каршында, уйлы карашын тәрәзәгә текәп, орчык кадәрле генә бер әби утыра. Тыңлыймы ул бу тел бистәсен, аңлыймы, белмим. Абзыйның бер олау сөйләп ташлаган сүзләренә ни кушылмый, ни каршы дәшми. Ә тегесе туктарга уйламый да, һаман үзенекен такылдый. Туйдырып бетерде инде. Каян гына шундый мәгънәсез юлдаш туры килде. Баядан бирле йокламакчы булып азапланам, башымны мендәр белән дә каплап карадым, файдасы юк, бер кирәкмәгән сүзләр әллә каян саркып керәләр дә, шишара кебек башыма коелалар. Ярый ла, мин өске киштәдә ятам, тел бистәсе каршында утыручы мескен әбигә Ходай ярдәм бирсен.

Бердәнбер тыңлаучысының битарафлыгына, үзенең акыллы, дөрес сүзләрен күтәреп, хуплап алмавына абзый үртәлде:

—Бабуля, син саңгыраумы әллә?—дип сорады.

Миңа кызык булып китте, шыпырт кына үрелеп аска карадым.

Әби аның соравыннан битәр, тынып калуына гажәпләнде бугай, карашын иренеп кенә юлдашына күчерде дә, гаепле елмаеп куйды:

—Ни панимайт бит...

Пырхылдап җибәрмәс өчен мендәремне тешләдем. Вәт шәп булды бу. Хәзер авызын йомар инде абзаң, йә башка буш колак эзләп китәр. Миңа гына бәйләнмәсен, шуңа йоклаганга салышып ятам.

—Не понимайт, да... Ну народ... стадо баранов! Поймешь, но поздно будет, старая карга,—дип сукрана-сукрана чыгып китте абзый.

Хәзер инде әбинең теле ачылды:

—Уф, Аллага шөкер, әллә кайчан шулай кирәк иде, кеше мыңгырәтеп утырасың монда. Синең Горбачевыңнан башка кайгым беткән ди. Миңа димәгәе, чукынышып бетсеннәр. Яшисен яшәгән инде. Кем булса да гади халыкны кайгыртмый барыбер. Безгә гомер буе нужа куарга, и Алла... Кысыр хәсрәт белән башымны катырып утырмаса соң...

Әби белән без Куйбышевта бергә утырган идек. Аны улы белән килене озатып калды. Мәңгегә аерылышкан кебек бик озак хушлаштылар. Ике тарафтан да бәйнә-бәйнә үгет-нәсихәтләр бирелде.

—Әнкәй, зинһар, теләсә кемгә ышанып ияреп китә күрмә. Миңлегөлнең килеп каршылавын көт,—дип кат-кат кисәтте улы.

—Беләм, улым, беләм. Юл йөргәнем бар, бала-чага түгел. Минем ише карчыклар кемгә кирәк? Үзегезне саклагыз. Әлбирт соңлап йөрмәсен. Бандитларга ияреп китәр дип котым оча,—диде әби.

Минем кыяфәт тә бандитларныкыннан ким түгел иде, шуңа күрә, вагонга керү белән, урын-җир алганчы ук, өске ятакка менеп кунакладым да, поезд кузгалып киткәнче тынымны да чыгармадым. Әмма өч тәүлек буе качып ятып булмый, анда-монда барып килгән арада да әбинең очлы күзе барысын да күреп-чамалап алды. Тик аның да бу дөньяда беренче көн генә яшәве түгел, әллә ни исе китмәде, хәлемә кереп:

—Ирең кыйнадымы әллә?—дип кенә сорады.

Миңа җавап эзләп баш ватасы да калмады. Бик шатланып, «ирем»нән зарлана башладым.

—Эчәдер әле, иблис. Шул шайтан суы адәмнәрнең акылын томалый,— диде әби.

—Эчә шул...

—Кибеттә булмаса, җир тишегеннән табып булса да эчәләр, имансызлар. Ул якка башлары эшли аларның. Минеке дә башы-аягы белән кереп чумган иде. Сугыштан өйрәнеп кайтты. Аңа хәтле аракы дигән нәрсәнең барлыгын да белми идек. Картайгач та ташламады, намаз укып утырасы урында шуны чөмерә иде. Теге дөньяда җавап бирәсең бар, иртәнге намазыңны булса да укы, дип үгетли идем, кая ул! Намаз укымагансың дип кире борып кайтармаслар әле, дип авыз гына ера иде. И-и, бозылды ирләр, бозылды... Шул нәрсә авызларына керсә, зина да кылалар, кан да коялар.

Әби миңа кызганыч караш ташлады:

—Ярый әле исән калгансың, олан. Бөтенләй имгәтеп ташламаган. Инде кая барасың соң?

—Әндиҗанга, апамнарга.

—И-и, бәбкәм, юлың бигрәк ерак икән. Башка туганнарың юкмыни? Киткәнеңне ирең беләме соң? Эзләп бармагае тагын.

—Юк, бармас. Миннән котылганына шатланып утырадыр әле.

—Алдагысы хәерле булсын, диң. Ходайдан бәхет, тәүфикълы иптәш сора.

Әби миңа байтак акыл өйрәтте. Мин дә ярыйсы гына борчак сиптем. Юлда очраган бер кешегә тормыш юлыңны бәйнә-бәйнә сөйләп утырмассың бит.

Оренбургка җиткәч, безнең янга менә бу акыл иясе, тел бистәсе менеп кунаклады. Салават күперенең барча төсләре белән бизәлгән «нурлы»

йөземне моңа күрсәтмәс өчен, мин тизрәк ятагыма менеп постым, урысча сөйләшүенең рәте-чираты булмаган әби дә телен аркылы тешләде.

Абзый, кереп урнашу белән, уфылдый-уфылдый сумкасыннан бер еллык запасын чыгарып, башта рәхәтләнеп сыйланды. Болай да мул корсагына бербөтен кыздырган тавык ите, өч кукәй, ике помидорны озатты, аннары аларны ике шешә сөт белән юдырып төшерде. Моның хәтле дә күп итеп, моның хәтле дә тавышланып, бөтен вагонны дер селкетеп ашаган кешене күргән юк иде әле. Авызын чапылдатканы хәтта тәгәрмәч тавышларын да күмеп китә. Тамагы туйгач, абзый, киерелеп утырды да, күнелен бушатырга керешге, сәгать буе нотык сөйләде. Биредә үзенә сокланучылар, харап акыллы сүзләрен хуплаучылар табылмагач, безнең бәхеттән, яңа буш колак эзләп чыгып китте.

—Тавышы башыма капты чисти, мәгънә белмәсә дә белмәс икән...

Әби үзалдына мыгырдана-мыгырдана, урын җәйде, теге җәфа әйләнеп кергәнче, ятып калыйм дигәндер инде.

Колагымда бер генә тавыш яңгырап калды: «тыкы-тыкы, тыкы-тыкы...» Бусына түзеп була. Бишек җыры кебек йоклата торган бертөрле көй. Тирбәлә-тирбәлә тыңлап барасың. Йоклыйсы иде тизрәк, беразга булса да баш авыртуы онытылып торыр иде, сызлап та куя. Женя сукканнан гына болай булмас, егылганда берәр каты нәрсәгә ныклап бәрелгәнмендер, мөгаен. И, Алла, канга батып, аңсыз яткан кешене мыскыл итәр өчен бөтенләй җансыз-кансыз булырга кирәктер. Чит ил видикларын карый-карый үзе дә маньякка әйләнгәнме әллә ул? Башта ук шулай рәхимсез булгандыр, яхшы булып кыланган гынадыр дип уйлыйсым килми. Әллә үземнең сукыр, беркатлы булуымны таныйсым килмиме?! Юк-юк, андый түгел иде Женя, бөтенләй башка, шундый ягымлы, назлы иде. Аның белән үткәргән көн-кичләрем күңелдә шундый матур истәлек булып калды лабаса. Югыйсә шулай өзелеп сагыныр идемме? Язмыш, имеш... Авылына кайтырга чыккач, Наргизәне очратсын да, тотып кыйнасын, мыскыл итсен әле дип, юлыма Женяны Аллаһы Тәгалә чыгармагандыр бит. Минем тәкъдир китабыма шул күрәчәкне ул язып куйды микәнни? Юк, булмас, Ходай шул хәтле мәрхәмәтсез түгелдер. Минем аңа ни зыяным тигән?

...Иксез-чиксез дала буйлап поезд алга ашыга. Туган авылым, якыннарым белән бәйләгән җеп алардан ерагайган саен тартыла-тартыла барыр да бөтенләй өзелер инде. Үткәннәремне мәңгегә яндырып китәм, кире кайтмаска дип китәм...

Китү җиңел булмады.

Больницадан төн уртасында чыгып качтым. Качтым дию генә җиңел, басып торырлык та хәлем юк иде. Ярый әле палатам беренче катта, дежур врач, медсестраның күзенә чалынмас өчен тәрәзәдән генә чыгып шылдым. Тулай торакка кайтып җиткәнче әллә ничә тапкыр туктап хәл алырга туры килде. Төнлә куркыныч та бит әле. Башымдагы ап-ак бинт светофор уты сыман әллә кайдан балкып-күренеп тора. Бер ишегалдында яшьләр эчеп-гөрләшеп утыра иде, коләргә-үртәргә тотындылар:

—Карагыз әле, өрәк йөри! Өрәкләргә ау оештырырга кирәк!

Тулай торакка кайтып җиткәндә таң беленә башлаган иде инде, җеп өзәрлек тә хәл юк, тизрәк керәсе дә урынга гына авасы. Тик... Бу вакытта тулай торак ачык була димени? Бикләгәннәр, әлбәттә, кем мине көтеп утырсын?! Вахтадагы апага бу килеш күренәсе килми. Аркамны салкын диварга терәп чирәмдә хәл җыеп утырдым-утырдым да, тулай торакка беркемгә сиздерми керү юлларын эзләп киттем. Ирләр бәдрәфенең тәрәзәсе ябылмаган булып чыкты, тәмәке исләре урамга чаклы аңкып тора. Кысыла-

кысыла шуннан керә башлаган идем, эчке яктан кемдер тартып-кочаклап алмасынмы! Куркудан котым калмады. Карасам, каршымда исерек бер егет чайкалып басып тора. Телен көчкә әйләндереп:

—Смелая девушка!—диде.—Кому это ты в гости собралась, душечка? Не ко мне ли?

—Ярдәм ит, зинһар... Мине кыйнадылар, тик беркемгә әйтмә.

Егет бармагын иреннәренә китерде:

—Могила!

—Коридорда кеше юкмы?

—Абсолютно никого! Ты да я, и мы вдвоем! Пошли!

Әкрен генә басып, өченче катка күтәрелдек. Икебез дә чайкалабыз, мин дә исеректән һич ким түгел. Бүлмәмә килеп житкәч, егетне тагын бер кат кисәттем:

—Беркемгә әйтмә, яме. Син мине күрмәден, килештекме?

Егет елмаеп кул гына болгады.

Мәдинә дөньясын онытып йоклый иде. Баштанаяк юрганымны ябынып, мин дә урынга аудым.

—Кызый, син нишләп монда? Кайтып китмәденмени?—дип сорады иртән Мәдинә.

Юрган астыннан йокы аралаш мыгырданып җавап бирдем:

—Автобус ватылды, кире кайттык...

—Ә-ә,—дигән булды Мәдинә.

Анарда минем кайгы түгел иде. Ашык-пошык җыенды да эшкә чыгып китте. Адымнары ерагайгач, мин дә урыннан кузгалдым. Хәлләр мөшкел, сызламаган җир юк. Кыяфәтем һич тә шәп түгел. Көзгегә карагач, имәнеп киттем хәтта. Күз төпләрем күгәреп чыккан, сул янак шешенгән. Шулай да, башка яулык бәйләп, биткә кара күзлек элеп тәвәккәлләп чыгып киттем. Чөнки саклык кассасындагы акчамны алырга кирәк. Барам шулай кача-поса, урамдагы һәр кеше мина аптырап карый төсле. Танышларны очратудан куркып, погонлы кеше күргән саен сискәнеп, катырак җил иссә дә таралып китәргә торган «җимерек» гәүдәмне көч-хәл белән өстерәп, йомышларымны үтәп йөрдем. Мәдинә кайтканчы тулай торактан чыгып китәргә, аның күзенә башка чалынмаска кирәк иде. Ул мине бу кыяфәттә күрергә тиеш түгел. Кием-салымише әйберләрне күтәрерлек хәл булмагач, үзем белән акча, документларны гына алдым да, вокзалга юнәлдем...

Инде менә Мәскәү-Ташкент поездында барам...

Әлегә мине эзләүче юктыр. Әлегә югалуымны белүче дә юктыр. Авылдагылар өчен мин Әлмәттә, ә Әлмәттәгеләр мине авылда дип белә.

Шуңа күрә күңелем тыныч. Алдагысын күз күрер. Минем бернәрсә турында уйлыйсым килми. Бары ял итәсем, үзем белән булган бу җан өшеткеч вакыйганы тизрәк онытасым килә. Барысын-барысын онытып, дөньяга өр-яңадан тугандай яшисем килә.

Тормышымны тәүге кардай ап-ак, чиста биттән башлар өчен, үз-үземнән качып, бик ерак, бик озын юлга чыктым мин. Үткәннәрдән башка киләчәк юк диләр. Әмма үткәннәргә нокта куелган, пәрдә корылган, август аеның кояшлы бер көнендә таныш түгел юллар буйлап, ашкына-ашкына, билгесез киләчәгемә таба, таулар артындагы кояшны эзләп китеп барам. Анда—яңа дуслар, яңа танышлар, яңа серле тормыш. Бәлки әле яңа, саф мәхәббәт тә... Үткән белән киләчәк арасындагы күпер дөрләп янды, кире кайтыр юллар мәңгегә өзелгән. Хәтта поезд тәгәрмәчләре дә, минем уйларым белән килешкәндәй, «тыкы-тыкы» диюеннән туктап, «өзел-де, өзел-де» дип кабатлый кебек...

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Жизнәм яшь вакытта харап чибәр кеше булган. Аның гаилә альбомындагы сурәтләрен карыйм да таң калам. Чиста тулы йөз, тигез кара кашлар, йөрәгенә утлы ук булып кадалырлык үткен, кыю караш. Ул чәчләр! Шундый куе, күпереп дулкынланып тора. Чибәр инде, чибәр, бу йөздән бер гаеп тапмассың. Карлыгандай кара күзләренең шаккатмалы матур икәнлеге шул тонык сыйфатсыз рәсемдә дә кычкырып тора. Фатыйма апаның бер күрүдә гашыйк булуы гаҗәпмени?! Әнисен елата-елата, артына да борылып карамыйча шул егеткә ияреп чыгып киткән бит авылдан. Әле кая диген, гомер күрмәгән җиде ят җиргә, кырыс каенана белән каената янына. Алар газиз улларын туган якка өйләнергә дип кайтарып җибәрәләр. Чыбык очы туганнары инде кәләш тә табып куйган була, бирнәләрен җыештырып, ияртеп кенә китәсе. Төенчекләре өстендә булачак киявен дүрт күз белән көтеп утыра ул кызый. Кайта Ләбиб, кичен киенеп-ясанып тугайга төшеп китә. Апасы кәләшнең нindirәк икәнен бәйнә-бәйнә аңлата: «Арада иң чибәре булыр, өстендә зәңгәр чәчәкле ситсы күлмәк булыр...» Эзләп таба Ләбиб кызны, кич буе шуның янында бөтерелә, озатып кайта. Өч көннән үзе белән ияртеп алып та китә. Ә теге кәләш төенчекләре өстендә утырып елап кала... Ләкин Фатыйма апаны да кәнфит-күмәч белән көтеп тормыйлар. Мәхәббәт сихереннән бик тиз айный, канатланып менеп киткән җиде кат күгеннән каты җиргә мәтәлеп төшә...

Фатыйма апа үзе турында сөйләгәндә, мине ахирәте урынына күреп, күңел төбендәге бөтен серен чыгарып селки:

—Әй сагындым да соң шул чакларда авылны, еламаган көн юк иде. Ләбиб чибәр, миңа гына карап утырмый, төрле якка чаба, аңа кызык кирәк. Ә минем итәк бозга ябышкан, кулда ике бала. Өйдәге эшне тавык чүпләп бетерә торган түгел. Каенатам харап та кырыс кеше иде. И-и, яшәдек инде, ничекләр түзеп бетелгәндер. Яшьлек белән генә сизелмәгәндер.

Хәзер каенана да, каената да юк, үзләре салган кыр хәтле йортта өчәү яшәп яталар. Ләбиб абый сурәттәге егеткә бөтенләй охшамаган. Гүя ул матур йөзне кемдер кыра-кыра каерып алган да, аның урынына бака тиресе ябыштырып куйган. Җир астында кояш күрми эшләгәнгәме, әллә эше зыянлы булгангамы, мин белгән шахтер абыйларның күбесе әллә нинди гайре табигый яшькелт-кара шадра йөзле, җыерчык өстендә җыерчык.

Ләбиб абый картларча бөкрәеп, иңнәрен җыерып йөри. Ул гадәте дә эше белән бәйледер, мөгаен. Җир астында күкрәк киереп, борын чөеп йөреп булмыйдыр шул.

Ә Фатыйма апа һаман матур әле. Үзен бик карап-тәрбияләп кенә тора. Витаминнарны учлап-учлап ашый. Аның файдасы турында сөйли-сөйли, минем башны да катырып бетерде. Югыйсә төймә-төймә дару эчкәнче, рәхәтләнеп яшелчә-җимеш аша! Әллә каян эзләп йөрисе юк, тулып ята бит. Карбызлар аяк астында тәгәрәп йөри, өрек-алмалар кайнар кояш астында изелеп пешә, өз дә рәхәтләнеп сыйлан, сатып аласы юк. Бакчага чыксаң, киерелеп басарга буш урын тапмассың, ни кызганыч булса да, агачтан коелган җиләк-җимешне изеп-таптап йөрергә туры килә. Монда бик тырышсаң да ачка үлеп булмыйдыр, ризык үзе синең арттан йөри.

Мин дә тауларга карап кына утырмыйм анысы, бер атна да кунак булмый, эшкә урнаштым. Дөресе, Фатыйма апа урнаштырды. Үзе эшләгән җирдән бернинди мәшәкатьсез медицина тикшерүе үткәнгә белешмә алып бирде дә, балалар бакчасына тәрбияче итеп кертеп тә җибәрде. Мондагы халык Россия белән чагыштырганда гадирәк, җинелрәк яши кебек, мең төрле инструкция-кагыйдәләр белән баш ватмыйлар. Бары «Сум-Тәңкә әфәнде»гә генә кадер-хөрмәт зур, акча янчыгың калынрак булган саен юлың кинрәк,

сулышын иркенрәк, карашын кыюрак була. Бу «ышанычлы иптәшләр» белән барча ишекләрне дә аяк тибеп ача аласың. Мин моны Әндижанга килеп төшкәч тә аңлаган идем.

Автовокзал кассасыннан билет алдым да, рейсны игълан итүләрен бер гамьсез көтеп утырам. Кузгалыр вакыт житте, тик белдерү-фәлән биргәннәре ишетелми. Аптырагач, урамга чыгып, үземә кирәкле автобусны эзли башладым. Карасам, бу инде кузгалып китеп тә бара. Кулымны селти-селти, билетымны күрсәтеп, туктаттым моны, этелә-төртелә кердем. Автобус тулы халык. Минем урында башына чуклы-чуклы чуар яулык бәйләгән, түгәрәк йөзе кояшта янып-каралып беткән бер үзбәкме, кыргызмы апае киерелеп утыра.

И-и, беркатлы авыл баласы, телемне әрәм итеп әйткән булам бит әле, имеш, ялгыш утыргансыз. Сүземне дәлилләп:

—Минем урын бит бу,—дип билетымны күрсәткән булам...

Керфеген дә селкетмәде апай. Юл хакын шоферның үз кулына тоттырмыйча, кассага (хөкүмәткә!) түләү бер дә килешә торган эш түгел икән монда, кеше рәнжетү була икән...

Ләкин мине аңлаучы, яклаучы табылды:

—Нәрсә тел әрәм итеп торасың бу тискәре ишәккә?! Билетың кулыңда лабаса. Куып төшер дә менеп утыр үз урыныңа! Аларны башкача җиңеп булмый. Туйган инде мондагы аңгыра халыктан, сарык көтүе белән бер алар!

Җирән чәчле, мунчала кашлы бер ир әйтте моны. Аның тупаслыгына хәтта мин шаккаттым. Ә кыргыз хатыны тәрәзәгә карап тыныч кына утыруында булды. Әллә ишетмәде, әллә аңламады. Әллә ишетеп тә аңларга теләмәде...

—Күренеп тора, Россиядән килгәнсең. Яңа кеше мондагы тәртипләрне белми әле. Ә мин егерме ел шул кыргыйлар арасында чиләнәм инде. Дәшмәсәң, башыңа менеп утыралар. Татардан да яман халык.

Шул сүзе белән пычаксыз суйды да куйды. Утлы табага төшкән су тамчысыдай куырылып-сискәнеп киттем. Кара ни ди бит, татарлар яман булып нишләгән әле, безнең халыкның моңа ни зыяны тигән? Бу бәндәгә бик нык ачуым килде. Бер сүзне күпме чәйнәргә була инде? Ә ул дәшмәвемне килешү дип уйлады бугай, бөтен салонны яңгыратып сукрануын дәвам итте:

—Урыс килеп күзен ачмаса, ишәк кебек шыр томана булып, хәерчелектә яшиселәр иде. Заводлар төзедек, укыттык, эшкә өйрәттек, кеше иттек тә үзләрен, хәзер кәпрәеп йөриләр. Яхшылыкны аңлый торган халык түгел болар. Кара син бу чурканы, атасын үтергәнмени, рәхмәт әйтәсе урынга, кан дошманы күреп акая. Юри идиот булып кылана алар. Яши-яши күрерсең әле үзең дә, үзегенә үтәрләр. Җибеп торма, куып төшер бу чүпрәк башны урыныннан!

Минем гауга оештырасым килмәде. Үз өемдә түгел лә, мин монда кунак кына. Кунак икәнсең, тыйнак бул, хуҗаларны хөрмәт ит. Шуңа күрә, җирән чәчнең өзми-куймый мыгырдавына, бер кирәксез җәнҗалга тизрәк нокта куярга теләп:

—Утырсын, олы кеше бит. Ә мин басып та барырмын. Ерак ара түгел, түзәрбез,—дидем.

Ләкин абзый тынычланмады, үз сүзе аста калганга гарьләнеп, агулы угын миңа күчерде. Мыскыллы тавыш белән:

—Башка җирдә телең озын бугай, матур чыраеңа фингалны юкка гына утыртмаганнардыр,—дип бәйләнергә тотынды.

Шулчак безнең «күңелле» әңгәмәгә салонның алгы ягыннан яңа тавыш кушылды:

—Житте инде сиңа, Аркаша! Һәр көнне бер балык башы. Кем сине монда чакырып китергән?! Ошамаса, кит тә бар, кем тота? Ачудан буылып, инфаркт белән егылмагаең.

Ни хикмәт, Аркаша абзый әлеге ирнең сүзенә бик тиз буйсынып, башка дәшмәде. Мин аның эчпошыргыч тавышыннан котылуыма сөенеп, тәрәзәгә борылып бастым да, юл буйларын күзәтеп бара башладым.

***

Минем Майлысуга беренче килүем түгел. Бер җәйдә Фатыйма апа безгә кайткач, үгетли-үгетли әниемне кунакка алып киткән иде. Әни мине дә үзе белән ияртте. Тик ул чакта әле бик бәләкәй идем, шуңа күрә яхшылап хәтерләмим дә. Харап биек таулар, бер-берсенә игезәктәй охшаган матур ак йортлар, тигез урамнар һәм чияләр, бик күп чияләр истә калган. Мин аларны ак чәчәкләр түшерелгән кечкенә чиләгемә тутыра идем дә, шуны үземнән калдырмый, көне буе ашап йөри идем...

Фатыйма апа сөйләгәнчә, ак матур йортларны иң башта немецлар салган икән. Бу халыкны сугыш вакытында Идел буеннан Урта Азиягә сөргәннәр. Немецлар бик пөхтә, тырыш халык, монда да югалып калмаган, җиң сызганып өр-яңадан тормыш корып җибәргәннәр. Алардан күреп урыслар, татарлар да нәкъ шундый уңайлы җыйнак йортлар сала башлаган. Әгәр тау башына,—юк, тау башына ук түгел, анда менүләре ай-һай...—әгәр өскәрәк, биеккәрәк менеп карасаң, поселок макеттагы уенчык шәһәр булып күренер иде. Гөлбакча эчендә утыручы ак кала!

Әйе, кайчандыр, әниемә ияреп, мин бирегә кунакка килгән идем. Ә хәзер, үткәннәремнән качып, тормышымны өр-яңадан башлар өчен бөтенләйгә дип килүем. Туган җиремнән мине беркем кумады, кумаса да, ирекле көннән аны ташлап, җиде ят җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булдым.

Мине күргәч, Фатыйма апа бер мәл һушсыз торды, аннары авызын зур ачып:

—Ә-ә?!—диде.

—Ә-ә шул...—дидем мин, бу хәлгә үзем дә бик аптыраган сыман. Тагы ни диим инде? Бердән, чакырылмаган-көтелмәгән кунак, икенчедән, йөземә карарлык түгел.

—Әстәгъфирулла! Наргизә! Синме соң бу, әллә күземә генә күренәсеңме?!

—Мин... Исәнме, Фатыйма апа...

—Киләсеңне ник хәбәр итмәдең? Приступ була язды бит. И-и, могҗиза диген, кил әле бер кочаклыйм үзеңне, ни гомер күргән юк! Ярый әле өйдә чагым туры килде. Ләбиб дусларына мунча салышырга киткән иде, Әнәс эштә. Капка төбендә аптырап басып торыр идең.

Фатыйма апа үз күзенә үзе ышанмагандай үрелеп-сузылып миңа карый:

—И Ходаем, нишләдең син, сеңлем?! Йөзеңә карарлык түгел. Ни булды, кыйнамаганнардыр бит?

Мин алдадым, әлбәттә. Поездда барганда өске ятактан егылып төштем, дидем. Апа анысына әллә ышанды, әллә ышанган булып кыланды гына, һәрхәлдә, бу турыда башка сүз кузгатмады.

Йөгерә-йөгерә чәй өлгертте, чәй янына әллә никадәр ризык тезде: үзе пешергән кекс-печеньелар, чебуриклар шунда, карбызы-кавыны... Минем ачыгу җиткән иде, кыстаганны да көтмичә, кабаланып ашарга керештем. Ә Фатыйма апа өстәлгә һаман тәм-том тезә. Үзе табын кора, үзе шул арада авыл хәлләрен сораша, ду китереп әтине сүгә:

—Кара син аны, азгын тәре, башта, башын-күзен тондырып чаба-чаба,

Гөлзадәне чиргә сабыштырып, гүргә кертте. Аннары, үлгәч, кабере дә суынмаган килеш, өйләнеп мыскыл итте. Чыдар әмәле калмаган икән чисти! Юньле адәм түгел инде, кырыгын үткәргәнче дә сабыры житмәде затсызның. Бу хурлыкка йөрәген янып, кара күмергә әйләнерсең. Ну үзем шунда булсам, артын кыздыра идем инде ул азгын иблиснең.

Фатыйма апа бөтенләй әнигә охшамаган, ул әрсез, усаллык-чаялыгы да бар. Әллә шундый булып туган, әллә читтә, жиде ят кеше арасында яшәп, усалланган-шомарганмы, әби әйтмешли, агулы энәләрен тырпайтырга гына тора. Үземнең дә әтигә мәхәббәтем ташып тормый торуын, шулай да Фатыйма апа авызыннан мондый зәһәр сүзләр ишетү бер дә рәхәт түгел. Ни дисәң дә, бердәнбер әтием бит ул.

Ләкин Фатыйма апаның әтигә карата ачу-нәфрәтле булуы ярап та куйды. Куркып-шикләнеп кенә:

—Мин бит кунакка түгел, Фатыйма апа... бөтенләйгә килдем,—дигән идем, йөзе яктырап китте:

—Бик дөрес эшләгәнсең, сеңлем! Ул аждаһалар янында кан елап ятканчы... Гөлзадәне дә әллә кайчан кайтып аласым калган. Рәхәтләнеп яшәр иде мескенкәем...

Фатыйма апаның күзләренә яшь тулды. Ул аларга рәхәтләнеп тамарга ирек бирми, кул аркасы белән сыпырып та алды. Болай да тулып ташкан күңелне тагы да нечкәртәсе килмәде, сүзне тизрәк башкага бордым:

—Жизни ни дияр икән, Фатыйма апа? Ачуланмасмы?

—И-и, аңа! Ике дөнья бер кәнди! Сине түгел, мине дә күрми әле ул. Әтиең монда киткәнеңне беләме соң?

—Юк...

—Әйтмичә дөрес эшләгәнсең.

Аның сүзеннән эчемә жылы керде. Минем теләктәшем, яклаучым бар!

—Фатыйма апа, монда икәнемне син дә әйтмәссең, яме. Әти барыбер эзләр инде ул. Бәлки хат та язар.

—Язсын! Алар белән кем сөйләшкән әле! Тик ятсыннар шунда ут йотып. Мидхәт тә хәсрәтләнсен әле бер. Артык рәхәт яшәмәкче була. Яшь хатын алдым дигәч тә... Син кайгырма, сеңлем, эшен дә жайларбыз, яхшы кияү дә табарбыз үзеңә. Монда шәп егетләр күп, кәләшләр генә житми. Кыз эзләп Рәсәйне айкап кайталар. Менә дигән татар егете белән таныштырам мин сине.

Шулай итеп мин ышанычлы кулга эләктем. Бер атна дигәндә Фатыйма апа, барысын жайлап-майлап, мине балалар бакчасына тәрбияче итеп эшкә дә урнаштырды.

***

—Әйдә, Наргизә, без синең белән бүген кунакка барыйк әле. Югыйсә күземне ачырмыйлар, очраган берсе, ник кареңдәшеңне бездән яшереп ятасың, диләр. Уллары буй житкән хатыннар килен рәхәтенә тиенмәкче булып мәш килә. Барысына да татар кызы кирәк.

—Әллә берәрсе белән таныштырмакчы буласыңмы?—дип сорадым куркып. Егет затыннан беркемне күрәсем килми, ераграк йөрсеннәр берүк. Ул халыктан жаным бизде. Кияүгә чыгарга атлыгып торган кеше юк әле монда.

—Өметләнмә дә! Таныштырмыйм да, берсенә дә бирмим дә сине, туганым! Бик рәхәт әле бергә. Бөтен эшемне эшләп торасың. Ике ир-ат карап хәлдән тая идем, син килгәч, рәхәткә чыктым. Әнәскә генә алып куярбыз әле үзеңне. Монда андый никахлар рөхсәт ителә. Әтиләре бертуган булса гына ярамый, әниләре карендәш булса, куркыныч түгел. Шундый

гаиләләр беләм мин. Үзләре туганнан туган, үзләре ир белән хатын. Балалары да сау-сәламәт. Валлаһи менә!

Үземне Әнәс кочагында күз алдыма китереп, чирканып киттем. Шул гына житмәгән иде, үз туганына кияүгә чык, имеш. Бергә яшәгән белән түгел, аны кочаклап ятасы да бар бит әле... Оялмыйча! Юктыр, мин башка беркемне ярата да, якын итә дә алмамдыр, ахры. Тәки шулай ялгыз яшәрмендер, мөгаен. Кунакка да барасым килми.

—Үзең генә бар әле, апа.

—Юк, алай булмый, туганым. Рәшидәләрдә аулак өй бүген. Ире санаторийга китте. Шикләнмә, анда хатыннар гына була. Монда гадәт шундый: ирләр, хатыннар мәжлесе аерым-аерым үткәрелә.

—Шикләнмим, барасым килми, шул гына.

—Үзебезнең яктан килгән һәр яңа кеше алтын бәясе монда. Туган як хәлләрен беләсе килә бит. Яхшы булса да торган жир, сагындыра туган ил, дип жырлыйлармы әле? Укаң коелмас, барырга кирәк. Аларның сине күрәсе килә.

—Башка вакытта барырмын, бүген түгел,—дип күпме карышсам да, тәки ияртте.

Фатыйма апаларныкы кебек үк ак балчык йортка килдек. Тәрәзәдән күреп торганмы, каршыбызга хужа апа килеп чыкты. Татар димәссең дә, табак битле, каратут йөзле, жәенке борынлы, кысык кара күзле. Бик ягымлы үзе, тәмле телле:

—И-и, Фатыйма бәгырь, шундыен да күркәм кызны яшереп тотарсың икән! Урларлар дип куркасыңдыр инде. Сөбханалла! Шундыен да ак чырайлы матур кызлар булыр икән! Монда барыбыз да нигырга әйләнеп беткәниек. Кер, кер, багалмам, ятсынма, төкле аягың белән үтәең. Сөбханалла! Улкаем булса, үз киләшем итәр ием лә сон, улкаем юк шул...—дип көйли-көйли каршы алды.

Кунак бүлмәсенә үттек. Биредә салкынча һәм караңгы. Ике як диварда да—зур затлы келәмнәр. Тәрәзәләргә—кояш нурлары, эссе үтеп кермәсен өчен калын бәрхет пәрдәләр эленгән. Бүлмә уртасында төрле сый белән тулган түгәрәк өстәл. Йомшак диван-кәнәфиләрдә берничә хатын-кыз иплләп кенә сөйләшеп утыра. Яшьләр юк, барысы да Фатыйма апа чамасындагы халык. Ялтыравык купшы бизәкләр төшерелгән яулыкларын артка чөеп бәйләгәннәр, өсләрендә, эссе булуга карамастан, озын жиңле күлмәкләр.

Рәшидә апа, йомшак кына инемнән төртеп, кунакларына дәште:

—Менә сезгә иң зур, иң кадерле күчтәнәч, бәгырькәйләрем! Туган якның саф жилләрен, кардәшләрнең кайнар сәламнәрен алып килгән. Күрдем дә үзен, таң калдым, матур да соң безнең татар кызлары, үтә матур!

Әллә ничә пар күз берьюлы минем тарафка юнәлде.

—Исәнмесез...—дидем оялып кына. Ят карашлардан тизрәк качарга теләп диванга сендем.

—Киләсе кунакларым килеп житте, әйдәгез, табынга сыеныгыз,—диде хужа апа.

Минем дә аш үткәргәнем бар. Юк ла инде, үзем генә түгел, әни белән. Мәжлес жыйган көнне ул мине беркая жибәрми иде. «Кул астында бул әле, кирәгең чыгуы бар»,—дип гел янында тота иде. Харап жаваплы эш ул аш үткәрү. Бездә табын патшасы—бәлеш, ансыз бер мәжлес тә үтми. Ите йә бәрәңгесе пешмәсә, камыры көеп китсә, яме бетә, битең пешә инде. Әни мескенкәем аш үткәргәндә шул бәлешләре өчен үзе дә яна-көя иде. Мич янына кырык тапкыр килеп әйләнә. Табынга чыгарып, капкачын ачкач кына: «Аллага шөкер, йөз кызартырлык түгел, бәлешем унган»,—диеп жиңел сулап куя иде.

Монда бәлеш пешермиләр икән. Чөнки бәрәңге кытлыгы. Ит исә ниндиен телисең шунысы бар. Карбыз-кавын, җиләк-җимеш тә тулып ята, ә менә бәрәңге юк. Булганы да күгәрчен күкәе зурлыгында гына. Шуна күрә мантыйны ит белән суганнан гына пешерәләр. Бәрәңге урынына кайчакта кабак турап салалар.

Бәлеш урынына монда пылау чыга. Үзбәк пылавы безнекенә охшамаган, итне ваклап түгел, зур итеп турыйлар. Аны дөге белән бергә бутамыйча, пылау өстенә кисәк-кисәк килеш тезеп куялар. Пылауны мамык маенда пешерәләр. Мин башта бик гаҗәпләнгән идем: мамыкның нинди мае булсын? Була икән. Бик файдалы һәм искиткеч тәмле май. Ул пылауга аерым, үзгә тәм бирә икән. Пылау һәр кешегә аерым бүлеп бирелми, зур таба хәтле сай тәлинкә белән табын уртасына куела.

Кара чәй урынына күбесе яшелне эчә. Чөнки ул тирләтми, сусауны баса. Мондагы татарлар да үзбәк-кыргызның яшәү рәвешен, йола-гадәтләрен алган. Кеше климатны түгел, климат кешене үзенә яраклаштыра.

Табындагы ризыкларны, хуҗабикәне мактый-мактый ашап-эчкәч, бөтен игътибар мина күчте. Башта Фатыйма ападан гына сораштылар, аннары үземне сорауга күмделәр:

—Безнен якларда ни хәлләр бар?

—Янгырлар вакытында яудымы?

—Печән әзерли алдыгызмы? Яшелчәләр үндымы?

—Көтү йөриме, көтүчегез бармы?

—Авылда яшьләр каламы? Акча яхшы түлиләрме?

—Суны каян аласыз, коеданмы, чишмәдәнме?

—Урып-җыю башландымы? Быел игеннәр ничек? Колхозыгызда комбайннар җитәрлекме?

Үләм дип торам. Каян белим мин боларны?! Авылга кайтканым бармы? Ярый әле Фатыйма апа ярдәмгә килде, минем өчен, белсә дә, белмәсә дә, ул җавап биреп утырды. Тисә тиде, тимәсә юк, кем барып тикшерә? Бу хатыннарга болар ниемә кирәк?! Нәрсә дип кеше башы катыралар? Көчкә түзеп утырдым, тизрәк чыгып ычкынасы иде моннан, ник кенә килдем.

Сүзгә сүз ялганып, беразга мине онытып тордылар.

—Инәй исән чакта авылга ел саен кайта идем,—дип сөйләп китте минем каршыда утырган озынча йөзле, очлы иякле апа.—И-и бездәге җәйләр! Әкият бит ул! Яшенле янгырларны үлеп ярата идем. Кешеләр куркып кача, ә мин, исәр, урамга чыгып басам. Инәй артымнан чыга, кер, йә яшен сугар, ди. Курыккан кешене генә суга ул. Манма суга батып керә идем. Янгырдан соң һаваның тәмлелеге! Җиләк исләре килә иде. Бал урынына ипигә ягып ашарлык. Сагынып үләм инде авыл җәйләрен.

—Җәе генәме соң, кышын әйт син, бөтен дөнья акка күмелә. Кар ашап тамак туя иде,—дип кушылды аның кырындагы хатын.

—Сездә кар яумыймыни?—дип сорадым мин.

—Ява да, шундук эреп тә бетә, күрергә дә өлгермисең. Тау башларында гына ел буе ята. Анда кем менгән? Кәҗәләр дә менеп җитәлми әле.

—Менәр иде дә, тау башында кардан башка җен дә юк. Кәҗәгә аңа матурлык кирәкмени, чәйнәр азык кына булсын.

—Тау дигәннән, бер кызык сөйлим әле сезгә,—дип сүзгә кушылды әлегәчә дәшми утырган зәңгәр күзле, саргылт чәчле бер апа.—Безнекеләрне эшкә йөртүче шофер Никулай кызык иткән бит боларны. Шулай кайтып барганда автобусын туктаткан да, капчыгын күтәреп, тау башына менеп киткән. Кая барасың, дигәннәр. Бу әйткән, алма җыярга, дигән. И көләләр икән моннан. Тау башында нинди алма, янәсе. Карасалар, теге тулы капчык белән төшеп тә килә икән, малакаем! Ышанмаганнар, ачып караганнар.

Валлаһи, алма икән, иллә кызыл, иллә эре алмалар. Моннан гына күренми, анда алма күп, ди икән Никулай. Икенче көнне болар да капчык белән алма җыярга менеп киткәннәр...

—Җыйганнармы соң?

—Җыйган ди сиңа, тот капчыгыңны! Нинди алма булсын ди анда? Кәкре каенга terәткән Никулай боларны. Икенче Хуҗа Насретдин! Төнлә тау башына алмалар меңгереп куйган да, икенче көнне шуны алып та төшкән.

—И-и, иренмәс җан икән. Кеше шаккаттырам дип тау башында үрмәләп йөрмәсә, башка эше беткәнме.

—Ирләр гомергә бала-чага бит алар. Безнең исәрләр дә, менә ышанып, тау башында алма эзләп йөргәннәр.

—Ату үзегездә юк!?

—Үзеңнеке тәмле булмый ул, бушка килгәне тәмлерәк.

—Никулайдан булыр. Көн саен берәр мәзәк чыгарып тора. Былтыр алдау көнендә ярты Майлысуны чиратта тотты бит. Иртәнге сәгать дүрттә үк кибет янына килеп баскан икән бу. Моны тәрәзәсеннән күреп бер карчык чыккан, нәрсә китерделәр, ни саталар бүген, ди икән. Комбикорма, дигән Никулай. Үзе киткән дә барган. Карчык кибет төбен саклап калган. Фая килгәндә кибете янында бер көтү халык көтеп тора икән. Егылып китә язган мескен.

—Мин дә бар идем анда, чынлап торып ышандык шул. Малларны ашатырга кирәк бит.

Фатыйма апалар гына түгел, монда үз хуҗалыгы белән яшәүчеләрнең күбесе куян-сарык, дуңгыз, хәтта сыер да асрый. Шуңа күрә биредә ит кытлыгы юк, базар тулы. Хакы да арзан, ит-колбасага бездәге кебек озын-озын чиратлар да күренми.

***

—Наргизә туганкай, берәр яңа җыр җырла әле. Безгә татар җырлары үтә дә тансык бит. Кыргыз, үзбәкнекен тыңлап туйган инде. Радиода да шул, телевизорда да шул... Җитмәсә урамда да көне-төне акырталар.

Судан коры чыккан идем, инде утка илтеп тыктылар. Таптылар шәп җырчыны! Мин бит татар җырларын белмим... Училищеда укыган чакта бию кичәләрендә гел урыс яки чит ил җырларын гына әйләндерә идек. Хәер, өйдә дә гел шулар, заманча көйләр яңгырады. Бормалы-сыгылмалы халык җырларын мәҗлесләрдә ишеткән бар барын. Өлкән яшьтәге абый-апалар гармунга кушылып бик моңлы итеп җырлыйлар иде. Ул җырлар миңа артык күңелсез, сагышлы булып тоела иде. Яшь күңел дәртле, җиңел көйләр сорый. Шуңамы, татар җырлары белән әллә ни дуслыгым юк. Хәер, белгән, яраткан, йөрәк түрендә йөрткән бер җыр—«Алтын алка» бар. Аны әни җырлый иде. Ул минем әниемнең җыры иде...

Бервакыт кызлар белән кич утырып кайтып килөм шулай. Җәй көне иде. Күктә бар дөньяны көмеш нурга күмеп тулы ай йөзә. Турыбызга җитәрәк, әни тавышын ишетеп, барган җиремнән кисәк туктап калдым. Шыпырт кына басып койма янына килдем. Карасам, әни бакчадагы таганга утырган да, тирбәлә-тирбәлә әкрен генә җырлый:

—Алтын алка сына диләр,  
Сынмый да бөгелми дә.  
Саф мәхәббәт сүнә диләр,  
Сүнми дә сүрелми дә.

Алтын алкаларым сынса,
Алырсың микән алка?
Булырсың микән үземә,
Калырсың микән ятка?

Әнинең ялгызлыктагы илаһи мизгелләрен өзәргә теләмичә, коймага сөялгән килеш тын гына басып тордым. Җырның көе генә түгел, сүзләре дә мине шул хәтле тетрәндерде, күнелем кылларына үзем дә анламаган бик тирән мон-сагышлар килеп уралды. Айлы төндә берьялгызы моңаеп утырган әнием шундый кызганыч булып китте. Янына килеп, аны кочып аласым, юатасым килде. Ләкин урынымнан кузгалмадым, кыенсындым. Ул чакта әле унике-унөч яшьлек бала гына, әнинең нигә шулай моңаюын аңлап та бетермәгәнмендер. Ләкин күнелем монда мин белмәгән ниндидер тирән сагыш, фажига ятуын барыбер сизде. Бу җыр миңа шул хәтле нык тәэсир итте ки, китаптан табып алып, аның сүзләрен көндәлегемә күчереп тә алдым әле. Әниемне югалтканнан соң тагы тынлыйсым килеп, телевизордан татар концертларын караштырсам да, ул җырны кабат ишетергә насыйп булмады...

Җыр белән бәйле тагы бер хатирә бар. Әтиемне туган көне белән котлап, дуслары радио аша җыр тапшырганнар иде. Сиңа нинди җыр ошый, дип әүвәл үзеннән сораганнар. Әти әйткән, Зөһрә Сәхәбиева җырлавын яратам, дигән. Сораулар буенча әзерләнгән ул концертны бергәләп тыңладык. Әтиемә багышлап «Әйткән идең» дигән җырны тапшырдылар... Аны Хәсән Туфан кадерле Луизасын югалткач язган икән. Ул җырда мондый сүзләр бар:

Юлыктым мин шундый бер чәчәккә,
Көтмәгәндә, уйламаганда.
Нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга...

Әнием аны тын да алмый тыңлады да, монсу гына: «Бик урынлы җыр булган бу...»—дип куйды. Әти ул чакта чынлап та бер «чәчәк»кә юлыккан булган икән. Тик, нишләргә сон дип, ул әни исән чакта ук баш ватып йөрде... Әни үлгәч исә аптырап, озак баш ватып тормады, барысы да бик тиз хәл ителде дә куйды...

Менә ул җырны, үч иткәндәй, бик еш тапшыралар. Бик матур, моңлы җыр үзе, ләкин аны ишеткән саен җан әрнүем янара, йөрәгем чәнчеп куя...

Әллә ни моңым булмаса да, Майлысу хатыннарына сер бирәсем килмичә, тамак кырып, «Алтын алка»ны башлап җибәрдем. Хәлемне аңладылар, миңа ярдәмгә килеп, әкрен генә башкалар да кушылды. Бергәләп тырышкач ярыйсы гына килеп чыкты.

—Маладис, иркәм, безнең яшьлек җырларын беләсең икән.

—Әни гел шуны җырлый иде, аннан өйрәнеп калдым.

—Урыны оҗмахта булсын мәрхүмәкәйнең, авыр туфраклары җинел булсын,—диеште хатыннар.

—Әй, яшь чакта иренми идек тә сон, ә Рәшидә? Хәтерлисеңме, синең белән Илһам Шакировны тыңларга Ташкентка кадәр барган идек? Тәки кердек бит, билетны кулдан мең бәягә алып булса да кердек.

—Элек җырчылар, артистлар килеп, күнелне юатып китә иде,—дип сүзне ялгап китте иягенә мин кунган апа.—Үзебезчә концертлар, театрлар карый идек. Бер елны Әндиҗанга Сара Садыйкова килгән иде. И аның

сөйкемлелеге, гел елмаеп кына тора. Безнең белән шундый гади итеп, үз итеп сөйләште.

—Кит аннан, шыттырасындыр ла! Нишләп синең белән сөйләшеп ваклансын ди ул?

—Валлаһи, чын әгәр, сөйләште! Концерттан соң картым белән янына барган идек, рәхмәт әйттек, тагын килегез, дидек. Шундый шатланды Сара апа.

—Элек шул ул! Ул чакта заманы да, кешеләре дә башка иде. Хәзер безнең якларда татар артистларының күренгәннәре дә юк. Без генә түгел, җырчылар да картая шул.

—Илһам һаман җырлый әле. Таһир гына күренми. Әллә кая югалды.

—Якуповмы? Эчә диләр бит аны.

—Эчмидер. Эчертәләрдер. Көнчеләр юри шулай эшли. Аныкы кебек тавыш беркемдә юк. Халык та яраткач, көнләшәләр.

—Казанга баргач, ул катнаша дип бер концертка кергән идем, сәхнәгә чыкмады. Афишага исемен язганнар, үзен чыгармадылар. Рәхәтләнеп «Олы юлның тузаны»н тыңлармын дигән идем. Шуны ишетсәм, тәгәрәпләр елыйм инде. Авыл да искә төшә, инәйләр дә.

«Олы юлның тузаны» дигәч, минем дә искә төште, ул җырны әби бик ярата, шуны тапшырсалар, радионы бар көченә ачып куя иде. Таһир Якупов җырлаган икән аны.

—Исәнме икән соң ул?

Бу сорау миңа төбәп бирелде. Белмәсәм дә чатнатып:

—Исән!—дидем.

Исән булуы хәерле.

Җырчылар турында фикер алышу дәвам итә:

—Ә мин Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхәбиеваны яратам. Икесе дә гөл кебек матурлар, ул тавышлары! Моң өстенә моң! Сандугачлар кебек сайрашып кына яшиләрдер алар.

—Зөһрә һөнәре буенча врач икән ул,—дип горурланып сүзгә кушыла Фатыйма апа.

—Эшли дәмени ул? Кит аннан, аларны да эшләтсәләр! Җырларга ничек вакыт тапсын ди аннары?! Андый талантлы кешеләрне уч төбендә биетеп, кадерләп-саклап кына йөртәсе.

—Хәзер яңа җырчылар чыга инде. Былтыр авылга кайткач, Фирзәр Мортазин дигән бер яшь җырчыны тыңлаган идем, күңелемә бик хуш килде. Үзенә бер төсле җырлый, тавышы җанга ята. Кассетасын монда да алып кайттым әле. Эч пошкан саен шуны тыңлыйм хәзер. Сүзләре дә бик мәгънәле. Шигырьләрен хатыны яза икән.

—Ник монда алып килмәдең, без дә тыңлар идек.

—Бәй, оныттыгызмыни? Маһинурның туган көненә алып барган идем, бергәләп тыңладык ич!

—Теге... ничек әле... «Бәрәңге чәчәге» җырлаучы егетме?

—Шул-шул, тач үзе инде. «Ага чишмә» дигән бик матур җыры бар:

Юлларга чыгам икән,
Уйларга чумам икән.
Карыйм, карыйм, һич табалмыйм,
Еракта томан икән.

—И-и, гел безнең турында җырлый икән бу егет. Әллә үзе дә читтә интегәме? Әй, үтте инде гомерләр... Яшәве бер хәл, шул җиде ят җирдә ятып та каласы бар бит, туганнар... Каберенне дә эзләп табалмаслар...

—Кабереңне эзләп килер кешең бармы? Өзелгән инде без туган жирдән. Шунда төпләнгән, тамыр жәйгән инде, Оркыя. Балалар да шунда үсте. Еласаң да юк, жырласаң да юк хәзер...

Кунактан мин авыр уйлар белән кайттым. Гомерләре читтә үткән апаларның өзми-куймый туган як турында сөйләшүләре, шул хәтле сагынулары мине таң калдырды. Монда яшәү күпкә кызыграк, жинелрәк кебек югыйсә. Көзен дә, кышын да жылы, кибетләрдә жаның ни тели—шул бар. Жиләк-жимеш арзан. Бай, житеш тормыш.

Әлмәттә хәтерлим әле, азык-төлек кибете киштәләрендә рәт-рәт балык консервлары гына тора иде. Май, колбасаише әйберләрне талонга гына бирәләр. Кибеттә ипи-сөт алып торганда, кайдандыр кайткан бер абзый мыскыл итеп:

—В России нищета, с голоду помрешь,—дигән иде.

Ә монда бит ожмах! Белеп сагынулары түгелдер. Йә андагы хәлләрне белмиләрдер.

Фатыйма апага шулай дигәч, ул баш чайкады:

—Әй, туганым, кешедә тамак кайгысы гына түгел бит. Жан дигәнең барыбер кендек каны тамган жиргә тарта.

—Алай сагынып булгач, ни дип киткәннәр соң? Артларыннан куучы булмагандыр ла...

—Булгандыр да шул... Анысын без белмибез инде. Кемдер үз ирегә белән чыгып киткән, кемдер аптыраганнан, жан саклап... Әллә нинди заманнар булды бит, сеңлем, сөйләргә генә ярамый.

—Мин дә шулай сагынырмын микән, Фатыйма апа?

—Яшь вакытта әллә ни сизелми әле ул. Олыгайган саен күңел нечкәрә, сагыш баса бара.

—Алайса, ник күчеп кайтмыйсыз?

—Жиңел уйлыйсың син, сеңлем! Кайда, кем көтә безне? Тормышны әр-яңадан башларга кирәк.

Миңа куркыныч булып китә. Әгәр монда төпләнеп калсам, аннары туган якны сагына башласам, аннары кайта алмасам...

Монсу уйларымны Фатыйма апаның көр тавышы бүлде:

—Шәп сыйладылар, әйеме? Хәзер бер атна ашамый торсаң да була. Рәшидә ашханәдә эшли, аш-суга бик оста. Шуны да белеп тор, туганым, сине бик ошаттылар. Яучылар килә башлавы да бар.

—Үзең Әнәскә алам дидең, үзең тизрәк аткармакчы буласың...

—Сине кияүгә бирергә жыенган кеше юк ла. Килсеннәр, ялынсыннар. Яучы килгән кызларның бәясе күтәрелә.

—Фатыйма апа, әллә калым түләтмәкче буласыңмы?

—Татарга бушка да бирербез. Үзебезнең егетләргә жәл түгел. Ну үзбәк-кыргыз белән бәйләнсәң, калымны каерып алабыз. Аларга тагын жиләк кебек кызны бушка тоттырам ди!

—Бушка алучылар табылыр анысы. Тик ансат килгәннең кадерен белүче генә булмас,—дип шаяртам мин.

—Карале, туганкаем, дөрес әйтәсең бит син! Хатын-кыз гомер буе ир-ат ялчысы ләбаса. Хөкүмәткә дә эшли, тыз-быз өендә дә чаба. Чит илдә савыт юып, өй жыештырып киткән өчен дә уч тутырып акча түлиләр икән. Элек безнең байлар да хезмәтче тоткан, бичәләре көзге каршында бизәнеп кенә утырган. Хәзер тигезлек, рәхәткә чыктык, ирләрне дә уздырып чабабыз...—Фатыйма апа үз-үзен үртәгәндәй кинаяле көлеп куя.—Ә үзбәк хатыннары хөкүмәткә эшләми, бер көтү бала-чага үрчетеп, өендә генә утыра.

—Алайса, мин үзбәк егетләренә якын да бармыйм. Кирәкләре бер тиен! Әзер хезмәтче булып, өйдә бикләнеп ятасым юк әле.

—И туганым, алай кистереп әйтмә, Алла сакласын, күрәчәгем булмасын дин. Сөйгәнең бака булса, сазлык туган йортына әйләнер ди.

Анысы хак, мин инде сазлык белән исәпләшеп торучылардан түгел. Яратсаммы?! Сөйгәнем артыннан төпсез коега да сикерергә әзер.

***

Ләбиб җизни дә минем тиз генә китәргә җыенмаганны аңлады бугай. Безгә бик кысылмый, гел үз эше белән мәшгуль булып йөри иде, беркөнне бераз салып кайткач, «по душам» сөйләшергә керешге:

—Син ничава кыз үзең, ну бажайны абижат иткәнсең. Качып киттең шту ли? Мидхәт шәп кеше ул, во парин! Түлке килмәде бит безгә. Туган була торып, хатынының сеңлесенә бит... Син уйлап кара, бажасына бит! Шту син... Бажасына! Ник бер тапкыр килсен. Күпме чакырдым, юк, килмәде. Мин, нәрсә, хәерче шту ли? Шәп итеп кунак итә алмыйм шту ли? Ерак шул инде, бажайга үпкәләп булмый. Яхшы кеше ул, ну шахтер түгел, нәчәлник. Нишли соң ул нәчәлник? Әйт, нишли синең әтиең?

Мин җизнигә ни дип җавап бирергә дә аптырадым. Чынлап та, нишли соң минем әтием? Җир сөрми, чөгендер эшкәртми, печән чапмый... Тик иртә таңнан ук эшкә дип чыгып китә, караңгы төшкәч кенә кайта, ниндидер җыелыш-киңәшмәләргә йөри, хезмәт хакы ала... Җизнәй сорамаса, бу турыда уйларга башыма да килмәс иде. Үземә дә сәер булып китте, минем әти берни эшләмәгән өчен акча ала микәнни... Парторг дигән һөнәр бармы соң ул дөньяда?

—Син монда калам дисең инде... Калсаң кал инде. Менә мин дә калдым.

—Җизни, ә сез Майлысуга ничек килеп чыктыгыз?

Җизнәм, бәйләнмәле, дигән сыман кул селтәде:

—Сөйләп бетерә торган түгел, иркәм. Кеше гомере бит ул... Һай, озын кыйсса...

—Сөйлә инде, җизнәй, кызык бит.

—Кызык түгел... Бер дә кызык түгел, иркәм. Шулай да айныгач, мужы бит сөйләрмен.

—Айнык чакта син минем белән сөйләшмисең дә әле.

—Шулаймыни? Кара син аны...

Җизнәй кырлы стаканына тагын аракы салды.

—Начар нәрсә бу. Ну ансыз да кызык түгел.—Шулай диде дә йөзен чытып күтәреп тә куйды.

—Сөйлә дисең инде... Вәт бит ә, нинди ул гомер дигәнең... Менә... у-у-у... Валлаһи, акиан! Ну түлке сөйли башласаң, учка сыя да бетә... Булмаган да кебек. Беләсеңме, иркәм, кеше гомереннән нәрсә кала?

—Беләм. Кабер кала.

—Анысы сама сабуй... Сызык кала, иркәм! Вәт! Менә бар син каберлеккә, ташларга кара. Нәрсә язган анда? Фәлән елда туган, фәлән елда үлгән. Уртада... кечтеки генә сызык. Кечтеки генә... Яшәгән көннәре шул сызык кына. Вут так. Бик җәлке. Әти дә юк, әни дә... И-и, алар күргәннәр...

Җизнәйнең күңеле йомшарып китте, сөремгә буялгандай кара кытыршы куллары белән күзеннән атылып чыккан яшьләрен сөртеп алды.

—Наргизә!

Мине Фатыйма апа чакырып алды:

—Зинһар, йөдәтмә Ләбибне, югыйсә ярсып китә дә, төне буе борчый. Миңа бәйләнә башлый. Кирәк булса, үзем сөйләп бирермен. Янында кеше булмаса, шулай утыра-утыра да йоклап китә ул. Тизрәк сүнсен иде инде.

Йокларга иртәрәк булса да, мин үз бүлмәмә кереп яттым. Ни йокламаган,

ни эшләмәгән, дөресе, кул кушырып тик утырган кешене уй баса. Мин яна тормышым турында уйланып яттым. Килүемә бернична ай гына булса да, бу шәһәр турында байтак беләм икән. Аның исеме кызык: Майлысу. Гел татар сүзе инде. Шулай дип кыргызлар кушкан югыйсә. Тау итәгеннән агучы елгада кара май таплары булганга яна төзелгән шәһәргә дә шул елга исемен кушканнар. Ә моннан ерак түгел, таулар арасында Сарбия бистәсе бар. Анда элек болыннар булган, шунда көтүләре белән сары бияләр йөргән. Поселок төзелгәч, кыргызлар аны Сары бия дип атаганнар, тора-тора ул исем Сарбиягә әйләнгән. Кешеләрнең генә түгел, шәһәр-авылларның да үткәне, үз тарихы бар.

Безнең бакчада Вера исемле бер апа эшли. Урам да себерә, төнге каравылда да тора. Шунда эшли дә, яши дә. Язмышы бик катлаулы аның. Әти-әнисен иртә югалтып, бала чакта ук угрылар арасына кереп киткән дә, төрмәгә килеп эләккән ул. Сталин үлгәннән соң, аның кебекләргә амнистия игълан итәләр. Чыгаралар моны төрмәдән, чыккач, капка төбендә үз ишләре белән аптырап басып тора икән: инде нишләргә, кая барырга? Күбесенең туган йорты, барып сыеныр почмагы юк. Шунда берсе киңәш бирә:

—Майлысуга барыгыз, анда хатынсыз тилмерүче ирләр буа буарлык.

Шулай итеп, болар Майлысуга юнәлә. Ә тегендә ябык зона, тикшереп, пропускы белән генә кертәләр. Хатыннар караңгы төшкәнне көтеп тора да су буйлатып кача-поса бистәгә керәләр. Шул вакыт ашханә турысына вахта автобусы килеп туктый, шуннан бер көтү буйдак ир коела. Ашыгыр җирләре юк, өйдә хатын, бала-чага көтми. Болар эштән кайтышлый гел шул ашханәгә кереп, сыра эчеп, күңел ачып утыралар икән. Төрмәдән чыккан хатыннар да алар артыннан ияреп керә. Шуннан һәркайсы парлы булып чыккан, имеш. Әллә чынлап шулай булган, әллә халык теленә кереп калган бер матур әкият кенә бу, белмим. Ни ишеттем—шуны сөйлим, күпмегә алсам—шул бәягә сатам...

Ләкин Вера апаның бәхете озын гомерле булмаган, ире тау эчендә югалган, ни тере, ни үле гәүдәсен тапмаганнар. Үзе сөйләп торды: алар харап яратышып, бер-берсен кадерләп яшәгән. Тик балалары булмаган. Ә Вера апа бала-чага дигәндә үлеп китә инде, берәрсен сөя башласа, кочагыннан көчкә каерып алабыз, ирек бирсәң, сытып бетерер иде, валлаһи.

Безнең мөдиребез немец хатыны. Алар элек Саратов шәһәрендә яшәгәннәр. Сугыш башлангач, гаиләләре белән Урта Азиягә сөреләләр. Эльза Фридриховнаның әтисе гомере буе шахтада инженер булып эшләгән. Немецларның әсирлеккә эләгеп килүчеләре дә бар. Уран рудасы чыгарырга эшчеләр кирәк булгач, бик күп әсирләрне бирегә төяп киләләр, алар башта землянкаларда яши. Тимерчыбык белән уратылган чып-чын лагерь була ул. Анда болай гына кереп-чыгып йөрергә ярамаган. Хәрби сакчылар этләр белән күзәтеп-саклап торган. Аннары ул әсирләрнең күбесе, үз илләренә кайтып китмичә, биредә төпләнеп калган. Тора-бара лагерьны сүткәннәр, хәзер инде аның эзе дә юк. Нинди генә халык җыелмаган Майлысуда. Хәтта кытайлар, кореялылар да бар. Һәр милләт үзләренчә аралашып, үз гадәт-йолаларын сакларга тырышып, берләшеп яши. Биредә беркайчан да ызгыш-талаш булмаган, чөнки Майлысуны бергәләп төзегәннәр, үзләренең уртак йортлары иткәннәр...

... Икенче көнне җизни ап-айнык килеш яныма килде дә:

—Наргизә, исерек булсам да, хәтерлим, син кичәгенәк миннән, ничек монда килеп чыктыгыз, дип сорашып утырган идең. Тыңлаучы барында сөйлим әле шуны. Моңарчы минем язмыш белән кызыксынган кеше булмады. Бәлки газетка язып чыгарсың.

—Мин язучы түгел лә...

Җизнәм аркамнан кагып:

—Язмасаң, сөйләрсең. Оныкларыма сөйләрсен,—диде.

Кулга ручка, кәгазь алып җизнәм каршына килеп утырдым.

—Язарга булдыңмыни?—дип сорады ул.

—Язып куймасам, онытырмын дип куркам.

—Картайгач, хәтернең рәте калмый шул,—дип гөрелдәп көлеп куйды җизнәй.

Шулай итеп, минем тырышлык белән бу дөньяда яшәүче гап-гади бер кешенең тормыш юлы турында ташка язып куелды. Ташка түгел, әлбәттә, агачка. Кәгазьне агачтан ясыйлар ди бит. Һәм ул тормыш юлы берничә биткә сыйды да бетте. Ярар инде, һәрхәлдә аркылы сызык кына булмас. Әнәснең, Рамиләнең балаларына, оныкларына бер истәлек булып калыр. Сырлап-матурлап, ап-ак кәгазгә күчереп тә куйдым мин аны. Барыбер әллә ни үрчемәде. Юк инде, миннән язучы чыкмый. Алар бит өч җөмләлек вакыйгадан да кирпеч калынлыгы роман язып куялар. Үзләреннән чыгарып өстиләрдер инде, гел чынын гына язсаң, кызык та булмас иде. Андый сәләтем булмагач, «роман»ым менә шундый гына булып чыкты:

«Минем әби-бабамнар гомер буе Юкәле авылында яшәгәннәр. Тормышлары таза, нык булган. Революция елларында әтиемне—анын исеме Мөбарәкша иде—солдат хезмәтенә алалар. Хезмәте тәмамлангач та ул авылга кайтып тормыйча Әстерхан шәһәренә барып урнаша. Чөнки безнен якларда бик хәтәр ачлык башлана. Әти бик тырыш, һәр эшкә оста кеше була. Елга портында эшли, пароходлар ремонтлый. Шунда әнием Зәйтүнә белән таныша, өйләнешеп бергә яши башлыйлар.

Авылда колхозлашу галәмәте башлангач, әби белән бабай да, Урта Азия якларына чыгып китә. Китәләр, чөнки авылда яшәргә рәт калмый. Җыен хәерче хуҗа анда, хәлле кешегә көн юк. Кеше байлыгын умырып талау башлана. Безнекеләрнең ике таш келәте, шәп йортлары булган. Барысын да тартып алалар... Йорт сугышка кадәр колхоз идарәсе булып торды, келәтләрне склад итәләр. Бер җәйне авылга кайткач карап йөрдем, ул келәтләр һаман урынында, таза, нык әле. Ни булсын аңа, таш бит, гомерлек итеп төзелгән. Шулай итеп, әби белән бабам, гомер буе җыйган малларын калдырып, ике төенчек күтәреп читкә чыгып китә. Бабай юлда чирләп үлә. Әбием Коканд шәһәрендә туктала, шундагы булнискә санитарка булып урнаша. Аннары курслар үтеп, медсестра булып эшли башлый. Ялгыз булса да куркып-югалып калмаган бит әбием, булдырган! Чөнки тамыр нык. Без бит, иркәм, керәшчеләр нәселеннән. Әбүзәр бабам заманында сабантуй батыры булып бөтен тирә-юньгә дан тоткан.

Менә шулай яшәп китә әби, үзбәк-кыргызны дәвалый башлый. Аннары әти белән әнине дә үз янына чакырта. Миңа ул чакта бары ике генә яшь була. Әти һөнәре буенча машинист-дизельче иде, аңа шундук эш табыла. Ә әни җылы одеяллар җитештерә торган фабрикага урнаша.

*Дәвамы киләсе санда*



Рәниф
Шәрипов

## ИКЕ ШИГЫРЬ

### Җыр

*Хезмәтеңә лаек соклануны ничек күрсәтергә,*
*болытларны туктатырлык итеп...*
Синь Цицзи (Кытай, 12 нче гасыр)

*Чишмәләр дә акмый тыңлады...*
«Рамай» (Татар халык җыры)

**«Ишеттем мин кичә», «чын безнеңчә»,**
**Син өздереп гармун уйнадың.**
**Нинди моңнар йөртте, кардәш дустым,**
**Эшләп каткан тупас кулларың.**
**«Башка килә төрле-төрле уйлар...**
**Әллә нинди моңлы, зарлы көй»:**
**Хафизәләм иркәм, ал Зәйнәбем,**
**Кара урман, Рәйхан, Әллүки.**
**Син уйнадың кичә. Мин уйладым**
**Яшь гомерем ничек узганын.**
**Чәчәкләргә кунды олы юлның**
**Без күтәргән кара тузаны.**
**«Бик еракта идек» әле без, әй,**
**«Бер алманы бишкә бүләек».**
**Донбассларда күмер кискән чакта,**
**Туган илне сагынып үләек.**
**Җитмеш чакрым ара үтеп килдек,**
**Оренбурдан мамык шәл алып.**
**«Ак калфакның табылган чагы» ла,**
**«Туганнарның сагынган чагы».**

«Бер күрешер өчен килдек без, әй,
Җитмеш чакрым якын җир түгел.»
«Кара да гынай урман, караңгы төн»,—
Моңлы көй уйнадың син бүген,
«Һаваларда йолдыз, суда кондыз,
Газизәкәй балдыз, елама.»—
Бик ерактан туганнарың килгән,
Син берүзең түгел дөньяда.
Әйдә, барыйк сахраларга бергә,
Гөлләр араларына, кардәшләр.
Әдрән диңгез аръягыннан, хәтта,
Сагынганнар килми калмаслар.
Безнең нәсел бик еракта калган,
Катлам саен аның катлавы.
Аргы яктан тагын берәү килә,
«Хафизәләм иркәм атлавы».
Гөлләр кебек сездәй матурларның
Тамырлары бер шул, Зәйнәбем.
Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем, бәгърем,
Рәхәт үтсен иде җәйләрең.
Фирдәвескәй, кара күзкәй, җаным,
Ай туганда әллә тудыңмы?
Кош тоткандай булам, ялгыш кына
Кулларыма алсам кулыңны.
Әллә кара карлыгачмы, әллә
Сары сандугачмы әнкәсе?
Башын борып бер караса миңа,
Чыңлап ала көмеш тәңкәсе.
«Шәмдәлләрдә генә утлар яна»,
Җиткән кыз да булды Гөлҗамал.
Кулларыннан киндер җеп үрелә,
Күзләреннән тамчы гөл тама.

Моңланып Ай нурларында кичә,
Син өздереп гармун уйнадың.
Нинди тылсым йөртте, әйтче, туган,
Кытыршы бу тупас кулларың?
Башка килә төрле-төрле уйлар,
Әллә нинди моңлы, зарлы көй.
Хафизәләм иркәм, ал Зәйнәбем,
Кара урман, Рәйхан, Әллүки.
Бик еракта без яшәдек шулай,
Бер алманы бишкә бүләек.
Кайда гына тир түкмәдек без, әй,
Туган якны сагынып үләек.
«Ак калфакның табылган чагы ла,
Туганнарның сагынган чагы».
Саубуллашып, бәхилләшеп калыйк,
Күрешмәбез, ахры, без тагын.
Чәчәкләрне күмгән олы юлның
Без күтәргән кара тузаны.
Син уйнадың кичә. Мин уйладым,
Чит якларда гомер узганын.
Чыңлаган шул гармун телләредәй,
Бер-бер артлы үтте елларым.
Яңрап үткән еллар авазыннан,
Түзмәдем мин, үксеп еладым.
Табылмаган дөнья малы өчен,

Каңгырыйдыр егет башлары.
Ил язмышы безне туган җирдән,
Өмет бирми, алып ташлады.
Нинди җыр бу диеп сорамагыз,
Күз яшьләре тынны буганда.
Бәхилләшү җыры шушы инде,
Сау булыгыз, кардәш-туганнар.
Идел бит ул, дускай, Идел бит ул,
Ерак бит ул, тирән, киң бит ул.
Татар күргән михнәт дәрьясына,
Күз яшенә аның тиң бит ул.
Әй, мөкатдәс, моңлы тальян гармун,
Уйнадың син бик аз. Нишләдең?
Үксеп-үксеп елый еракларда
Аерылган кардәш-ишләрең.
«Озата барма, дускай, озата барма»,
Адаштырмас, бәлки, олы юл.
Без китәбез инде. Сез каласыз.
Татар җыры—матәм җырымы ул?
Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Галиябану, Рәйхан, Гөлҗамал,
Мин сагындым сезне... Күзләремнән
Тамчы тама... Сагыш, моң тама...

## Террор

*(Берәү сөйләде)*

*Кайбер кеше үтерүчеләр аларны*
*үтерүне тыя торган закон*
*булганга күрә генә исән яшиләр...*
Хови Э. У. Америка язучысы.
1853-1937.

*Ул да кемнеңдер баласы...*
Равил Фәйзуллин.

«Таза егет—мыек асты
Яңа гына кипкән әле—
Сабый кызы күз алдында
Бер фәкыйрьне типкәләде.
Кызык өчен, тик торганда,
Кыйнады ул бер юашны,
Йә китереп суга берне,
Йә яңадан тибә башлый.
Яшь агызып, бер ялгызы
Карап тора мескен сабый—
Ник әтисен шулай итә
Бу әшәке, сәер абый?
Кысылырлык гайрәтем юк,
Булышырлык юк бер бәндә.
Шулай инде, беркем булмый,
Син дигәндә, мин дигәндә.
Көннәр үтте. Тынгы бирми
Шул сабыйның күз яшьләре.
Булышасым килгән иде.
Бик теләдем... Тик, дәшмәдем.
Мәгънәсе юк, файдасы юк
Бездән, минемище юк-бар.
Бәреп егар да җенләнеп,
Икеләтә каты тукмар.
Ә сабыйның елаганы
Күз алдымнан китми һаман.
Җәлләп шуны, оныталмый,
Ахыр чиккә җиттем тәмам.
Торган җирен, йөргән җирен
Белә идем бәдбәхетнең.
Төн йокламый исәп кордым,
Бер почмакка посып көттем.
Һәм, ниһаять, бу хәшәрәт
Кайтып килә алпан-тилпән.
Бераз салмыш... Һәрхәлдә дә,
Чайкалмыйдыр инде җилдән.
Кулда күсәк, җанда исәп,
Сабый бала күз алдымда,
Ордым берне арт ягыннан,
Кинәт кенә кузгалдым да.
Туктады да катып калды,
Чайкалып бер мизгел генә.

**Җир тетрәтеп, әзмәвердәй,**
**Авып төште юл читенә.**
**Сөенмәдем. Үкенмәдем.**
**Уйламадым артын, алдын.**
**Йокла сабый, оныт барсын—**
**Әткәң өчен мин үч алдым!**
**Күрәм, кайчак, «әзмәвер»не,**
**Хастаханә—йөргән юлы.**
**Вөҗдан, кайчак, бимазалый—**
**Ул да кемнеңдер бит улы.**
**Минем дә бит бар әнкәем...**
**Тик, юаныч шуннан табам—**
**Сабый кызның елаганы**
**Күз алдымда тора һаман.**
**Беләм, аңлыйм. Арттан сугу—**
**Сөйләмәслек кабахәт эш.**
**Нишләргә соң? Чара юк бит!**
**Адым саен золым, фәхеш...**
**Аң-белемем күп түгелдер,**
**Берәү әйтер: утыр да түз!**
**Сез акыллы... Минем өчен**
**Башка чара юк дигән сүз.**
**Һәркемнең дә әнкәсе бар,**
**Һәркем—кемнеңдер бит улы.**
**Үз ишенә, иң беренче,**
**Күтәрелә кемнең кулы?**
**Дөрес! Кизәнә көчлерәк,**
**Шуннан башлана барысы.**
**Булмый, андыйлар көченә,**
**Шул ук юл белән карышып.**
**Арттан сугу—куркак эштер,**
**Ләкин, аның сәбәбе бар.**
**Мәрхәмәтсез ерткычларның**
**Җавап тотар сәгате бар.**
**Ил башлыгы зур түрәләр,**
**«Террор!»—дисез. «Террор!»—дисез.**
**Мин килешәм—кабахәт эш.**
**Ник сәбәбен тикшермисез?**
**Әллә шуңамы—үзегез,**
**Держава, милек сагында,**
**Туганнарын үтерәсез**
**Сабыйлары күз алдында.**
**Мин надандыр... Кемдер әйтер:**
**Синең акыл эше түгел...**
**Бомба ташлап йорт яндырган—**
**Кеше түгел! Кеше түгел!**
**Һәркемнең дә әнкәсе бар,**
**Һәркем—кемнеңдер бит улы!**
**Мин надандыр, аңлый алмыйм—**
**Шулмы Хак Тәгалә юлы?**
**Сөенмим дә, үкенмим дә...**
**Сәбәбен мин үзем беләм.**
**Ходай каршына барырга,**
**Җавабым да үзем белән.»**

***Редакциядән:*** *Бу айда журналыбызның даими авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Татнефть»нең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты шагыйрь Рәниф Шәриповка 60 яшь тула. Укучыга яхшы билгеле күп шигырь һәм поэмалар (алар «Тәрәзәдәге утлар»» «Ян, учагым!», «Мәңгелек сер» һ. б. китапларда тупланган) авторы. Рәниф зур юбилеен яңа әсәрләр язып каршылый. Шагыйрьне ихлас котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗади шатлыклар теләп калабыз.*



# Миңзифа Әхмәтшина

## ЯЗМЫШЛАР ЯРДА КАВЫША...

### Рәхмәт, сөю!

Бүтән өзеп капмам дидем
Әче алмаларыңны:
Ялгыштым, инде әчесе
Көйдерә җаннарымны.

Йоклыйсы гына идем дә
Тыныч башым мендәрдә.
Йокысыз уза төннәрем,
Газаплыйсың ниләргә?

И, син, Сөю! Бар икәнсең
Көзендә дә гомернең:
Рәхәтләнеп янам, янып
Кышларыма керермен.

Ялгыш кына капкан идем
Әче алмаларыңны...—
Рәхмәт, Сөю, миңа рәхәт,
Гел яндыр җаннарымны!

### Кайгы күле ут кына

Кайгы күле тозлы түгел,
Кайгы күле—ут кына...
Әче ялкын, тышы салкын,
Йота алсаң, йот кына.

Кайгы савыты бушамас,
Сөялеп каеннарга.

Миңзифа ӘХМӘТШИНА—*шагыйрә; берничә китап авторы. Әлмәттә яши.*

Җырласам елый башлыймын,
Түзәлмәс кайгым барга.

Яраларга кагылучы
Булмады түгел, булды.
Гаҗәбе шул: аларның да
Кайгы күлләре тулды.

Агач башларыннан түгел,
Адәм башыннан үтә:
Бар да җитеш, дигәч кенә,
Җаннарны кисеп китә.

## Китсәң, кит икән...

Китсәң, кит икән илеңнән,
Яшь чакта, җүләр чакта...
Киттем дә гомер көзендә—
Күңел гел туган якта.

Яз җитсә, кырда күңелем,
Буразна чәчә... сыза.
Йөгерә-йөгерә орлык сибәм
Өй яны бакчасына.

Җәйләрен җиләк җыямын
Урманнар, кырларымнан.
Сихерләнеп ләззәт алам
Сандугач моңнарыннан.

Көзләрен күңелем белән
Бодай ташыйм амбарга.
..Кулда көрәк, ярсый йөрәк,
Калмасын яңгырларга.

Китсәң кит икән илеңнән
Яшь чакта, җүләр чакта...
Гомер көзе—күңел нечкә.
Ашкына туган якка.

## Бәхет—сөйгән яр барда

Ялгыз, ялгыз, диеп, каз кычкыра
Су буйлары куе камышта.
Сагынуга түзәлсә да йөрәк,
Түзә алмый икән сагышка.

Язмыш юлларында аймыл булдык,
Әллә еллар микән аерды?
Ике якта ике сыңар кош без,
Канатларны кемнәр каерды?

Бәхеткә, дип юрыйм төшләремне,
Өзелеп сөйгән ярлар кавыша.
«Язмышлар бит ярда кавышалар....»—
Иярәмен шушы тавышка.

## Без—шул еллар кызлары

И, безме ул?! Тәрбияле үстек,
Итәк-чабу иде җыюлы...
Юк, әйтмәгез, өй кошлары, диеп,
Гөрләп торыр иде су юлы.

Кичен, ашыктырып, көтә идек
Әнкәйләрнең сыер сауганын:
Маллар ашатабыз, дип булса да
Матурлыгын күрдек таңнарның...

Мал кайгысы онытыла иде,
Күзләр таба иде күзләрне...
И, ул чаклар!
Егетенең дә бит
Назлы иде әйтер сүзләре.

Гөрләп торыр иде су юлы...
Итәк-чабу иде җыюлы.

## И, оялдым...

*Ир-ат дигән затның куенында*
*Кылыч йөрсә, диләр, хак булыр.*
*Кулында көч, күңелендә аның,*
*Диләр, иярләгән ат булыр.*

Алып гәүдәң, атлауларың
Яндыра, көлләр итә.
Карашларың салкын кышны
Эретеп, гөлләр итә.

Әйтер сүзең—сөт өстенә
Күтәрелгән каймактыр?
Караңгы төн, күзең күрәм,
Болыт ерып ай бакты.

Учың куйсаң, учларымны
Беләм өтәреңне дә.
И, оялдым!
Койды яңгыр,
Болыт күтәрелде дә...

Ким
Миңнуллин

# ГЫЙЛЕМ ЙОРТЫБЫЗ БӘЙРӘМЕ

Республикабыздагы иң зур гыйлем йортларыннан берсенә—Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына—70 яшь тулды. Ул ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты 3050 номерлы боерыгы нигезендә 1939 елның 7 октябрендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты исеме белән төзелде, ә 1941 елның февраленнән Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты статусын алды. 1946 елдан СССР Фәннәр академиясенен яна ачылган Казан филиалы составына кертелеп, ярты гасырдан артык Татарстанда гына түгел, ә бөтен Идел—Урал буенда татар гуманитар фәннәрен өйрәнүче бердәнбер академик Институт булып килде. Татарстан фәннәр академиясе төзелгәнгә кадәр ТӘҺТИ гуманитар һәм иҗтимагый гыйлемнәр буенча республика координация советын җитәкләде, якын һәм ерак чит илләрнең (шул җөмләдән, Төркия, Финляндия, Венгрия, Алмания, Англия, АКШ һ. б.) академик оешмалары һәм тюркология үзәкләре белән тыгыз иҗади элемтәләр урнаштырды.



Институтта татар гуманитар белемнәренен барлык мөһим өлкәләрендә: тел белеме, лексикография, әдәбият белеме, текстология, фольклор фәне, театр сәнгате, музыка сәнгате, сынлы сәнгать, тарих, археология, этнография, иҗтимагый фикер һәм ислам дине һ. б.лар буенча җитди теоретик һәм гамәли тикшеренүләр алып барылды. Узган йөзнең 80 нче еллары ахырында биредә Татарстандагы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр Җыелмасын төзү башланды, 1990 елда татар энциклопедиясе төркеме оештырылды (соңрак ул Татарстан Фәннәр академиясе карамагына күчерелде һәм Татар энциклопедиясе институтын төзү өчен нигез булды.). Институтта милли мәдәниятебезнең ифрат бай фонды тупланды һәм иң кыйммәтлесе шул: биредә гуманитар фәннәрнең алда санап үтелгән барлык тармак һәм юнәлешләрендә нәтиҗәле эш алып барырга сәләтле бердәм хезмәт коллективы үсеп житеште.

Институтның озын бай тарихы, гыйльми юнәлешләре, структурасы, галимнәре, биредә язылган туган китаплар, уздырылган фәнни конференцияләр һәм әдәбимәдәни чаралар турында тәфсиллерәк сөйләүгә күчкәнче, ТӘҺТИ төзелгәнгә кадәр Татарстанда гуманитар фәннәрне өйрәнүнең торышын кыскача гына искә төшереп үтү урынлы булыр.

* * *

Идел—Урал буенда яшәүче халыкларның, шул исәптән татарларның мәдәнияте, тормыш-көнкүреше белән кызыксыну шактый күптәннән башлана. Казан Император университетында 1829 елда ачылган Көнчыгыш разряды, 1855 елда Санкт-Петербургка күчерелгәнгә кадәр, шәрекъ халыкларын, аеруча төркиләрне өйрәнү үзәге булып тора. Соңрак мондый эшчәнлекне 1878 елда Казан университеты каршында төзелгән «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» дәвам итә. Җәмгыять үзенең «Хәбәрләр»ен («Известия») дә булдыра һәм 1929 елга кадәр актив эшләп килә. Анда татар галимнәреннән Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәезханов, Г. Әхмәров, Р. Фәхретдинов, Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласи һәм башкалар хезмәттәшлек итә.

Татарстан АССР төзелгәннән соң, 1921 елның 3 декабрендә, Халык мәгарифе комиссариаты каршында Академик (яки: Гыйльми) үзәк төзелә. Аның составында фәнни-сәяси, фәнни-техник, фәнни-педагогик, сәнгать комиссияләре эшли. Үзәкнең беренче рәисе Г.Максудов була (1922—1924). Анардан соң бу вазифаны 1927 елның мартынача Г.Ибраһимов, 1929 елга кадәр М. Таһиров, 1929—1930 елларда С. Атнагулов башкара. Биредә татар әдәбияты тарихы, татар теле, халык иҗатын җыю һәм бастыру, төбәк тарихын өйрәнү, терминология, орфография мәсьәләләре, сүзлекләр төзү, мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм программалар язу буенча зур эшчәнлек җәелдерелә. Үзәк хезмәткәрләре арасында Е. Чернышёв, Н. Фирсов, М. Худяков, Г. Гобәйдуллин, М. Корбангалиев, Х. Бәдыйгый, Г. Рәхим, Ж. Вәлиди, Г. Алпаров, М. Фәзлуллин кебек танылган галимнәр була.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә комитеты карары нигезендә 1934 елның 4 июнендә Татар марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү институты төзелә. Андагы галимнәрнең бер төркеме профессор М. Корбангалиев һәм Ш. Рамазанов җитәкчелегендә татар башлангыч һәм урта мәктәпләре өчен уку әсбаплары язу, ә С. Атнагулов җитәкчелегендәге тәрҗемә бюросы сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә.



*Институт оештырган бер конференциядән күренеш.*

Бу кыскача тарихи күзәтүдән бер нәтиҗә: гәрчә институтыбызның яше җиде дистә дип саналса да, ул тикшерә торган проблемалар 1921 елда ук төзелгән Академик үзәктә һәм аннан соңгы фәнни оешмаларда, институтларда ук башланган, аларда эшләгән гыйльми көчләрнең байтагы һәм иң күренеклеләре алга таба ТӘҺТИдә хезмәт иткән. Димәк, ТӘҺСИнең заманында Гыйльми үзәкне җитәкләгән Г. Ибраһимов исемен йөртүендә тирән символик мәгънә бар! Һәм менә, ниһаять, ТАССР Үзәк Башкарма комитеты Президиумы 1937 елның 16 апрелендә Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты төзү турында карар кабул итә. Халык комиссарлары советының 1939 ел, 29 август карары буенча Институтның нигезләмәсе, штатлары, сметасы раслана һәм, инде әйтелгәнчә, шул елның 7 октябрендә Институт эшкә керешә. Директор вазифасы вакытлыча Укытучылар белемен камилләштерү институты директорының укыту эшләре буенча урынбасары М. А. Нигъмәтуллинга (төп эшеннән аерылмыйча) йөкләнә.

70 ел дәвамында Институт директоры булып Х. А. Шабанов (1939—1942),

Х. Х. Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми) (1942—1944), М. Х. Гайнуллин (1944—1953; 1959—1961), Х. Ф. Хәйруллин (Хәсән Хәйри) (1953—1959), К. Ф. Фәсиев (1961—1963), М. К. Мөхәррәмов (1963—1982), Я. Г. Абдуллин (1982—1986), М. З. Зәкиев (1986—2000), Н. Ш. Хисамов (2001—2006) эшләде. 2006 елның октябреннән институт белән К. М. Миңнуллин җитәкчелек итә.

Институт төзелгәннән алып 1941 елга кадәр аның штатында нибары 14—17 кеше санала. Бөек Ватан сугышы елларында алар 8 дән артмый. Ә 1970 еллар азагына хезмәткәрләр саны 130 га җитә. Институт структурасында озак вакытлар эшләп килгән төп фәнни секторлар (бүлекләр) эшчәнлеге белән аерым-аерым танышып узу кызыклы булыр.

Тел бүлеге Институт төзелгән көннәрдә үк оеша. Аның тәүге җитәкчесе танылган тел галиме Латиф Җәләй була. Аннан соңгы бүлек мөдирләре: В. Хангильдин (1951—1953), М. Гайнуллин (1953—1955, директор вазифасын үтәү белән бергә), янә Л. Җәләй (1956, 1961), Л. Мәхмүтова (1961—1986), М. Зәкиев (1986 дан хәзергәчә).

Бер үк вакытта рус теле бүлеге да оештырыла. Ул 1941 елның сентябрендә ябыла һәм 1945 елда янә торгызыла, бер елдан соң татар теле секторына кушыла. Рус теле бүлеге белән М. Сударчиков (1939—1941 еллар), Р. Газизов (1945 елда) җитәкчелек итәләр.

Тел бүлеге иң баштан ук шөгыльләнгән төп проблемаларның берсе—татар диалектологиясе. Бездә бу эшнең пионеры Л. Җәләй булды. Студентлар өчен беренче дәреслекне ул язды, баштагы экспедицияләрне ул оештырды, аларның материалларын җыентыклар итеп чыгаруны ул башлап җибәрде. Бүлектә Л. Т. Мәхмүтова, Н. Б. Борһанова, Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, Т. Х. Хәйретдинова, З. Р. Садыйкова кебек югары дәрәҗәле белгечләр үсеп чыкты. 1955—1990 елларда диалектология буенча материаллар җыентыкларының 9 чыгарылышы дөнья күрде.

Фәнни тикшеренүләрдән «Исследования по исторической диалектологии татарского языка» исемле күмәк җыентыклар (1979, 1982, 1985), Д. Рамазанованың ике кисәктән торган «Термины родства и свойства в татарском языке» (1991), «К истории формирования говоров пермских татар» (1996), Т. Хәйретдинованың «Названия пищи в татарском языке» (1993), З. Садыйкованың «Зоонимическая лексика татарского языка» (1994), Ф. Баязитованың «Татар халкының көнкүреш йолалары» (1996), «Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты» (1997) һәм башка унлаган китапларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Диалектологик сүзлекләр турында бераз соңрак сүз булыр. Диалектологларыбызның игътибарга аеруча лаеклы хезмәтләренә мисал итеп Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, Т. Х. Хәйретдинова, З. Р. Садыйкова, Р. С. Барсуковаларның ике китаптан торган «Татар халык сөйләшләре» монографиясен («Мәгариф», 2008, I китап, 463 б.; II китап, 463 б.) һәм Урта һәм Түбән Идел, Урал буе, Көнбатыш Себер татар сөйләшләренең 3 томлык Атласын күрсәтергә кирәк. Аның баштагы ике томы 1989 елда дөнья күрде (250 карта һәм аларга комментарийлар). Өченче томны Казан университеты лексикологлары әзерләргә тиеш иде, ләкин кайбер объектив сәбәпләр аркасында бу эшләнмәде. Әлеге том Көнбатыш Себер, Волгоград, Әстерхан өлкәләре һәм Ставрополь крае татарларының сөйләшләрен эченә алырга тиеш иде. Соңыннан аны да ТӘҺТИ диалектологлары үз өсләренә алдылар. Алабуга педуниверситеты профессоры Л. Ш. Арсланов җыйган бай мәгълүматлар да файдаланылды. Өченче томны төзү белән бергә беренче һәм икенче томнарга төгәллекләр кертелде һәм өч томлык Атлас хәзер басмага тәкъдим ителде.

Диалектология белән тыгыз бәйләнештә, бүлектә тарихи грамматика проблемасы эзлекле өйрәнелде. Тарихи фонетика һәм тарихи морфология буенча Л. Җәләй кызыклы хезмәтләр бирде. Стилистика һәм текстология юнәлешендә Х. Курбатов, И. Бәширова, М. Мөхәммәдиев, И. Абдуллин, Г. Әмиров, Я. Әхмәтгалиева, Ф. Фәсиев кебек галимнәр актив шөгыльләнделәр. Тел тарихы белән тыгыз бәйләнештәге фән булган топонимия өлкәсендә Ф. Гарипова нәтиҗәле эш алып бара. Аның тарафыннан ике китаптан торган «Словарь гидронимов Татарстана» (1984, 1991), «Исследования по гидронимии Татарстана» (1991), «История в названиях» (1995), «Калалар һәм авыллар тарихы» (1995) һәм башка хезмәтләр нәшер ителде.

Бүлектә әзерләнеп, 1992—1993 елларда татар һәм 1998-2002 елларда рус

телләрендә «Татар теле грамматикасы»нын өч томлык академик басмасы дөньяга чыгу Институт күләмендә генә түгел, ә республиканың фәнни тормышында да зур вакыйга булды. Бу фундаменталь хезмәтнен төп авторлары М. З. Зәкиев, Д. Г. Тумашева, Ф. А. Ганиев, К. З. Зиннәтуллинага Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләге бирелде.

Институт оештырылганда ук тел бүлеге составында лексикографлар төркеме дә эшкә керешә. Аны бу өлкәдәге танылган белгеч Риза Газизов житәкли. Сүзлекләр төзү эшенә штаттан тыш хезмәткәрләр сыйфатында Нәкый Исәнбәт, Гаяз Ишмөхәммәтов, Касыйм Хәмзин, Хәмит Мөштәри, Габбас Сәйфуллин кебек тәжрибәле сүзлекчеләр чакырыла.

1950 елда 20 меңгә якын сүз һәм тәгъбирне эченә алган «Татарча-русча сүзлек» басыла. 1955—1959 елларда дүрт томлык «Русча-татарча сүзлек» дөнья күрә. Аның авторлары арасында Р. С. Газизов, Л. Т. Мәхмүтова, Ә. М. Ахунжанов, Ф. С. Фәсиев, Ф. М. Газизова, М. Г. Гимадиев, Г. С. Әмиров кебек инде ул вакытта ук танылу тапкан лексикографларны күрәбез.

1958 елда әлеге төркем лексикография бүлеге итеп үстерелә. Аның мөдире Г. С. Әмиров житәкчелегендә ике төп юнәлештә: зур күләмле татарча-русча сүзлек һәм татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеген төзү буенча эш жәелдерелә.

Бер үк вакытта югары квалификацияле кадрлар хәзерләүгә даими игътибар бирелә. Сәләтле яшьләрдән М. Мөхәммәдиев, Г. Ахунжанов, Ф. Ганиев, И. Абдуллиннар аспирантурага кабул ителәләр. Алар сонрак барсы да абруйлы лексикографлар булып танылдылар.

Секторда, әле аталган ике зур хезмәттән тыш, аерым тармакларга караган сүзлекләр дә төзелә килде. Әйтик, 1962 елда Ш.Ханбикованың «Синонимнар сүзлеге» басылды. Ниһаять, 1966 елда Мәскәүдә 38 меңгә якын сүзне һәм фразеологик берәмлекне эченә сыйдырган «Татарча-русча сүзлек» нәшер ителде.

1962 елда лексикография секторы, янадан төркемгә әйләндерелеп, тел бүлеге составына кайтарылды. Шуна да карамастан алга таба да бу өлкәдә кыйммәтле зур хезмәтләр чыгару дәвам итә. Институт оештырган күпсанлы экспедицияләр материалларына нигезләнеп, Н. Б. Борһанова, Л. Т. Мәхмүтова, З. Р. Садыйкова, Г. К. Якуповалар төзегән «Татар теленең диалектологик сүзлеге» басыла (1969). (Сонрак, 1993 елда, аның икенче китабы да үз укучыларына ирешә.) 1971 һәм 1984—85 елларда ике мәртәбә «Русча-татарча сүзлек» нәшер ителде.

М. Мөхәммәдиев житәкләгән төркем «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» өстендә эшләүне дәвам итте. Ул 3 миллион сүз һәм сүз формаларыннан торган картотекага нигезләнде. 1977—1981 елларда сүзлек өч том булып Татарстан китап нәшрияте тарафыннан мәйданга куелды. Алар татар лексикографиясенең генә түгел, бәлки бөтен тюркологиянең зур казанышы, төрки телле сүзлекләрнең иң яхшысы итеп бәяләнде. Бу фундаменталь хезмәтне тудыруга ТӘһТИ хезмәткәрләреннән И. А. Абдуллин, Ф. Ә. Ганиев, М. Г. Мөхәммәдиев, Г. Х. Ахунжанов, Р. Г. Әхмәтжанов, Ш. С. Ханбикова, Ф. М. Газизова, С. Б. Вахитова, Р. К. Рәхимова, Л. Р. Гайнанова, Л. Т. Мәхмүтова, К. С. Сабиров һ. б. катнашты.

1989 елда лексикография төркеме янадан сектор итеп торгызылды, ә 1991 елда ул мөстәкыйль лексикография һәм лексикология бүлеге буларак эшли башлады. Аның белән 2001 елга кадәр Ф. Ә. Ганиев, 2007 елга кадәр—Ш. Н. Асылгәрәев житәкчелек иттеләр. Хәзер аның мөдире—яшь галим, фән докторы А. Ә. Тимерханов. Лексикография бүлегенең соңгы еллардагы зур казанышлары рәтенә ике томлык «Татарча-русча сүзлек», бер томлык аңлатмалы сүзлек дөнья күрү, мәктәпләр өчен төзелгән Аңлатмалы сүзлекнең басмага тапшырылуы һ. б. керә. Бу сүзлекләрнең язмышында бер уртак күренеш бар: алар, нигездә, элеккерәк чорда, өлкәнрәк буын галимнәр тарафыннан әзерләнеп, вакытында дөнья күрмиләр һәм бүгенге яшь белгечләр редакциясендә басылып чыгалар. Бүлектә хәзерге вакытта эшне урта һәм яшь буын фән кандидатлары Ф. Гаффарова, Ф. Таһирова, Г. Сәмирханова, И. Сабитова, А. Гайнетдинова, О. Бятикова, Э. Сафиналар алып бара.

Хәзер исә бүлекнең төп бурычларыннан берсе—татар теленең дүрттомлык аңлатмалы сүзлеген гамәлгә кую. Аның гомуми күләме 450 табак итеп планлаштырылды. Сүзлектә

150 меннән артык лексик берәмлек булачак, аларның мәгънәви-тематик байлыгы, аңлатылу дәрәҗәсе дә күпкә югарырак булыр дип көтелә.

Әдәбият бүлеге Институт оештырылган көннәрдә үк эшли башлый. Аның җитәкчесе итеп Я. Х. Агишев билгеләнә. Секторның беренче хезмәткәрләре В. Х. Хаҗиев, М. Х. Гайнуллин, Г. Х. Хисмәтуллин (Хәй Хисмәтуллин) була. 1940—1950 елларда анда А. Х. Камский (1941 елга кадәр), Гали Халит (1942—1953 елларда мөдир дә), Б. А. Яфаров, М. В. Галиев (Мөхәммәт Гали), М. С. Кәшшафетдинов (Гази Кашшаф) эшлиләр. Тикшеренүләрнең проблематикасы киңәя. Галимнәргә татар әдәбияты тарихын язу, аерым язучыларның иҗатын өйрәнү, урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр төзү кебек бурычлар йөкләнә. 40 нчы елларда Г. Халитнең «Халык шагыйре Габдулла Тукай» (1939), «Мәҗид Гафури иҗады (Критик очерклар)» (1941), М. Галинең «Г. Камал: тормышы, иҗаты, татар әдәбиятындагы һәм гомумән татар культурасында тоткан урыны» (1941), Я. Агишевнең «Габдулла Тукай—патриот» (1942), М. Гайнуллинның «Горький и татарская литература» (1944), «Каюм Насыри: научная и просветительская деятельность» (1945), Г. Халитнең «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре: (Критик очерклар)» (1948), Х. Хәйринең «Һади Такташ (Тормыш һәм иҗат юлы)» (1949) дигән хезмәтләре дөнья күрә.

Институтта урта гасыр татар әдәбиятын тикшерүне Б. А. Яфаров башлап җибәрә. Ул XIV йөздә иҗат иткән Мәхмүд Гали әл-Болгаринең «Нәһҗел-фәрадис» («Оҗмахларның ачык юлы»), Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» («Күңелләр нуры») әсәрләрен, Габдерәхим Утыз Имәнинең (XVIII) һәм башка әдипләрнең иҗат мирасларын өйрәнә. Соңрак әлеге өлкәдә М. Гали актив шөгыльләнә.

«XX йөз башы татар әдәбияты. Очерклар» (Г. Халит, Х. Хисмәтуллин, Б. Гыйззәт, 1954) дигән күмәк хезмәт илленче еллар әдәбият гыйлеменең җитди бер казанышы буларак бәяләнергә хаклы. Авторлар чор идеологиясе таләпләренә ярашып әдәбиятны социологияләштерү белән мавыкмыйлар, ә әсәрләрнең сәнгати эшләнеш ягына да зур игътибар бирәләр. Алай да анда XX йөз башы татар әдәбияты панорамасы тиешле дәрәҗәдә күрсәтелә алмый. Аерым язучылар, шагыйрьләрнең, мәсәлән, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думавиларның әдәби процесстагы рольләре шактый түбәнәйтелә. Ә менә «Татар әдәбияты. XX йөз» дигән хезмәтнең (М. Гайнуллин, Ж. Вәзиева) икенче басмасында (1965), шул чорның тәнкыйтен һәм эстетик карашларын истә тотып, авторлар инде халык шагыйре Габдулла Тукайга, халык язучысы Мәҗит Гафуригә игътибарны арттыралар.

Әлеге чорда, секторда һәм, гомумән, татар әдәбият белемендә беренче булып, М. Х. Гайнуллин фән докторы дәрәҗәсенә ирешә, ә Б. Гыйззәт, Н. Г. Гыйззәтуллин, Х. Г. Мөхәммәтов, Р. Ш. Башкуров, Ш. Ш. Абилов кандидатлык диссертацияләре яклыйлар.

1960—1970 елларда бүлектә Татар әдәбияты тарихы буенча очерклар бастыру традициясе дә уңышлы дәвам иттерелә. Шундыйларның берсе—«Татар совет әдәбияты тарихы: очерклар» 1965 елда рус телендә Мәскәүдә нәшер ителә. Бу хезмәт милли совет әдәбиятларының башкалада басылган беренче үрнәге була.

Татар әдәбиятчыларының эшчәнлегендәге җитди яңалык буларак аларның Союзкүләм фәнни-тикшеренүләрдә актив катнашуларын билгеләп үтү зарур. А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятлары институты нәшер иткән күпмилләтле совет әдәбияты тарихының фундаменталь күптомлыгын (1970—1974) язуда Г. Халит, Р. Башкуров, Б. Гыйззәтуллин, Н. Гыйззәтуллин, В. Воздвиженский, Н. Юзиев, Х. Хәйруллин, А. Әхмәдуллин, Р. Сверигин зур тырышлык күрсәтәләр.

70 нче елларда хезмәткәрләрдән Н. Г. Юзиев докторлык, К. С. Дәүләтшин, М. Ш. Маннурова, Р. Х. Сверигин, М. В. Гайнетдинов, З. З. Рәмиев, Н. Г. Ханзафаров, Н. Ш. Хисамов кандидатлык диссертацияләре яклыйлар.

1971 елдан әдәбиятчылар алты томлык фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы»н төзү эшенә керешәләр. Аны башкаруга Казан, Ленинград, Уфа, Оренбург филологлары да җәлеп ителә. 1984 елда алтытомлыкның борынгы һәм урта гасырлар дәверенә багышланган беренче томы нәшер ителә (җаваплы мөхәррир

Ш. Ш. Абилов). Том әдәбият тарихының XIII—XVIII гасырларын инли. Анда күп кенә чыганаклар беренче тапкыр фәнни кулланылышка кертелә. Икенче том 1985 елда дөнья күрә (җаваплы мөхәррир М. Х. Гайнуллин). Ул XIX йөз татар әдәбиятын колачлый. Анда яна чыганаклар, яна исемнәр, бай фактик материаллар кин файдаланыла. Милли мәгърифәтчелек әдәбияты үсешенең закончалыклары аеруча тирән анализлана. Өченче томда (1986—җаваплы мөхәррир Г. Халит) XX йөз башы татар әдәбияты тарихына багышлана. Анда 1905—1917 елларның катлаулы әдәби панорамасы шактый тулы яктыртыла. Дүртенче томда (1986—җаваплы мөхәррирләр Н. Г. Юзиев, Н. Ш. Хисамов) 1917—1941 еллар татар совет әдәбияты анализлана. Бишенче томда (1989—җаваплы мөхәррир Н. Г. Гыйззәтуллин) Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941—1960) яктыртыла.

«Татар әдәбияты тарихы»ның алтынчы томы үз вакытында нәшер ителә алмады. Ул тик 2001 елда гына дөнья күрде (җаваплы мөхәррир Н. Ш. Хисамов). Анда үткән гасырның 60—90 нчы еллар әдәбияты үзгәртеп кору чоры башлангач туган яңа таләпләр һәм мөмкинлекләр нигезендә яктыртылды.

Классикларның тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнүне уңышлы дәвам иттереп, Г. Халит «Тормыш һәм ирек җырчысы: Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турында очерк» (1980), «Поэзия дерзаний: (Творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов)» (1980) дигән монографияләр язды. Язма әдәбиятыбызга нигез салган мәшһүр шагыйребез Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган «Поэт-гуманист Кул Али» (1987) һәм «Урта гасырлар татар әдәбияты тарихыннан» (1982) дигән фәнни җыентыклар, Н.Ш.Хисамовның «Бөек язмышлы әсәр» (1984) монографиясе һ.б. әдәбият белемебездә мөһим вакыйгалар булдылар.

XX йөз классиклары турында Г.Халитнең «Портреты и проблемы» (1985), М.В.Гайнетдиновның Х.Туфанның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган «Давылларда, җилләрдә...» (1989) китаплары, Муса Җәлил (1978), Габдулла Тукай (1979, 1997), Галимҗан Ибраһимов (1980), Галиәсгар Камал (1981), Мәҗит Гафури (1981), Гафур Коләхмәтов (1986), Һади Такташ (1983) турындагы тематик җыентыклар әлеге әдипләрне өйрәнү юнәлешендә тагын бер адым булып тора.

Бүлек хезмәткәрләре Н.Г.Ханзафаров, Н.Ш.Хисамов, Ә.Г.Мәхмүтов докторлык, Р.Ф.Исламов, Д.Э.Ибәтуллина, Р.С.Зарипова кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Үткән гасырның азаклары, барыннан да элек, татар әдәбияты классигы, прозаик, драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйның (1878—1954) мирасын халыкка кайтару белән бәйле. Күпсанлы хезмәтләр арасында Ф.М.Мусинның бай архив материаллары нигезендә язылган «Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге)» дигән монографиясе дә бар (1998).

Урта гасыр һәм яңа татар әдәбияты циклының дәвамы буларак рус телендә «Средневековая татарская литература (VIII—XVIII вв.)» (1999—җитәкчесе һәм фәнни мөхәррире Н.Ш.Хисамов) басылып чыкты. Анда ун гасырлык төрки-татар әдәбияты шактый тулы күзаллана.

Урта гасыр төрки, төрки-татар язма мирасын өйрәнү нәтиҗәле дәвам иттерелде. Р.Ф.Исламов «Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни бәйләнешләр» (1998), «Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се (Текст һәм чыганаклар. Шигырь төзелеше һәм стиль)» (2001) дигән монографияләр бастырып чыгарды. Ф.К.Бәшировның «XX йөз башы татар прозасы» (2002) исемле хезмәте татар прозасының үсеш этапларын һәм шул дәвер әдәби хәрәкәтнең катлаулы халәтен ачыклауга юнәлтелгән.

«История татарской литературы нового времени (XIX—начало XX в.)» (фәнни редактор Г.Халит, җаваплы мөхәррир Н.Ш.Хисамов) исемле коллектив хезмәт 2003 елда дөнья күрде. Ул элеккеге идеологик стереотиплардан мөмкин кадәр арыну, күрсәтелгән дәверләр әдәбиятын яңача бәяләү юнәлешендә башкарылган. Анда XIX йөз—XX гасыр башы татар әдәбияты үсешенә һәрьяклы һәм тулы анализ ясала; традиция һәм новаторлык, иҗади индивидуальлек, жанр төрлелеге мәсьәләләре өйрәнелә. Аеруча татар әдәбияты классиклары иҗатын яңача тикшерүгә игътибар бирелә.

Бу чорда М.В.Гайнетдинов, Р.Ф.Исламов, Ф.К.Бәширов докторлык, Л.Р.Гарәпшина, З.З.Гыйләжев, Ф.Х.Миннуллина кандидатлык диссертацияләре якладылар.

* * *

Әдәбият бүлеге эшчәнлегендә текстология мәсьәләләре Институт оешуның беренче елларыннан ук үзәк урынны алды. Г.Тукай хезмәтләренен ике томлык «Академик басма»сы (1943, 1948) шушы өлкәдәге житди унышларнын беренчесе булды. Аны төзүчеләр Х.Хисмәтуллин белән Я.Агишев, Тукайның тууына 70 ел тулуга нисбәтән, шагыйрьнен дүрт томлыгын басмага әзерләделәр һәм ул 1955—56 елларда укучылар кулына иреште.

50 нче еллар ахырында ижтимагый тормышнын кайбер өлкәләрен либеральләштерү нәтижәсендә әдәби мирасыбызның билгеле бер өлешен халыкка кайтару мөмкинлеге туды. 1963 елда борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты буенча хрестоматик характердагы «Борынгы татар әдәбияты» дөнья күрде (төзүчеләре: Х.Мөхәммәтов, Х.Хисмәтуллин, Ш.Абилов һ.б.). 1966 елда Ш.Абилов тарафыннан әзерләнгән Мөхәммәдьяр поэмалары басылып чыкты. 1977 елда анын тарафыннан ук шагыйрь әсәрләренен тагын да камилләшкән жыелмасы бастырылды.

1974—75 елларда К.Насыйриның ике томлы «Сайланма әсәрләр»е (төзүчеләре: С.Алишев, М.Гайнуллин, М.Гайнетдинов, Х.Мәхмүтов һ.б.), 1975—76 елларда дүрт томда «М.Жәлил әсәрләре» (төзүчесе: Г.Кашшаф, Н.Ханзафаров һәм Ф.Ибраһимова) нәшер ителде. Шул ук елларда Г.Тукай әсәрләренен Р.Гайнанов әзерләгән дүрт томлыгы басылып чыкты.

1976 елда әдәбият секторында З.З.Рәмиев житәкчелегендә махсус текстология төркеме төзелә. Ә 1987 елда әдәбият бүлеге нигезендә «Әдәбият белеме» һәм «Кульязмалар һәм текстология» бүлекләре оештырылды. Беренчесен Ф.М.Мусин, икенчесен Н.Г.Юзиев житәкләде. Бу чорда XX гасыр классикларыбыз мирасын барлау һәм аларнын күптомлыкларын басмага әзерләү буенча актив эш алып барыла. 1978—88 еллар эчендә Г.Тукайның биш томлыгы, Ф.Әмирханнын дүрт томлыгы, Г.Ибраһимовнын сигез томлыгы, М.Гафуриның дүрт томлыгы, Г.Камалнын һәм Һ.Такташнын өч томлыклары дөнья күрделәр. Бу казанышларга узган гасырларның мавыктыргыч хикәятләреннән тупланган «Мәжмугыл-хикәят», «Гыйбрәтле хикәятләр», «Кәлилә вә Димнә» (басмага әзерләүче Н.Исмәгыйлов), Ф.Халидинен «Мен дә бер сәхәр» (З.Мөхәммәтшин) китаплары да өстәлде. Әдәбият тарихынын аерым чорлары буенча бүлектә кызыклы антологияләр әзерләнде: «XX гасыр башы татар лирик поэзиясе» (З.Рәмиев), «XX гасыр башы татар эпик поэзиясе» (Ф.Яхин), «XVIII гасыр татар прозасы» (М.Әхмәтжанов, Ә.Алиева, Н.Исмәгыйлов һ.б.). Г.Исхакыйнын төрле жанрларда ижат ителгән күпсанлы әсәрләрен туплау, системага салу, шәрехләү һәм 15 томда басмага әзерләү бүлек эшчәнлегенен аеруча мөһим тармагын тәшкил итә. Бүгенге көнгә бу басманың 8 томы гамәлгә ашырылды инде.

Бүлек хезмәткәрләре чыганакларны өйрәнүнен теоретик проблемаларына зур игътибар бирәләр. Беренче чиратта Н.Г.Юзиевнын «Әдәбият чыганаклары белеме», З.З.Рәмиевнен «XX гасыр башы татар әдәбияты текстологиясе» кебек монографияләрен күрсәтеп үтәсе килә. «Яңа археологик материаллар һәм татар әдәбияты тарихы буенча тикшеренүләрдә аларның әһәмияте» дигән монографиясе нигезендә М.И.Әхмәтжанов докторлык диссертациясе яклады. Н.Гәрәева белән С.Гыйләжетдинов Мирасханәбездәге гарәп һәм фарсы кульязмаларнын фәнни тасвирламасын эшләделәр.

Фольклор секторы—институтнын яшьтәше. Анын мөдире Х.Х.Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми) 1940 елда ук Себергә «Радлов эзләре буйлап» дигән экспедиция оештыра. Анын барышында себер-татар фольклоры буенча кызыклы материаллар, атап әйткәндә, «Идегәй» дастанынын күп кенә фрагментлары язып алына.

1946—1961 елларда фольклорчылар әдәбият бүлегендә аерым төркем тәшкил итә. Аннан Институтта халык ижатын һәм сәнгать тарихын колачлаган яна сектор оеша, анда фольклорчылардан И.Н.Надиров, Э.С.Касыймов, В.Ф.Павлова, Х.Х.Гатина, театр белгечләре Ф.Н.Гыйззәтуллин, Х.Х.Гобәйдуллин, Д.Ә.Гыйманова һәм

музыка белгече М.Н.Нигъмәтжановлар эшли. 1961—1972 елларда секторны татар фольклорчыларыннан беренче фән докторы Х.Х.Ярмөхәммәтов житәкли.

Фольклор экспедицияләре 1945—1955 елларда Татарстан Республикасының барлык районнарын өйрәнеп чыккач, аннары татарлар күпләп яшәгән күрше төбәкләргә (Киров, Пенза, Рязань, Оренбург, Горький, Саратов, Куйбышев, Әстерхан, Ульяновск, Волгоград, Пермь, Свердловск, Чиләбе өлкәләренә һәм Мари, Чуаш, Мордва, Удмурт республикаларына) оештырыла. 1967 елдан фольклорчылар Себергә: Новосибирск, Омск, Төмән, Иркутск һәм Чита өлкәләренә юл ала.

1951—1972 елларда татар халык ижаты буенча күп кенә жыентыклар: «Татар халык ижаты» антологиясе (1951, икенче басмасы 1954), «Татар халык әкиятләре» (ике китапта, 1946, 1956), «Татар халык жырлары» (1965), «Татар халкының уен һәм бию жырлары» (1968) һ.б. нәшер ителә. Халык ижаты бүлеге фәнни кадрлар әзерләүгә дә житди игътибар биреп килде. Әйтик, 50—60 нчы елларда И.Н.Надиров, Э.С.Касыймов, Т.Н.Галиуллин, Ф.И.Урманчеев, Ф.В.Әхмәтова, В.Ф.Павлова, Х.Ш.Мәхмүтов кандидатлык диссертацияләре яклады.



*Институтның фәнни басмалары*

1948—1970 елларда бүлек хезмәткәре В.Ф.Павлова республикадагы рус фольклорын туплау һәм басмага әзерләү белән шөгыльләнде һәм «Русское народно-поэтическое творчество в Татарской АССР» (1955), «Это было в Бездне: устные народные рассказы» (1962) дигән жыентыклар төзеп чыгарды.

Күпьеллык экспедицияләр нәтижәсендә бүлек фондында бай текст материалы тупланды, бу исә фольклорчыларга татар халык ижатының күптомлы жыелмасын әзерләү мөмкинлеген тудырды. Әлеге эшне бүлек мөдире И.И.Надиров житәкләде. 1976—1988 елларда жыелманың төп жанрларны эченә алган 12 томы дөнья күрде. Күптомлыкны фәнни һәм ижади жәмәгатьчелек хуплап каршылады. Аны әзерләүчеләрдән И.Н.Надиров, Х.Х.Ярмөхәммәтов (вафатыннан соң), Х.Ш.Мәхмүтов, Л.Ш.Жамалетдинов һәм Ф.В.Әхмәтовага 1989 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Узган йөзнең 70—90 нчы елларында татар фольклор фәненең мөһим мәсьәләләре буенча махсус жыентыклар: «Татар фольклоры жанрлары» (1978), «Борынгы татар фольклоры проблемалары» (1984), «Татар фольклорында социаль мотивлар» (1986), «Татар халык поэтик ижатының бүгенге торышы» (1988), «Татар фольклоры поэтикасы» (1991) һ.б. дөнья күрә.

1992 елның сентябреннән бүлекне филология фәннәре докторы Ф.И.Урманчиев житәкли. Күп еллар дәвамында урнашкан күркәм традицияләрне уңышлы дәвам иттереп, бүлектә югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә дә игътибар көчәйтелә. А.Х.Садыйкова, Л.Ш.Жамалетдинов, К.М.Миннуллин кандидатлык диссертацияләре яклый. 1995 елда Х.Ш.Мәхмүтов, ә яңа меңьеллык башында К.М.Миннуллин, А.Х.Садыйкова докторлык дәрәжәсенә ирешәләр. Хәзер Институтның халык ижаты бүлегендә 4 фән докторы, 4 фән кандидаты эшли, ел саен бүлеккә 4 аспирант кабул ителә. Фәнни-теоретик эзләнүләр, экспедицияләр үткәрү белән бергә, бүлектә төп игътибар 25 томлык «Татар халык ижаты» һәм 15 томлык «Татарское народное творчество» жыелмаларын әзерләүгә юнәлтелгән.

Милли сәнгать белеме үсешендә житди бер адым итеп, 1968 елда институтта мөстәкыйль сәнгать бүлеге төзелүне санарга кирәк. Аның беренче мөдире Ф.Н.Гыйззәтуллин (Бәян Гыйззәт) инде бу вакытка СССР Сәнгать тарихы институты каршында әзерләнгән «Совет драма театры тарихы» алты томлыгы авторларының

берсе була. Бүлек үз эшчәнлеген төп өч юнәлештә алып бара: татар халкының театр сәнгате, музыкаль культурасы һәм декоратив-гамәли һәм тасвирый сәнгате. Бүлек эшчәнлегенә, Ф.Х.Вәлиев, М.Н.Нигъмәтжанов, И.И.Илялова. Х.Г.Гобәйдуллин кебек танылган белгечләр белән бергә, яшьләрдән Һ.К.Мәхмүтов, Д.Ә.Гыйммранова, З.Н.Сәйдәшевалар да тартыла.

Бүлектә революциягә кадәрге һәм аннан соңгы чорлардагы вакытлы матбугатта басылган материалларны, архив һәм музей фондларын өйрәнү нәтиҗәсендә «Татар совет театры» (1975), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (1988), «Актёрское искусство современного татарского народа» (1978) кебек коллектив монографияләр, И.И.Илялованың «Межнациональные связи татарского театра» (1985). Д.Ә.Гыймрановаңын «Гөлсем Болгарская», «Габдулла Шамуков» (1985), М.Г.Арслановның «Хусаин Уразиков» (1986), «Татарское режиссерское искусство (1906—1941)» (1992), «Татарское режиссерское искусство (1941—1956)» (1997) һ.б. күләмле хезмәтләре басылып чыкты. «Театр белеме» белгечлеге буенча М.Г.Арсланов башта кандидатлык, сонрак докторлык, Ф.С.Кадыйрова кандидатлык диссертацияләре якладылар.

Мона кадәр сүз Институтның тел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге эшчәнлеге турында барды. Ләкин, алда әйткәнебезчә, ТӘһТИдә ярты гасырдан артыграк тарих профилендәге бүлекләр дә нәтиҗәле эшләп килде, фәндә тирән эз калдырды. Аларга тукталмыйча, Институт тарихын тулы һәм объектив яктырту һич мөмкин булмас иде.

* * *

Институтта тарих бүлеге 1941 елның февралендә оештырыла. Сугыш чорында анда бер генә кеше—А.А.Тарасов кына эшләгән вакытлар да була. Ләкин бүлек эзлекле төстә киңәя, ныгый бара. 1988 елда анда инде фән кандидатлары гына да 10 га житә. ТӘһТИ чорында 8 кеше докторлык дәрәҗәсенә ирешә.

Бүлекнең нигезен салган, аның йөзен билгеләгән Е.И.Чернышев, Х.Г.Гыймади, Н.И.Воровьев, М.К.Мөхәррәмов, Х.Х.Хәсәнов, З.И.Гыйльманов кебек зур белгечләр белән эшләп, алардан фәнни эстафетаны кабул итүчеләр исемлегенә А.Н.Григорьев, А.Х.Халиков, С.Х.Алишев, А.М.Җәләлов, Ю.И.Смыков, Р.Г.Фәхретдинов, А.Г.Мөхәммәдиев, Р.У.Әмирханов, М.А.Сәйдәшева, К.А.Нәҗипова, З.Г.Гарипова, И.Г.Гыйззәтуллин, К.Д.Дәүләтшин, Г.Л.Фәйзрахманов һ.б. керә.

Бүлекнең ТӘһТИдә тарихи проблемаларны тикшерү эшчәнлеген шартлы рәвештә ике этапка бүлеп була: а) 40—80 нче еллар; ә) 80 нче еллар ахырыннан—мөстәкыйль тарих институты төзелгәнгә кадәрге чор.

Беренче этапта татар халкы тарихын бары тик автономияле республика кысаларында гына яктырту рөхсәт ителә иде. Хәлбуки, сыйнфыйлыкка һәм партиялелеккә, конъюнктурага буйсыну таләп ителгән шартларда да гуманитар өлкәдә һәм ижтимагый тормышта эз калдырган хезмәтләр языла. 1950—60 еллар арасында алты мәртәбә рус һәм татар телләрендә ике томлык «Татарстан АССР тарихы» бастырыла. Идеологик климатның бераз йомшаруыннан соң әлеге хезмәт шул ук исем белән ике телдә бертомлык итеп чыгарыла (1968, 1970). Ул үз вакыты өчен бер казаныш булды. Ә 1973, 1980 елларда әлеге басманың кыскартылган һәм иң соңгы чор өстәмәләре кертелгән яңа варианты—«Татарстан АССР тарихы» чыга.

Икенче этапта исә бөтен милләт тарихын өйрәнү өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Бүлек Урта Идел—Урал төбәкләре күләмендәге фәнни проблемаларны хәл итү буенча координация үзәгенә әйләнде. 80 нче еллар ахырында коллектив тышкы дөньяга «тәрәзә ачты», халыкара фәнни мәйданга чыкты. Чит илләрдә фәнни конгрессларда катнашу, башка ил галимнәрен Татарстан туфрагында кабул итү, алар белән актив хезмәттәшлек алып бару тотрыклы төс алды.

80 нче елларда бүлек Идел буеның күп кенә республикаларында һәм шәһәрләрендә аграр проблематикага багышланган төбәкара конференцияләр уздыра. Аларның материаллары аерым җыентыклар булып басыла. 1988 һәм 1991 елларда, күп еллык тикшеренү-эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, ике томда «История Казани» нәшер ителә.

Элек ТӘһТИдә эшләгән галимнәрнең байтагы хәзер Тарих институтында

«История татарского народа» дигән фундаменталь хезмәтне тудыруда актив катнашалар.

* * *

Татарстанда археологик эзләнүләр XIX гасырда ук башланган. XX гасыр башында бу эштә Н.Ф.Калинин, М.Г.Худяков, В.Ф.Смолин кебек танылган белгечләр катнашкан. Аларның игътибарын борынгы чор археология истәлекләре генә түгел, үзебезнең мәшһүр шәһәр үзәкләре—Болгар, Биләр, Казан һ. б.лар да—җәлеп иткән. 30 нчы елларда А.П.Смирнов җитәкчелегендә борынгы Суар һәм Болгар шәһәрләре урыннарына экспедицияләр оештырыла. Институт археологик тикшеренүләр буенча махсус үзәккә әйләнә. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы оешканнан соң археологик тикшеренүләр академия кысаларында үткәрелә башлый. Алтмышынчы елларга кадәр археологлар Куйбышев ГЭСы зонасында җитди тикшеренүләр алып баралар. Бу экспедициянең бишенче (Казан) отрядын Н.Ф.Калинин җитәкли. Н.Ф.Калинин һәм А.Х.Халиков җитәкчелегендә кыска гына вакыт эчендә Обсерватория, Займище поселоклары, Зур Утар, Атабай, Карташиха авыллары төбәгендәге борынгы һәйкәлләрне өйрәнү оештырыла. Археологик культурага исем биргән Имәнкискә калдыклары тулысынча ачыклана.

Илленче елларда археологлар төркеменә аспирантура тәмамлаган Һ.В.Йосыпов, Т.А.Хлебникова, В.Ф.Генинглар килеп кушылды. Алтмышынчы елларда «археология» белгечлеге буенча аспирантураны П.Н.Старостин, Е.П.Казаков, Р.Г.Фәхретдинов; җитмешенче елларда—Р.С.Габәшев, Р.Ф.Шәрифуллин; сиксәненче елларда Ф.Ш.Хуҗин, Г.И.Дроздова, М.Ш.Галимова, В.Н.Марковлар тәмамлый. Аларның күбесе хәзерге Тарих институтының Археологик тикшеренүләр милли үзәгендә эшли.

Институтта 1961 елда А.Х.Халиков җитәкчелегендә археология һәм этнография бүлеге оеша. Ул елларда эзләнү эшләренең төп бурычы Татарстанның археологик картасын төзү була. Бу эш җитмешенче еллар ахырына тәгалләнә һәм берничә елдан алты томлык булып басылып чыга. Археологик картаны төзүгә зур өлеш керткән А.Х.Халиков (вафатыннан соң), Р.С.Габәшев, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин, Р.Г.Фәхретдинов, Т.А.Хлебникова, Ф.Ш.Хуҗин, Һ.В.Йосыпов (вафатыннан соң) 1994 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә лаек булалар.

Заманында Көнчыгыш Европадагы иң эре шәһәрләрнең берсе саналган Биләр шәһәре калдыкларын эзлекле тикшерү эшләре 1967 елда башланды (бу экспедицияләрне башта А.Х.Халиков, аннан Ф.Ш.Хуҗин җитәкләде). Чирек гасыр дәвам иткән өзлексез эзләнүләр нәтиҗәсендә Биләрнең һөнәрчелек районнары, җәмәгатьчелек биналары (мәчет һәм мунчалар) калдыклары, саклану корылмалары конструкцияләре һәм башка объектлар ачыкланды. Болар борынгы Биләр урынында археологик музей оештырырга мөмкинлек бирде.

50 нче еллар ахыры һәм 60 нчы елларда башында А.П.Смирнов, аннан соң Т.А.Хлебникова җитәкчелегендә борынгы Болгар шәһәре калдыкларын өйрәнү эшләре дәвам итә. Болгар шәһәренең тарихы һәм мәдәнияте турындагы биш томлы очерклар әзерләнә. Археологларыбыз үз эзләнүләре буенча 50 ләп китап бастырдылар.

Татарстан Фәннәр академиясе оештырылгач, Институтның археология бүлеге Археологик тикшеренүләрнең милли үзәге итеп үзгәртелде һәм аңа Республика территориясендә уздырыла торган барлык археологик тикшеренүләрнең баш оешмасы статусы бирелде. Яңа шартларда ТӘҺТИ археологлары борынгы Алабуга территориясенә, Казан Кремленә, Болгар тыюлыгына экспедицияләр уздырдылар.

* * *

1941 елда ТӘҺТИнең тарих бүлеге составында этнографлар төркеме туплана. 1961 елда археология һәм этнография секторы төзелгәч, әлеге төркемне 1967 елга кадәр профессор Н.И.Воробьев, 1972 елга кадәр—Г.М.Хисаметдинов, 1986 елга кадәр Р.Г.Мөхәммәдова җитәкли. Аспирантура аша фәнгә яшь галимнәр килү татар халкының тарихи этнографиясе буенча яңа проблемалар күтәрергә мөмкинлек бирә. Тикшеренү объекты итеп Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары алына, чөнки анда, нефть сәнәгате үсү сәбәпле, традицион көнкүрештә тизләтелгән үзгәреш

процесслары күзәтелә. Алар Р.К.Уразманованың кандидатлык диссертациясендә һәм күп кенә мәкаләләрендә яктыртылыш тапты.

ТӘҺТИ этнографларының 1960—70 нче еллардагы интенсив эшчәнлеген басылган хезмәтләр ачык дәлилли. Мәсәлән, «Наука» нәшриятында (Мәскәү) Н.И.Воробьев житәкчелегендә әзерләнгән зур хезмәт—«Татары Среднего Поволжья и Приуралья» исемле коллектив монография дөнья күрә (1967). Анда халкыбызның килеп чыгышы, саны, урнашуы, ижтимагый һәм гаилә мөнәсәбәтләре, хужалык, матди һәм рухи мәдәнияте, фольклоры күп яклы яктыртылыш тапкан.

1972 елда Р.Г.Мөхәммәдованың «Татары-мишари» монографиясе нәшер ителә (М.: Наука). Бу—этнография фәнендә мишәрләргә багышланган беренче махсус хезмәт. Шул ук елларда безнең этнографлар СССР Фәннәр Академиясенең Этнография институты тарафыннан «Народы Мира», «Очерки общей этнографии» һ.б.ш. жыелма хезмәтләр язуга да жәлеп ителделәр.

«Татар халкының тарихи-этнографик атласы»н төзү (житәкчесе Р.Г.Мөхәммәдева) милләтебезне этнографик яктан өйрәнүнең өченче этабы булды. Тамбов өлкәсеннән Көнбатыш Себергәчә жәелгән зур территориядә урнашкан 400 ләп татар авылын колачлаган 30 дан артык экспедициядә ифрат бай материал тупланды (кыр көндәлекләре, 50 меңгә якын карточка, бер мең тирәсе фотоплёнка кассеталары, мең ярымлап рәсем һәм сызым һ. б.). Тарихи-этнографик Атлас автор монографияләре рәвешендә язылган 6 томны эченә ала. Алар татар халкының этник һәм мәдәният тарихын өйрәнү өчен фундаменталь база булып тора.



*Дәрдемәнднең 150 еллыгына багышланган конференциядә катнашкан Уфа һәм Казан галимнәре (декабрь. 2009 ел).*

1970—80 нче елларда этнографларыбыз хәзерге мәдәни-көнкүреш һәм социаль-демографик процессларны өйрәнүне дә дәвам иттерделәр. Р.К.Уразманованың «Современные обряды татарского народа» дип аталган монографиясе басылды (1984); Р.Н.Мусина «Современная сельская семья: традиции и инновации» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады. 1990 нчы еллар башында бүлектә этносоциология төркеме төзелеп, ул «Урта Идел һәм Урал татарлары арасында этносоциаль һәм демографик процесслар»ны өйрәнүгә керешә. Бу эшкә Мәскәүнең Этнография институтыннан һәм Казан вузларыннан да белгечләр тартылды.

1993 елдан бүлектә «Татар халкының этносәяси тарихы (VI—XVI йөзләр)» дигән тема буенча да унышлы эш алып барылды. Башкаручысы—тарих фәннәре докторы Р.Г.Фәхретдинов. Аның урта мәктәпләр, лицейлар, гимназияләр өчен «Татарлар һәм Татарстан тарихы» дәреслеге (Казан, 1997; Монреаль, 1998; рус һәм татар телләрендә), фәнни жәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды.

Д.М.Исхаков, Р.К.Уразманова, Й.Г.Мөхәммәтшин, С.В.Суслова, Н.А.Халиковлар 1994 елда нәшер ителгән «Народы России» энциклопедиясенең «Татары» бүлеген язуда катнаштылар.

* * *

1975 елның апрелендә Институтта мөстәкыйль ижтимагый фикер тарихы бүлеге оештырылды. Аны төзүнең инициаторы һәм 11 ел дәвамында житәкчесе философия фәннәре докторы Я.Г.Абдуллин булды.

1993 елдан бүлек «Ижтимагый фикер тарихы һәм ислам белеме бүлеге» итеп үстерелде. ТӘҺТИдә мондый бүлек төзү татар ижтимагый фикеренең күпгасырлык тарихын, аның тарихи-фәлсәфи, социаль-сәяси, хокукый, әхлакый-этик аспектларын эзлекле рәвештә комплекслы тикшерү, белемнәрнең бу өлкәсендәге тикшеренүләрне координацияләү зарурлыгыннан килеп туган иде.

Бүлек формалашкан чорда фәнни-тикшеренү эшләре үзәгендә XIX гасыр—XX гасыр башындагы рухи мирасны, аның фәлсәфи, идеологик, мәдәни эчтәлеген үзләштерү бурычы торды. Бигрәк тә мәгърифәтчелек, җәдитчелек проблемаларына, татар басма китабы тарихына, XIX гасырдагы татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри һ.б.) иҗатына, шулай ук XX гасырда татар ижтимагый фикеренең революцион-демократик агымына игътибар зур булды.

Я.Г.Абдуллинның «Татар мәгърифәтчелек фикере» (1976), Ә.Г.Кәримуллинның «Татарская книга пореформенной России» (1983), М.Х.Йосыповның «Шигабутдин Марджани как историк» (1981), Ф.М.Солтановның «Хөр фикер юлында» (1986), Р.М.Мөхәммәтшинның «Окрылённый борьбой» (1987), авторлар коллективының «Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в.» (М: Наука, 1990) монографияләре, шулай ук күпсанлы тематик җыентыклар һәм фәнни конференцияләр материаллары бу проблемалар өстендә эшләүнең житди нәтиҗәләре булды.

80—90 нчы еллар чигендә—ижтимагый тормышны демократияләштерү һәм милли мәдәниятне торгызу шартларында—бүлектә җәмгыять белеменең чыганак базасы һәм тематикасы күзгә күренеп киңәя. Ислам белеме проблематикасының мөстәкыйль фәнни юнәлешләрен билгеләүдә 1989 елда Идел Болгарстанында исламны рәсми кабул итүнең 1100 еллыгына (һиҗри буенча) багышлап уздырылган фәнни конференция мөһим роль уйнады. 90 нчы елларда бүлекнең халыкара фәнни элемтәләре көчәеп китте, ул мәгълүмат алмашуда, уртак проектлар эшләүдә, бүлек галимнәренең халыкара фәнни конференцияләрдә (АКШ, Англия, Франция, Төркия, Иордания, БДБ илләре) катнашуында, ижтимагый фикер тарихы һәм ислам белеме проблемалары буенча Казанда халыкара фәнни форумнар уздыруда чагылыш тапты.

* * *

1989 елның гыйнварында Татарстанның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре Җыелмасын әзерләү өчен Институтта тарих фәннәре докторы Ю.И.Смыков җитәкчелегендә вакытлы иҗат төркеме (соңрак—бүлек) оештырылды. 1997 нче елның июненнән бүлек Тарих институтына күчерелде һәм аны Р.Р.Хәйретдинов җитәкли башлады.

Шул рәвешчә, бүлек эшчәнлегенең сигез елы ТӘҺТИ чорына туры килә. Бу елларда бүлек хезмәткәрләре, бер яктан, Мәскәү, Петербург, Казан, Самара, Ульяновск, Уфа, Киров һ.б. шәһәрләрнең архив фондларындагы материалларны барлап, икенче яктан, Татарстанның барлык шәһәр-авылларында тарих-мәдәният һәйкәлләрен өйрәнеп, паспортлаштырып чыгалар. Аеруча зур игътибар ижтимагый, дини һәм гражданлык биналарына, тарих, шәһәр төзү, монументаль сәнгать һәйкәлләренә бирелде.

Озакламый бүлектә «Республика Татарстан: памятники истории и культуры. Каталог-справочник» дип исемләнгән коллектив хезмәт дөнья күрде (1993). Икенче җитди басма—Р.Р.Салихов һәм Р.Р.Хәйретдиновның «Татарстан Республикасы: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVII г. ахыры—XX г. башы)» китабы—1995 елда, ягъни шулай ук ТӘҺТИ чорында чыкты. Китап ике бүлектән тора. Беренчесе татар мәдәниятенең мәркәзе булган Казан һәйкәлләренә багышланган. Икенче бүлектә республиканың авыл районнарындагы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр турында язылган. Монда, табигый, ислам һәйкәлләре, ягъни мәчетләр турындагы очерклар зуррак урын алып тора.

Шулай итеп, Институтта озак еллар дәвамында тарих профилендәге 6 бүлек нәтиҗәле эшләп килде һәм соңыннан алар барлык хезмәткәрләре (берничә дистә фән докторы һәм кандидаты) белән бергә ТФАнең Татар энциклопедиясе һәм Тарих институтларын төзү өчен нигез булдылар.

Әйе, ТӘһСИ үзенең 6 бүлеген «башка чыгаргач» та «югары хәзерлекле, күпкырлы, абруйлы һәм нык институт» дигән сыйфатларына лаек булып калды. Ул тора торган «дүрт кит»—тел, әдәбият, фольклор һәм сәнгать белемнәре—асылда һәр кайсы үзе

бер Институт булып үсү перспективасына ия дисәк тә арттыру булмас. Бу инде элеккеге союздаш республикаларда—хәзерге БДБ илләрендә—күптән шулай.

Хәзерге вакытта Институт алдында барлык фәнни көчләрне заман таләп иткән перспективалы тикшеренүләр тирәсенә туплау бурычы тора. Бу максатка ирешү өчен ТӘҺСИнең структурасында өч ел элек житди генә үзгәртүләр үткәрелде. Әйтик, тел белеме проблемалары белән хәзер 3 бүлек: Гомуми лингвистика (мөдире Ш.Н.Асылгәрәев), Лексикология һәм диалектология (М.З.Зәкиев), Лексикография (А.Ә.Тимерханов) бүлекләре шөгыльләнә. Соңгысы, җәмгыятебездә төрле тип сүзлекләргә ихтыяжның зур булуын, лексикография фәненең яңа казанышларын үзебездә гамәлгә кертүнең мотлак зарурлыгын истә тотып, мөстәкыйль бүлек итеп төзелгән иде.

Исемнәрен атап үтү рәвешендә генә булса да, ТӘҺСИнең тел белеме өлкәсендә алып бара торган тикшеренүләре белән танышып үтик.

Академик грамматикабызның, «Лексикология» бүлеген дә өстәп, янартылган 4 томлыгын әзерләп бастыру.

Берничә томнан торачак һәм әлегә тюркологиядә күренмәгән «Татар теленең функциональ грамматикасы»н төзи башлау.

150 мең лексик берәмлекне эченә алган 4 томлык аңлатмалы сүзлек, 100 басма табактан торачак ике томлык гидронимнар сүзлеге төзеп бастыру.

Татар теленең лексикологиясе, фонетик төзелеше буенча тикшеренүләр алып бару, орфографик, орфоэпик сүзлекләр төзү.

Институтта ике томлык татар әдәби теле тарихын язу уңышлы башланып китте.

Соңгы вакытларда «Татарстанда тел вәзгыяте һәм тел сәясәте» дигән актуаль проблема буенча актив тикшеренүләр алып барыла. ТӘҺСИ Татарстанның суверенлыгы өчен көрәштә төрле яклап һәм актив катнашты. «ТР халыкларының телләре турында Закон», «ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы» проектлары нәкъ менә бирелдә әзерләнде. Галимнәребез ТР Конституциясе проектын төзүгә, мәгарифкә һәм мәдәнияткә караган закон проектларын камилләштерүгә житди өлеш керттеләр. Институтта, телләр турында Закон кабул ителүгә 15 ел тулу уңаеннан, зур фәнни-гамәли конференция уздырылды. Якын арада яңа «Социаль лингвистика бүлеге» оештыру планлаштырыла. Ул республикадагы тел процессларын анализлау һәм пропагандалау белән шөгыльләнәчәк.

ТӘҺСИ тагын бер фундаменталь хезмәтне—Көнбатыш Себер һәм Түбән Идел буе татар сөйләшләре Атласын (150 табак) нәшер итәргә җыена.

Перспективалы структур үзгәрешләр 2007 елда әдәбият бүлекләренә дә якыннан кагылды. Мөстәкыйль «Кулъязмалар һәм фәнни архив фонды» бүлеге (мирасханә) барлыкка килде. Аның житәкчесе итеп танылган археограф, фән докторы М.И.Әхмәтҗанов билгеләнде. Мирасханәдә күренекле татар язучыларының, композиторларының, театр эшлеклеләренең 170 тән артык шәхси архивы саклана. Монда тагын 7000 нән артык кулъязма китап, 3000 чамасы сирәк басма китап, берничә дистә мең аерым кулъязма тупланган. Алар гуманитар фәннәребезнең барлык юнәлешләрендә эшләүче белгечләр өчен уникаль чыганак булып тора. Арада борынгы әдәбятыбызга гына түгел, медицинага, астрологиягә, юриспруденциягә, шул җөмләдән мөселман хокукларына караган чыганаклар да күп. Көнчыгыш (бигрәк тә гарәп, фарсы) телләрендәге хәзинәләр дә зур игътибарга лаек, аларның байтагы турыдан-туры татар әдәбияты һәм мәдәниятенә мөнәсәбәтле. Мирасханәнең киләчәктә Кулъязмалар Институты булып үсү перспективасы зур. Президентыбыз М.Ш.Шәймиев карары нигезендә, Кулъязмалар, фәнни һәм архив фонды бүлегендәге барлык материалларны тиешенчә саклау, тәртипкә китерү һәм өйрәнү өчен уңайлы шартлар тудыру максатында, бүлеккә Казан Кремлендә житәрлек эш мәйданнары бүлеп бирелде. Бирелдә аспирантура аша махсус әзерлекле белгечләр тәрбияләнә. Соңгы вакытта бүлек мөдире итеп филология фәннәре докторы Р.Ф.Исламов сайланды.

Институт текстологларына хәзер шулай ук мөстәкыйль бүлек статусы бирелде. Беренче чираттагы бурыч—Габдулла Тукайның 6 томлык академик басмасын әзерләү, Г.Исхакыйның 15 томлыгын нәшер итүне төгәлләү. Ә әдәбият белеме бүлегендә татар әдәбияты тарихының яңа таләпләргә җавап бирерлек 7 томлыгын язу буенча эш бара. Гомумән, күптомлы хезмәтләр—институт эшчәнлегенең характерлы

бер билгесе ул. Фольклорчыларның 25 томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасын төзүләре инде әйтелгән иде. Сәнгатьчеләрнең планында дүрт томлык «Татар театры тарихы», өчтомлык «XX гасыр Татарстан рәссамнары» антологиясе, ике томлык «Татарстанда китап сәнгате» кебек фундаменталь хезмәтләр каралган.

Фәнни бүлекләрдән башка, Институт структурасында аспирантура бүлеге, Диссертация советы мөһим урынны алып тора. Казан филиалында аспирантура бүлеге 1946 елдан бирле эшли. Баштарак ул барлык институтларга хезмәт күрсәтә иде (физикларга, химикларга, биологларга һ.б.). Тарихчылар Шамил Мөхәммәдьяров, Мидхәт Мөхәррәмов, драматургия белгече Бәян Гыйззәтуллин ТӘһТИнең беренче аспирантлары булдылар. Байтак еллар бездә аспирантура бүлегенә җитәкчелек җәмәгать башлангычында алып барылды. Аннан соң штатлы җитәкчесе булган идарә оештырылды, 2007 елдан идарә ике кешедән торган мөстәкыйль бүлек итеп үзгәртелде. Мөдире—филология фәннәре кандидаты З.Р.Шәйхелисламов.

Ел саен аспирантурага—көндезге һәм читтән торып укуга—25 кеше кабул ителә. Алар диссертацияләрен мондый белгечлекләр буенча әзерлиләр: РФ халыклары әдәбияты (татар әдәбияты); фольклористика; РФ халыклары телләре (татар теле); театр сәнгате; музыка сәнгате; тасвири, декоратив-гамәли сәнгать һәм архитектура.

Институттагы аспирантлар саны 75—80 арасында тирбәнә. Аларның бер өлеше ТӘһСИнең үзендә эшкә кала, бер өлеше Казанда һәм Алабуга, Чаллы, Уфа, Стәрлетамак, Бөре һ.б. шәһәрләрдә педагогик яки фәнни эшчәнлек алып бара. Әлбәттә, аспирантура тәмамлаучының хезмәт юлын уңышлы дәвам итүе өчен зарури шарт—диссертация яклау. Ә моның өчен тотрыклы эшләүче Яклау советлары булырга тиеш. ТӘһТИнең үзендә тел һәм әдәбият белгечлекләре буенча андый совет 1982 елдан бирле эшләп килә. Шул вакыт дәвамында бирегә 265 кандидатлык диссертациясе якланды (башка оешмалардан килеп яклаучылар белән бергә). Ә докторлык диссертацияләрен татар филологлары Мәскәү, Алматы, Баку, Ташкент шәһәрләрендә яисә махсус, рөхсәт алып, Казан университетындагы кандидатлык советында яклап килделәр. ТӘһТИнең үзендә исә беренче докторлык диссертациясен «Татар фольклорының афористик жанрлары» дигән темага 1995 елда Х.Ш.Мәхмүтов яклады. Моның өчен ВАК (Югары аттестация комитеты) безнең институтта бер генә мәртәбә яклау советы төзеде. Ә даими нигездә эшләүче докторлык советы бездә 1997 елның апрелендә оештырылды. Шунысы да бик мөһим иде: ана, тел һәм әдәбият белгечлекләреннән тыш, фольклор буенча да яклату хокукы бирелде. Шуннан бирле совет аша 23 докторлык диссертациясе узды. Аларның уннан артыгы—ТӘһСИ хезмәткәрләренеке.

Хәзерге вакытта Институтта 85 фәнни хезмәткәр, шул исәптән 18 фән докторы һәм 48 фән кандидаты эшли. Бер галим—М.З.Зәкиев—Татарстан фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Ф.Ә.Ганиев, М.Г.Арсланов, К.М.Миңнуллиннар—бу академиянең мөхбир-әгъзалары. Коллективта сигез кеше «РФнең атказанган фән эшлеклесе» һәм «РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре», 25 кеше «ТРның атказанган фән эшлеклесе», «ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә. Институтта әзерләнгән фундаменталь хезмәтләр өчен 8 галим Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә, 11 кеше Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә лаек булды, 3 кешегә ТФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге бүләге тапшырылды.

Шулай итеп, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм аның тырыш коллективы үзенең 70 еллыгын күркәм казанышлар белән билгеләп үтте. Алда—яңа үрләр. Аларны яулау өчен Институтның тулы мөмкинлекләре бар.

# АФЗАЛ ШАМОВ—ГОМӘР БӘШИРОВ: ФРОНТ ҺӘМ ТЫЛ ХАТЛАРЫ

*Бөек Ватан сугышы җиңү белән тәмамланганга 65 ел. Күпме гомер узган. Әмма ул дәһшәтле сугыш елларының сулышы әле бүген дә сүнмәгән, халыкның хәтерендә яши. Бүген безнең өчен ул елларның ядкарьләре бигрәк тә кадерле. Ватан сугышы елларында безнең аталарыбыз хатлар алышканнар. Язучы Афзал Шамов 1943-1946 елларда башта Калинин, аннан соң Беренче Балтыйк буе фронтларының «Алга, дошман өстенә» һәм Байкал арты фронтының «Суворовча кысырыклау» исемле газеталар редакцияләрендә хәрби хәбәрче булып хезмәт иткән. Ә Гомәр Бәширов сугыш елларында «Совет әдәбияты» журналының җаваплы сәркәтибе, ТАССР ХКС каршындагы Радиолаштыру һәм радиотапшырулар комитетының баш мөхәррире вазыйфаларын үтәгән.*

*Алар алышкан хатларның саны күп түгел, ни барысы 26. Әмма ул хатларда сугышның фронттагы кайнар сулышы да, тылдагы халыкның көндәлек авыр тормышы да реаль чагылыш алган. Һәм шунысы да игътибарга лаек, ике язучы арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре, бер-берсенә булган ихтирам һәм игътибарлык бүгенге көндә барыбызга да яхшы үрнәк булып торырлык.*

*Бүген, Бөек җиңү бәйрәме көннәрендә, без аталарыбызның архивларыннан ул хатларны алып, хөрмәтле укучыларыбызның игътибарына тәкъдим итәбез.*

**Әлфия ШАМОВА,**
**Зөфәр БӘШИРОВ**

Хөрмәтле Разин[1] иптәш!

Мин әле генә алгы линияләрдә йөреп кайттым. Бу материалны шуннан алып кайткан идем. Бәлки, радио аша бирә алырсыз. (Билгеле, әгәр инде соңга калмаса.)

Очерклык материалларым шактый. Кирәк тапсагыз, эшләштергәләп җибәргәләрмен.

Иптәшләргә сәлам диген: Кавигә[2], Гарифка[3], Газый Кашшафка[4], Таҗига[5] һәм башкаларга.

---

[1] Разин – Гомәр Бәшировның псевдонимы. (1901-99), язучы, фольклорчы.
[2] Кави – Кави Нәҗми (1901-57), язучы.
[3] Гариф – Гариф Гобәй (1907-83), язучы.
[4] Газый Кашшаф – (1907-75), тәнкыйтьче, әдәбият галиме.
[5] Таҗи – Таҗи Гыйззәт (1895-1955), драматург.

Вакыт табып, озын итеп, бер хат язармын әле. Бусы болай гына.

Сәлам белән, А.Шамов.

28/III-1943.

P.S. Мирсәй[6] кайтмадымы? А.Ш.

***

10 май, 1943ел.

Гомәр дускай!

Хәзер генә хатынны алып укыдым да, күңелемдәге шатлык хисләре искергәнче җавап язарга утырдым. Чыннан да, Гомәр, исәнлегенне белдереп, чамасыз шатландырдың. Синен шундый бәлагә очравынны ишетеп бик тә кайгырган идем. Үзенне саклый күр, дус кеше! Кирәк син безгә, бик кирәк! Сине югалту—бик зур югалту һәм чамасыз кайгы булыр иде.[7]

Үзең әйтмешли, башыңның ныклыгы өчен тырышкан атана рәхмәтләр яусын!

Җибәргән әйберләремне алгансыз икән. Җибәргән нәрсәләремнән үзем болай берсеннән дә канәгать түгел. Эш арасында гына язылган әйберләр. Мина монда редакциянең кара эшләрен бик зур камыт киеп алып барырга туры килә.

Мин монда калдым шикелле ахры. Шундый карарга килдем. Кешеләр сугышалар, кан коялар, хәтта җаннарын да бирәләр, ә мин бертөрле дә файдалы эш күрсәтмичә йөри бирәм. Бәлки, монда бераз файдам тияр, дидем. Файдалы булырмынмы, юкмы,—анысын киләчәк күрсәтер.

Болай үзем Казанны, иптәшләрне һәм аеруча балаларны бик сагынам. Семьямны мин бернәрсәсез диярлек калдырып киттем.

Озакламый кунакка кайтып киләчәкмен. Шулай сөйләшелгән иде.

Үзеңә һәм семьяңа бик күп сәлам.

Элекке шикелле тазарып җитүенне теләп, А.Шамов.

21475-С

Г.Бәширов кулы белән өстәлгән:

23/V 43ел. Ж. яздым.

***

Афзал!

Сиңа һәм андагы барча иптәшләргә бик күп сәлам.

Шундый яхшы теләктә булуың, шатлык белдерүең өчен сиңа чын күңелдән бик зур рәхмәт. Шундый вакытта якын иптәшләрнең җылы сүзләре күңелне күтәреп, көчне арттырып җибәрә.

Алайса, син шунда ныгыгансың икән. Гаҗәп яхшы булган. Безнең мәхәллә кешеләренең фронтта иң кирәк һәм иң файдалы тармакта эшләүләре өчен мин бик шат. Киләчәктә безнең халыкның бу тиңсез батырлыгы турында иң һәйбәт әсәрләрне сездән көтәргә бөтен мөмкинлегебез бар һәм ышанычыбыз зур. Эшеңә уңыш телим.

Иптәшләр монда искечәрәк кенә эшләп киләләр. Әллә ни зур үзгәрешләр юк дип әйтерлек. Бу арада барыбыз да бик тырышып җир сөрдек, бәрәңге, чөгендер шикелле тәмле әйберләр үстерәбез. Боерган булса, көзгә таба кишер, чөгендер бөккәннәре ашарга тагын бер кунакка кайтып кит. Үзебез үстергән бакча җимешләре белән менә дигән итеп сыйлап җибәрербез.

Кашшаф белән Кави язгы чәчүгә чыгып киттеләр, Мирсәй кайтты да хәзер Радиода барыбыз өчен дә тирли-тирли эшләп ята. Фатих[8] дигән егетебез һаман да

[6] Мәрсәй – Мәрсәй Әмир (1907-80), язучы, драматург.

[7] 1943елның март аенда Г.Бәшировны эштән кайтканда караңгы кичтә йөк автомобиле бәреп, башын каты җәрәхәтли. Өч атна больницада ята, соңыннан озак кына вакыт укый-яза алмый.

[8] Фатих – Фатих Хөсни (1908-96), язучы. Ул вакытта Көньяк фронтында чыга торган «Сталин байрагы» исемле газета редакциясендә командировкада була.

кайтып житә алмый әле. Ие, онтылганчы язып калыйм: Ибрайның[9] монда хаты килми диләр, ул ни хәлдә икән, син аның белән хәбәрләшмисеңме?

Кунакка кайтып килә алсаң, чыннан да бик шәп булыр иде, һәйбәтләп бер сөйләшеп утырыр идек. Балаларың белән бергә без дә сагынабыз. Тик мин сине күрә алмам шикелле. Мине, агаене, тегеннән-моннан әтмәлләп бер айга авылга озаталар, бераз җилләп, катык-сөт ашап кил диләр. Шундый кызу эш, каты сугыш вакытында ике айдан бирле эшкә тотына алмау бер дә егетлек тә түгел, килешми дә, күңел дә риза булмый. Каһәр төшкән бу аяк астыннан чыккан бәланы алай тиз генә җинеп булмый икән. Сугышта берәр эш күрсәтеп сафтан чыккан булсаң, ичмаса ул ягыннан вөҗданың борчылмас иде.

Ярый, шуннан соң килеп, бәлки иң кирәк чагына без дә барып житәрбез әле. Өмет юк түгел.

Я, исән-сау бул, батыр сугыш.

Кулыңны кысып, Гомәр Бәшир углы.

Вакыт таба алсаң хат яз.

23/V 43ел. Казан, әлеге Акком—асты.[10]

***

Әфзалетдин!

Синең «бер кемгә дә түгел» хатыңны берәүнең өстәлендә күреп хәйран калдым. Гаҗәп инде безнең халык, шундый ваемсыз, шундый пәрвайсыз.

Болай безгә пычагым да булмаган. Бары да үз урнында. Нык утырабыз, инде утыргычларыбызга мүк үсә башлады.

Нинди яңалыклар бар дисең син. Моннан элегрәк булганнарын син ишеткәнсең инде. Соңгылары шундыйлар: Мирсәй «Җенлекамал»ын[11] язып театрга тапшырды. 15/IV дә карарга барабыз. Агаенең һәм дәү абыйларның фикере яхшы. Шәт бер уңышлы әйбер күрербез дип торабыз. К. шадра[12] г.Сафиуллин янына китеп бетә алмыйчарак йөри. Исәнбәт[13] яза, Мирсәй яза, Гомәр шадра[14] да язгандай итә, әлхасил барысы да яза. К.Газый[15] В.Совет—ХКС—НКТ—НКТЦ—һ.б. НК лар маршрутына чүп төшермәскә тырышты. Әдәбият хадимнәрен кайгыртырга кирәк ләбаса.

Гонорар хәл ителер төсле (ничә айдан бирле!)

Менә шул. Шулардан башка телгә алып әйтерлек берни дә юк диерлек.

Үзеңдә ни хәлләр бар? Ничегрәк сугышасың? Соңгы вакытларда мин синең турыда берни дә диярлек ишетә алмадым. Бер көннәрдә иптәшеңне очыратып сорашкан идем. Синнән хат килми торуын әйтте.

Соңгы көннәрдә синең «Өзелгән кыллар» дигән хикәяңне укып чыктым. Ул журналның 2-3 номерына керде. Син сугышны бетереп кайтуга өстәлеңдә булыр. Шушы арада Газый тагын бер хикәяңне күрсәтте. Язгалап торуың бик шәп. Кыендыр инде, ул шундый шартларда ансыз булмас. Юк вакытны бар итеп әдәби әсәр язу ул үзе генә дә зур батырлык.

Мин дә тырышкан булам. Әгәр яңадан эшкә тотып утыртмасалар, җәйгә бер әйбер әтмәлләп чыгарырмын шикелле.

Казанда яз. Янгырлар яугалый. Язгы чәчүгә иртәрәк чыкмакчы булабыз.

Абдул Әхмәт[16] ни эш бетерә? Аңа һәм иптәш Гимадиевка[17] күп сәлам.

---

9 Ибрай—Ибраһим Гази (1907-71),язучы. Шул ук «Сталин байрагы» исемле газета редакциясенең штаттагы хәрби хәбәрчесе.

10 Акком-асты—Казанның Иске бистәсендәге борынгы урам. Хәзер ул урам юк.

11 «Җенлекамал»—Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» (1944) пьесасын язучылар үзара шаяртып шулай атаганнар.

12 К.шадра—Кави Нәҗми. Язучылар үзара шаяртып әйткән кушамат.

13 Исәнбәт—Нәкый Исәнбәт (1899-1992),язучы,драматург.

14 Гомәр шадра—Гомәр Бәширов.

15 К.Газый—Гази Кашшаф.

16 Абдул Әхмәт—Абдулла Әхмәт (1905-76),язучы.

17 Гимадиев—Минһаҗ Гыймадиев (1903-70),журналист,Беренче Балтыйк буе фронтында чыга торган «Алга, дошман өстенә» исемле газета редакциясендә редактор урынбасары.

Вакытың мөмкинлек бирсә хат яз.

Сәлам белән Г.Разин

(Син бу хатның башын укый башлаганчы мөгаен ахырын әйләндереп карыйсың инде. Бүген минем башым да, кулым да кыйшайган иде. Тегеннән моннан түгел, болай гына)

22/III.44

***

16/IY—1944.

Акком астының чибәр егете!

Хатыңны алгы сызыкка чыгып китәр алдыннан гына алдым. Шуңа күрә дә бик ашыгып, аяк өстеннән генә язам. Хатың гаҗәп озак килгән. Кайда булса да кысылып яткан булса кирәк.

Хатыңа һәм искә төшерүеңә гаҗәп зур рәхмәт. Тагын бер мәртәбә рәхмәт. Казандагы иптәшләр арасыннан бик азлары гына хатка каршы хат язу әдәбен беләләр. Ә син, мин язмый торып та, кулыңа каләм алгансың. Бәлки, шуңа күрәдер дә, мин сиңа бүген аеруча хөрмәт саклап, юлыма чыгып китәм. Монда иптәшләрдән хат алгач, ничектер аякны да җинелрәк атлыйсың, хәтта иркенрәк, киңрәк сулаган шикелле дә буласың. Менә, кечкенә генә кәгазь кисәге дә карт солдатны нишләтә ала!

Иптәшләрнең эшләүләрен ишетеп, бик шатландык. Төкле аяклы ел булсын иде бу безнең әдәбиятка!

Урыны туры килгәндә, дусларча гына әйтеп үтим әле. Ну үзеннең дә почеркың! (Гәрчә минем үземнең дә бик начар!) Гапдулла[18] белән икәү хатыңны укый торгач, тәмам тирләп пештек. Хәер, аның шулай булуы да ярый. Алгы кырыйдан әйләнеп кайткач, мин әле, изүләремне чишеп җибәреп, тагын бер тапкыр укыячакмын. Миңа әле ул серләре ачылып бетмәгән хат шикелле булып тора.

Син тагын үпкәләмә. Бу сүзләр хөрмәт һәм шатлык аша язылалар.

Казандагы иптәшләргә бик күп итеп сәлам әйт. Газыйга, Кавигә, Мирсәйгә, М.Галига[19] аеруча.

Сәлам белән, кулыңны кысып, Афзал.

P.S.

Бик ашыгып кына сызгаладым. Үзең киртәсенә кертеп укырсың!

А.

21475-С

***

Афзал!

Хатың өчен рәхмәт. Сезгә кайчакларны хат язарга вакыт табу да кыен була инде ул, шулай була торып та язгансың әле.

Бик яман илһамланып (янәсе инде) язып утыра идем, Иделдән бик матур, бик тә монсу һәм рәхәт итеп пароход тавышы ишетелде (Син беләсең, безнең Акком-астына бик якын бит инде ул). Шуннан, тукта әле, Афзал дуска бер хат язып ыргытыйм дип мона тотындым. Менә шулай каршымда гына Мәскәү сәгате суга (димәк, 5нче майга атлыйбыз), ә мин сиңа хат язам.

Бу арада бөтен халыкка бакча бизгәге тиде. Кыр тулы халык, чуп-чуар. Түтәл саен әбиләр, җингиләр, балалар... Яулыклар артка бәйләнгән, кулда көрәк. Бәрәңге бакчасы казыйбыз. Быел бер карыш җир дә казылмый калмас шикелле.

Шулай, казыйбыз, бар да хатын-кыз, әбиләр, балалар. Алар арасында, сирәк мирәк утырган әрем сабагы шикелле без, әлеге саплылар. Шулай каранып торасың да кайчак үзеңне гаепле кеше шикелле тоя башлыйсың. «Нигә без монда? Нигә

[18] Гапдулла — Абдулла Әхмәт.

[19] М.Гали — Мөхәммәт Гали (Галиев) (1893-1952), язучы, әдәбият галиме.

болай?» Кайбер хатын-кызлар күзендә дә ара-тирә шундый дип уйларлык, күнелсез хис калдыра торган караш очыратасың. Үзең теләп шулай бер читкәрәк тайпыласың кебек, үзең шуны теләмәсән, син дә анда, юньле кешеләр янында булыр иден кебек. Бәлки синең монда калуыңнан көнләшмиләрдер дә, бәлки ул шулай тоела гына торгандыр. Һәрхәлдә, мин фәкыйрегезгә берничә елдан бирле әнә шул авыр хисне җилкәмә күтәреп йөрергә туры килә.

Ни өчен калуыбыз мәгълүм: язарга кирәк. Әгәр юньлерәк әйберләрне тиз генә язып булса, ул әле тагын бер хәл иде. Менә өч ел утырабыз бит инде, әле кулга алып укырлык нибары бер-ике әйберебез генә бар. Менә кайда бәлә. Сез бит бер заман кайтырсыз. Капитан да майор, полковник та генерал... Дөньяны тетрәтеп кайткан сугыш офицерлары, күкрәге орден белән тулган каһарман содатлар янында без нәрсә булып калабыз инде, чүп, тфү...

Син инде үз кеше, телең дә бик алай ачы түгел... (син бит йомшак әйтеп каты утыртасың.) Әнә анда, синең янында Әхмәт агай утыра. Менә ул әйтә тек әйтә инде. «Вот понимаешь! диер, безобразие! диер, өч ел буена шушы булдымы бөтен эшегез?» диер. Безнең агай-эне шунда инде почмакта посып кына утырган җиреннән чыгып күрсәтеп карар каравын «Менә, дәү абыйлар, без менә шушы кечтеки әйберләрне язып караган идек каравын да, сезгә ошаса...»

Әгәр ул әйберләр сезнең солдат халкына шунда бер-ике тапкыр махра төрергә бетә торган булса? Шулай эшләр, Афзал дус. Эшләребез хәзергә бик хөрти. Зур әйберләр хәзергә юк әле. Алар өметтә генә. (Ләкин унышлы әйберләр күбәя башлады, анысы бик күнелле факт. Мәсәлән, Мирсәйнең «Миңлекамал»ы Академияда[20] бик унышлы бара, «Фәридә»гә[21] музыка язылып бетеп килә. Аны да яхшы диләр).

Мин дә бер әйбер язып ятам.[22] 2-3 айдан үзем теләгәнчә итеп эшләп бетерә алсам бик канәгать булыр идем. Болай ярыйсы бара шикелле. Ләкин бик авыр, дус кеше, шундый авыр, кайчакларны үземә-үзем ышанмый башлыйм. «Әллә мин булдыра алмыйммы икән?» дип шөбһәләнеп тә куям. Ләкин шунда ук күнелгә яхшы уй килә, булдырам төсле, менә бу төшен генә җинәсе, менә монысын гына болай эшлисе, аннан соң җинеләя кебек. Шулай итеп үз-үзенне батырайтып утырасың инде ул.

Хәер, миңа кыен булуы да гаҗәп түгел. Бик тә соң тотындым бит. Миңа бер үк вакытта белемемне дә тирәнәйтергә, өйрәнергә дә, эшләргә дә туры килә.

Я, мин үзем турында лыкылдап синең хәлеңне дә сорашмый калам бугай. Ничегерәк сугышасың? Ничек яшисең? Журналга язарга вакыт таба алмыйсыңмы?

Абдулла һәм башка иптәшләргә миннән күп сәлам. Абдул гүзәле дә, синеке дә бүген бәрәнге җире казырга барганнар иде. Бер тирәдә эшлибез. Иртәгә хат килүен әйтермен.

Кәгазь бетә, минем сүз бетми. Бу хатны язуы күнелне күтәреп җибәрде әле. Мин шулай такылдыйм, ә син минем каршыда я хуплап, я үчекләп мыек астыннан гына елмаеп тыңлап утырасың шикелле.

Хуш, туган, хат яз. Сәлам белән, Гомәр Аккомасты.[23]

5/V-44.

***

4/VII-1944.

Гомәр дус!

Мин синең озын һәм жылы итеп язылган хатыңны бик күптән алган идем. Шушы көнгә кадәр һич тә җавап яза алмадым. Гафу итүенне үтенәм. Сәбәбе болай булды: озын хат язарга вакытым булмады, мин озын хат язмакчы булып өметләнеп йөрдем.

---

[20] Академия—Татар академия театры, Галиәсгар Камал исемендә.

[21] Фәридә—композитор Михаил Алексеевич Юдинның (1893-1948) «Фәридә» исемле операсы (1945).

[22] Сүз «Намус» романы турында бара.

[23] Гомәр Аккомасты—автор шаяртып борынгы традиция буенча фамилиясен торган урам исеме белән атаган.

Һөҗүмгә хәзерлек унае белән еш кына чыккалап йөрергә туры килде. Аннары инде, үзенә мәгълүм, кызу көннәр башланып китте. Мондый көннәрдә безнең хезмәт тә зур оперативностьны таләп итә. Ахырда, шушы кыска гына хатымны язарга булдым.

Әле генә алгы кырыйдан кайтып кердем. Йөз километрдан артык араны немецлар ташлап калдырган техника һәм аларның череп, сасып ята торган үләкләре аша үттем. Без шушы ел ярым эчендә күп мәртәбә һөҗүм итеп карадык. Бу һөҗүм элекке һөҗүмнәрдән үзенең омтылышлылыгы һәм алга барудагы уныш белән генә түгел, ә немецларның меңнәрләп кырылуы һәм безнең бик аз, хәтта уйламаган дәрәҗәдә аз югалтуыбыз белән дә характерлы. Сугышчыларның рухы гаять күтәренке. Аларның, һәркайсының да йөзләрендә шатлык һәм батырлык аңкып тора. Хәтта без дә, каләм белән генә сугышучылар да, кайчакларында кулыбызга автомат алабыз, кызылармеецлар белән бергә сугышка кушылып китәбез. Шундый хәлләр туры килгәли.

Миңа соңгы баруымда берничә мәртәбә җитди генә сынауларны үткәрергә туры килде. Аллага шөкер (моны карт аллага ышанганга түгел, ә мона туры килерлек сүз булмаганга күрә генә язам), бер сынауда да йөзгә кызыллык китермәдем. Моны мактанып әйтүем түгел, ә миңа ике тапкыр рекомендация биргән кешегә хөрмәт итеп һәм отчет бирергә теләп әйтүем генә. Киләчәктә дә рекомендацияне акларга тырышырмын, дускай.

Шушы көннәрдә генә И. Газыйдан хат алдым. Ул Казандагы иптәшләрнең хатка каршы җавап язмаганлыклары өчен үпкәли.

Г. Кашшафның авыруы турында ишетеп бик борчылдык. Сез зинһар анда ана бөтен ярдәмне күрсәтергә тырышыгыз. Кулдан килгәнне барсын да, барсын да эшләргә кирәк. Егетне ничек тә аякка бастырырга кирәк. Сездән минем үтенеч шул.

Зур уңышлы иҗат эшләре белән шөгыльләнүегезгә барыбыз да шатланабыз.

Әгәр вакытың булса, ара-тирә Казан хәлләре турында язгалый тор. Монда безгә андагы һәрбер хәбәр яңа һәм кадерле.

Аннары без синнән үзеннең нәрсә өстендә эшләвең турында язып җибәрүеңне сорап, хат җибәргән идек. Җавап көтәбез әле без. Онытканыбыз юк.

Кулыңны кысып, сәлам белән, А.Шамов.

21475-С

***

Гомәр! Дускай!

Мин командировкада вакытта, әгәр дөрес булса, синнән открытка килгән булган икән. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, миңа ул хатны күрергә насыйп булмады. Аны безнең арадагы каһәр төшкере егетләрнең берсе алган да югалткан. Хәтта югалтканын да әйтми. Гафу үтенү турында уйлаган да юк. Кеше хатларын еш кына шулай алып, югалта торган бер кеше бар безнең. Аннан мин генә түгел, башкалар да зарланып бетә алмыйлар.

Шулай итеп синең кош теледәй хатың минем кулга эләкмәде.

Син белә торган егетләр без монда барыбыз да исән-сау, җен кебек тазалар.

Сиңа без бервакыт редакция исеменнән, Әлменов[24] артыннан бер хат җибәргән идек,. җавап бирергә теләмәдең, күрәсең. Ах, егет, егет, шулай ярыймы соң! Әллә җилләнеп кенә сызгалап җибәрәсеңме? Без бик шат булыр идек.

Габдулланың да, минем дә Казан хәбәрләрен бик беләсе килә. Шундый хәбәрләрнең вагына-төягенә кадәрен тутырган бер хат җибәрсәң, башларыбыз күккә тияр иде.

Яза торган әсәреңне бетердеңме? Әгәр бетергән булсаң кулыңны кысарга рөхсәт ит.

[24] Алменов – Байназар Альменов (1909-76), график. 1944 елда ике айдан артык «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасы редакциясендә иҗади командировкада була.

Иптәшләрдән кемнәр, нәрсәләр өстендә эшлиләр?

Газый Кашшафның хәле ничек? Сез ана инде, дуслар, кулдан килгән барлык ярдәмне күрсәтегез. Без кайткан вакытка ул типсә тимер өзәрлек булсын.

Мине сораган иптәшләргә яисә искә төшергәннәргә сәлам диярсең инде.

Дусларча кулыңны кысып калам. Афзал.

P.S.

Хатымны керентеле-чыгынтылы язганга гаҗәпләнмә. Ерак юлга чыгып китәр алдыннан гына язам. Без кайчагында шулай юлга киенгәч, револьверны, автоматны һәм капчыкны асып җибәргәч, Матбугат йортына бер генә минутка булса да шулай барып чыгасы иде дибез. Ә мин кайчагында гранаталар тагып та кайтып керәм. Имеш, авызы пешкән кеше. Өреп кабам янәсе.

Чыннан да, сезгә күренү түгел, ә сезне күрү зур бәхет булыр иде.

А.

Г.Бәширов кулы белән өстәлгән:
15/X хат яздым.
2/XI дә А.Әх. белән икесенә открытка.
26/XI—үзенә. 44.

***

Афзал!

Исәнме, агаене, таза-сау гына торасыңмы? Күрше-коланнарың да иминлекме, мәсәлән, Габдулла күршең.

Кош теледәй хатымның башына җиткәннәр икән, хәерле булсын. Әйдә, аның орлыгы Бохарада түгел, аның урнына менә дәүрәген языйм. Сезне матбугат йорты бик кызыксындыра икән. Гаҗәп түгел. Нихәтле тузанлы һәм шапшак булса да без барыбыз да ул йорттан аерыла алмыйбыз.

Әйдәгез, телисез икән, бергәләп барып кайтыйк.

Акком астыннан чыгар алдыннан, җинелрәк булсын өчен, бер кечкенәне сындырырга мөмкин. Чыгып киттек. Кояш, җылы, аяк астында сары яфраклар кыштырдый. Татарстан урамында тәтен. Тротуарга асфальт җәяләр. Урам тулы бәрәңге. Ничек кенә ташымыйлар! Күтәреп тә, уфалла[25] белән тартып та, автомобильдә дә, трамвайда да. Тик самолетка гына менеп җитә алмадык. Нәтиҗә: идәннәр тулды, чарлакларда да урын калмады, су кисмәгенә тутырдык, кроватьларга өйдек. Әгәр хәзер сезнең белән колхоз базарыннан узсак, яз кәне берничә бәрәңге алган акчага бер пот бәрәңге алган булыр идек. Бер пот! (Мин үзем бакчаны консерв банкалары белән ашлау сәбәпле 13 капчык алдым.)

Ярый, ары киттек. Чатта витамин суы. Таза булыйм дисәң, рәхим ит: бөтен бәләсе бер акча. Менә афишалар. Цирк ачыла. БДТда «Отелло», «Тот, кого искали» һ.б. Электрода[26] «Ураган». Ә Академияныкы күренми. Хәер, аны мин күрмичә дә әйтә алам: «Банкрот», «Хажи әф...»[27]

Матбугат йортының 3нче катында сулга борылыйк. Мирсәй әйтә, Кавигә югары менеп йөрү кыен булганга без түбәнрәк төштек ди. Мин үзем аңа ышанмыйм.

Ярый, Казанлыларга ишек шакымыйча гына барып кердек ди. Монда сез Кашшаф белән Кавине күрәсез. Кашшаф ипиен ашый-ашый дәү абыйлар алдына куясы тезисларын язып утыра, ә Кави язмыйча да билгеле, анысы нинди дә булса бер проект оештыра булыр. Менә ике хәрби кеше килеп керәләр. Берсе Ерикәй[28], икенчесе Әхмәт Фәез[29]. Болар икесе дә кунаклар.

—Кем нәрсә яза, кайчан бетерә? «Батырлар китабы» ни хәлдә? Нигә фронтовиклар нәрсә язуларын әйтмиләр? Язалармы алар, әллә юкмы? Нинди зур әйберләр булуы

[25] Уфалла—халыкта кул арбасын ачы ирония белән шулай атыйлар иде.
[26] Электро—кинотеатр, хәзерге исеме «Татарстан».
[27] «Хажи әф...»—«Хажи әфәнде өйләнә»—Шәриф Камал комедиясе.
[28] Ерикәй—Әхмәт Ерикәй (1902-67), шагыйрь.
[29] Әхмәт Фәез—Әхмәт Фәйзи (1903-58), шагыйрь.

мөмкин?—Сүз шул турыда бара. Кави бер зур әсәргә тотынган. Ел ахырына бетерәм ди. Димәк, мин мыштырдап өлгерә алмасам да безнең бер зур әйберебез буласы икән. Монысы шәп. Әхмәт Юнус[30][6] поэма «өстендә утыра», Тажи пьесасын язып бетереп килә, Н.Исәнбәт—«Нур Вахитын»[31]. Менә Мирсәй. Ул хәзер дә чишелеп бетми. Шулай да тел төбе өметле күренә.

Тагын нәрсәләр? Кичке Марксизм-Ленинизм университетына языласы, иртәгә подсобныйга бәрәнге, кәбестә, помидор алырга барасы, жомга көн жыелыш уздырасы, тагын әллә нәрсәләр эшлисе бар. Кыскасы эш күп, эшләүчеләр житенкерәми.

4нче катка менсәк, коридорда кулын болгап алпан-тилпән атлаган Гумеров[32] булыр. Һаман да шул элекке Гумеров. «С.Ә.»[33]ндә гәпнең куерган чагы. Кем күпме бәрәнге алган, күпме кәбестә. Әнәснең[34] эче авырта, Фатихның[35] кайсы төшедер. 6нчы номер чыкмаган әле.

Каршы якта Композиторлар союзы. Узып барышлый Нәжип Жиһановны яна операсы белән тәбрик итеп узарга мөмкин. «Түләк батыр»га язылган музыкасы гажәп яхшы чыккан диләр.

Менә тагын бер хәрби кеше белән очрашабыз. Синең элекке әшнәң Ермәки (түгел Ярмәки)[36] кешеләр, хәрефләр алып китәргә дип Польшадан махсус кайткан. Аның хәзер бер үзендә өч язучы икән. Синең төтен күршең Ибрай[37], Кутуй[38], Гариф Галеев[39]...

Кәгазь туласы житмәгәнлектән бу сәяхәтне кыскартып шуның белән очласан да була.

Хәлләр кыскача менә шундый, дус кеше. Начар да түгел, бик яхшыдан дип мактанып та булмый.

Инде минем хәлгә килсәк, бер көйгә акырын гына кыштырдыйбыз. Сызабыз да бозабыз дигәндәй, беләсең инде. Шулай итеп син мине тәбрик итәргә кулынны сузмый тор, мин бетергәнче аруы бар.

Бик хәтерле кеше икәнсең. Әллә онытылырмы икән дип йөри идем, булмас ахырысы. Газетага нәрсә эшләвем турында язып жибәрүне искә төшерергә мәжбүр итеп сине борчуым өчен гафу ит. Язарга иренүдән түгел. Турысын гына әйткәндә, әллә нинди зур эшләр кырган кеше шикелле мин фәләнчә, тегәнчә дип шапырынырга бик кыенсынам.

Шуның белән очлыйм инде. Ләкин ничек укырсың икән? Мина язганда минем почерк турында язганнарың искә төште дә кулым тагын да ныграк калтырый башлады. Чамалап кына булса да ерып чыгарсың инде.

Хуш, бик күп сәлам белән Гомәр Аккомасты.

4/X-44.

Егетләр, бу ни хәл бу? Нигә сез альманахка нәрсә жибәрүегез турында язмыйсыз? Абдул нәрсә яза, син үзең нәрсә бирәсең? Абдулга h.б. иптәшләргә күп сәлам һәм иң яхшы теләкләр.

***

Афзал!

Утырышта синең хатынны уйлап утырдым да шул кызу белән сина тиз генә хат язып ташлыйм дидем.

---

[30] Әхмәт Юнус – Әхмәт Юныс (1916-76), шагыйрь.
[31] Нур Вахит – «Мулланур Вахитов», тарихи драма.
[32] Гумеров – Абдулла Гомәр (1906-74), тәржемәче, журналист.
[33] »С.Ә» – «Совет әдәбияты» журналы, хәзерге исеме «Казан утлары».
[34] Әнәс – Әнәс Камал (1908-78), драматург.
[35] Фатих – Фатих Хөсни (1908-96), язучы.
[36] Ермәки – Ярулла Ярмәкиев. Беренче Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасының редактор урынбасары.
[37] Ибрай – Ибраһим Гази (1907-71), язучы. «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.
[38] Кутуй – Гадел Кутуй (1903-45), язучы. «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.
[39] Гариф Галиев (1903-85), язучы. «Кызыл Армия» газетасының хәрби хәбәрчесе.

Алай, син әнә кайларга барып чыккансың! Ул яктан син бәхетле, сугышның иң кыен һәм иң күнелле вакытында үзен дә катнашасың. Халыкның канын эчеп симергән ул үрмәкүчнең оясын тузгытуга мин дә бик шатланып катнашыр идем. Син инде безнең ачуны да үзең белән алып йөр.

Бу юлы мин сиңа бик кыска хат язам. Моннан элек килгән хатына каршы бик озын итеп язган идем, ул бармады ахыры, син җавап язмадың. Күрәсең, бик озын хатлар кемгәдер ошамый ахырысы.

Бездә нинди яңалыклар бар? Әллә ни юк кебек. Һаман шул ук кешеләр. Аерым искә алырлык яңа әсәрләр күренми. Хәер, шушы арада Т.Гыйззәт Донбасс шахтерлары тормышыннан «Зарзаман» дигән пьеса язып бетерде. «С.Ә»ның 7-8 номеры чыкты. Ул сезгә бара торгандыр?

Тагын, Татарстанның 25 еллыгына хәзерләнәбез. Мина һәм тагын берничә иптәшкә шул уңай белән бик күп эшләр йөкләнде. Җөмләдән берсе, оригиналь әсәрләрдән бер яхшы китап оештыру. Бу турыда мин сиңа язган идем шикелле. Күптән түгел Абдул белән икегезнең тагын бер исегезгә төшергән идем. Срогы бик кыскарды. Нәрсә җибәрәсез? Яки хәзер яңа әйберең булмаса, журналда басылганның берәрсен тәкъдим итәсеңме? Сиңа читтә калу һич мөмкин түгел. Фото рәсемеңне дә җибәр.

Минем хәлне сорауың өчен рәхмәт. Әле язып бетерә алганым юк. Килеп каптым, ничек ерып чыгасы булыр инде. Хәер, безнең монда өскә явып тормый, сездәге кебек түгел. Җае белән бер бетәр әле.

Сездә ничегрәк соң? Бик чабасызмы? Бүтән иптәшләрнең кәефе ничек? Абдул ни кырып йөри?

Шушы әйберемне бетергәч, минем дә бер шул якларга барып чыгасы килә иде, ничек булыр.

Я, һәммәгезгә һәммәбездән бик күп сәлам. Хат көтәм. Кыска гына булса да сызып җибәр. Әсәр җибәрү турында Абдулның да исенә төшерсәнче.

Исәнлек һәм эшегездә уңыш теләп, Гомәр Аккомасты.

26/XI-44ел.

***

11 декабрь, 1944ел.

Гомәр дускай, Акком асты егете!

Бөтен Казан хәбәрләрен тутырып язган хатыңны алганга биш былтыр булды. Шулай да әле аның өчен сиңа рәхмәтемне җиткергәнем юк. Мин дә нәкъ синең шикелле үк итеп язарга уйлап йөргән идем, ләкин күрәсең, булдыра алмадым. Соңгы вакытларда өйдә күп утырырга туры килмәү шактый ук комачаулады булса кирәк.

Безнең монда хәзер Казанны безнең туган шәһәребез булган өчен генә түгел, анда хәзер салкын кыш булган өчен дә сагынабыз. Кар шыгырдатып, колаклар туңдырып, рәхәтләнеп йөри торган урын ул. Ә без монда бетмәс—төкәнмәс көз җәфасын, былчырак, яңгырлы көз җәфасын чигәбез. Бу як халкының телен белмәгән кебек, табигатенең серен дә төшенеп бетереп булмый. Кайсы көнне аз гына катырган кебек була, ә аннары җылытып җибәрә дә, атналар буенча вак яңгыр коя, аяк астында тездән пычрак. Өс-баш юеш, бөтен тәнгә үтә. Эт булып, пычранып бетәсең. Менә шуңа күрә дә без хәзер кышкы Казанны аеруча сагынабыз.

Мин сезнең барыгызга да Германия җиреннән бер гомуми хат язган идем. Алгансыз. Әллә ул барып җитмәдеме икән? Мин аны һөҗүм итеп баручылар арасында, шактый ук кызу минутларның берсендә, башы-күзе акайган бер почтальонга биргән идем. Бик алгы кырыйда иде ул. Аның барып җитмәве дә бик мөмкин. Әгәр хат язсаң, аны алу—алмавыгыз турында язсаң ярар иде.

Иптәшләрнең зур-зур әсәрләр өстендә утыруларына, әдәби уңышларына шатланабыз. Ә үзебез өчен бары борчылырга, әрнергә генә туры килә. Барлык вакыт мондагы эшкә китә. Күп кенә вак очерклар яздым, ләкин барсы да үзебез өчен генә.

А. Әхмәткә язган хатка караганда, альманах синең кулда булса кирәк. Мин аның чыгачагын бары хәзер генә белдем диярлек. Ана катнашмый калу бик үкенеч булачак. Бәлки сез ана, әгәр яраклы булса, «Өзелгән кыллар», «Куаклар арасында»» һәм «Күзгә чәчәкләрне» кертерсез.

«Күзгә чәчәкләр» дигән хикәямне Г. Альменов артыннан җибәргән идем. Бу соңгысы турында «С. Ә»на берничә хат яздым, ләкин алар җавап язып ваксынырга теләмәделәр. Гаҗәп дәрәҗәдә борыннарын күтәргән кешеләр ахыры анда, хәтта үзләренең изге бурычларын да оныталар. Җибәргәнгә 10нчы ай. Ярамаса, яраксыз дип язарга тиешләр иде.



*Афзал Шамов белән Гомәр Бәширов— Татарстанның матур әдәбияты редакциясе редакторлары. 1940 ел. Казан. Ибраһим Гази фотосурәте.*

Менә шул өч кечкенәне кертеп булмасмы? Аларның өчесе бер урынына, бары юк урынына. Шундыйрак нәрсәләр инде алар. Үзең беләсең, минем өчен бер тиенлек тә ташлама ясалырга тиеш түгел.

Их дускай, дускай! Без монда сезнең яза алуыгызга чиксез кызыгабыз. Әгәр исән калып, исән кайтсак, без дә бераз бары әдәбият белән генә шөгыльләнер идек дип, күңелләребезне юатып һәм өметләнеп торабыз. Алла насип итсен диген, дускай!

Син инде «Намус»ны язып та бетергәнсең. Озакламый уку бәхетенә дә ирешербез.

Безнең семьяларга утын мәсьәләсе нихәл икән анда? Алар узган елда китертә алмаганнар иде. Әгәр быел да кайбер фронтовикларга китертә торган булсагыз, мина да китертә алмассызмы икән?

Без хәзер камалган ерткычны «тукмаклап бетерү» эшен дәвам иттерәбез. Иптәшләргә сәлам диген.

Кулыңны каты итеп кысып, А. Шамов

***

21/XII—1944.

Гомәр!

Бу хатымны мин алгы кырыйдан язам. Моннан 2-3 көн элек кенә өйдән чыгып киткән идем. Чыгып китәргә берничә минут калганда гына синең өчпочмаклы хатыңны алдым. Хатың өчен һәм җылы сүзләрең өчен бик зур рәхмәт.

Моннан берничә көннәр генә элек бер хат язган идем. Алгансыңдыр дип уйлыйм.

Барыгызга бергә җыеп язган хатны мин Германиядән җибәргән идем. Бусын Балтик буеннан язам. Юлбашчы докладындагы тукмаклап бетерү районыннан. Төрле урыннарда булуыма бик гаҗәпләнмә. Безгә шулай төрле урыннарда булырга туры килә. Быел алгы кырыйда узган елгыга караганда бик еш булгаладым. Хәер, быел елы да аеруча булды бит.

Сездә каты кыштыр инде.簡дә әле кышның килеп җиткәне юк. Һаман яңгырлы, пычрак көз булып торды. Тәмам туйдык. Йөргән вакытта, эт булып, пычранып бетә идек. Менә инде 2-3 көннән бирле каты салкыннар тора. Аяк астын катырып җибәрде. Син тагы каты салкын дигәч тә, әллә ни дип уйлама. Литвалылар өчен генә каты салкын ул. Ә безнең өчен әллә ни түгел. Өстебездә ак тун (исеме генә

ак анын, ә үзе җир белән бер), башыбызда колаклы бүрек, кулда да хәтта җылы бияләй. Урамда очратсаң, танымассың да, дус итеп, кыйнап китүем мөмкин.

Узган хатымда хикәяләр турында язган идем. Үзең карарсың инде шунда. Ярамаса, бернәрсәгә дә карама, ташла. Рәсемемне, әгәр кирәк була икән, җибәрермен.

Безнең газетага берәр нәрсә җибәрә алмыйсыңмы син. Машинада кучерелгәч, бик зур дигәч тә, 4-5 биттән артмасын. Кечкенә хикәя яисә берәр очерк. Бүгенге Казан турында берәр нәрсә эшләп җибәрә алмассыңмы. Гомумән, синең исемеңне газетада күрәсе иде.

Иптәшләргә сәламымны тапшырырсың инде.

Үзеңә аеруча кайнар сәлам белән Афзал.

P.S.

Фронтка барганда, кай якка барырга уйлыйсың? Әгәр безгә килеп чыксаң, бик риза һәм бик шат булыр идек.

А.

***

22/I-45

Афзал!

Гафу ит, мин сине бераз көттердем шикелле. Авылларда идем. Аһ-ваһ килеп менә әле генә кайтып кердем. Әле итекнең карын да какмаган, билбауларны да чишмәгән, синең берьюлы ике хатыңны китереп бирделәр. Ибрай әйтмешли (дөресрәге: язмышлый) «тегәрҗеп урамында[40], үз өемдә, үз бала-чагам белән чөкер-мөкер килеп...» кулларны пешерә-пешерә бәрәнге ашаганда бик әйбәтләп укып җибәрдек.

Күптән хатыңны алган юк иде, рәхмәт, бик күңелле булып китте.

Иң элек эш турында. Альманах турында сиңа хат язылган иде, гаҗәп, ничек кулына керми калды икән? «Көзге чәчәкләрен» табылды, ул журналда басылып ята, «Кыллар» югала торган түгел, ә «Куаклар арасында»ның һич очына чыга алмыйм әле. «С.Ә» кешеләре, ягъни Фатих белән Әнәс «бездә юк» диләр. Инде Альменовта гына булмаса, белмим, каян эзлисе булыр. Андый әйберләрең булганда туп-туры миңа җибәрергә мөмкин, әйткән урныңа үзем тапшырыр идем. Тегеләрен шушы арада бастырып алам. Инде тагын бер нәрсә генә калды: рәсемең кирәк. Мыеклы булса бигрәк тә шәп.

Моннан бераз элек карчыгыңны күргән идем. Кәефе яхшы күренә. Бу арада Союздан берәр йөк утын да бирделәр. Шәт өйләре дә елынгандыр.

Гонорар мәсьәләсе хәзер ярыйсы дип әйтергә ярый. Шигырьнең юлы 5-7 сум, проза әфәнде алай ук бәяле булмаса да берникадәр ул да ярыйсыланды. Хәзер табагына бөтен ярымнан алып була. Сез кайтуга тормышлар тагын да юнләнәнер дип торабыз. Шулай булса, сезгә романнарны бере артыннан берен ишеп кенә торырга мөмкинлек булачак. Ихлас. Мондагылардан буламы, юкмы, киләчәк әдәбиятының, сугыштан соңгы зур әдәбиятның зур әсәрләрен сездән көтәбез. Каян беләсең, бәлки безнең Наташалар, Пьер һәм Ростовлар синең куен дәфтәреңдә үк кысылып йөри торгандыр әле. Инде, үзең әйтмешли, исән-сау кайтып язып бирергә насыйп булсын. Мин хәер-догада.

Бу арада куаныч бик зур. Кичтән башлап ярты төнгә кадәр приказ тыңлыйбыз. Халыкның күңеле күтәренке. Бәлки, сез дә күтәрелеп киткәнсез инде. Шул кызулык белән бәлки сез аны, авыл агайлары әйтмешли, күтенә тибеп тегендә олактырырсыз, җан көеге булып анда эленеп тормас иде. Хәер, анысын, шәт иншалла, миннән башка да кайгыртучылар бардыр.

Искиткеч батырлык, тиңсез фидакарьлек. Сталинның приказын тыңлаганда 41нче елның 16 ноябре, Сталинград көннәре күз алдына килә. Менә бит нинди вакытлар бар иде. Ә бүген менә Кызыл Армия Берлинга, бандитның үз өенә бары 280 километр гына калды.

[40] Тегәрҗеп урамында—Тегәрҗеп Казанның Иске бистәсендәге, Акком асты белән янәшә урам. Хәзерге исеме Гражданский. Тегәрҗеп—киндер яки җитеннән эрләп катылган җеп.

Монда искечә әле. Барысы да исән-сау. Бу арада Ибрайдан хат алдым. Аның бер китабы чыгып ята («Алар өчәү иде»). Бераз үпкәләгән, хат язмыйсыз, дигән, үз хатыннарыгызның елы куйнында карт песи шикелле мырлап ята торгач, безнең ише аю кебек урманда яшәүчеләрне оныттыгыз, дигән. Ни дисең, хак сүзгә җавап юк.

Безнең башлыклар (Кави һәм Кашшаф) Мәскәүгә киттеләр, ниләр оештырып кайтырлар.

Мине янадан «С.Ә»нә куйдылар (кычкыртып, конечно). Аның өстенә такыр башны кашый-кашый укып ятабыз, гыйлем гранитын[41] кимерәбез. «Намус»ка төннәр генә кала, ул да әле бөтен булмый. Инде бетәргә ерак түгел иде, менә болай булгач тагын сузыла инде. Сез кайтканчы өлгертсәм бик хуп. Өлгермәсә оятка калырга туры килә.

«С.Ә»нә хикәяләр, очерклар, бүтәннәр җибәрә алсаң бик яхшы булыр иде, бик сусыйбыз. Мин берәр әйбер җибәрергә тырышырмын.

Син бик һәйбәт «автомат» белән язасың. Шунда берәр фрицтан алып миңа да берне җибәр әле, сугыш истәлеге булыр. Син кайтуга мин монда бәрәңге үстереп торырмын.

Барча иптәшләрдән һәм үземнән күп сәлам. Гомәр.

***

30/IV 45

Афзал!

Соңгы айларда синең хатларың килми башлады. Эшең бик күп булып, вакыт таба алмаудан гына булса аңысы төзәтеп була торган хәл, бүтәнчә була күрмәсен.

21/XIIдә алдынгы кырыйдан язган хатыңнан соң миңа хатың килгәне юк. Син анда хикәяләреңнең кайсын кертү турында язган идең. Агаене монда «Буранлы төндә»не кертүне мәгъкул күрде. Ул китап хәзер типографиядә. Бәйрәмгә чыгарып җиткерергә дигән уйлары бар, хода ни бирер.

Син бу тирәнең яңа хәбәрләрен белеп торасыңмы? Хәер, семьяң яза торгандыр. Кашшаф һаман да авырый. Монарчы Мәскәүдә иде, хәзер монда инде. Аның синең турыда дәү абыйлар белән сөйләшә башлаган сүзе бар. Ни булып бетәр, хәзергә үзе дә белми. Әле дә командировкага гына китәм дигән булып ычкындың да, инде сугышны бетереп үк кайтырга чамалыйсың, ахрсы. Бер яктан, сугышның үз эчендә булуың, зур тарихи вакыйгаларны үз күзең белән күреп, үз кулың белән эшләвең—бик әйбәт, икенче яктан, монда бик сыек калды. Инде шәт бик озак тормассың, бик күп булса—берничә ай. Инде сезне каршы алырга төшәргә дә күп калмагандыр. Син кайларда икән инде, ә? Берлиндамы икән, башка берәр җирдәме? Кайда гына булсагыз да бик ерак инде сез. Исән-сау әйләнеп кайтырга булсын. Ф.Кәрим[42] турында ишеткәнсең. Сугыш бетә дип торганда гына тагын бер шагыйребезне югалттык. Сугыш вакытында аеруча ялкынланып яза башлаган иде. Үлеп китүе бик үкенечле булды.

Союзда хәзергә Мирсәй. Озакламый башка бер кеше булуы да ихтимал.

Мин үзем С.Ә.ндә эшлим. Теге әйберне бетерим дигән идем. Кеше юк, икесен дә берьюлы алып бар, журналда да эшлә, әсәреңне дә тәмамла диләр. Аны бит әйтүе генә ансат. Үзем җитмәсә авырудан арына алмыйм. Әле күптән түгел шифаханәдә ятып чыктым, менә тагын эшләр шул тирәдә. Теге елны автомобиль белән сөзешкәннән соң минем шөрепләр бөтенләй какшап эштән чыгып калды. Шулай итеп, менә шулай эшләр, дус кеше. Бу минем сиңа кечтеки генә зарланып алуым булды инде.

Ярый, моңысы шуның белән бетте. Мондый вакытта авыру—гөнаһ. Бик ашыгыч, хәзер үк тазарырга кирәк!

Я, үзеңдә ни хәлләр бар? Һаман шулай чабып йөрисең инде син. Әллә кай

[41] Гыйлем гранитын – Сүз мәҗбүри кичке Марксизм-Ленинизм университетында уку турында бара.

[42] Ф.Кәрим – Фатих Кәрим (1909-45),шагыйрь. 1945 елны Көнчыгыш Пруссиядәге сугышларда батырларча һәлак була.

җәһәннәмләргә, истә-оста юк урыннарга, әллә нинди вакыйгалар эченә барып керәсең. Сызгаларга вакыт калмый торгандыр. Әгәр аныңчы кайтмасаң, бәйрәм №ына, шул унай белән әйтәсе сүзләреннән бер әйбер язып җибәрә алмассыңмы. Хикәя дип тә, зур очерк дип тә әйтмим, андыйларга вакытың булмас. Кечкенә бер парча, бәйрәм унае белән әйтергә теләгән сүзләреңне, солдат уйларын (язучы-солдат) язып җибәрсәң дә ярар. Аннары рәсемеңне җибәр. Бик көтәбез.

Хәзергә шуның белән тәмамлап торыйк. 1нче май белән тәбрик итәм. Абдулга күп сәлам.

Исәнлек теләп, Гомәр Аккомасты

***

10/V—1945. Көнчыгыш Пруссия.

Гомәр дус!

Зарыгып көткән көн килеп җитте. Ерактан торып булса да, шуның шатлыгынннан синең кулыңны каты итеп кысарга рөхсәт ит.

Моннан берничә көн элек кенә синең Ахметовка язган хатың килеп җитте. Анда син Татарстан бәйрәменә кайбер язучыларны чакырырга хәзерләнүегез турында язасың. Бик яхшы эш! Моны һичшиксез эшләргә кирәк. Бәлки әле юбилей алдыннан язучыларның киңрәк бер җыелышын да үткәрә алырсыз. Анда катнашуны һәр язучы үзенең бәхете санар иде.

Ф. Кәримнең һәлак булуын бик зур кайгы итеп каршы алдык. Йөрәгемә хәнҗәр калагандай булды. Бик зур, бик зур югалту! Их егетләр, егетләр, шуны саклап алып калып булмады бит! Нәрсә генә эшли алабыз соң без!

Безнең фронтта Исхак Закиров[43] та үлде. Каһарманча, чын коммунистларча сугышып үлде. Ул да бик кызганыч! Аңа булган хөрмәтне һәм аның батырлыгын иптәшләре әле дә оныта алмыйлар. Аның ничек үлүе турындагы кайбер мәгълүматларны шушы көндә сина яисә Я.С—га җибәрермен.

Анда безнең шактый гына фронтовик язучылар Казанда йөриләр икән инде. Ничек кайта алдылар соң алар?

Кайнар сәлам белән, Афзал.

Г.Бәширов кулы белән өстәлгән:

21/V да алдым һәм хат яздым.

***

21/V-45

Афзал!

Сиңа һәм Абдулга бик күп сәлам.

Бу соңгы хатың гаҗәп тиз килгән. 10/Vда яздым дигәнсең, ул инде 21ендә Казанда иде. Минем хат та шулай тиз генә барып җитмәсме дип хатыңны ачып укуга җиңел кулдан мин дә менә моны сызгаларга тотындым.

Җиңү белән тәбрик итеп сиңа хат яза алмадым, чөнки ул көннәрдә шифаханәдә идем. Соң булса да мин дә бик нык итеп кулыңны кысыйм. Шул кадәр озакка сузылган иде, әле менә хәзер дә бетүенә күңел ышанып җитми.

Халыкның хәзер кәефе бөтенләй башка. Күңел күтәренке. Инде синең кайтуыңны көтәбез.

Бу арада башлыклар Мәскәүдә әле. Син яңа рәисне ишеткәнсең инде. Хәзер Ә.Ерикәй бит. Кашшаф авырый. Тиз генә эшкә тотынырлык түгел. Мирсәйнең язасы бар, дигәндәй, шулай итеп хәзер яңа кеше. Анда пленум буласын ишеткәнсең, шуңа киттеләр. Кайбер язучыларны кайтару мәсьәләсен дә шунда хәл итеп кайтыр шикелле дип сөйлиләр. Ләкин нигәдер бик саран маташалар шикелле. Югарыдан алай бик юмарт булырга әйтмәгәннәр имеш дип кенә әйттеләр. Хәер, ул әле сугыш

[43] Исхак Закиров (1911-44), шагыйрь. Бөек Ватан сугышында һәлак була.

беткәнче иде. Бәлки хәзер үзгәргәндер, ул кадәресен белмәдем әле. Бу турыда мин сина язган идем. Шуннан башка яна хәбәр әйтә алмам шикелле.

Хәзер бәрәнге утыртабыз. Казанда агачлар бөреләнеп килә. Үләннәр яшәрә. Анда гына түгел, бездә дә җәй башлана. Аннары безнең бит үзебезнеке, российский җәй.

Синдә ниләр бар? Син үз хәленне бер дә язмыйсың. Шул элекке эштәме, һаман шулай чабасыңмы? Кайчан кайтасың? (син карт кеше бит инде) Сызгаларга бер дә вакыт калмыймы? Кайтканыннан сине берәр елга үз иркенә көйләп роман язып ыргытсаң шәп булыр иде, ә! (Һа, сразу роман, повесть кына да түгел. Менә бит кеше дигәнең нинди комсыз, нинди пәрвәйсез!)

Теге хатымда мин синнән бәйрәм №ына берәр нәмәкәй җибәрүенне үтенгән идем шикелле. Син аны онытма инде, туган. Гәрчә мин хәзер жур.да эшләмәсәм дә (анда хәзер Г.Иделле[44]) журнал бит барыбызныкы да, аны чибәррәк итеп чыгарасы иде. Абдулның да исенә төшер әле.

Я, хәзергә шунын белән тәмамларга да була. Мирсәйдән, Гумеровтан, Кашшафтан, Г. Иделледән сәлам. Сина исәнлек теләп, Гомәр Р.

Вакытың булса хат яз.

Фронтовик язучылардан монда хәзер беркем дә юк. Хуҗи[45] булды да китте. Ә. Фәез авырып кайтты, Айдар[46] да шулай.

***

26/V—45.

Гомәр дус!

Менә сина бер хикәя җибәрәм. Журналның юбилей номерына керсә, яхшы булыр иде. Бәлки, альманахка да соң түгелдер әле. Гомумән, үзең карарсың.

Редакциягә җибәргән бер хикәямнең югалуы сәбәпле, моны синең өй адресы белән генә җибәрергә булдым. Алгач, хәбәр итәрсең дип уйлыйм.

Сәлам белән, А. Шамов

Г. Бәширов кулы белән өстәлгән:

Алдым, хикәясе белән (Дустым кабере янында). 8/ VI—45.

***

2 сентябрь, 1945ел, Кытай.

Гомәр!

Язмыш җиле безне дөньяның бер читеннән икенче читенә ташлады. Хәзер без Кытайда. Куе кытай чәе эчәбез, аларның тозсыз пешерелгән мантыйларын ашыйбыз. Син тагын, манто дигәч тә, өскә кия торган мантоларны ашый башлаганнар икән бу җүләр солдатлар дип уйлый күрмә. Һич тә андый нәрсә түгел. Ул бары кабартма шикелле ашамлык кына.

Кытайларның ашын ашагач, тормышларын күргәч, мин ирексездән: «Я раббым, я раббым, туган илемнең өтек чыпчыгы да мондагы сандугачлардан матур!»—диярга мәҗбүр булам.

Гомәр, синең редакциядәге китап чыккандыр инде. Мина тиешле бер данәсен минем өйгә җибәрсәң һәм, мәрхәмәтен килеп, берсен безнең редакциягә җибәрсәң, бик тә яхшы булыр иде.

«С. Ә»нда кем хәзер? Бик күрәсе килә шул журналны. Гаҗәп сагындырды.

Теләнә башлагач, теләнеп бетерим инде. Анда «Батырлар китабын» алырга мөмкинлек юкмы? Әгәр шундый мөмкинлек булса, минем семьяга хәбәр иттер әле. Алар, акчасын түләп, килеп алырлар.

Сәлам белән, А. Шамов

П.п. 74232-П.

[44] Г.Иделле – Газиз Иделле (Усманов) (1905-85), язучы.

[45] Хуҗи – Гали Хуҗи (Хуҗиев) (1912-66), шагыйрь.

[46] Айдар – Әсгать Айдар (1906-59), язучы.

***

24/IX-45

Афзал!

Хат язуың өчен рәхмәт. Үземнең дә язасым килә иде, тик адресынны белә алмый йөрдем. Бер гражданский адрес биргәннәр иде, аңа ышанасым килмәде һәм ышанмый яхшы иткәнмен: сез бит әнә кайларга барып чыккансыз! Шундый сәяхәттән мәхрүм калдым лабаса. После пожара... дип әйтмә, ихлас сүз, рыясыз.

Синең бу хатыңны бер укып чыктым да тагын бер укып карадым. Гаҗәп, синең бервакытта да болай сүзгә саранланганың юк иде. Хәтта, мин әйтер идем, бөтенләй киресенчә була торган иде. Хикмәт, әллә югыйса сез ашый торган ул мантоның шундый сүзне бөяп тота торган берәр хасияте бармы? Бу хатыңда синең бары өч кенә сүз язылу шәрәфенә ирешкән.

Беренче. Мин монда манто ашап тукланам.

Икенче. Безнең өтек чыпчыгыбыз мондагы сандугачлардан мең тапкыр матуррак.

Өченче. Минем өемә бер китап җибәр, ә монда ике китап.

Ә болай гына әйткәндә бу стиль минем үземә дә ошады. Ник дисән...(анысын язарга иренәм инде) Синең юлдан китеп хатымны болай дәвам итәсем килә:

Беренче. Син сораган китапларны я бәлкем җибәрербез, я бәлкем юк.

Икенче. Без бәрәңге алабыз.

Өченче. Кытай чәе чыгышлымы? Быел бәрәңге бик үк чыгышлы түгел.

Сораулар:

Син берәр кайчан кайтырга уйлыйсыңмы, әллә шунда дөге басуы кырыена берәр фанза салып, манто гына ашап торыргамы исәп?

Чын илендә син берүзең генәме, әллә безнең халыктан тагын берәр кеше бармы? (Мәсәлән, Абдул Әхмәт һәм Гыймади дигән кешеләрне шул тирәдә очратканың юкмы?)

Һ.б.һ.б.

Тагын ни? Барын да язып бетердем шикелле.

Хатың көтмәсен өчен син әйткән йомышларның үтәлүен көтеп тормадым, яза бирдем. Барсын да булмаса да, шаять, журнал, китап («Әдәби Татарстан») җибәрү кадәресен эшләп булыр.

Монда зур яңалык юк. Картлар кайта (Мәс. Х. Садрый[47]), агаене элеккечә мыштырдый. Тегермән әйләнә, тик оны чыкмый.

Кыек күзләрне к. тибеп олы дингезгә төшереп бетердегезме инде? Чынлап, отставка турында ул тирәдә бер ни дә ишетелмиме? Кайтарга иде, брат, ә!

Син андагы егетләр белән хат алышмыйсыңмы? Бер-икене җибәрим булмаса.

Г.Әпсәләмов[48]—п.п. 73803 (Ул беренчедә)

С.Баттал[49]—п.п. 15088-п

Вакытың сыйдырса хат язгала, без бик шат булырбыз.

Һәммәгезгә бик күп сәлам. Гомәр

(С.Ә.дә Г.Иделле)

Синең йомышларны үтәгәч тагын бер хат язармын әле. Вәссәләм.

***

4.X.45

Афзалетдин!

Сине тагын бер азаплыйм әле. Сукрана-сукрана, бер тибеп бәреп, тагын алып укый торгач, бәлки уннан берен генә булса да танып алырсың.

Син, язуыңа караганда, быел да бәрәңге пәрәмәче ашарга кайтмассың ахрысы. Әллә чиннарның мантысы татар пәрәмәченнән тәмлерәкме? Әллә җибәрмиләрме?

[47] Х.Садрый—Халик Садри (1890-1955),язучы.

[48] Г.Әпсәләмов—Габдрахман Әпсәләмов (1911-79),язучы.

[49] С.Баттал—Салих Баттал (1905-95),язучы.

Иң элек сине кызыктырган мәсьәләләргә җавап язарга ашыгам. Геройлар китабы 100 данә генә чыкты да таралеп калды. Ни өчен таралгәнен язсам бик озак. Кыскасы, аның төзәлеп кайчан чыгып җитәсен мин түгел, хәтта Кави үзе дә белми. Ихтимал, ул чыгып җиткәнче син үзең кайтып килерсең. Инде алай булмаса, чыга башлау белән сиңа иң кайнар саннан берне алып бирербез диделәр. Монысы шулай. Инде «Әдәби Татарстан» дигәнебез һәм «С. Ә.» сиңа озакламыйча барып җитәргә тиеш. «Әдәби Т.» Зөбәйдә җибәрә, адресыңны бирдем. Тегесен Фатих үз өстенә алды. Әгәр 6нче № барса, анда Г. Бәшир дигән бер бәндәнең өзеге бар. Вакыт табып шуңа күз сал әле. Синең фикереңне мин бик рәхәтләнеп тыңлар идем. Мактауны көтмим, кимчелекләрен яшермичә яз.

Тагын нәрсә?

Казанда көз. Шыбыр-шыбыр яфраклар коела. Өстә сап-сары кояш, һавада ефәк тоҗымнар. Ә төннәрен мыекка ап-ак кырау куна. Шундый һәйбәт, әйтеп бетергесез. (Напрасно кайтмыйсың!)

Сезнең андагы шыксыз сопкалар арасында бездәге шикелле сөйкемле кояш та, шундый тоҗымнар да, сары яфраклар да юктыр әле.

Союзда һаман элеккечә. Ерикәй өйдә һәм башкалар да өйдә. Кашшаф та кайтты. Кичә бер ай срок белән Берлиннан Гариф Галиев кайтып төште. Шундый матурланып, мутланып кайткан, бер каш сикертү белән солдаткаларның һушын җибәрә. Валлаһи! Вот малай! Без дә йөргән булабыз... чабата кайтарып.

Әпсәләмгә хат язгалыйсыңмы? Бүген генә хаты килде. Үз илебезгә җиттек ди. Сез дә чыккансыз инде.

Әхмәт агай Утыртинский андамы? Бер дә тавышы чыкмый. Ул педагог кеше бит. Аның эшләр ничегерәк?

Үзем, биргәненә шөкер, хәзергә сау сәламәт. Акрын гына, картларча кыймылдап язып яткан булам. Турысын гына әйткәндә, шундый килеп каптым, үзем исән-сау чагында бер очлап чыга аламмы инде, юкмы?

Ярый, шуның белән хәзергә мөхтәсәр кылыйк.

Сезнең турында Ерикәй башкалада сөйләшеп исемлек биреп кайткан иде, болай берәр нәтиҗәсе чыкмасмы әле. Шулай була күрсен иде дип хәер-догада торабыз.

Абдулга, иптәш Гыймадиевка күп сәлам.

Гомәр
Казан,
Аккомасты.

*Ахыры киләсе санда*

---

**Хөрмәтле Бөек Ватан сугышы ветераннары!**

2010 елның 2 яртыеллыгына «Казан утлары»на арзанрак бәягә язылырга мөмкин. Җиңүнең 65 еллыгы уңаеннан уздырылучы әлеге акциядә Бөек Ватан сугышында катнашучыларга 20% ташлама каралган. Сезнең өчен «Казан утлары»на язылу бәясе—**210 сум 12 тиен**.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Явлаштау

Явлаштау авылы Саба районында, район үзәге Байлар Сабасыннан —15, тимер юл станциясе Шәмәрдәннән 18 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл Казан ханлыгы чорында ук булган. Явлаштауда XVIII йөздә 69 ясаклы татар яшәгән. Явлаштау халкы күршедәге Курсабаш, Мичәнбаш, Кырбаш, Олыяз, Пүкәл, Өтернәс, Эзмә, Иске Шекше, Яңа Шекше, Мишәбаш, Сәрдә, Иләбәр, Көек, Бөкмеш авыллары белән берләшеп июнь уртасында Калатау җыены үткәргән. Җыен үткәрелгән урынны өлкән яшьтәгеләр хәзер Әчтерхан урыны дип атап йөртәләр.

Явлаштау (Түбән Мишәбаш) авылы Мишә суы буена утырган.

Авылның өлкән буын кешеләре Явлаштауның нигезләнүе турында болай сөйли. Көнкүреш өчен уңайлы булганлыктан, бу җиргә «Бәймәч» һәм «Миләч» дип билгеле булган ике гаилә йорт салып яши башлаган. Берничә елдан Мазар исемле кеше дә килеп нигез корган. Хәзерге Мазар тавы шул Мазар исемле кешегә нисбәтән барлыкка килгән.

Еллар узу белән авылда баеп киткән гаиләләр барлыкка килә һәм авыл халкы байларга һәм ярлыларга аерыла.

Авыл төрле яктан таулар белән уратып алынган. Тауларның урнашуына нисбәтле ябалдаш сүзеннән авылга Яблаштау исеме бирелгән дип исәплиләр. Тора-бара ул Явлаштау дип атала башлаган.

1880 елда авылга Сәйфетдин исемле кеше килеп утыра. Ул биредә беренче булып кибет ача. Монда шулай ук Казан бае Юнысовлар тире заводы ачалар. 1910 елда авылга Касыйм дигән кеше килә. Ул сәүдәгәр Зариф кызына өйләнә һәм күп табыш китерә торган йон заводы ача.

1917 елда революция булгач, Казан байлары үзләренең байлыкларын Явлаштауга китереп яшермәкче булалар. Алар бирегә 600 капчык җимеш китерә. Әмма революциядән соң, халык бу җимешләрне үзара бүлешә.

1928 елда илдә коллективлаштыру башлана. 1929 елда 9 хуҗалыктан торган колхоз төзелә. 1925 елда Явлаштау авылында мәчет салына, ә 1931 елда ул бетерелә. Анын бинасын клуб итеп үзгәртәләр.

1925 елдан авылда укый-яза белмәүчелекне бетерү өстендә эш алып барыла башлый. Мәдрәсәләр урынына 4 еллык башлангыч мәктәп ачыла.

1951 елда колхозлар берләшеп, «Калинин» исемендәге колхоз оеша. Бу колхозга Мишәбаш һәм Явлаштау авыллары керә. 60 елларда биредә мәдәният йорты, медпункт, 8 еллык мәктәп, балалар бакчасы, машина-трактор паркы, ашханә, кибет, колхоз идарәсе һ. б. салына. Юллар тәртипкә китерелә, районга бара торган юл дамба итеп күтәртелә. Колхоз бөтен республика күләмендә таныла.

Авыл кырыеннан боргаланып Мишә елгасы ага. Элек елганың суы да мул бул-

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

ган, балыгы да мул үрчегән. Авылның барлык елга-сулары, чишмә-кизләүләре дә Мишә елгасына кушыла.

Авыл янындагы тау башында ялгыз нарат үсеп утыра. Ул ничек сакланып калган соң? Тау өстендә нарат урманы булган. Аны бетереп, байлар чәчүлек җирләре ясаганнар. Әхмәт исемле карт: «Минем киләчәк буыннарыма шушы нарат истәлек булып калсын»,—дип нарат агачын кистермәгән. Бүгенге көндә дә нарат агачы авылга ямь биреп, горур басып тора. Элек ана табынганнар, ә хәзер яшьләр шул нарат янына менеп кичке уеннар уйныйлар.

## Түбән Барыш

Түбән Барыш авылы Апас районында, район үзәге Апастан —20, Чишмә (Ключи) станциясеннән—13, Тәмте пристаненнән 28 чакрым ераклыкта урнашкан. Авылда татарлар һәм чуашлар яши. Тарихи чыганакларда авылның исеме—Ясаклы Барыш. Бу авыл халкы дәүләткә ясак түләп көн иткән.

Авылның язылган тарихы булган, 1921 елда көчле янгын вакытында әлеге тарих янып юкка чыга.

Авыл оешу, барлыкка килү турында халык телендә төрле легенда-риваятьләр йөри. Олылар сөйләвенә караганда, авылны беренче булып чуашлар нигезләгән. Идел-Кама буйларындагы дәүләт илбасарлар тарафыннан яулап алынгач, халык төрле урыннарга таралып утыра башлый. Авыл янында бер калкулык бар. Аны Морзалаш дип йөртәләр. Җәйге эссе көннәрнең берсендә шушы калкулыкка Морза исемле кеше килеп шалаш кора. Авыл чуашларыннан сыену урыны сорый, нәселе барын әйтә. Авылда ул вакытта буш урыннар күп була. Морзага авылга килеп урнашырга рөхсәт итәләр һәм ул нәселен, гаиләсен алып килеп шушында төпләнә. Элек авылның тирәягы калын урман булганга, тырыш кешегә йорт житкерү жинел була.

Түбән Барыш тирә-якта иң ярлы авылларның берсе исәпләнгән. Хәреф танучы, яза белүче монда икәү генә булган. Адрес яздыру өчен авыл кешеләре аларга килеп, йә 3 тиен акча, йә йомырка биреп киткәннәр. Дөрес, биредә байлар да яшәгән. Авылда күмәч салу һәм сатучылар, йомырка сатучылар һәм тегермән тотучылар да була. Революциягә кадәр авылда өч-дүрт жил тегермәне һәм бер су тегермәне эшләгән. Ит, йомырка белән сату иткән Зиннур һәм Зиннәтулла исемле кешеләрне байлар дип Себергә куганнар, мал-мөлкәтләрен тартып алганнар. Күмәч сатып йөрүче Хәлим исемле кешене ни өчендер сөрмәгәннәр. Ул менә нәрсәләр язып калдыра: «Күмәч сату белән шөгыльләндем. Хатыным тәүлеккә 7 тапкыр мичкә ягып күмәч пешерә иде. Иртә таңнан ат жигеп күмәчне базарларга алып барып сата идем. Юл газабы—гүр газабы диләр, янгыр һәм буран астында калган вакытлар күп булды, арбалар, көпчәкләр ватылулар да һәрдаим иде». Авылда үз көче белән хәлле генә яшәгән кешегә хөрмәт беткән ул елларны. Революциядән соң тегермәнчеләрне дә эзәрлеклиләр, тегермәннәрен ваталар. Тегермән тоткан Мостафа һәм Гатаулла исемле кешеләрне төрмәгә утырталар.

Авылда ике мәчет һәм ике мәдрәсә эшләгән. Утызынчы елларда мәчетләрнең манараларын кисәләр, муллаларны төрмәләргә утырталар, йортларын, малмөлкәтләрен тартып алалар, балаларын укудан читләштерәләр. 1933 елда Хәлиулла мулланың йортын тартып алалар да гаиләсе белән урамга куып чыгаралар. Ул мунчада яши башлый. Мунчаны да тартып алалар. Аннары мулла балчыктан, саманнан салынган кладовоенда яши башлый. Кладовойда ул гаиләсе белән 19 ел тора. Башка йорт салдыртмыйлар. Шул балчык өйдә яшәгәндә дә муллага салым өстенә салым салып торалар.

1921 елны бик каты ачлык була. Бик күп хужалыкларның бәрәңгеләре һәм игеннәре тишелми. Сирәк кенә тишелеп чыккан игеннәр эсселектән май урталарында һәлак була. Июнь аенда инде уныш күтәргә бернинди өмет калмый. Авылда терлекләрне сую башлана. Итләрне тураклап һәм ваклап кояшта киптерәләр. Калдык-постык ашлыктан он тарттыралар, ипи пешереп сохари әзерлиләр. Кайбер хужалыклар авылны калдырып шәһәргә китә башлый. Юлда гаиләләре белән үлеп калучылар да күп була. Ачлык афәте узгач, 1923 елда төрле яклардан авылларына кире кайта башлыйлар.

Илдә яңа икътисад сәясәте башлана. Крестьян барлык көчен жыеп, юк-бар орлыкны барлап чәчү чәчә, җиң сызганып җир эшкәртергә тотына. Вак сәүдәгәрләр барлыкка килә. Ләкин бу иркенлекләр озакка бармый. Тоташтан күмәкләшү һәм колхозлашу еллары башлана. Колхозга кермәүчеләргә налог өстенә налог салалар. Аны түли алмагач җирдән мәхрүм итәләр, җирен тартып алалар. Колхозга «Ашлы күл» дип исем бирәләр. 1929 елдан башлап авыл халкының күбесе шәһәрләргә күчеп китә. Шулай ук олы юлга якынрак булган урыннарга да күчеп китүчеләр була. Кама Тамагы районының Якты Алан, Идел буенда урнашкан Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылына күчеп утыралар. 360 хуҗалыгы булган авылның 84 кенә йортында тормыш чаткылары күренә...

1941 елның октябрь аенда яше-карты, хатын-кызлар, яшүсмерләр хәрби кыр ныгытмалары, блиндажлар, танкка каршы окоплар казырга мәҗбүри хезмәткә алына. Сугыш елларында хатын-кызларның механизатор булып эшләүчеләре дә күп була. Кабинасыз тракторларда алар җәен-кышын, буранда һәм янгырда көне-төне эшлиләр. Төнлә эшләү өчен тракторларның фаралары булмый. Трактор алдына кабызылган фонарьлар куеп җир сукалыйлар. Ягулык яки трактор радиаторында су бетсә, авылга кайтып шуларны кырга җәяү алып киләләр. Тракторда 17-18 яшьлек кызлар эшләгән.

Авылдан сугышка киткәннәр арасыннан 80 ир-ат кире әйләнеп кайта алмый, ил азатлыгы өчен башларын салалар.

Авыл аркылы Үләмә суы ага, авыл уртасында зур күл бар. Элек монда кәрәкә балыгы, буе ярты метрга җитә торган ак балыклар, ташбашлар йөзгән. Куе камышларында су тавыклары, кыр үрдәкләре оя корган. 1912 елда авыл күле чистартылган һәм тирәнәйтелгән. Үләмә ярына шул чорда таш түшәгәннәр, чишмәләрне чистартканнар. Үләмә аша тимер-бетон күпер салырга да фәрман килгән булган, ләкин кайбер авыл өлкәннәре моңа каршы килгән, салым түләтүдән курыкканнар.

Авылның төньягында Туры тау, ә көньяк-көнбатышында Кала тау урнашкан. Кала тау башында зур кала, ә авыл урынында дингез булган диләр. Кала тау борынында Изгеләр чишмәсе ага, аның тирә-ягы әйләндереп алынган, суын эчү өчен савыт куелган. Чишмәдән якын гына Мәрьям ана күз яше дип аталган, җәенкөзен ямь-яшел үләннәр үсеп утыра торган сазлы урын бар. Ерактан карасаң ул, чынлап та, ике бөртек күз яшенә охшаган.

Акчалы тау дип аталган тау да бар. Авыл кешесе мәрхүм Зиннәт Хәйруллин бу тау турында менә нәрсәләр язып калдырган: «1918 елны Буа якларына чехлар узып киткән. Казан ягыннан килгән чехларның йөкләре, кораллары авыр булган. Капчыкларында байтак көмеш акчалар да булган булса кирәк. Йөкне җиңеләйтү өчен, кайтканда кереп алырбыз дип, акчаларын, имеш, тау башына күмеп киткәннәр. Бу хәлне тау башында уйнап йөргән балалар күргән. Акчамы, яисә башка әйбер күмгәннәрме, анысы билгесез». Тау башына чехлар көмеш акча күмгәннәр дигән хәбәр авыл халкы арасында тарала. Кайбер күрәзәчеләр тау башыннан хәзинә табу өчен сыерның дүрт аягына дүрт чабата кидереп таугa алып менергә кушалар. Шулай эшләүчеләр дә була, ләкин хәзинә генә табылмый. Күрәсең, чехлар бернинди хәзинә дә калдырмаган. Шуннан соң бу тау Акчалы тау дип йөртелә башлый. Түбән Барыш белән Зур Күккүз авыллары арасында Камил чокыры дигән чокыр-елга бар. Яз көннәрендә бу елга-чокырдан үтеп булмый, агымсу көчле була. 94 яшенә җитеп үлгән Мостафа бабай бу чокыр турында болай дип сөйләп калдырган: «Бу чокырда яз көне юлаучы Камил исемле кеше батып үлә. Сөйләүләргә караганда, чокырда агач күпер булган. Бер мосафир салкын вакытта төнлә күпер астында кунган. Җылыныр өчен ул күперне ут төртеп яндырган».

Хәзер авылда ике милләт вәкилләре—татар һәм чуашлар үзара дус һәм тату яши. Татарлар Түбән оч, Ком очы, Олы урам, Мукри дип исемләнгән урамнарда яши. Чуашлар яши торган урам Чуаш очы дип атала.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# К

**КӘРИМОВ** Марат Нәби улы (9.1.1930, Башкортстан АССРнын Зианчура р-ны Кугәрчен ав. туа), язучы, Башкортстан респ-касынын атказ. мәдәният хезмәткәре, халык шагыйре (1994, 2003). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Мәскәүдә М. Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (1961). 1954-56 елларда КПСС ҮК каршындагы Үзәк (Югары) комсомол мәктәбендә укый. 1956-57 дә «Ленинчы» газетасында әдәби хезмәткәр, 1958дән (өзеклек белән) «Сәнәк» ж-лында (1968-78дә баш мөхәррир) эшли; 1964-68 дә «Пионер» ж-лынын баш мөхәррире. «Бөреләр» (Уфа, 1956; русчага тәрҗемәдә «Весенние почки», М., 1961), «Йәшлегем йәшнәр көнөм» (Уфа, 1965), «Тормыш—гашиктарга» (Уфа, 1969), «Ете көнем—ете мон» (уфа, 1981), «Тәгәрәй гүмерем йомгагы» (Уфа, 1994) кебек шигырь җыентыклары, «Алланын кашка тәкәһе» (Уфа, 1968), «Ялган һукмак» (Уфа, 1987), «Адәм көлкесе» (Уфа, 1998) исемле сатирик һәм юмористик хикәя җыентыклары авторы. Уфа шәһ. яши.

Әсәр.: Һайланма әсәрзәр. Шигырзар. Өфө, 2000.

**КЕРБАБАЕВ** Бирде Морад улы (3.3.1894, хәзерге Төркмәнстан Респ. Теҗен р-ны, Коуки—Зерен а.—23.7.1974, Ашхабад), Төркмәнстан ССРнын халык язучысы (1967), Төркмәнстан ССР ФА нең хакыйкый әгъзасы (1951), Соц. Хезмәт Герое (1969). «Хәлиткеч адым» («Алып адым», 1947; СССР Дәүләт бүләге (1948), «Нәбит—Даг» (1957), «Могҗиза белән туган» («Гажайыппен орнаган», 1965) романнары, «Корбан Дүрди» (1942), «Ак алтынны аймакнын Айсолтаны» («Ак алтынды аймактын Айсолтаны», 1949; СССР Дәүләт бүләге, 1951; татар теленә тәрҗемәсе «Айсолтан», 1960) повестьлары, «Айлар» (1943) поэмасы, «Мәхтүмкүли» (1943) пьесасы һ.б. авторы. Иҗатында татар язучылары, бигрәк тә Г.Ибраһимов әсәрләре йогынтысында формалаша. Г.Тукай, М.Җәлил шигырьләрен төркмән теленә тәрҗемә итә.

Әсәр.: Эсерлер топлумы: 6 кіт. Ашгабад, 1958—60.

*Р.К.Ганиева.*

**КИЗЛӘВИ** (псевд., чын исеме-фамилиясе Сөләйманов Ягъкуб) (якынча 1885, Казан губ., Чистай өязе, Кизләү а.—1940), шагыйрь, тәрҗемәче. «Күз яшьләре» (1913) шигъри җыентык, үзенен шигырьләре һәм М.Ю.Лермонтов, А.В.Кольцов, С.Д.Дрожжин, Л.Н.Толстой әсәрләренен тәрҗемәләре кергән «Бер баланын җир хакында уйлары. Күнел ачкычы. Толстой әкиятләре» (1913) китап авторы. Г.Тукай вафаты унаеннан кайгырып «Сөекле шагыйремез мәрхүм Габдулла Тукаев рухына» (1913) шигырен яза. Иҗатында татар халкынын мәгърифәтле булуын тели, анын киләчәк язмышын кайгырта. Шигырьләренә күнел төшенкелеге (пессимистик рух), тормышнын галелсез булуына офтануы хас («Дөньяда тордым...», 1913).

Әд.: Татар шигърияте: XX гасыр башы / Төз. З.Рәмиев. К., 2004.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**КИЛӘЧИ** Бәдретдин (19 йөз ахыры—20 йөзнен 1 нче яртысы), шагыйрь. Шигырьләре «Ан» ж-лында, «Идел» газетасында басыла; 4 шигыре Г.Тукайга багышланган. 1930 нчы елларда нахакка репрессияләнә, вафатыннан сон реабилитацияләнә.

**КИНДЕР** Иван Фёдорович (30.9.1928, Украина ССРы, Каменец-Подольск өлкәсе, Шепетов р-ны Судилково а.—1.12.1995, Казан), язучы, РСФСРнын атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан ун-тын тәмамлый (1959). 1961-89 да Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. Бөек Ватан сугышы елларында эшендә имгәнә һәм гомерлек инвалид булып кала. Повесть һәм хикәяләр кергән «Текә юл» («Крутая дорога», 1971), «Юллар чатында» («Развилок», 1978), «Озын җәй» («Долгое лето», 1983), «Тәгәрмәч» («Колесо», 1987), «Дөньяда күпме могҗиза?» («Сколько чудес на

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

свете?», 1990) һ.б. җыентыклар авторы. Аның геройлары—безнең замандашлар, катлаулы язмыш кешеләре, алар тыйнак, максатчан, гражданлык бурычына тугрылар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**«КИСЕКБАШ КИТАБЫ»**, 14-15 йөзләр төрки-татар дини-дидактик әдәбият истәлеге. Авторы билгесез. 270 шигъри юлдан тора. Поэманың сюжеты әкиятимаҗаралы: Мөхәммәт пәйгамбәргә киселгән кеше башы ярдәм сорап үтенеч б-н мөрәҗәгать итә. Ул ана диюнең шәһәрне җимерүе, улын ашап йотуы, чибәр хатынын урлавы, ә үзен Кисекбашка әверелдерүе турында сөйли. Мөхәммәт пәйгамбәр йомышы буенча аның тугрылыклы сәхабәсе Гали дию биләмәсенә бара һәм әсирләрне коткара. Усаллык җинелә, гаделлек җиңә. 1846 елдан соң күп тапкырлар нәшер ителеп, Идел-Урал төрки халыклары арасында киң тарала, мәдрәсәләрдә укыла. «К.К.»ның Казан, С.-Петербург, Мәскәү, Баку, Анкара китапханәләрендә күпсанлы кульязма нөсхәләре саклана. Татар әдәбиятында «К.к.» сюжетына нигезләнеп Г.Тукай, Н.Исәнбәт, Н.Баян, Ш.Мөдәррис, Ә.Исхак, Ә.Камал сатирик әсәрләр иҗат итәләр.

**«КИТАБЕ ГӨЛЕСТАН БИТ-ТӨРКИ»** («Төркичә Гөлестан китабы») урта гасырларның төрки-татар әдәбияты ядкәре. Тезмә һәм чәчмә формада язылган Алтын Урда дәвере шагыйрьләреннән Сәйф Сараи, Әхмәд Хуҗа, Габделмәҗид, Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүләнә Гыймад Мәүләви, Мәүләнә Исхак, Тугълы Хуҗа, Сараи Гөлестани һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләре җыентыгы. 14 йөзнең ахырында Мәмлүкләр Мисырында аноним автор тарафыннан (Сәйф Сараи дип фаразлана) төзелгән һәм Мәмлүкләр әмире Бәтхаска багышланган. Җыентыкның төп өлешен Сәйф Сараиның Сәгъдинең (1258) «Гөлестан» китабын «Гөлестан бит-төрки» дип тәрҗемә ителгән әсәре, ш.у. аның алда аталган шагыйрьләр газәлләренә нәзыйрәләре тәшкил итә. Китап патшалар тормышы, дәрвишләр әхлагы, эндәшмичә торуның файдасы һәм аз б-н канәгать булуның хәере һ.б. турында сөйләгән 8 бүлектән тора. Бу җыентык әсәрләренә афористик стиль, фикер тирәнлеге һәм кыскалыгы хас. Китапның билгеле булган бер кульязмасы (373 бит) Голландиянең Лейден ун-ты китапханәсендә саклана. Беренче тапкыр Анкарада (1954), аннан Будапештта (1969) һәм Казанда (1980, 1999) нәшер ителә.

Әсәр.: Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

Әд.: Наджип Э.Н. Тюркоязычный памятник XIV в. «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык: В 2 ч. А.—А., 1975; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; аныкы ук Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

*Х.Й.Миннегулов.*

**«КИТАБЕ ДӘДАМ КОРКЫТ»**, 10-11 гасырларның төрки-татар әдәбияты ядкәре. Китап угыз баһадирларының басып алган Кавказ җирләрендә кәферләргә каршы сугышкандагы батырлыклары турындагы героик дастаннар циклын тәшкил итә. Төп геройлар—угызлар ханы Баюндур, аның кияве Казан баһадир, улы Гаруз һ.б. Хикәяләү фикер иясе Коркыт исеменнән бара. Аның турында мәгълүмат китапның кереш өлешендә урнашкан. Ике күчермәсе билгеле: Дрездендагы (12 дастаннан тора) һәм Ватикандагы (6 дастаннан тора) кульязмалар. «К.д.К.»ның бердәм сюжеты юк. Дастаннарның күбесендә Кавказдагы угызларның патриархаль-феодаль күчмә тормышлары тасвирлана. Хәзерге Азәрбайҗан җирләрендә һәм аның тирәсендә урнашкан шәһәрләр, кальгалар, елгалар, күлләр исемнәре атала. Аерым эпизодлар әкияти, мифик характерда бирелгән. «К.д.К.» болгар язучысы Кол Гали иҗатына, «Кисекбаш китабы» авторына нык тәэсир итә. 1922 дә В.В.Бартольд тарафыннан эшләнгән ядкәрнең рус теленә тәрҗемәсе, вафатыннан соң 1950 дә басылып чыга. Китап берничә тапкыр Германия, Италия, Төркиядә нәшер ителә. Ин борынгы күчермә 16 йөзгә карый.

Әд.: Книга моего деда Коркута. М.—Л., 1962; Деде Коркут. Баку, 1950.

*А.М.Ахунов.*

**КОЖЕВНИКОВ** Лев Афанасьевич (5.3.1947, Киров өлкәсе, Омутнинск ш.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Киров пед. ин-тын (1971), Мәскәүдә Әдәби ин-тны (1976), Театр сәнгате ин-ты каршындагы Югары режиссер курсларын (1983-85) тәмамлый. 1977 дән Казанда. 1977-80 дә «Советская Татария», «Вечерняя Казань» газеталарында эшли. К. иҗатына жанрлар төрлелеге хас. Ул Мәскәү, Кустанай, Рязань, Магадан һ.б. шәһәрләр сәхнәләрендә куелган «Вакансия» (1982), «Анонимка» (1985), «Алдау» («Подлог», 1987) пьесалары, курчак театры өчен язылган «Пётр I һәм солдат» («Пётр I и солдат», 1983), «Барабашка» (1996), «Ут-кош» («Жар-птица», 2003) пьесалары; «Афродита елмаюы» («Улыбка Афродиты», 1993),

«Прокурор үлеме» («Смерть прокурора», 1993) повестьләре, «Олимпия» (1993) романы, фәнни-популяр «Славян мәҗүси аллалар, ияләр һәм женнәр» («Славянские языческие боги, духи и нечистая сила», 1994) китабы авторы.

Әсәр.: Театральный детектив: Пьесы. К., 1983.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КОЖЕВНИКОВА** Роза Хабиевна (19.12.1950, Әстерхан өлкәсе, Красноярск р-ны, Дельта станциясе—27.12.2007, Казан), шагыйрә, тәрҗемәче, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Рус телендә яза. Мәскәүдә Әдәби ин-тны (1977) тәмамлаганнан соң 1983 кә кадәр Казан резина-техник әйберләр з-дының күп тиражлы «Прогресс», Татшвейбытның «Рабочая честь» газеталарында, Татарстан өлкә комитеты нәшриятендә, «Комсомолец Татарии» газетасы редакциясендә эшли. 1983-89 да ТАССРның телевидение һәм радиовещание буенча Дәүләт комитетында әдәби-драматик тапшырулар редакторы. 1989-2006 да «Идел» ж-лында: мөхәррир, 1991 дән баш мөхәррир урынбасары. «Миләш тәлгәше» («Гроздья рябины», 1985), «Ике тавыш» («Два голоса», 1990), «Таң сызыгы» («Меж светом и тьмой», 2000) шигъри җыентыклар, балалар өчен «Кышкы яңгыр» («Зимний дождик», 1988) шигырьләр китабы авторы. К.ның иҗаты эчкерсез һәм каршылыклы (парадоксаль). Ул Г.Сәмитева, С.Хәким, Н.Арсланов, Ш.Галиев, Ә.Баян, Г.Сабитов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Зөлфәт, Р.Миннуллин, Г.Зәйнашева, Х.Халиков шигырьләрен, татар халык әкиятләрен, курчак театры өчен пьесаларны рус теленә тәрҗемә итә.

Әд.: Малышев С. Три жизни Розы Кожевниковой // Татарстан. 2002, №3.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КОЛ ГАЛИ** (1183 тирәсе—1233 һәм 1240 арасы), шагыйрь. «Кыйссаи Йосыф» лироэпик поэма авторы. Татар тюркологы Ә.Н.Нәҗип, әсәрнең тел үзенчәлекләреннән чыгып, ул Түбән Иделдә язылган дип фаразлый, чөнки анда ул чорда угызлар һәм кыпчаклар арасында актив рәвештә үзара этномәдәни аралашу күзәтелә. Әсәр ахырында автор аның кайчан язылуын күрсәтә:

Ул мәүләдән ярдәм, җиңү килгән көндә,
Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
Һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында,
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде инде.
(Янача 1233 нең 12 маенда).

Поэманың эчтәлеге (мәс., төп персонажларның берсе—фикер иясе Ягъкуб картның фикер йөртүе), стиле һәм тоны К.Г. нең үз заманасы өчен күпкырлы белемле кеше булган, гарәп-фарсы әдәбиятын яхшы белгән дип фаразларга мөмкинлек бирә.

Поэма ахырында ул болай яза:

Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек,
Гъәрәб-фарсы телләречә бәян иттек...

Аерым юлларның тәмамланмаганлыгы хәвефле монгол явы чоры, яки авторның үлүе (ихтимал, монголлар һөҗүме вакытында) текстка тулысынча редакция ясарга мөмкинлек бирмәгән дигән фикергә этәрә. К.Г. иҗаты татар язма әдәбияты, бигрәк тә поэзиясе формалашуына аеруча көчле тәэсир ясады.

Шагыйрьнең образы татар әдәбияты әсәрләрендә һәм сынлы сәнгатьтә киң чагылыш тапты: 1965 тә Б.Урманче мрамордан «Кол Гали» сынын ясый, 1973 тә Татар академия театр сәхнәсендә Н.Фәттахның «Кол Гали» исемле трагедиясе куела, 2005 тә Казанның мең еллыгы паркында Кол Гали һәйкәле куела һ.б.

Әсәр.: Гали (XII йөзнең азагы, XIII йөзнең башы) // Татар поэзиясе антологиясе. К., 1956; «Йосыф вә Зөләйха» // Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Кыйссаи Йосыф. К., 1983; Йосыф кыйссасы. К., 2000; Юсуф и Зулейха (отрывки) // Антология татарской поэзии. К., 1957; Сказание о Йусуфе. К., 1985.

Лит.: Поэт-гуманист Кул Гали. К., 1987; Ахунов А.М. Арабский источник средневековой тюрко-татарской литературы: на материале трудов ат-Табари. К., 2001; Хисамов Н.Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XII—XV вв.: Проблема версий. К., 2001; аныкы ук Бөек язмышлы әсәр. К., 1984; Таһирҗанов Г. Фирдәүси һәм Колгали // Казан утлары. 1968. № 12; Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.1. К., 1984; Фәсиев Ф. «Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы турында // Казан утлары. 1988. №3.

*Н.Ш.Хисамов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ШИШКИННАР.** Бик тә рус фамилиясе, 1586 елдан дворяннар (ОГДР III, 43). Ләкин Шишкиннар XVI йөздә төрки дөнья белән эш иткән актив фамилия, ягъни төрки телләрне әле яхшы белгәннәр: Шишкин Иван Васильевич, 1549—1550 елларда Казанда яшәгән һәм 1550 елда Мәскәүгә җибәрелгән (ПСРЛ 29, 62); Шишкин Русин Никитич 1566 елда Нугайга Урус морзага илче (ПСРЛ 29, 350). Н.А.Баскаков (1979, 123-124) фамилияне төрки шиш + ка сүзенә—ин рус кушымчасы ялганган дип уйлый.

**ЮСУПОВЛАР.** ОГДРда (III,. 2) Россия графларының X1Y гасырның 70 нче елларыннан соңламыйча рус хезмәтенә чыккан нугай Муса улы нугай морзасы Йосыфтан башлануы язылган, чөнки 1580 елда Ил-морза Йосыпов Борис Годунов белән бергә Россия гаскәренең алдынгы полкы белән җитәкчелек иткән була (ПСРЛ 34, 233). Мәшһүр Казан патша бикәсе Сөембикә—Йосып-Йосыфның кызы.

**ЯКУБОВСКИЙЛАР.** Поляк-Литва татарлары арасыннан, XIX гасыр башында алар арасыннан бигрәк тә генерал Йосыф Якубовский аерылып торган (В.,D. 1986, 135). Нәселләрендә танылган галимнәр—А. Ю. Якубовский һәм хәрбиләр—И. М. Якубовский.

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

БК, I—«Бархатная книга». Родословная книга князей и дворян Российских и выезжих. Часть I, М., 1787.

БК, II—«Бархатная книга». Родословная книга князей и дворян Российских и выезжих. Часть II, М., 1787.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения. М., Наука, 1979.

Белокуров С.А. 0 посольском приказе. М., 1906.

Бычкова М.Е. Родословные книги XY1-ХУП вв.М., Наука, 1977.

Веселовский С.Б. Исследования по истории класса служилых землевладельцев. М., 1969.

Веселовский С.Б. Ономастикон. Древнерусские имена, прозвища и фамилии. М., Наука, 1974.

Веселовский С.Б. Дьяки и подьячие на Руси. М., Наука, 1983.

Гафуров А. Имя и история. М., Наука, 1987.

Загоскин Н.А. Очерки организации и происхождения служилого сословия в допетровской Руси. Казань, 1883.

ДТС.—Древнетюркский словарь. Л., Наука, 1969. 0 Зимин А.А. Формирование боярской аристократии в России во второй половине XV—первой трети XVI века. М., Наука, 1988

---

*Ахыры. Башы үткән елгы 5, 6, 8, 9, 11, 12, быелгы 2 саннарда.*

ИРРД——История родов русского дворянства. В двух книгах.
Кн. I и II составил П.Н. Петров. СПб, 1886.Переиздание—М., 1991.
ОГДР—Общий гербовник дворянских родов Российской Империи. а—XX). СПБ, 1797——1842.
Перетяткович Г. Поволжье в XV и XVI века (Очерки по истории края и его колонизации). Одесса, 1877.
ПКК—Писцовая книга Казани. Материалы по истории народов СССР, Л., 1932.
ПВЛ—Повесть временных лет («ИЗБОРНИК». Сборник произведений литературы Древней Руси. М., 1969).
ПСРЛ——Полное собрание русских летописей. Том 9., СПб, 1856; Том 25., М.—Л., 1949; Том 29., М., 1965; Том 34., М., 1978.
РБС—Русский биографический словарь.
Савва В.И. 0 посольском приказе в XVI веке. Харьков, 1917.
Савва В.И. Дьяки и подьячии Посольского приказа в XVI веке. М., 1983.
Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // Ученые записки Мордовского университета, вып. XI., Саранск, 1960. Ц. Скрынников Р.Г. Борис Годунов. М., Наука, 1983.
ТСТ Толковый словарь татарского языка. На татарском языке. Том 1: От А до Й. Казань, 1977. Том 2: От К до С. Казань, 1979; Том 3: От Т до Н. Казань, 1981. Халиков А.Х. 0 времени, месте возникновения и названии города Казани //Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976.
Халиков А.Х. Монгольское нашествие и судьба Великого города // Археологические памятники Нижнего Прикамья. Казань, 1984.
Халиков А.Х. Волжская Булгария и Русь. Этапы политических и культурно-экономических связей в X—XIII вв.// Волжская Булгария и Русь. Казань, 1986.
Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. Казань, 1989.
Халиков А.Х. Основные этапы урало-индоевропейских связей в Среднем Поволжье и Приуралье// URALO—INDOGERMANICA. Часть II, М., 1990.
ЭС—Энциклопедический словарь. М., 1987.

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**


*Мәхмүт Нигъмәтҗановка 80 яшь*

# КЫЙММӘТЛЕ ХӘЗИНӘ ОСТАСЫ

Әле «милләт», «татар» сүзен бик кычкырып әйтергә ярамаган бер чорда ук милли музыкабызны, сәнгатебезне үстерүгә күп тырышлык куя ул.

–Унбер яшемнән үз акылым, үз көчем белән яши башладым, кемнәр белән генә аралашмадым да, кайларда гына булмадым...–ди Мәхмүт ага Нигъмәтҗанов.

Милли җанлы, нык рухлы, Г. Тукай премиясе лауреаты, профессор, күренекле музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның тормыш елъязмасына күз салсаң, чынлап та гомеренең яртысы диярлек чит-ят җирләрдә, башка милләт кешеләре арасында узганын күрәсең.



1930 елда Саба районы Олы Арташ авылында туып-үскән егетнең 1939 елда гаиләләре белән әтисе шахтада эшләү сәбәпле Донбасс якларына китүләре дә, сугыш башланып–әтисе Урал шахталарына эшкә, абыйсы белән апасы сугышка алынуы да, әнисе үлеп киткәч фронт сызыгын үтеп Мәскәүгә кайтырга теләгән малайның Белгородта приютка эләгүе дә, төрле һөнәрләр үзләштерү дә–бар да бар анда. 1943-44 елларда хәрби заводта столяр эшен дә эшләргә туры килә. Беренче тапкыр рояльне дә әнә шул приютта күрә ул. Туган якларда чакта әнисе көйләгән бәетләрдән, әтисе шахтадан ялга кайткан чакларда тальянда уйнаган төрле халык көйләреннән алынган тәэсирләр күңел почмагында шытып чыгарга үз вакытын көтеп яткан диярсең... Ул бирелә үзлегеннән рояльдә, соңрак аккордеонда уйнарга өйрәнә. Мәскәүдә «Сталинские трудовые резервы» дип аталган концертта Сталин каршында фортепианода да уйнарга насыйп була әле аңа.

Бу йомгаклау концертында катнашу берничә елдан Мәхмүт аганың язмышы хәл ителүдә мөһим роль уйный.

...1950 елда комсомол җыелышында Үзәк Комитетның «Космополитизм»га багышланган җыелышында каршы чыгыш ясый ул. Бөтен әйберне–паровозны да, очкычларны да руслар уйлап тапкан дигән «ачышларга» каршы чыга.

–Минем чыгыштан соң шундук җыелышны яптылар. Дүрт ай төрле инстанцияләрдә йөрттеләр, хатаңны таны дип тенкәгә тиделәр. Алда әйтеп киткән концертта катнашу коткарды, диделәр соңыннан.

Профессиональ музыкага аяк басканчы күп өлкәләрдә эшли ул. Мәскәүдә тимерьюлчылар техникумын тәмамлап машинист та, шушы ук училищеда укыта да, Казан дәүләт университетының математика факультеты студенты да... Төрле

уен коралларында профессиональ дәрәҗәдә уйнау аны 1953 елда Казан дәүләт консерваториясенен композиция факультетына укырга алып килә.

Бирeдә уку белән беррәттән Казан мәктәпләре һәм музыка училищесында дәресләр дә бирә, консерваториянен стена газетасында төрле тәнкыйть язмалары белән чыга–үзен чын-чынлап татар музыкасы язмышын кайгыртып йөрүче итеп таныта.

Кемнәрдер бер-берсен пычратып карьера ясарга омтылса, Мәхмүт ага Нигъмәтҗанов үзенә сүз килүдән дә курыкмыйча хаксызга рәнҗетелгән С. Габәши, С. Сәйдәшев һ. б. исемнәрен яктыртырга алына.

Ә инде халкыбызнын энҗе-җәүһәрләре саналган халык җырлары–Мәхмүт Нигъмәтҗановнын иҗади эшчәнлегендә төп урыннарнын берсен алып тора.

Эсселе-суыклы көннәрдә, егерме ел буена унсигез килолы магнитофон күтәреп халык җырларын җыеп йөрү–аны туплау–чын-чынлап халкыбыз мирасына әйләндерә алу–үзенә күрә бер батырлык.

–Төрле холыклы кешеләр бар бит. Телен ачтырыйм дисәң кайчакта печәнен дә чабышырга, утынын да ярышырга туры килә иде,–ди Мәхмүт ага ул чакларын исенә төшереп.

1970 елда Мәскәүдә «Советский композитор» нәшриятында татар музыкасы тарихында беренче тапкыр чыккан «Татар халык җырлары» китабы аерым хөрмәткә лаек. Мәхмүт аганын иҗади тормышында алар исә шактый. Халкыбыз моннарына, милли музыкабызга багышланган хезмәтләре аңа ил күләмендә генә түгел, чит илләрдә дә танылу алып килләләр.

Әлеге китапка биргән бәяләмәсендә Хәсән Туфан менә нәрсәләр ди: «Татар музыкаль фольклорынын беренче гранит нигезе булачак бу зур гыйльми әсәрдәге җырларны кызыксынып, хәтта анда тупланган байлыкнын–халкыбыз иҗат иткән байлыкнын бөеклегенә сокланып күздән кичердем.

М. Н. Нигъмәтҗановнын чиксез зур көч куеп чын мәхәббәт белән җыйнаган бу гыйльми хезмәтендә биш миллионлы татар халкынын йөрәге–күнеле генә түгел, анын гасырлар аша үткән зур, бай гомере дә, тарихы да чагыла.

Бу әсәр татар халкынын төрле шивәләре эчендәге җырларны табып алып беренче тапкыр дөньяга–мәйданга чыгаруы белән яна ачыш булып тора.»

Берәүләр соклану белдерсә, икенчеләр көнчелек утында яна. Хәтта нәшриятнын үзендә дә аптырыйлар:

–Нинди милләт сез? Башка халыклар үзләре турында Мәскәүдә китап чыгару өчен бүләк ташыйлар, сезнекеләр исә донос язалар,–диләр.

Музыка өлкәсе–сәнгатьнен кайбер башка төрләренә караганда да четреклерәк, катлаулырак. Милли музыка исә бигрәк тә. Бүгенге көндә «милли» сүзе каядыр читкәрәк китеп, сәнгатьтә очсызлы эстрада алгарак чыгып, яшь-җилкенчәкнен сәхнәдә үзен күрсәтүгә генә кайтып калды кебек.

–Менә, кара,–Мәхмүт ага минем каршыма ике газета китереп куйды. Беренчесе–1929 елда Газиз Әлмөхәммәтовнын «Кызыл Татарстан» газетасында чыккан «Бездә музыка мәсьәләсе» дигән язмасы. Икенчесе–үзенен (М.Н) 1987 елда «Советская культура» газетасындагы «Как выходить из тупика?» дип исемләнгән әнгәмәсе.–Бу язмалар арасында берничә дистә еллар. Ә проблемалар нигездә шул ук. Бүгенге көндә белемле, зәвыклы музыка белгечләре юк дәрәҗәсендә. Музыка белгече бөтендөнья музыкасыннан кин мәгълүматлы һәм намуслы булырга тиеш.

–Җыр сәнгате буенча берничә махсус югары уку йортларыбыз да бар, югыйсә. Ә нигә сон ул көннән-көн артка тәгәри? С. Сәйдәшев, Р.Яхин, А. Ключаревны алыштыра алырлык, горурланырлык композиторларыбыз бүгенге көндә нигә юк?

–Бу–сәясәт. Халыкнын рухын эчтән таркату өчен махсус шулай эшләнелә. Сәнгатьне тоталитар режим шушы хәлгә китерә. Ә андый властька гуманитар фәннәр кирәкми. Консерваториядә композиторларны милли рухта тәрбияләү гомумән дә булмады.

–Югары зәвыклы милли әсәрләр яза алырлык композиторлар әзерләү өчен татар музыка мәктәпләренең дә милли рухта булуы кирәктер бәлки...

–Мәктәп дигәннән... Саба һәм Кукмара районы үзәкләрендә тарихи ике мәктәп бар. Бу районнан чыккан күренекле кешеләр әле ул турыда, бәлки белмиләрдер дә. 1928-1930 елларда минем эти Нигъмәтҗан Мөхәррәмов салдырган мәктәпләр алар. Донбасс шахтерларыннан татар шахтерларына тырыш хезмәтләре өчен 400 мең сум премия бүлеп бирелә. Әти шушы акчаларны мәктәп салдыруга тота. Бу турыда язып бирәр мемориаль такта куйсалар яшь буын өчен начар булмас иде. Нәрсә генә әйтсәк тә бу–тарих. Урал яклары, Донбасс шахталары татарлар тормышында үзе бер тема, халкыбыз җырларында да кин яктыртыла ул. Биргә килеп, шахтерлар белән аралашып, шахтаны үз күзе белән күреп Такташ атаклы «Камил» драмасын яза.



*17 яшьлек егет чагы*

–Мәхмүт ага, Сез бит әле берничә ел филармониянең сәнгать бүлеге җитәкчесе булып та эшләгәнсез?

–Әйе. Тик мин беркайчан да түрәлеккә омтылмадым. Минем өчен иң кирәкле, кадерле эш–үз кулым, үз фикерем белән тормышка ашырыла торганы. Татарстанның 50 еллыгына Мәскәүдә «Россия» һәм Чайковский исемендәге концерт залларында зур концерт куйдык. Ул вакыттагы таләпләрне беләсез. Соңыннан аны Казанда да күрсәттек. Зур уңыш казанган бу концерттан соң җитәкчеләр тарафыннан бик югары урыннар тәкъдим ителде. Тик мин 125 сумга ИЯЛИгә кайттым, берничә ел Арча укытучылар әзерләү көллиятенә барып татар телендә теория буенча дәресләр биреп йөрдем...

–Р. Яхин бер мәкаләсендә: «Бездә музыковедлар күп, ә музыковедение юк»,–ди. Сезнең хезмәткә исә зур бәя бирә...

–Чыннан да, бездә татар музыкасын өйрәтүгә тиешле игътибар бирелмәде. Чөнки чын музыка белгече әзерләү, үстерү фәкать милли мохиттә генә мөмкин. Бездә татар телендә укыту гомумән булмады, татар телендә музыка буенча хезмәтләр түгел, мәкаләләр язылганын да хәтерләмим. Киләчәктә бу юнәлештә нәтиҗәле эш башкарырга теләсәк, укыту процессын тамырдан үзгәртү зарур, бүгенге җитәкчелек бу турыда уйлансын иде.

...Чын тарихны яктырткан язмалар көннән-көн кадерлерәк була барган кебек, татар музыка сәнгатенең үсешенә фәнни һәм иҗади яктан зур өлеш керткән музыка белгече, галим Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның «Народные песни волжских татар», «Татарские народные музыкальные инструменты», «Тукай һәм музыка», «Татар халык җырларының төзелеше» һәм башка хезмәтләренең дә тарихи кыйммәте җуелмас.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

## Вакыйф Нуруллинга 75 яшь



Вакыйф Нурулла улы Нуруллин 1935 елның 1 маенда Татарстанның Балык Бистәсе районы Югары Әшнәк авылында туа. Балачагы Ватан сугышы һәм аннан соңгы авыр елларга туры килә. Кыен тормыш шартларына карамастан, ул күрше Олы Әшнәк авылына йөреп җидееллык һәм Олы Солтан авылында урта мәктәпне тәмамлый. 1954-1957 елларда армия хезмәтендә булып кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1961 елда, университетның соңгы курсында укыган чакта, аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясенә эшкә алалар. Башта әдәби хезмәткәр, аннары проза бүлеге мөдире булып Вакыйф Нуруллин 1977 елга кадәр журналда эшли. 1977 елның июль аенда аны Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире итеп билгелиләр. 1989 елның ахырына кадәр ул шул хезмәтендә була. 1990 ел башыннан нәшрият эшеннән китә һәм 1992 елның ахырынача фәкать язучылык белән генә шөгыльләнә. 1993-2008 елларда Вакыйф Нуруллин Татарстанның берләштерелгән дәүләт музеенда (хәзер Татарстан Республикасының Милли музее) әдәбият бүлеге мөдире булып эшли.

Вакыйф Нуруллин үзенең беренче әсәре белән үк татар әдәбиятына яңалык алып килә—«Шинельсыз солдатлар» повестен яза. Язучының «Күпер чыкканда» исемле икенче повесте да (1969) авторга уңыш китерә. 1974 елда, Татарстан телевидениесендә, телевидение тарихында беренче буларак, шул повесть буенча эшләнгән (сценарий авторы—Эльс Гаделев, режиссеры—Марсель Сәлимҗанов) татарча спектакль күрсәтелә.

Узган гасырның җитмешенче еллары дәвамында Вакыйф Нуруллин, иҗат осталыгын үстерә барып, «Әгәр .син булмасаң...» (1973), «Аккан су юлын табар» (1978) повестьларын һәм «Яшьнәп үткән яшьлек»документаль әсәрен (1975) яза. Әдипнең автобиографик «Ике урам арасы» (1984), «Җавап бир, кеше!» (1985) һәм «Сагынырсыз әле» (1993) повестьлары да укучылар тарафыннан җылы каршы алына.

Вакыйф Нуруллин—ике дистәдән артык китап авторы. 1991 елда Татарстан китап нәшрияты аның ике томлык «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгара. Әдипнең барлык төп әсәрләре рус теленә һәм кайберләре украин, таҗик, әзәрбайҗан, каракалпак, казакъ телләренә дә тәрҗемә ителде.

Вакыйф Нуруллин үзе дә тәрҗемә белән, авторларның проза әсәрләрен әдәби эшкәртү белән шөгыльләнә.

***Танылган әдип, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният эшлеклесе Вакыйф Нуруллинны юбилее белән котлыйбыз, яңа иҗат уңышлары, нык сәламәтлек телибез.***

## Мәгъсум Хуҗинның тууына 80 ел

Минем өлкән яшьтәшем. Узган гасырның туксанынчы елларында язган бер мәкаләмдә Мәгъсум абый турында шулай дип әйткән идем. Болай әйтергә хакым булгандыр, дип уйлыйм, чөнки, кем әйтмешли, серләребез сыеша, уйларыбыз килешә, очрашсак—сөйләшеп туялмыйбыз... Көн саен диярлек телефон аша хәл-әхвәлләребезне белешкәләп торабыз дигәндәй... Ул үзе дә мине яшьтәше итеп саный. «Ерактагы кыялар» китабына салган култамгасы да менә бер дәлил: «Ләбиб яшьтәшкә—Мәгъсум абыйдан». Бервакыт мин аңа мондыйрак сүз әйттем: «Мәгъсум абый, син «олыгая» белмисең шикелле. Һаман яшьләргә тартыласың (әллә киресенчә, без—синамы?!). Яшьләр белән аралашудан нинди кызык-тәм табасың?» Аның җавабы болайрак яңгырады: «Сезгә, яшьләргә тартылуым «кечкенә» хәйләгә бәйле. Сез, безнең буын кешеләренә караганда, күпкә гыйлемле. Сездән өйрәнергә телим мин. Һәм язуда да шулай. Ихлас. Сез, яшьләр, һәм мин, бабай, төрле очракларда да бер даирә булып тора алабыз ич, тар урында да сыешабыз ягъни. Сезнең һәркайсыгыз бер-берегезнең (һәм минем дә) фикерен үстерергә сәләтле. Сезгә тартылуым үз ягымны каеруда, димәк...»



*Мәгъсум Хуҗин шигырь бәйрәмендә. М. Галиев фотосы*

Әлеге җаваптан ук күренеп тора: яшьләрне ярата (иде, диясе килми) Мәгъсум абый. Алар белән гәпләшергә, бәхәсләшергә ярата. Ә аның андый гәптәш-каләмдәш «яшьтәшләре» бихисап—Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләис Зөлкарнәй, Камил Кәрим, Зиннур Хөснияр, Марат Закир, Вакыйф Нуриев, Тәлгат Нәҗмиев, Ирек Нигъмәти...

Мәгъсум абый—һөнәрчеләр төбәге, осталар ягы булган Сабадан,төгәлрәк әйткәндә, затлыдан-затлы хәситәләр, беләзек-балдаклар, алкалар ясарга маһир мәшһүр көмешчеләре, атаклы күмәччеләре белән данлыклы Тенеки авылыннан. Сабадан биш кенә чакрым ераклыкта урнашкан шул атаклы авылны, шул төбәктәге Аждаһа күпкан төшне, Шүрәле сазлыгын, Төпсез чишмәне, Арыслан тавын, Алпамша-Пәһлеван чабатасын каккannan соң барлыкка килгән кибән-тауны (болар хакында Мәгъсум абыйның бик тәмләп, тәфсилләп сөйләгәне әле дә исемдә) бик күрәсем килде. Бергә кайтабыз, дип Мәгъсум абый белән берничә мәртәбә алгысындык та хәтта. Дөнья мәшәкатьләре белән матавыкланып, көн артыннан көн, ай артыннан айлар узды. Еллар акты дигәндәй... Тенекигә барырга-кайтырга берничек тә җай чыкмады. «Бөтен барлыгым—атам-анам тәрбиясеннән, туган ягымнан. Һөнәрчеләр ягы—Саба төбәге мине табигатьне, тормышны анларга өйрәтте, кешеләр язмышына якынайтты»,—дияргә яраткан Мәгъсум абый көтмәгәндә бакыйлыкка күчте...

Бер сүз сөрешебез вакытында мин Мәгъсум абыйдан: «Узган гомереңнән, яшәвеңнән канәгатьме син?»—дип сораган идем. Җавап кыска булды: «О. Генриның бер новелласында мондый фикер әйтелә: кеше тормышының тулылыгы өчен өч нәрсә кичерергә тиеш—ярлылык, мәхәббәт һәм сугыш... Мин боларда сыналдым!»

Әйе, язмыш тарафыннан Мәгъсум абый каты сыналды. Әмма сынмады ул, сыгылмады. Тормышындагы сагыш-әрнүләрен, ачы сөенечләрен, якты көенечләрен

могтәбәр әдип гамьле хикәяләр итеп ак кәгазь битләренә күчерде.

Китапларын, аерым әсәрләрен кайта-кайта укый торгач, шуны искәрдем: Мәгъсум Хужин хикәяләренең байтагы Олуг Мәхәббәт турында икән бит! «Калатауга бөркет кунган», «Айнын уты сүнгән», «Беренче боз», «Хыянәт», «Йолдызлар артында—йолдызлар», «Ике авыл арасы», «Исәнме, Раушания!..», «Мәхәббәт бит ул», «Оҗмах агачы»... Болар—М. Хужиннын Мәхәббәт-сөю хакындагы хикәяләренең кайберләре генә. Хикәяләрнең үзенчәлеге шунда: әсәрләрдәге каһарманнар ике-өч кешедән артмый. Бер-берсенә гашыйк булган егет һәм кыз, ир һәм хатын: Фазыл-Раушания, Ләбиб-Мәйсәрә, Надир-Фәһимә, Баязит-Галия, Әкбәр-Сәгъдия...

«Мин сине яратам-сөям, ә син нигә яратмыйсын? Сагындым үзенне, кил инде, синсез яши алмыйм...» кебегрәк тезмәләрдән торган шакмаклы такмакларны чын шагыйрьләр шигырьгә дә санамый. Шигырьдә Мәхәббәтне «Мин сине яратам» дип әйтмичә дә сурәтләп була. Шәп хикәя язу да чын шигырь язуга тин ул. Хикәядә дә Мәхәббәт турында язылган чын шигырьдәге кебек үк: шул ук эчке кичерешләр, күнел газабы, уй-хисләрнең галибанә яктылыгы, ләззәтле сагыш-моң, борчулы куанычнын ялгыз ай сыман бәргәләнүе...

Әйе, Мәгъсум Хужин хикәяләре чын шигырьләргә бәрабәр. Әдипнең минем күнелемә аеруча хуш килгән «Ак колын» дигән хикәясендә Биюш исемле бер малайкарт образы бар. Биюш һәр нәрсәдән—ак колыннын тоякларын тыпырдатуыннан, идәнгә чәчрәп очкан чынаякнын үзенә генә хас аһәң чыгарып зенләвеннән, өй түбәсендә тыпырдап биегән янгыр тамчыларыннан, күзгә ботакларнын сыкрануыннан моң эзли. Көй эзли. Бала чагын, кечкенә Биюш чагын сагына... «Сәер кеше инде мин,—дип уйлый Биюш.—Һаман акыл кермәгән—колыннын тояк тавышлары ничек моң булып таралсын инде? Әллә монны йөрәк тоямы? Кем белгән... Әллә тау сөзәгендә җирнең моң телләре бармы сон? Туктале, ак колын, әнә шул телләргә басып, көй чыгара икән бит!..» Хикәяне укып чыгасын да уйлап куясын: «Биюш шикелле шигъри күнелле «сәер җаннар» күбрәк булса, дөнья никадәр сафланыр, яна, матур төсмер алыр иде...»

«Мәгъсум Хужин геройлары—табигатькә, җиргә, игенче хезмәтенә, авыл мохитына фанатикларча гашыйк кешеләр. Алар, туган якнын инеш ташларына кадәр үз күреп, туган җирнең олы язмышын кайгыртып яши торган шигъри җанлы, гамьле кешеләр...»,—дип язган иде үз вакытында Фаил Шәфигуллин аркадаш-каләмдәшенең иҗатына югары бәя биреп. Мәшһүр шагыйребез Зөлфәт тә, Мәгъсум абыйнын әсәрләрен укып-сокланып, бер язмасында («Тыкрыктагы аулак сукмак») болай дигән иде: «Чәй» повесте эчендә бер хикәят бар. Балта остасы үзенең эч серләрен сөйли. Анын бу дөньяны саф, төзек, гөнаһсыз итәсе килә. «Бөтен хикмәт шунда—бездән дөнья гүзәл калсын!»—ди ул. Кешелек шагыйрьләренең хыялы түгелме сон бу?»

Заманында үзе дә шигырьләр язган, шулардан өчесен матбугат битләрендә бастырган («Шөкер, мең шөкер, аларны беркем дә белмидер»,—дип елмайганы истә Мәгъсум абыйнын) әдип Ш.Маннур, Г.Хужи, С.Баттал, Н.Арслан, Ф.Хөсни, М.Максуд кебек бик күп олпат шагыйрь-язучылар белән дустанә аралашып яшәгән кеше. Гомеренең сонгы елларында ул шул замандашлары хакында кечкенә истәлек-кыйссалар язды. Минемчә, Мәгъсум абыйнын бу әсәрләре дә аерым игътибарга лаек.

Язмам ахырында төрле һөнәр ияләре белән аралашкан, дус булган Мәгъсум абыйнын балачак хыялын искә төшерәсем килә: «Сулар-җирләр гизәсе иде! Дөнья күрәсе иде! Сәяхәт итәсе иде! Тик җәяүле малайнын ерак сәфәре дә авыл каршындагы тау түбәсеннән, якындагы урманнан, Мишә болыннарыннан ары китми иде...»

Инде хәзер беләбез: җәяүле малай көннәрдән беркөнне җәяүле олуг әдипкә әйләнде. Анын ерак сәфәре әле дә дәвам итә: укучылар күнелен яулаган тәэссоратлы әсәрләрендә, шигъри җанлы китапларында...

**Ләбиб ЛЕРОН**

# ТАТАР БАТЫРМЫ?

Татар тарихка батырдан да батыр халык булып кергән. Ярты дөньяны яулаган ташкын алдында юл ярып, кылыч айкап, «ура!» кычкырып татар угланнары (оланнары) барган бит. Җиңелмәс угланнар үрнәгендә Көнбатыш Европаның күп кенә мәмләкәтләрендә соңрак җиңел кавалерия гаскәре—*улан* полклары да оешкан хәтта. «Ура!»га килсәк, шагыйрь «И грянул русское ура» дип язса да, аларга һичшиксез татардан йоккан бу яу ораны, аның урысчасын «окружай!» дип кычкырасы булыр иде. (Хәер, В. Даль аны татарның «ур»ын (бей) хәтерләтә дип яза.)

«Җиңелмәс» татарлар да Идел буенда бер җиңелгәннәр үзе. Болгарлар җиңгән аларны. Тегеләре дә, болары да безгә, хәзерге татарларга, бабаларыбыз тия. Беренчеләре—«әти ягыннан», икенчеләре «әни ягыннан» диикме икән инде?

Бабаларыбызның «уру-урау» даны XX гасыргача килеп җиткән. Юкса Тукай «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» дип язар идеме икән?

Бәлкем, Бөек Ватан сугышынача татарның дан-шөһрәте генә түгел, тиңсез көч-гайрәте дә исән-имин килеп җиткәндер әле? «Кызыл Армия бу сугышта яндырган немец танкларының 67 процентын татарлар юк итте; дошманның 42 процент самолетын татарлар бәреп төшерде; Бөек Ватан сугышында кулга төшерелгән 90 процент немец генералын татарлар әсирлеккә алды, сугышның иң хәтәр юнәлешләрендәге 80 процент командирлар татарлар иде...» Борынгы бабаларыбызны да шаккатырырлык бу саннар 1995 елны «Шәһри Казан»да (5 июль саны) басылып чыккан. «Мактанырга хакым бар» дигән әлеге мәкаләнең астында «Рәис Чумарин» дигән имза, аның астында «Татар-Информ»—агентлык атамасы тора. Автор бу саннарны «Известия» газетасының 1948 елгы 16 гыйнвар (№ 14) санында китерелгән статистик таблицадан алынды дигән.

«Рубин» яисә «Ак барс» җиңүләрен чагылдырган саннар гына түгел лә бу, безнең горурлык ак болытлардан да ашып, планетага космик биеклектән багарга тиеш булгандыр инде. Ләкин мин үзем, редакциягә шушы саннар да булган мәкалә килеп кергәч, аларны сызып калдырдым. Чөнки 1939 елгы җанисәп буенча СССРда яшәүчеләрнең 2,5 процентын тәшкил иткән татар халкы[1] (җәмгысе 4313,5 мең) вәкилләре, әйтик, шулкадәр самолет бәреп төшерер өчен, әкияти батырлыкка ия булган хәлдә дә, осталык җәһәтеннән дә башкалардан нык кына түгел, үтә нык аерылып торырга тиеш ләбаса. Кайда күрәбез соң без мондый аерманы?.. Икенче тапкыр, бусы әле күптән түгел генә, янә шул саннарга таянуга тап булгач, түзмәдем, китапханәгә киттем. «Известия»нең 1948 елгы 16 гыйнвар саны һич тә 14нче түгел, 13нче сан икән. Ләкин ни тегесендә, ни бусында әлеге шаккаткыч мәгълүматлар юк иде.

Алайса ни булып чыкты инде бу гамәл? Татарга мондый ялган олылык кирәкме соң?

Саннарның дөресе нинди икән? Һәм хәрби статистикада моның ише күрсәткечләр була ала микән әле ул?

Хәер, батырлыкның эзе күкрәктә дә кала бит. «Алтын Йолдыз»ны, ягъни 1934—91 елларда СССРда иң югары дәрәҗәле исем булган «Советлар Союзы Герое»н ярдәмгә дәшик әле. Бөек Ватан сугышындагы батырлыклары өчен

[1] Бу санны онытмыйк, алда кирәге чыккалар аның.

бу исемне 11633 кеше алган[2]. 2006 елны Мәскәүдә «Великая Россия. Имена» энциклопедиясенә өстәмәләр сериясендә чыккан «Татары: воины. Труженики. Патриоты» дигән китапта мондый 167 милләттәшебезнең исеме теркәлгән. Ягъни алар бөтен Геройларның 1,5 процентын тәшкил итә икән. Теге 2,5 процент янына куйгач, аз күренә бит бу сан!

Патша заманындагы шанлы «Георгий Тәресе»нең советчыл тиңдәше булган югары орденның—«Дан»ның (1943 елда булдырыла) тулы кавалерлары, ягъни аның өч дәрәҗәсен дә алучылар 2642 кеше икән. Шуларның 56сы татар икән[3] (шул ук «Татары: воины.Труженики. Патриоты» дигән китаптан алынды). Бу юлы татарлар өлеше 2,1 процент килеп чыга.

Батырлыкның «тәрҗемә» сорамыйча, турыдан-туры төгаен санга әйләнгән (нык тырышып эзләгән-барлаганнан соң, әлбәттә) төре дә бар. Бу—тәнең белән амбразураны каплау. Мондый каһарманнар шактый күп икән—җәмгысе 432 кеше. Һәм шуларның 24е безгә милләттәш тия икән[4]. Монда өлешебез саллырак инде—5,5 процент.

Батырлык кимәлен аныклый торган бүтән үлчәмдәге күрсәткеч тә бар әле. Пленга эләккән сугышчыларның 2,2 проценты татарлар булган. Мисал өчен, урыслар әсир төшкәннәрнең—48, украиннар—28,2, белоруслар 7,5 проценты икән[5]. (1939 елда бу халыклар СССРда яшәүчеләрнең 59; 20,9 һәм 4,8 процентын тәшкил иткәннәр.)

Безнең сан үз 2,5 процентыбыз янында зыянсыз күренә. Ләкин татарга хаксыз тарихи үпкә саклап, аңа гел күзенең агы белән караган Мәскәүгә татар язмышын кыл өстендә тотар өчен шул да бик җитә кала. Һәм... чечәннәр, ингушлар, калмыклар, карачайлар, балкарлар, Кырым татарлары кебек имештер хыянәтчел халыкларга ияртеп 1944 елны безне дә аздан гына сөрми калалар. (Бу хакта академик Миркасыйм Госманов дәлилләп һәм тәфсилләп сөйли ала.) Күп булуыбыз һәм хыянәт мисалчыклар җитмәү генә тотып калган, ахрысы... Әгәр дә мәгәр берәр татар командиры, юк, генерал-лейтенант Андрей Власов[6] кебек армия кадәр армияне димим, корпусны да, дивизияне, полкны, батальонны да түгел, йөз кешелек ротаны гына булса да немец ягына алып чыкса, шул берәзлексез чәйнәлеп, татарга, һичшиксез хыянәтче халык тамгасы сугылыр иде.

Муса Җәлилнең костюм киеп хөр-иркен йөрү фактын күтәреп селкеп, татарга каршы уйнатырга омтылулар булды. Яшерен оешма да төзелсен, эш тә ачыктан-ачык алып барылсынмени? Соң алайса без «Семнадцать мгновений весны»да Исаевның Штирлиц булып фашист офицеры формасыннан йөрүен дә гаепләп карарга тиешбез бит... Әйтерсең лә татар легионнары каршы якка чыгып фашистлар белән дә сугышмаган, фашист суды карары белән башлар да чабылмаган!

Соңгы вакытта янә шул ук картаны уйнатырга омтылуны күрәбез. «Мирас» журналында басылган драма әсәрендә Җәлил Гитлер белән очраша. Аннан бүләк тә ала әле. Ни дип бәялик соң моны?

Бөек Ватан сугышына татарның милли мәнфәгатьләре җәһәтеннән караганда ни килеп чыгар? Татар өчен дә бөекме ул сугыш? Һәм—Ватан сугышымы? Җиңүче милләттәшләребезне илдә нинди милли сөенечләр, үсеш мөмкинлекләре көткән? Туган җир капкасы бөтенләй ачылмаска да мөмкин булган түгелме соң?.. Хәер, болары «Мирас» әһелләрен һич борчымагандыр. Бу журналның Сөембикә Шаһгали белән Казанны алышырга килгән дип язып чыкканы да булды лабаса.

Кычкырып әйтелми торган бер сүз бардыр кебек: «Берәр халыкны зәгыйфьләндерим дисәң, аның бөекләрен пычрат». Пычраттырмыйк бөекләребезне!

Мусаны советка каршы уен уйнаган итү ул, ихлас түгелгә чыгарып, дөньякүләм данлыклы «Моабит» дәфтәре»нең да башын чаптыру булыр иде.

Кешелеккә һәм кешелеклелеккә яу ачкан фашизм афәте белән көрәштәге батырлыкларның балкышы беркайчан да тоныкланмас.

---

2 Кара: Герои Советского Союза. М.,Воениздат. – 1984 – С. 190.

3 Татарлар саны күбрәк булган исемлекләр дә бар.

4 Ш. Мостафинның «Хәтер яктысы» дигән китабында аларның тәфсилле исемлеге бирелгән. (Татар. кит. нәшр.,2004,286.).

5 Г. Кривошеев җитәкчелегендә әзерләнгән «Гриф секретности снят» дигән китаптан. М.,Воениздат,1993.

6 Соңрак РОА – Урыс азат итү армиясен оештыра һәм аңа җитәкчелек итә.

Илдар Юзеев үзенең «Язылмаган поэма»сын багышлаган Хәйретдин Мөҗәебез дә бар бит әле безнең. Язучы, шанлы полк командиры. Әсирлеккә эләккәч, Даһау концлагерында яшерен оешма төзүчеләрнең һәм восстание әзерләүчеләрнең берсе була ул (яшерен исеме—Самсон). Фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.

Кызганыч ки, пленнан качу статистикасы юк. Иң күп качучы татардыр кебек тоела миңа. Минем Мәсгут абыем да, әтием Юныс та (әле теге, 1914 елдагы сугышта ук!) качканнар.

Инженерлык гаскәрләре генерал-лейтенанты Дмитрий Карбышев, яраланып пленга эләккәч, лагерьда фашистларга каршы агитация алып бара. Фашистлар аны төрлечә үз якларына тартырга—аннан Власов ясарга тырышып карыйлар, ләкин ул бирешми. Бер салкын кышкы төндә аңа боз һәйкәлгә әйләнгәнче су сибеп торалар... Маутхаузен лагере капкасы янында ак мәрмәрдән куелган чын һәйкәлдә аның сыны гүяки боздан калкып чыга. Данлы совет генералына, татар кешесенә[7] куелган ошбу һәйкәл әсирлектән качкан яки чәнечкеле чыбык эчендә көрәшне дәвам итә алган меңнәрчә милләттәшебезне дә яд итү булсын иде.

Геройларыбыз өлеше күп булмаса да, аларның саны буенча урыслар, украиннар һәм белоруслардан кала дүртенче урында торабыз без, халык санына нисбәттә караганда исә белоруслардан да алдабыз (аларның 8,3 млн. кешегә 311 Герой). Ягъни автономияле республика халкы булып һәм ил буйлап чәчелеп-сибелеп тыйнак-мескен генә яшәп яткан татар сугыш башлангач кинәт алга томырылып чыга, авыр һәм хәтәр сугыш йөген төпкә җигелеп тарта башлый.

15 ел элек миңа армия генералы, Россиянең Хәрби фәннәр академиясе президенты Мәхмүт ага Гәрәев белән әңгәмә үткәрү насыйп булган иде. Шунда ул болай дип тә әйтте: «Урыс булмасаң, юл бирмиләр иде. Шуның өчен татар кешесенә, мөселман кешесенә башкаларга караганда ике-өч тапкыр күбрәк эшләргә кирәк иде күтәрелер өчен». Бу хәл батырлыкны бәяләгәндә дә сизелми калмагандыр шул. Милләттәшләребезнең Герой исеменә икешәр (хәтта өчәр!) тапкыр тәкъдим ителеп тә бюрократик баскычны үтә алмау очраклары күп икән. Әмма сугыш эчендә кайнаган хәрби җитәкчеләр (И. Конев, Р. Малиновский, Л. Говоров, А. Еременко), мәгълүм ки, татар яугирләренең гайрәтле, батыр булулары турында бик матур сүзләр әйтеп калдырганнар. Данлыклы язучы Илья Эренбург үзенең «Татары» дигән очеркында немец ефрейторы Рудольф Вольгангның хатыннан менә мондый сүзләр китерә: «Монда безгә каршы татар күп. Болар шашкан халык. Һәм мин татар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем».

Баскын яу татар белән сугышның беренче көнендә үк очраша. СССР дигән илне тоташ иңләп эчкә тирән үтеп керә ул. Бер җирдән генә айдан артык үтә алмый интегә—соңыннан «герой-крепость» дип табылачак Брест кирмәненнән генә. Кирмәннең иң җете каһарманы милләттәшебез, полк командиры майор Петр Гаврилов була... Фашист явы татарны сугышның азагында да күрә. Хәер, үзен, бәлкем, күкрәген йөрәге янынннан ук тишеп үткән тәнгә пуля гына күргәндер. Ә менә ул Рейхстаг түбәсендә кадерле ядкарь—чиккән кульяулыктан тасмалар ертып бәйләп куйган Җиңү байрагын иртән бик күпләр күрә. Бары олуг хәрби түрәләр генә күрергә теләмәде аны. Алар Җиңү байрагы дип күп соңрак әленгән «дөрес» (М. Егоров белән М. Кантария—урыс белән грузин әлгән!) байракны таныдылар. Ләкин тарих сукыр түгел. «Первыми в 22 часа 30 мин. (время московское) 30.04.1945 года водрузили Знамя на крыше Рейхстага на скульптурной группе «Богиня Победы» артиллеристы-разведчики 136-й армейской пушечной артиллерийской бригады ст. сержант Г. К. Загитов, А. П. Бобров, А. Ф. Лисименко и сержант М. П. Минин из состава штурмовой группы 79 стрелкового корпуса, возглавляемой капитаном В. Н. Маковым».—Бу сүзләр «Хәрби энциклопедия»нең 3нче томына теркәлгән (1995) ...Заһитовның исеме—Газый. Гарәпчәдән күчерсәң, «сугышта җиңеп чыгучы» була[8].

Константин Симоновның данлыклы «Живые и мертвые» романының әвәлге өлешләре басылып чыгуга тәнкыйтьчеләр аның баш герое генерал Серпилин турында, ул рус рухының олылыгын чагылдыра кебек фикерләр әйтергә ашыгалар. Әсәрнең һәм гомеренең азагында исә генерал... татар көен көйләп

[7] Кара: 1) Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан,2002; 2) Татары: воины. Труженики. Патриоты. – 2006 – С. 138.

[8] Г. Заһитов һәм аның бу батырлыгы турында Ш. Рәкыйпов, Я. Шәфыйков, И. Абдуллин, З. Зәйнуллин, Ш. Мостафин һ.б. язды.

җибәрә. Безнең Самат Шакирның шул хактагы соравына әдип «Мин батыр татар генералларын күп күрдем» дип җавап бирә... «...в бою за деревню Чернушки погиб 19-летний комсомолец, верный сын русского народа...» «Он настоящим был героем. Он русским человеком был»,—үзенә шуның кебек күп-күп мәкалә, шигырь, җыр сүзләре багышланган Александр Матросов исә Шакирҗан Мөхәммәтҗанов булып чыга[9]. Матросовка әйләнүенең сәбәбе гап-гади икән: балалар йортларында урыс булмаганнарны кешегә санамыйлар.

...Мәскәү янындагы бәрелешләрнең үтә авыр чорыннан соң Мәскәү шәһәр комитетының беренче секретаре, Кызыл Армиянең Баш сәяси идарәсе башлыгы В. Щербаков Сталиннан бердәнбер кешегә Советлар Союзы Герое исемен бирүне үтенә. Бу кеше «катюша»лар бригадасы командиры Бари Йосыпов була. Сталин исә үтенечне кире кага, Мәскәү яны сугышларының бу этабын оттырдык без, шуннан соң да начальник кешегә Герой бирсәк, безне дөрес аңламаслар, ди. Күп тә үтми, Щербаков янына данлыклы скульптор Вера Мухина килә һәм, миңа Кызыл Армиянең иң батыр сугышчысын күрсәтегез әле, ди. Щербаков аны госпитальгә, Йосыпов янына алып китә, менә аны ясагыз, ди. Барый Йосыповның «Мужество» дип аталган скульптур бюсты Третьяков галереясында бөтен Кызыл Армия батырлыгының гәүдәләнеше булып тора...

Инде куелган сорауга җавап бирик: батырмы ул татар? Бик тә, бик тә «Батыр, батыр минем татарым!» дип әйтәсе килә. Ләкин хак җавап башкачарак шул: татар батыр да, куркак та. Һәм минем белән килешүчеләр аз булмастыр. Сугышта түш киереп үлемгә каршы барган гайәр ирләрнең бәләкәй генә түрә кисәге янында да агарынып-күгәренеп басып торганын күргән бар ләбаса. Борынгы «Үрә кат!»ны канга артыграк сеңдергәнбез бугай шул! Хәер, кабинетларда урыслар да «Смирно!»га бик матур басып тора беләләр анысы. «Әти ягыннан бабаларыбыз» холкы үзен тагын да шул яктан сиздергән: алар кайсы яу башында баруның аермасын бик тоймаганнар да бугай. Татар иң зур дәрәҗәгә ятларга хезмәт итеп ирешкән. Шаһгали әнә урыс армиясендәге иң югары генерал-фельдмаршал чинын алган. Буа татары Борһан Шаһиди Кытай компартиясендә Маоның урынбасары булган.

«Шәлперәй!»не дә җиренә җиткереп үтибез. Тәмам мәлҗерибез! Шәхси хокукларыңны яклый алмау—куркаклык, туган халкың хакын якларга теләмәү—хыянәтчел мескенлек бит юкса... Өстәгеләрнең җылы күз карашы дигәндә, карьера дигәндә татар атасын да сатар!..—авыр бер шаукымга бирелеп шулай дип уйлап куюым булды, күз алдымнан бөтенләй бүтән төрле затлар үтте. Хәрбиләрдән милли хәрәкәттәге полковниклар да искә төште. Армиядә дә ата татар булып яши алган Зәки Зәйнуллиныбыз. Фәндәс Сафиуллин, Рашат Сафиннар... Армия генералы, Генераль штаб башлыгы урынбасары килеш тә милләтен кайгыртып яшәгән, кайбер олы түрәләрне шөбһәгә салып, беренче тапкыр татар генералларын очрашуга җыя алган Мәхмүт Гәрәев...

Батырлыкмы, куркаклыкмы—кайсы як өстен чыгар? Нинди булыр икән ул безнең язмыш?

**Рәфикъ ЮНЫС**

**P.S.** Мәкалә өчен материал туплаганда күренекле эзтабар язучы Шаһинур Мостафинның ярдәме тиде.

[9] Кара: 1) Татар энциклопедия сүзлеге. 2) Татары: воины...



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

# БЕР ТЕЛЕФОН ТАРИХЫ

ХИКӘЯ

Мин «Samsung-C 235» модельле телефон. Хуҗабикәм кулына килеп керүемә инде ике ел. Уналты яшенә әтисе бүләк итте аңа. Шул чаклы гына булса да, мин аның бар серләрен, йөргән егетләренә әйтергә теләп тә әйтмичә калган сүзләренә кадәр беләм.

Ләйсән телефоны булып яшәвемне мин өч этапка бүләм, ягъни минем өч тапкыр җиргә бәрелеп тә, ватылмый калган аралар. Бу вакыйгалар минем үлем белән яшәү арасында калган минутлар гына түгел, алар хуҗабикәм язмышына да зур йогынты ясады.

## I бәрелеш

Яз иде. Әле дә хәтерлим, тал песиләре белән аңкыган караңгы авыл урамы, резин итекләргә кыштан калган салам бөртекләре, үзле балчык ябыша. Минем хуҗабикәм ялгыз гына концерттан кайтып бара. Шулчак артыннан ниндидер авыл гыйбады килеп иseме белән эндәште. Алар сөйләшә башладылар...

Моңарчы ул миңа гына шулай елмая иде! Гыйбад димичә ни дисең инде? Әле бит җырчы да икән! Гарьлегеңнән зарядканы кабул итми башларсың, валлаһи! Сайрый гына егеткәй... Тик минем Ләйсәнемне алдап буламыни! «Әбиеңә ашат бу тәмле токмачыңны»,—дип капыл гына борылып китмәкче иде дә, мине кулыннан төшереп җибәрде. Их, үзем дә инде, бөтен эшне боздым. Алар икесе бергә мине алырга үрелделәр. Һәм, ни хикмәт, чын әкият диярсең, күзләре очрашты да, Ләйсәнем кызарды, ә җырчы сандугач аның бит очына томшыгын тидереп алды.

Шул көннән башланды инде минем кичке саф һава сулап йөрүләрем.

Йөрмәгән сукмак, таптамаган тыкрык калмады. Әле ул гынамы? Төнлә, көндез, кичен, иртән смслар, шылтыратулар!..

Тик шулай да матур йөрделәр алар. Мин болай гына, көнләшүдән генә арттырам инде...

Вәләкин... бернәрсә дә гомерлек булмый икән... (Бу сүзләр миңа кагылмый!) Беркөнне, кыш иде ул, шәп кенә кар ява, чехолым булмаганга, юешләнеп, күшегеп беткән идем, Ләйсән янына минем исемлектә «Сертотмас үрдәк» дип язылган бер кыз килде дә, егетеңнең башка авылда кызы бар, диде. Ул төнне мин аның күз яшьләре өчен җырчы сандугачның бар каурыен йолкып бетерергә әзер идем. Вакыт—дәва диләр, миңа яңа брелок алганда Ләйсән янә шаяра, көлә, елмая иде инде.

## II бәрелеш

Мин сөйлим дә сөйлим, ә иң мөһимен әйтергә онытканмын. Ләйсән—тыныч холыклы, акыллы, сөйкемле кыз ул. Мине тәүге тапкыр кулына алгач ук аңа гашыйк идем инде. Әлегә ул мәктәптә укучы кыз гына... Ярый, тагы сүзем озая, «безлимитка» түгел бит, вакыт үтә...

Шулай беркөнне тыныч кына өстәл өстендә ял итеп ятам. Таныш булмаган кемдер шылтырата,миндә исеме юк. Ләйсәнем аяк очларындамы,канатларындамы очып килде дә: «Алло!»,—диде. Ә анда җавап итеп: «Ләйсән,бу—Рамил. Мин сине яратам. Бары сине генә»,—диделәр дә,өзделәр. Ләйсән каушап,кызарып, уйланып,куанып утырган арада мин сезгә аның серен ача торам.

Ул мине бер тимер кисәге генә дип уйлый. Ә мин барысын да күреп,тоеп торам. Ул кеше күрмәгәндә гел минем кнопкаларымда Рамил исемен җыя. Ләйсән янә гашыйк булды. Ә бүген шул Рамил шылтырата. Кем булган ул минем йокымны бүләргә? Бөтен тынычлыгымны,Ләйсәнемне урларга телиме ул юкса?

Шулай 10 минут үтте. Төгәлрәк булсак,9 минут 49 секунд. Янә шылтырыйм. Бусы тагы кем? Чыбыкларыма хәтле кызыша,ток йөрешем туктап калды,ахры. Тагы бер билгесез: «Алло!». Җавапка кабат шул ук сүзләр...

Ләйсән тик тора алмый,бер миңа,бер көзгегә карый,инде елмаймый да, йөзендә курку хисе язылган.

1 сәгать 42 минут 53 секунд үтте. Тагын бер билгесез номер. Фу,нәләт, имансызлар! Экраным парланып чыкты. Йөрәгем булса,күптән ярылыр иде. Ләйсән бу юлы озак алмый торды. Тик ахырдан барыбер кызыксынуы җиңде: «Кем кирәк?»—җавап: «Ләйсән,бу—Рамил...»

Көне буе канатланып йөрде хуҗабикәм! Эшләмәгән эше,сөртмәгән тузаны, җырламаган җыры калмады... Кич. 21 сәгать 50 минут 01 секунд. Тагын таныш булмаган номер. Мин дә,Ләйсән дә борчылмыйбыз. «Алло!» «Ләйсән,бу—Рамил. Без шаярдык кына,чынга алма,зинһар. Тыныч йокы.»

Мин Ләйсәннең йомшак кулының катгый боерыгыннан соң дивар тарафына очтым... Ай!.. ватылмадым тагын,Аллага шөкер!..

Шушы көннән Ләйсән бер егетнең дә сүзенә ышанмаска,алар өчен еламаска сүз бирде.

Һәм сүзендә торды да. Әллә ничәсе минем экраныма матур сүзләр юллады, Ләйсән кире бора торды. Көлде,елмайды,шаярды... Шул кирәк аларга!

## III бүлек

Яз килде. Урамнарда сирень исе,кызлар берсеннән-берсе кыска итәкле.. Нурлы,моңлы,назлы Казан язы...

Ләйсән—студентка. Казанга иярләнә башлаганына бер ел. Мин әле дә аның юлдашы. Брелокларымны да еш алыштырдым,аның егетләре санынча булды алар... Дөрес,һәрберсе өчен мин җиргә очмадым,билгеле,һәм менә быел яз килде. Ләйсән өчен беренче Казан язы...

Инде миңа акыл кергән,Ләйсәннең төннәр-көннәр буе китап укып утыруыннан, дәрескә бизәнмичә чыгып китүеннән,дискотекаларга йөрмәвеннән һәм,ниһаять, аңа бер генә дә «матурым,мин сине сагындым»,—дигән «смс»ка килмәвеннән туйган,арыган идем. Көнләшергә кеше булганда, үземә дә күңеллерәк булган икән.

Һәм мин җиргә очтым. Ләйсән мине күреп өлгергәнче, мине ул—шәһәр каланчасы—кулына алып Ләйсәнгә суздщ. Минем хуҗабикәм бу юлы инде кызармады,теге дә бит очына үрелмәде. Мин инде җиргә сикергәнемә үкенә дә башлаган идем. Шулчак егеткәй (ул хәтле каланча да түгел инде):

—Сезнең телефон номерыгызны алырга ярыймы? Ул җиргә төшкән саен килеп җитәр идем,—диде.

Ләйсәнем серле генә елмаеп,минем номерны әйтте. Ә мин күкнең җиденче катында идем... Каланча шәхси коткаручыма әйләнәчәк! Мин бәхетле! Ләйсән дә,Каланча да... Һәм мин,Samsung-C 235,бүтән беркайчан да җиргә очмаска сүз бирдем.

Менә шулай. Язмыш белән озак уйнарга,күктән—җиргә,җирдән—күккә сикерергә ярамый. Кайчан да булса барыбер берәрсен сайларга туры килә. Менә мин дә бүтән хуҗабикәм кулыннан сикереп төшмәскә булдым,тик...

—Юк,Ләйсән,атма-а-а!!!

**Алисә ЗАРИПОВА**

# БӘЛӘКӘЙ ТУФАН

## Ярылган корсак

Авылыбызның аскы ягында Күпер ермагы дигән ермак бар. Тирән ермак. Ярлары текә. Яз көне таулардан шуып төшкән кар суы ермакны тутырып ага. Җәй көне ермак кибә. Ләкин бер чоңгыллы урында су җыелып кала. Без шунда чупырдашабыз. Йөзгәндәй итәбез, хәтта биек ярдан шуңа сикерәбез дә. Кайвакытта баш су төбендәге ләмгә (бездә ләмне душкын диләр) кадала. Көлешәбез. Кайберләребез сикергәндә суга корсагы белән төшә. Анардан мыскыллап көләбез.

—Корсагың ярылмадымы?—дип корсагын караган булабыз. Бервакыт бездән өлкәнрәк Хәсән абый ярдан сикерде дә корсагы белән шапылдап суга килеп төште. Без көләргә тотынган идек, Хәсән абыйның кычкырып җылаганын ишетеп туктап калдык.

Хәсән абый бер кулы белән корсагын тотып, икенче кулы белән үлән тамырларына тотына-тотына яр өстенә менде. Үзе җылый.

—Ни булды?—дибез.

Ул корсагыннан кулын алды. Анда кып-кызыл эз—корсагы ярылган. Хәсән абый:

—Үләм!—дип җиргә егылды, без авылга йөгердек. Хәсән абыйларга барып фаҗигане хәбәр иткәч, Хәсән абыйның кемедер (хәтерләмим) безнең белән бергә ермак буена чапты. Барып житсәк, Хәсән абый чалкан яткан да шаркылдап көлә... Калганын сөйләп тормыйм. Корсак ярылуның серен генә әйтәм. Хәсән абый үзе белән кызыл җеп алып килгән икән. Судан чыкканда шул җепне юеш корсагына ябыштырып куйган.

Тамак ач, өс ялангач дип тормый идек, көләсен көлә, шаярасын шаяра идек шул. Балачак бит, нишләтәсең.

## Ярыш

Өченчедә укый идек микән, дүртенчедәме, кыш көне мәктәптән кайтып килешли сүздән сүз чыгып бәхәсләшеп киттек. Кызлар инде әллә кайчан өйләрендәдер, без һаман этешәбез, төртешәбез. Җыен юк-барны оештырырга мин һәвәс идем.

—Әйдәгез, ярышабыз,—дидем. Минем тәкъдимне барысы да хупладылар. Унбишләп малай юл кырыендагы кар көртенә карап тезелешеп бастык та сиптерергә тотындык. Ярышның кагыйдәсе гади—кем ераккарак сиптерә—шул җинә. Берничәбез ярышта катнаша алмады. Теләкләре юк булып чыкты.

Мавыгып киткәнбез, янибызга Гыйльми бабай килеп басканны күрмәгәнбез. Хәер, күрсәк тә без анардан курыйкмыйбыз, бала-чаганы ярatканын беләбез. Гыйльми бабай безне куәтләп тора. Җинүчене дә ул билгеләде.

Күп вакыйгалар онытылган, бу ярыш истә. Чөнки Гыйльми бабайның сүзләре хәтердә.

—Сезнең хәзер дилбегә озынлыгын да уздырып пес итәр чагыгыз, чабата башына пес итәр көннәрегез алда әле,—дигән иде. Әй, көлгән идек. Көлгән идек шул, көлгән идек...

## Абый

Малай чакта иң кызык, иң рәхәт нәрсә абыйга ияреп йөрү. Абыйсыз малайлар нәүмиз булалар. Без абыйларга ияреп урманга барганны, анданиләр күргәнне, абыйлар сыман җиннәре төенләп бәйләнгән күлмәк белән Ылгыма елуыннан маймычлар сөзгәнне мактанып сөйләгәндә абыйсызлар кызыгып тыңлыйлар.

Минем туганнан туганым Мөнир белән икебезгә бер абый иде. Безгә сигез-тугыз яшь, абыйга—унике. Унике генә булса да—абый. Аның тиннәре бар. Бергәләшеп урманга, су буена баралар. Төрле кызыклы уеннар уйныйлар. Алар арасында кайнашу безгә зур бәхет. Алар белән бергә агач башына менеп, әле өлгереп тә җитмәгән миләшне яки кыргый алманы өзеп төшеп, чырайны сыта-сыта шуны ашау бәхете кемгә тәти?

Тик шунысы начар—абый абыйлыгын итә, һәрвакытта да безне иярми. Чөнки безнең күз кирәкмәгәнне күрә, колак кирәкмәгәнне ишетә. Аларның Ылгыма ярына тезелешеп ятып тәмәке тартканын әниләр белмәскә тиеш. Ә без сер сакларга өйрәнеп җитмәгән. Бер-ике тапкыр үзебез дә сизмәстән сатканыбыз бар. Мин әләкләргә ярамаганны китаплардан укып түгел, абыйга ияреп йөргәндә белдем. Абыйга ияреп йөрү бәхетенә ирешү өчен түләргә дә кирәк иде. Без Мөнир белән икәүләп «уфалла» дип аталган арбага утыртып абыйны тартып йөрергә тиеш идек. Ләкин бу эшне без интегеп түгел, яратып эшләдек. Арбаның тәртәсенә ике яклап ябышып кешни-кешни чаба идек. Абый: «На! На!» дип безне куалый иде. Кайвакыт тауга түбән безне утыртып үзе уйнаклап чаба иде. Әй, аның рәхәтлеге. Кайчакларда «чыгымлап» китеп абый юл кырыена чыга, чокыр-чакыр, түмгәкләр өстеннән тәгәрәгәндә арба үрле-кырлы сикерә. Безгә кызык, арба үрәчәсенә чытырдап ябышып, җибәгән малай түгеллегебезне раслыйбыз. Безгә абый кирәклеген без белә идек, абыйга да энекәш кирәклеген исә соңрак аңладык. Олыгаеп, инде әтиләр булгач, бервакыт Мөнир әйтә миңа:

—Син бәхетле, Туфан, синең энекәшең бар,—ди,—ачуың килгәндә сугу өчен дә, булмаган акылыңны өйрәтер өчен дә энекәш кирәк икән,—ди.

Хәзер уйлап-уйлап торам да абыйсыз һәм энекәшсез малайларны кызганам. Нәүмизләр алар. Абыйлар мәктәбен үтмәгәнгә күбесенә ир-атлык та җитеп бетми.

## Бабай

Әнинең әтисе иде ул. Заманында таза хәлле крәстиян булган. Әнинең сөйләвенчә, үзе дә чабата кимәгән, балаларына да кидермәгән, чабаталы кешеләрдән мыскыллап көлгән. Бөтен тапкан малы үз көче белән табылган. Совет власте аны чабата кияргә һәм чабата ясарга өйрәткән. Без сугыш елларында бабай ясаган чабата киеп үстек. Шул чабаталы елларның матур истәлеге күңелдә сакланып калган. Без, бабайның дүрт баласының оныклары, бабай өенә—төп йортка еш кына җыела идек. Әминә, Мөнир, мин—бер яшьтәгеләр бабай чабата ясаганда аның янында бөтерелә идек. Ул чабатага юкә телгәндә булыша идек, шөшлесе төшеп китсә, аны алып бирү өчен өчәүләп ызгыша идек. Ә иң кызыгы бабай чабата табанын тезгәндә аның уң кулы янында утыру иде. Бабай юкә телемен уң улы белән тартканда терсәге белән безне этеп җибәрә дә без авып китәбез. Бабай көлә.

—И, син иденмени анда, күрмәгәнмен,—дигән була. Без бабайның уң кулы янына утырырга чират торабыз. Бабайның күңеле булсын өчен авып кына түгел, тәгәрәп тә китәбез. Кайчакта бабайның уң ягына тезелеп утырабыз. Бабай үзе янындагын терсәге белән этkән була да, өчебез бергә тәгәрәп китәбез. Тәтәгә (әнинең йә әтинең

әнисен бездә тәтә диләр) чыр-чу килүебез ошамый.

—Комачау итмәгез бабагызга,—ди.

—Тимә аларга,—ди бабай коры тавыш белән. Бабайның авылда коры, кырыс диган даны булган. Без аны һич сизмәдек. Колхозда ул ат җигеп эшли иде. Еш кына безне буш арбага утыртып авыл башына хәтле алып бара иде. Дилбегәне безгә бирә иде. Без чиратлашып атның ян-якларын дилбегә белән каккалап, бабайча итебрәк:

—На, әйдә, йоклама, атла аягыңны,—дип атны куалыйбыз.

Бәки авылы янында Чабыр тавы бар. Җәйнең матур бер көнендә тирә-яктан шунда бәйрәмгә җыйналалар иде. Бәйрәмгә барганда ни өчендер атларны куып, чаптырып баралар иде. Миңа биш яшьләр чамасы булгандыр, мине дә Чабырга алып бардылар. Юлда ат кушаяклап чапканда мин арбадан атылып төшеп калдым. Ниләр булганын, кайсы җирем авыртканны хәтерләмим. Үкереп җылаганым һәм бабайның:

—Үкермә, син ир кеше,—дигәне генә хәтердә калган. Шул сүздән соң җылаудан туктадым шикелле.

## Замана балалары



Заман безне иртә өлгертте, 13-14 яшьләрдә без кызлар озата идек инде. Бөтен шартын китереп озатабыз. Клубтан чыккач бездән качып йөгергән кызларны капка төпләрендә куып тотабыз да кочаклап алып бит урталарыннан үбәбез. Куып тоттырырлык итеп кенә йөгергән кызлар «И, җүләр тәре» дигән була да капкадан кереп китә. Без Берлинны алган солдатлар шикелле түш киереп сызгырына-сызгырына өйгә кайтабыз. Икенче көнне җыелышып мактанышабыз, бер тапкыр ашык-пошык үпкәнне ун тапкыр кыз үзе үпте дип сөйлибез. Мин Вәли абый кызы Диләфрүзне озата идем. Чибәр иде мәрхүмә. Беркөн, каян күргәнбелгән диген, Вәли абый урамда туктатты да:

— Нихәл, кияү, кайчан туй ясыйбыз?—диде. Вәли абыйның болай мыскыллап көлүе миңа ошамады—кызын ташладым. Диләфрүз ташлавымны авыр кичергән икән, олыгайгач бер очрашканда:

—Мин сине яраткан булганмын, ахры, гел исемә төшәсең,—диде.

Бер көнне Наил өлкән егетләрнең сөйләшкәненен тыңлап торган. Антон авылында маржа кызлары бик чибәр икән. Барысы да сары чәчлеләр икән (кара чәчле кызлардан туеп беткән бит инде). Безнең авыл кызлары кебек саран түгелләр икән. Рәхәтләнеп үптерәләр ди. Унлап малай киттек Антонга маржа кызлары үбәргә. И барабыз хыялланып. Белгән урысчабызны ничегрәк әйтергә дип киңәшәбез. «Яратам» дигән сүз «лүблү» икән, «әйдә, үбешәбез» дигәне «давай патсилуемся» икән. Антон шактый ерак—бездән биш чакрымлап булыр. Антонга кояш баеганда барып җиттек. Кызлар җыелган җирне эзлибез. Урамда беркем юк. Кемдер әйтте:

—Алар чиркәү янына җыелалардыр,—диде. Киттек шунда. Анда да беркем юк. Урам буйлап әрле-бирле йөренгәндә судан кайтып килүче бер кыз очрады. Каршысына төштек. Урысчаны шәп белүче буларак, мин алга чыктым.

—Ыздырастуй!—дидем. Бездән куркып калды, ахрысы, кыз дәшми карап тора. Алдан әзерләп куйган «давай патсилуемся»ны да әйткәч, кызыбыз чиләккөянтәләрен ыргытты да артка борылып чапты. Без аны куып маташмадык, кайтыр юлга таба йөгердек.

—Әтисе килеп чыкса, иманыбызны ала,—диде кемдер.

Динур:

—Килеп кенә карасын,—дип әтәчләнергә тырышкан иде, тынлаучы булмады.

Авылга кайткач, бармый калганнарга ниләр булганын сөйләдек. Авызларын ачып, көнләшеп тыңладылар. Сөйләвебез буенча, без маржа кызлары белән туйганчы үбешкәнбез икән. Үбешеп кенә дә калмаган хәтта...

## Җылы мунча

Кичләрен авыл яшьләре клубка җыела: бииләр, түгәрәк уеннары уйныйлар. Безне анда кертмиләр—ярамый, мәктәп балалары төнлә чыгып йөрмәскә тиеш. Әмма кем тотып тора ала бала-чаганы, барыбер без урамда. Урамда салкын булса, җылы мунчага җыелабыз. Кемнәр мунчасыннан көндез төтен чыкканын белеп куябыз. Чиратлашып өйдән керәчин (керосин) урлыйбыз. Лампабыз бар. Эченә филтә тыгылган дару шешәсе. Әй, мунчадагы күңеллелекне, рәхәтлекне берни дә алыштыра алмый. Ләүкәгә, эскәмиягә, идәнгә—кемгә ничек җайлы, шулай урнашабыз да тотынабыз ялганлашырга. Ялган да түгел инде ул, фантазиянең уйнавы гына. Айга да менәбез, су төбенә дә төшәбез. Беребез укыган әкиятенә үзеннән дә өстәп җен-пәриләр турында сөйли, кайсыбыздыр ул җен-пәриләрне күргән дә булып чыга. Кайчакларда бергәләшеп җыр чыгарабыз. Без аны җыр дип түгел, бәет дип атыйбыз. Алар гадәттә авылыбызның берәр кызына аталып чыгарыла. Жанры буенча сатира белән юмор арасында. Язганнарыбызны мәктәптә үзләре күрмәгәндә кызларның дәфтәрләренә күчереп язабыз. Кызлар укытучыга әләкләшә. Укытучы такта янына чыгарып бастыра. Кем язганны язуыбыздан таный. Ләкин такта янына бастыру укытучы файдасына булмый. Без укытучыга күрсәтми генә маймылланабыз, телләребезне чыгарабыз, күзләребезне акайтабыз, колакларыбызны селкетәбез... Класс дәрес тыңламый, безгә карап утыра. Кайчак класстан куып чыгаралар. Анысы безгә җәза түгел инде, бүләк. Дәрестән котылунын рәхәтлеген котылган укучы гына белә. Җәзаның иң катысы—тәртип бозуыбызны әнигә әйтү. Әти куркыныч түгел, әни куркыныч. Әтиләр чөнки вакланып тормый, ә әнинең кулында уклау. Язган бәетләребезнең берничәсе хәтердә сакланган. Бүген дә алар ярыйсы ук ишетеләләр. Унике-унөч яшьлек малайлар чыгарган димәссең.



*Сездә бүген ничәсе?*
*Бездә бүген кичәсе.*
*Ярты чиләк чәй эчкән ди*
*Айтуган Хәдичәсе.*
*И аузың зур, аузың зур.*
*Аузыңны нишләтергә?*
*Бер ягына кирпә ясап,*
*Кәнүшни эшләтергә.*
*Өегезнең капкасы—*
*Нарат икән тактасы*
*Синнән матурырак әле*
*Безнең мунча бакасы.*

Шушы бәетне чыгаргач тәгәрәп көлгәнебез истә. Чөнки ул үзенең матурлыгына масаеп йөргән кызга атап чыгарылган иде. Соңрак белдем, мунчада җыелып бәет чыгару безнең авылда гына булмаган икән. Шуңа күрә татар халык иҗатында мунча фольклоры дигән аерым бүлек булырга тиештер. Халык иҗатын өйрәнүчеләргә бу идеяне сатам.

## Аулак өй

Аулак өйләр турында күп язылган, кабатланып тормыйм. Без дә аулак өйләрдә аунап үстек. Шуны гына әйтәм, аулак өйнең рәхәте—күзең төшкән кыз белән чоланга кәҗә карарга чыгу. Чоланга алып чыккан кызына син үзең дә ошаган булсаң—жан рәхәте. Кышкы салкын чоланда иненә бишмәт салган, башына шәл бөркәнгән кызны кочаклап торуга ни житә. Сөйләшмисең. Беренчедән, сөйләшергә рәтле-юньле сүз юк, икенчедән, кем әйтмешли, сүзсез дә аңлашыла. Бүтән чакта, әйтик, озатып куйгач, кызларны яңагыннан үбү әбәзәтелни йола саналса, кәҗә караганда ни өчендер үбешү юк иде. Һәрхәлдә, үбештек дип әйткәнне ишеткәнем булмады, үзем дә андый «гөнаһ» кылмадым шикелле. Ин шәбе—бер-береннең жылысын тоеп кочаклашып тору. Малай гына булсак та дәрт уяна башлаган бит инде. Унөч яшь, мин сиңа әйтим, бала-чага яше түгел. Ә кызлар инде ул яшьтә өлгерә башлыйлардыр, түшләрендә чыпчык йомыркасы чаклы гына ике төер дә беленә. Шулар ике күлмәк аша түшкә тиеп китә дә... Юк, артыгын язмыйм, карт кешегә килешми. Кәҗә караганда озаграк торсаң, куып кертәләр. Алып чыккан кызың сине ошатмаса, мәсьәлә тиз хәл ителә: кыз сине этеп жибәрә дә кереп китә. Син ничегрәк итеп үч алырга икән дип план корырга каласың Аулак өйдә анысы өчен уйлап табылган уеннар да бар. Унөч яшьтә үк аулак өйләргә йөргән дип гажәпләнәсе юк, яшүсмерләр өлкәннәр тәжрибәсендә житлегә.

Өлкәннәр дигәннән, бер вакыйга истә калган. Кайбер якларда аулак өйләрдә егетләр кунып кала, бездә кунып калу бәхете эләкми иде. Күршеләренә чыгып торган өй хужалары кайтып, егетләрне куып тараталар иде. Кызларның да кайберләре үз өйләренә кайтып китә иде.

Көннәрдән бер көнне Рушанияләрдә өлкән яшьтәгеләрнең аулак өе булачагын белгәч, без дә кагылып үтмәкче булдык. Без дигәнебез егермедән артык малай—утыз бишенче, утыз алтынчы елгылар бергә йөри идек. Безне инде, билгеле, аулак өйгә кертмәделәр. Тәрәзә каршында нишләргә инде дип таптанып торганда яныбызга Әкбәр абый чыкты.

—Малайлар,—ди бу,—безне чыга алмаслык итеп тыштан бикләп куегыз, Мәрфуга апа Разия апаларда, аларны да бикләп куегыз, чыга алмасын,—ди.

Без, әлбәттә, ишектәге йозак элгеченә таяклар тыгып бикләдек. Ләкин моны гына азсындык, ишек-тәрәзәләрне кар өеп томаларга булдык. Кар жепшек иде. Кар тәгәрәтеп зур-зур кар туплары ясыйбыз да, ишек-тәрәзәләрне каплыйбыз. Өя торгач, башта Мәрфуга апаларның, аннан Разия апаларның өен кар белән тышлап куйдык. Үз гомеремдә алай тырышып эшләгәнем булмады. Кырмыскалар кебек кайнаштык. Өлкән егетләр аулак өйдә кунып калды, без Әкбәр абыйдан «малатсый» дигән сүз ишеттек.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## ЯЛГЫШЛЫК БҮЛӘК ИТКӘН АЧЫШ

Остазларымның берсе, профессор Александр Дмитриевич Дубяго, без студент халкы белән дәрестән тыш вакытларында аралашырга ярата иде. Хәер, моның өчен шартлары да шәп булды: йөз ярым студент арасында һәр курста астрономнар саны ярты дистәдән артмый иде ул елларда. Минем астроном курсташларым икәү генә иде. Өч кенә студент алдында ике профессор, өч доцент лекцияләр укыды, ассистентлар гамәли дәресләрен уздырды. Бигрәк тә «кыен» андый шартларда уку, лектор баш миенне микроскоп аша күреп тора диярсең, ничек аңлаганыңны һәркайсы һәрчак белеп тора. Ул яктан Александр Дмитриевич искиткеч сизгер иде. Тәнәфес вакытларында, курста үзем бердәнбер астроном егет заты булгангадыр, мөгаен, күбрәген минем белән гәпләшә иде.

Мин аның беренче ачышын студент чагында ук башкарганын белә идем. Үкенәм хәзер, гәпләшкән чакларда шул ачышы хакында шәрехләп сөйләтергә җаен тапмадым. Дөресрәге, бу турыда сорарга җөрьәт тә итмәгән идем. Кызганыч, бишенче курста диплом эшемне ул җитәкләгән обсерваториядә башкарган чагымда профессорны инсульт афәте бәреп екты, шактый озак авырганнан соң ул якты дөньядан китеп тә барды, авыр туфрагы җиңел булсын.

Аның беренче ачышының тарихын обсерваториянең олы яшьтәге хезмәткәрләренең берсе сөйләгән иде. Галим халкы, көндәлек эшләре белән мәшгуль булып, ачыш турында уйланып йөрми, ул планында каралган, агымдагы, кайчагында шактый эчпошыргыч тикшеренүләрен башкара. Өстәвенә, обсерваториядә эшләгән һәр хезмәткәр коллективның барысына да кирәк булган уртак тикшеренүләрдә дә катнаша иде ул заманнарда. Мәсәлән, вакыт үлчәү, хронометрларның төгәл йөрүен күзәтү һәркемнең вазифасына кергән ул чакларда. Көндез эшли астроном, аяз булса, төннәрен дә эшкә чыга. Көндез бинада эшләсә, төннәрен ачык һавада, телескоп янында уздыра.

Бәйрәмгә тәңгәл килгән кичләрнең берсендә һава бик болытлы була, күк йөзендә йолдыз әсәре дә, Ай да күренми. Хезмәткәрләр, аңлашыладыр, форсаттан файдаланып, бәйрәм мәҗлесен кешеләр шикелле уздырырга булалар. Күнелле генә итеп утырганда кемдер урамга чыгып, күк йөзенә күз ташлый һәм, тиз генә кире кереп, һаваның бөтенләй чистаруын, йолдызларның искиткеч тыныч, аз гына җемелдәвен җиткерә. Астроном халкы аяз күкне ычкындырмый, әлбәттә, һәркем үз карамагындагы телескобы янына киткән. Студент егет тә үзенә ышанып бирелгән телескопны тиз генә ачкан, аның көпшәсен тиешле координатлар буенча кирәкле ноктага юнәлтеп, окуляр аша бакса, ни хикмәт, өр-яңа, беркем белмәгән комета—койрыклы йолдыз фокус яссылыгының шактый өлешен биләп тора имеш. Шулай итеп, яшь егет үз кометасын «приватлаштырып», ана үз исемен бирү хокукына ия булган. Дубяго кометасының тулы булмаган тарихы шундый. Әмма бер бәләкәй генә нюансы да бар. Тиешле ноктаның координатларын билгеләгәндә егет бик ашыккан шикелле, аларның берсен йөз сиксән градуска (!) ялгыш итеп исәпләгән, нәтиҗәдә телескопны күк йөзенең горизонт өстендәге капма-каршы ноктасына төбәп куйган. Менә шулай, галим халкын хаталар да ачышка юлыктыра кайчагында.

**Ким ШАКИРОВ**

## *Интер-кайтаваз («WWW. matbugat. ru»дан)*

### Бәләкәйләр (№ 3,4)

Күңелле сәхифә. Бәләкәй чакларны искә алу, матур хатирәләрне янарту һәркемнең күңеленә рәхәттер ул, ни генә булса да. Безгә дә уку бик күңелле. Хуплыйм, табыш бу!Киләсе санда берәрсенең бәби чагы белән дә танышырбыз әле, бәлки?

**Моңсылу**

### «Ак җилкән». Айгөл Сәләхова шигырьләре (№ 4)

Чибәр син, Айгөл! Шигырьләрең дә шундый үтемле. Рәхмәт куандырган өчен.

Беренче күрү.
Синең күзең,
Йомшак йөзең,
Борының туры утырган.
Иренең—алма,
Колагың—чәчәгең,
Маңгаең чәчеңә капланган.

**Егет**

Бигрәкләр дә матур язган бит япь-яшь булса да. Уңышлар телим сиңа, матур кыз бала!

**Моңсылу**

Өмете сүнмәгәч, хәлләре әйбәт инде бу кызның. Менә минем бер өметем дә калмады бу тормышта. Хет утырып ела. Ну, шул әби-бабайларны уйлыйм да, моннан да куркынычрак заманда яшәгәннәр бит әле дип юанам инде. Аларның хет мәхәббәтләре булган. Ә безнең! Мәхәббәт түгел, наз бирерлек ирләр юк... Тфъу! Күлмәк үтүклә, чәй яса, бәтинкә чистарт...

Менә бу кыз 18-20дә ничек белеп язган бит, ә:

«Бәләкәчем»,—димә,—«матурым»,—да димә,
Кочагыңа гына ал әле.
Өшегән күңелем уянса,
Аңлармын мин: сөю бар әле!

Юк инде, юк.
Кем мине менә шулай юатыр?


**Өметсез**

Матур сүзләр, матур! Ни дисәң дә, Сөю дигән нәрсә бардыр әле бу дөньяда дигән өмет яши!

**Сөмбел**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*




**2006 ел башында (№3) ачылган бу сәхифә
сездән кызыклы, матур яңалыклар,
саф җил көтә, яшь-җилкенчәкләр.
Аны ничек үзгәртик?
Нәрсә артык һәм нәрсә җитми?**



*Бөек Ватан сугышында катнашкан язучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Нури Арсланов, Газиз Иделле, Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Гариф Галиев, Хатип Госман, Салих Баттал; икенче рәттә—Шамил Шаһгали, Әмирхан Еники, Мөнир Мазунов, Мәхмүт Хөсәен, Ибраһим Нуруллин, Атилла Расих, Сафа Сабиров, Әбрар Кәримуллин, Баян Гыйззәт; өченче рәттә—Нәби Дәүли, Сәет Шәкүров, Әдип Маликов, Кави Латыйп, Мәгъсүм Насыйбуллин. Казан. Язучыларның Тукай клубы. 1982 ел.*



*Балалар язучысы Госман Бакир (1896-1982). Ул I һәм II Бөтендөнья сугышларында катнашкан шәхес. Уникаль хәл: һәр сугышта да ул Украинаның Тернополь шәһәрен азат итүдә катнаша.*



*Язучыларның Тукай исемендәге клубының эчке күренеше. 1941 елда Мәскәүдән Казанга эвакуацияләнгән байтак язучылар һәм аларның гаиләләре иң әүвәл шушы бинага килеп төшәләр. Кайберләре беркадәр вакыт монда яшәп тә ала. Соңрак аларны Татарстандагы төрле шәһәрләргә тараталар.*



*Фронттан исән-сау әйләнеп кайтып, зур иҗат уйлары белән тыныч хезмәткә керешкән шагыйрьләр: сулдан уңга—Сибгат Хәким, Мәхмүт Хөсәен, Әнвәр Давыдов. Үткән гасырның 50нче еллары.*



*Кырымтатар халкын данлаган легендар очучы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Әмәтхан Солтанга Алупка шәһәрендә (Кырым) куелган һәйкәл-бюст.*



*Муса Җәлил көрәштәшләренең берсе Фәрит Солтанбәков. 1994 ел.*

## ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЯҢА РӘИСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үзенең 2010 елның 22 апрелендә үткән җыелышында Халиков Илдар Шәүкәт улын Татарстан Республикасы Премьер-министры итеп раслады. Ул—1967 елның 21 ноябрендә ТАССРның Әгерҗе шәһәрендә туган. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1985 елда Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән. 1987 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетына «хокук белеме» белгечлеге буенча укырга керә.

1993 елдан 1995 елга кадәр әйдәп баручы белгеч, кыска сроклы һәм озак сроклы кредитлаштыру, депозит һәм кыйммәтле кәгазьләр идарәсе башлыгы вазифаларын башкаручы, «Челны-банк» акционерлык коммерция банкы идарәсе җитәкчесе була.

Халиков И. Ш. 1995 елдан 1996 елга кадәр—«КамАЗ» ААҖнең хокук идарәсе башлыгы урынбасары. 1996 елдан 2003 елга кадәр «КамАЗ» ААҖнең финанслар буенча директоры, икътисад һәм финанслар буенча генераль директор урынбасары—икътисад һәм финанслар директоры, генераль директорның корпоратив стратегия буенча генераль директор урынбасары.

2003 елдан 2005 елга кадәр Чаллы шәһәренең хакимият башлыгы, 2006 елның 1 гыйнвареннан «Чаллы» шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы, шәһәр мэры булып эшләде.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ҮЗГӘРЕШЛӘР

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә Россия Мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко белән очрашты.

Министр башкалабызга Казан дәүләт университеты гыйльми советының чираттан тыш утырышында катнашу өчен килгән иде. Рөстәм Миңнеханов бүген Казанның 2013 елда Бөтендөнья җәйге Универсиадасын кабул итәргә әзерләнүче студентлар шәһәре буларак танылуын, моның исә КДУга федераль университет статусы алу мөмкинлеге биргән ияртте.

Шуннан соң Казан (Идел буе) федераль университетының актлар залында вузның гыйльми советының чираттан тыш утырышы булды. Анда Татарстан башкаласында федераль университет оештыру турында мәсьәлә каралды.

Утырышта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко, ТР Мәгариф һәм фән министры вазыйфаларын башкаручы Альберт Гыйльметдинов, Казан мэры Илсур Метшин, КДУның элеккеге ректоры Мәгъзүм Сәлахов һәм Алабуга мэры Илшат Гафуров (хәзер ул федераль университетны җитәкләячәк) катнашты.

Министр Андрей Фурсенко үз чыгышында университетны автоном учреждение формасында яңадан теркәп, ректорын билгеләгәннән соң, Казан университетының гыйльми советына Мәгъзүм Сәлаховны университет президенты итеп сайлау турында тәкъдим кертәчәген белдерде.

## БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ ОЛЫЛАДЫЛАР

1 апрельдә Мәскәүдә РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Александр Жуков 2009 елда мәдәният өлкәсендә зур тырышлык күрсәтеп, уңышка ирешкәннәргә РФ Хөкүмәте Премиясен тапшырды.

Бүләкләүдә безнең республика вәкилләре дә катнашты. ТР вице-премьеры—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендәге иҗат төркеме тарафыннан Алабуга шәһәрендә оештырылган музей комплексы игътибарга лаек булган. Премияләр Зилә Вәлиевага, Алабуга шәһәре мэры Илшат Гафуровка, Алабуга районының башкарма комитеты җитәкчесе Фәрит Хәнифовка, район башлыгы урынбасары Лилия Нургатинага һәм Алабуганың музей-тыюлыгы җитәкчесе Гөлзада Руденкога тапшырылды. Шулай ук бу премиягә лаек булучылар арасында Валентин Распутин, Александр Кабаков кебек язучылар, модельер Вячеслав Зайцев, кинорежиссер Алла Сурикова, «Россия балалар фонды» бөтенроссия җәмәгатьчелек хәйрия фонды рәисе Альберт Лиханов та бар иде.

## СӘНГАТЬКӘ—ПРЕЗИДЕНТ ГРАНТЛАРЫ

Президент Рөстәм Миңнеханов мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә ТР Президенты грантларын бирү турындагы Указга кул куйды. Указ нигезендә, быел грантларны М. Җәлил исемендәге

Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, В. Качалов исемендәге Казан рус Зур драма академия театры, ТР дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, ТР дәүләт симфоник оркестры һәм «Татаркино» дәүләт учреждениесе алачак. 2010 елда мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә ТР Президенты грантларынын гомуми күләме 68 миллион 120 мең сум тәшкил итә.

### ОНЫТЫЛМАС БӨЕК ШАГЫЙРЬ

***

Моннан нәкъ 100 ел элек, 15 (искечә 2 се) апрель көнне «Шәрык» клубында Г. Тукай үзенең «Халык әдәбияты» дигән атаклы, бүгенге көннәрдә дә актуальлеген югалтмаган лекциясен укый.

Аның халык фольклоры проблемаларына, халык җырларын саклау, профессиональ сәнгатебезне үстерүгә кагылышлы уй-фикерләре киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудыра. Үз лекциясен Тукай бөтен татар дөньясы гасырдан артык еллар буенча яратып укый һәм җырлый торган атаклы «Туган тел» шигыре белән тәмамлый. Тагын 3 елдан соң, нәкъ шушы көнне шагыйрьнең гомере өзелә...

Быел Г. Тукайның әдәби музеенда, шагыйрьнең әлеге атаклы лекциясе М. Җәлил һәм Г. Тукай премияләре лауреаты, Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов башкаруында кабат яңгырады.

***

Габдулла Тукайның туган көне алдыннан Татар ПЕН-үзәге Милли китапханәдә язучылар, галимнәр, нәширләр һәм журналистлар катнашында шагыйрьнең киләсе елда булачак 125 еллык юбилеена әзерлек мәсьәләләренә багышланган утырыш үткәрде.

Анда Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров шушы юбилей уңаеннан башкарылган эшләрнең беренче карлыгачы—Г. Тукайның тормышына һәм иҗатына багышлап, «Таттрансгаз» ширкәте булышлыгы белән чыгарылган 700 битлек бүләк басмасын тәкъдим итте.

Утырышта Татар ПЕН-үзәге президенты Р. Вәлиев әлеге юбилейга шагыйрьнең дөнья телләренә тәрҗемә ителгән әсәрләрен туплап чыгару нияте барлыгын әйтте. Бу җәһәттән Милли китапханә инде Тукайның инглиз, гарәп, төрек, фин, үзбәк, кыргыз һ. б. телләрдә дөнья күргән берничә китабын сайлап та куйды. Утырышта бу тупланманы әзерләү буенча шагыйрь Гәрәй Рәхим җитәкчелегендә оештыру комитеты да төзелде.

Татар ПЕН-үзәге әгъзалары Зиннур Мансуров һәм Нәбирә Гыйматдинова утырыш барышында шагыйрь исеме белән бәйле тарихи урыннарны саклау, мемориаль үзәкләргә әйләндерү мәсьәләсен күтәрделәр.

Утырышта катнашучылар, әлбәттә, «Болгар» кунакханәсен торгызу мәсьәләсен дә күтәрделәр.

### ТЕЛ ЯЗМЫШЫ—ИЛ ЯЗМЫШЫ

Апрель башында Татарстан халыклары Ассамблеясе советының утырышы булды. Утырышны Ассамблеянең җитәкчесе, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып барды. Сүз башында ул республикадагы сәяси вәзгыять, милләтара татулык һәм балаларның үз ана телләрен өйрәнү мөмкинлекләренә тукталды. Мәгълүм булганча, Фәрит Хәйрулла улы күптән түгел Страсбургта аз санлы халыкларның телләрен саклау һәм үстерү турында чыгыш ясаган иде. «Глобальләшү коточкыч тиз бара ки, бер 100 елдан бик күп телләрнең архив язмаларында гына калуы бар. Үзебездә дә дәүләт, акча түләп, балаларга татар телен укыта, ә балалар, үзләре түләп, инглиз телен өйрәнә. Глобальләшү менә шулай сиздермичә килә. Югыйсә, берәү дә үз туган теленең юкка чыгуын теләми»,—дип сөйләде ул әлеге утырышта.

Казанның төрле милләт балалары укый торган якшәмбе мәктәбе директоры Майя Кукунашвилли мәктәпнең тормышы һәм андагы кыенлыклар турында сүз алып барды. Барлык мөмкинлекләр булса да, Казанда кайбер милләт вәкилләре балаларын туган тел дәресләренә йөртми икән. Мәсәлән, грек, казакъ, мари, чечен сыйныфлары бөтенләй ябылган. «Ябуы бик тиз, ачуы кыен. Милләттәшләребез арасында аңлату эше алып барыгыз. Гади мәктәптә укыганда балаларның милли хисе тоныклана, телне дә онытырга мөмкиннәр. Ә безнең мәктәптә алар милләттәшләре, яшьтәшләре белән уртак тел таба. Аеруча милли бәйрәмнәрдә сөенечләре эчләренә сыймый»,—диде М. Кукунашвилли.

Татарстан халыклары дуслыгы йорты директоры Гөлирам Габдрахманова исә алда булачак чаралар турында сөйләде. Быел Җиңүнең 65 еллыгына, ТАССР оешуның 90 еллыгына, Укытучы елына һәм булачак Универсиадага багышланган 400 төрле бәйрәм чарасы үткәреләчәк. Бу максатларга 4 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелгән.

### «ГАСЫРЛАР АВАЗЫ»НА—85

22 апрельдә «Казан эрмитажы» үзәгендә «Гасырлар авазы» журналының беренче саны дөнья күрүгә 85 ел һәм аны яңадан нәшер итә башлауга 15 ел тулуга багышланган «Тарихи чыганак һәм тарихи истәлек» дигән фәнни-гамәли конференция булды.

Конференциядә катнашучыларны республика җитәкчелеге исеменнән ТР

Министрлар Кабинеты Аппаратының мәдәният, спорт һәм халыклар телләрен үстерү идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина сәламләде. Ул Татарстан Президенты Рөстәм Миннехановның журнал коллективына юллаган котлавын укып үтте.

«Гасырлар авазы» баш редакторы Дамир Шәрәфетдинов әйтүенчә, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе нәшер итә торган бу журнал елына ике тапкыр басылып чыга.

### «ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ—2009». ҖИҢҮЧЕЛӘР

Камал татры бинасында Халыкара театр көненә багышланган кичә үтте. Әлеге кичәдә «Яңа татар пьесасы-2009» конкурсының җиңүчеләре игълан ителде. Менә алар: 1нче урынга «Урманнарга керсәң» пьесасы белән Уфадан Әлфис Гаязов лаек булды. 2нче урынны «Әниемне төшемдә күрдем» әсәре белән Айзирәк Гәрәева яулады. 3нче урын «Искән җилләр көенә» пьесасы өчен Зөлфәт Хәкимгә бирелде. Кызыксындыру бүләкләре «Хәтерлим» әсәре өчен Сөмбел Гаффаровага һәм «Вәгъдә бүләге» драмасы өчен Рафис Фазылҗановка тапшырылды. Җиңүнең 65 еллыгына багышланган «Эт тырнагы» әсәре өчен Вакыйф Нуриев махсус бүләккә лаек булды.

«Бүтән формат» номинациясендә Илгиз Зәйниевнең «Күсе һөҗүме» һәм «35 яшькә кадәрге яшь авторлар» төрендә дә шул ук авторның «Кем мин?» пьесалары җиңеп чыкты. Мәдәният министрлыгының махсус бүләгенә «Поезд идущий к морю» әсәре өчен Салават Юзеев лаек булды.

Халыкара театр көнендә актерлар да бүләксез калмады. Хатын-кыз эпизодик ролен башкарган өчен Люция Хәмит, ир-атлар арасыннан эпизодик роль өчен Ирек Баһман бүләкләнде. Икенче пландагы роль өчен Алсу Гайнуллина белән Олег Фазылҗанов бүләк алды. Баш рольләрне иң шәп уйнаучы дип Әзһәр Шакир, Ринат Таҗетдин һәм Нәфисә Хәйруллина табылды.

### МӘСКӘҮ ИЛҺАМНЫ ТЫҢЛЫЙ

Мәскәүнең Кремль сараенда Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакировның юбилей кичәсе узды. Аны оештыруга Наилә Фатыйхова җитәкчелегендәге «Рух» продюсерлык үзәге, Татарстанның Россиядәге вәкиллеге, Татарстан Мәдәният министрлыгы, «Мәрҗани» фонды көч куйды.

Мәскәүләр чын мәгънәсендә сәнгать бәйрәмен тамаша кылды. Тамашачыларны Татарстан мәдәният министры урынбасары вазыйфаларын башкаручы Айдар Гайнетдинов, күренекле әдипләр Туфан Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Мәскәү төбәгендәге татар автономияләре җитәкчеләре Рәсим Акчурин һәм Фәрит Мохтасаров тәбрикләде. Халык Илһам Шакировның чыгышын әсәрләнеп тыңлады. Татарстаннан килгән һәм Мәскәүдә яшәүче эстрада йолдызлары, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор музыкасы ансамбле чыгышлары бәйрәм кичәсен тагын да ямьләде.

### ТАТАР КЫЗЫН ДӨНЬЯ ТАНЫЙ

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җырчысы Альбина Шаһиморатова дөньядагы иң мәртәбәле театр сәхнәләренең берсендә—Нью-Йорктагы «Метрополитен-опера»да беренче тапкыр чыгыш ясады. Ул анда гаять зур уныш белән В. А. Моцартның «Тылсымлы флейта» операсында Төн патшасы партиясен башкарды. Контракт буенча, А. Шаһиморатова бу партияне әле тагын берничә спектакльдә җырлаячак. М. Җәлил исемендәге театрның яшь примасы—Татарстаннан «Метрополитен-опера» сәхнәсендә җырлаган тәүге вәкиле. Россия җырчыларыннан әлеге данлыклы театрда Федор Шаляпин, Галина Вишневская, Елена Образцова, Дмитрий Хворостовский, Анна Нетребко чыгыш ясаган.

### ОЛУГ АРТИСТ КИЧӘСЕ

Г. Камал театрында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге премиясе лауреаты Әзһәр Шакировның 70 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичә булды.

«Ул—уйлаучы, фикер йөртүче артист. Әзһәр Шакировның һәр нәрсәгә үз фикере бар»,—диде бәйрәмдарны котларга килгән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. Парламент җитәкчесе фикеренчә, Әзһәр Шакиров уйнаган рольләр үзенчәлеге һәм тирәнлеге белән аерылып тора. Аннары спикер юбилярга «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды.

Юбилярны котларга республика районшәһәрләреннән генә түгел, илнең төрле төбәкләреннән дә кунаклар килгән иде.

Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов исә Әзһәр Шакировның берлеккә шәрәфле әгъза буларак кабул ителүе хакында белдерде. (Әзһәр Шакировның укучыларыбыз өчен бик тә гыйбрәтле берничә язмасы безнең «Казан утлары» журналында да дөнья күрде.)

Кичәдә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

### ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕН БАРЛАУ

Казанга Россиянең халык уен кораллары оркестры һәм ансамбльләре «Кинкырлы Россия» фестиваленә җыелды. Әлеге фестиваль 2006 елда Россия Мәдәният

министрлыгы тарафыннан тәгаен ителде һәм иң яхшы коллективларны барлау, үзешчәннәргә карата игътибарны көчәйтү, сирәк уен коралларын халыкка күрсәтүне максат итеп куйды.

Конкурста катнашучыларның чыгышларына Санкт-Петербург дәүләт консерваториясенең халык уен кораллары факультеты деканы Анатолий Тихонов җитәкчелегендәге жюри бәя бирде.

Идел буе республика-өлкәләре халык уен кораллары ансамбльләре Казанга җыелса, Россиянең башка төбәкләре өчен фестиваль Бурятиядә, Дагыстанда, Карелиядә узды. Соңыннан Россиянең иң яхшы коллективлары Мәскәүдә зур концерт күрсәтәчәк.

Башкалабызда үткән фестивальдә Россиянең атказанган артисты Георгий Клементьев җитәкчелегендәге «Виртуозы Самары» рус халык уен кораллары оркестры Гран-прига лаек булды.

Беренче дәрәҗәдәге диплом исә Казан дәүләт консерваториясенең Рөстәм Рәхмәтуллин җитәкчелегендәге «Ихлас» халык уен кораллары һәм Әстерхан өлкәсе Лиман районы Камышовский мәдәният йортының «Саратов гармуннары» балалар ансамбльләренә бирелде.

## БӘЙСЕЗЛЕК БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

Төркиядә 23 апрель—Милли бәйсезлек һәм Балалар бәйрәме көне. Бу бәйрәмгә Төркиягә җыелган барлык дөнья балалары үз илләрен музыка һәм биюләр белән тәкъдим итә. Әлеге чара уңаеннан башкаланың «Казан» милли мәдәният үзәгендә Төркия Республикасының Казандагы генераль консуллыгы балалар өчен бәйрәм үткәрде. Моны Генераль консуллык, ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Халыклары ассоциациясе, Казан шәһәре мәгариф идарәсе һәм А. Алиш исемендәге балалар иҗаты сарае белән тыгыз хезмәттәшлеге нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Бәйрәмгә чакырылган кечкенә кунаклар Төркия турында театральләштерелгән сәяхәттә, балалар рәсемнәре күргәзмәсендә, конкурсларда катнаштылар.

## «ТАТАРСТАН КИНОСЫ»

Май башыннан башлап 3 июльгә кадәр һәр атнаның чәршәмбесендә «Мир» кинотеатрында «Татарстан киносы» программасы кысаларында Татарстанның иң яхшы уен һәм документаль фильмнары күрсәтеләчәк. Анда «Күктау», «Дилемма», «Өч аяклы ат», «Бөркетләр» һәм башка фильмнарны күрергә мөмкин булачак. Шулай ук анимация һәм документаль картиналар да тәкъдим ителәчәк. Татарстан фильмнарын күрсәтү ТАССР оешуга 90 ел тулуга багышлана. «Татарстан киносы» программасының максаты—республикада төшерелгән фильмнарны популярлаштыру. Чараның оештыручысы—«Татаркино» дәүләт учреждениесе.

## ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫН ИСКӘ АЛУ

Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең тууына 80 ел тулу уңаеннан аның туган ягы Арча районында әдәби очрашулар булып узды. Әлеге чараларда Казаннан кайткан кунаклар—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, аның урынбасары Вакыйф Нуриев, прозаик һәм шагыйрьләр Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Рөстәм Галиуллин, Арчада яшәп иҗат итүче язучы Радик Фәизов, шулай ук әдипнең хатыны Лилия Мәһдиева, кызы Гәүһәр Хәсәнова, сеңлесе Җәүһәр Галимова катнашты.

Әдәби очрашуларда катнашкан кунакларны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Надия Мифтахетдинова, «Казан арты» әдәби музейлар берләшмәсе директоры Ринат Фазлыйәхмәтов озатып йөрде. Каләм әһелләре иң әүвәл Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктә каберен зиярәт кылды, аннары әдипнең шушы авылда төзелгән музее белән таныштылар. Шунысы сөенечле, бирегә кешеләр еш килеп тора, музей даими рәвештә яңа экспонатлар белән баетыла, монда мәктәп укучылары өчен язучы иҗатына багышланган махсус дәресләр оештырыла.

Булачак әдип Мөхәммәт Мәһдиев җидееллык белемне якында гына урнашкан Сикертән авылы мәктәбендә алган. Бирегә үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә мәктәп укучылары башкаруында аның әсәрләреннән өзекләр яңгырады, шулай ук җыр һәм биюләр тәкъдим ителде һәм, әлбәттә, Казаннан килгән каләм әһелләре Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләр һәм аңа багышланган шигырьләрен сөйләделәр.

Халык язучысының якташлары—Арча педагогия көллияте директоры Наил Габдрахманов, ветеран укытучы Нәкия Абдуллина һәм башкалар классик әдип турында горурланып сөйләделәр.

Мәшһүр әдип һәм галим М. Мәһдиевнең 80 еллыгына багышланган чаралар республика районнарында дәвам итә. Май уртасында аңа багышланган тантаналы кичә Казанда—Кәрим Тинчурин театры бинасында үтәчәк.

## ЯЗУЧЫЛАР ТЕЛӘЧЕДӘ

12 мартта Теләче районында татар әдипләре белән очрашулар үткәрелде. Әлеге сәнгати бәйрәм уңаеннан шушы төбәктә туып-үскән язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һади Такташ исемендәге премия лауреаты Рашат Низаминың 60 еллык юбилее да билгеләп үтелде.

Шагыйрьнең туган авылы Олы Мишә урта мәктәбендә һәм мәдәният йортында әдәби-музыкаль очрашу үткәрелде. Әлеге очрашу мәктәп балаларының җыр һәм биюләре белән үрелеп барды. Казан кунаклары, туй тамашасына тап булып, кияү белән кәләшкә татар язучыларының бер кочак китапларын бүләк иттеләр.

Теләченең туган як музее белән танышканнан соң язучылар делегациясен район муниципаль хакимияте башлыгы Илдар Низамов каршылады, мәдәният сараена зур әдәби-музыкаль кичәгә җыйналган әдәбият сөючеләр каршында чыгыш ясады. Әлеге чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, язучылар Тәлгат Галиуллин, Марсель Галиев, җырчы-композитор Тәслимә Низами, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Татарстан милли китапханә директоры Наил Камбиев, Сабадан—Тәлгать Нәҗмиев һ. б. катнашты.

Кунакларны район башкарма комитеты урынбасары А. Фәтхуллин, район мәдәният бүлеге җитәкчесе Д. Иксанов озатып йөрде.

### МАЛИКОВЛАР КИЧӘСЕ

10 апрельдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында Маликовлар гаиләсенең юбилей кичәсе булды. Ул Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты Рөстәм Маликовның—60, Татарстанның атказанган артисты, «Ел хатын-кызы» бәйгесе лауреаты Гүзәл Маликованың 50 яшьлек юбилейлары һәм аларның иҗат эшчәнлегенә 30 ел тулу уңаеннан оештырылды. Концертта Муса һәм Гайсә Маликовлар, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Мөнир Якупов, Рафаэль Сәхабиев, «Зөләйлә» төркеме, Г. Маликова җитәкчелегендәге «Дуслык» ансамбле һәм эстрадабызның башка йолдызлары катнашты.

### КҮПКЫРЛЫ СӘЛӘТ ИЯСЕ

Чаллының «Энергетик» мәдәният сараенда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Зөләйха Минһажеваның 55 яшьлеге уңаеннан иҗат кичәсе үтте. Юбилярны тәбрикләү тантанасында Татарстан Язучылар берлеге, Чаллы шәһәр хакимияте җитәкчеләре, мәдәният хезмәткәрләре, каләмдәшләре, аның иҗатын якын итүчеләр катнашты.

Зөләйха Минһажева—Чаллыда танылган шәхес. Яхшы сценарийлар авторы, сәләтле режиссер, милли бәйрәмнәрне оештыручы. Шәһәр мәдәният идарәсендә эшләү елларында ул Чаллыда гомер кичерүче төрле милләт кешеләре үз милли тамырларын, гореф-гадәтләрен онытмасын өчен фидакарь хезмәт куйды. Чаллы шәһәрендә «Нардуган», «Кыш озату», «Питрау» кебек милли-йола бәйрәмнәренең торгызылуы да, иң беренче чиратта, аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Гомумшәһәр Сабан туе бәйрәменең сценариен да, менә ничә ел инде, Зөләйха Минһажева яза.

Зөләйха—шагыйрә дә. Аның сүзләренә бик күп популяр җырлар иҗат ителгән. Иҗат кичәсендә Чаллының сәхнә йолдызлары әлеге җырларны тамашачыларга тәкъдим итте. Чаллы Татар дәүләт драма театры артистлары аның пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтте.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеше, күпьеллык нәтиҗәле иҗади хезмәте өчен «Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесенең драма артисты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Галиев Фәнәвил Әхми улына** «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

***

2010 елның 4 апрелендә, 84нче яшендә галим, тәнкыйтьче, публицист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналыбызның актив авторы **Мәхмүт Рәхимҗан улы Әхмәтҗанов** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «Хәйриячегә һәйкәл» скульптурасы (Әсгать Галимҗановка багышланган). **Асия Миңнуллина** эше.

*Дүртенче биттә:* Татарстанның халык язучысы **Хисам Камалов**.

# Яңа китаплар




История татар с древнейших времен (7 томда). III том. Казан. ТР Фәннәр академиясе. 2009.—1056 бит. Тиражы—4000 данә.

Соңгы дистә еллар эчендә Татарстанның Ш. Мәржани исемендәге тарих институты фундаменталь халкыбыз тарихына багышланган хезмәтләрне байтак чыгарды. Шулар арасында иң күренекле, иң әһәмиятлесе, мөгаен, 7 томга тәгаенләнгән «Татар тарихы»дыр. Алар рус телендә нәшер ителә. Күптән түгел генә бу томлыкларның 3нче томы дөнья күрде. Ул—тарихыбызның Алтын Урда чорын (XIII-XV гасыр) тасвирлый. Бу калын һәм саллы китапта бик күп галимнәрнең, шул исәптән чит илнекеләрнең дә, фәнни мәкаләләре урнаштырылган. Әмма томлыкның төп «хуҗасы»—шул чор белгече академик Миркасыйм Госманов. Ул бу китапка кереш сүз язучы да, аның фәнни редакторы да.

Китап галимнәр, студентлар, гомумән, тарих белән кызыксынучы һәркем өчен кызыклы һәм файдалы чыганак булачак.




**Һади Такташ.** Әсәрләр. Өч томда. Казан: Татар кит. нәшр., 2010. I том—407 б., II том—383 б., III том—367 б. Тиражлары—2500 данә.

Бу томлыклар шагыйрьнең элек чыккан китапларыннан үзенең тулылыгы һәм фәнни эшләнеше белән аерылып тора. I томга—шигырьләр һәм поэмалар, II томга—проза әсәрләре, әдәбиятсәнгать тәнкыйте мәкаләләре, публицистика; III томга—сәхнә әсәрләре, көндәлекләр, хатлар һәм документлар тупланган. Томлыкларны төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче галимнәр—Марсель Әхмәтҗанов, Лена Гайнанова, Нажия Садыйкова. I томга шагыйрь Рәдиф Гаташның Такташ турында кереш мәкаләсе урнаштырылган.



Хисам Камалов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)